# КАЗАН УТЛАРЫ

5
МАЙ
1979

# ТАССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫНА БАГЫШЛАП


## «Замандаш» конкурсы йомгаклары



Р. МИНГАЛИМОВ



Н. ГЫЙМАТДИНОВА



К. КӘРИМОВ

«Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналы 1978 елның беренче санында бүгенгә хезмәт кешесенә багышланган хикәяләргә «Замандаш» конкурсы ачып җибәргән иде. Конкурс үрнәк моральгә ия булган совет кешесенең коммунизм төзүдәге мактаулы эшләрен, аның күркәм сыйфатларын тагын да тулырак чагылдыруны, хикәя жанрын тагын да активлаштыруны, язучылар игътибарын бүгенге көн проблемаларына ныграк җәлеп итүне максат итеп куйган иде.

Язучыларыбыз бу конкурста актив катнаштылар. Конкурс тәкъдим иткән тема яшь язучыларны аеруча нык кызыксындырды. Әдәби тәнкыйтебез 1978 елда журнал битләрендә хикәя жанрының җанлануын билгеләп үтте.

Редакция конкурста катнашкан бөтен иптәшләргә дә рәхмәт белдерә.

Журнал редколлегиясе һәм жюри «Замандаш» конкурсын Татарстан язучыларының IX съездына багышлап йомгакларга булды. Атилла Расих, Мирсәй Әмир, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баянов, Гәрәй Рәхим составындагы жюри (председателе А. Расих) үзенең утырышында түбәндәге карарны кабул итте:

**Беренче премиягә лаек хикәяләр булмады дип исәпләргә;**

**Икенче премияне (100 сум) «Мәскәү — Нью-Йорк — Токио» дигән хикәя өчен Рөстәм Мингалимовка бирергә;**

**Өченче премияләрне (75 әр сум) «Су хикәяте» исемле әсәре өчен Нәбирә Гыйматдиновага һәм «Тәнәфес» дигән хикәясе өчен Камил Кәримовка бирергә.**

Редколлегия һәм жюри лауреатларны чын күңелдән котлыйлар, иҗатларында яңа уңышлар телиләр.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**5**

МАЙ
1979

## Бу санда

Н. АРСЛАНОВ. Яшә, илем! Шигырьләр . . . . 3
В. НУРУЛЛИН. Аккан су юлын табар. Повесть . 10
З. НУРИ. Яз дәфтәреннән. Шигырьләр . . . . 60
Ш. МАННАПОВ. Чехолдагы ракеталар. Хикәя . . 65
Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Кыска шигырьләр . . . . . 78
Р. МИҢНУЛЛИН. Мәңгелек сәфәр. Шигырьләр . . 82
Х. ТӨХФИ. Робагыйлар . . . . . . . . . . 87

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Ф. САДРИЕВ. Гадәти иртә. Хикәя . . . . . . 90

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. ШАҺИМӘРДӘНОВ. Югалган кыз. Хикәя . . 107

ОЧЕРКЛАР

Д. СИРАЙ. «Элемтәгә чыгам» . . . . . . . . 113
С. ШАКИР. Чемпион кыз Галимә . . . . . . . 129

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Бүгенге поэзия турында сөйләшүгә йомгак . . . 136

ӘДӘБИ ОСТАЛЫК ТУРЫНДА

Ф. ХӨСНИ. Орлыклар кая төшә... Этюдлар . . . 150

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ә. БУЛАТОВ. Мәгърифәтче язучы Гариф Чыкалый 161

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Т. НАСЫЙРОВ. Ямашевның туганы, Тукайның дусты . . . . . . . . . . . . . . 164

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ВӘЛИЕВ. Тынгысызлык уты . . . . . . . 168

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Лессинг . . . . . . . . . . . . . . . . 171

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ТӨРЛЕСЕННӘН

А. ГАЛИЕВ, В. МАКСИМЕНКО. Шагыйрьнең абыйсы . . . . . . . . . . . . . . 174
И. ЗӘБИРОВ. Җәлилнең сабакташы . . . . . . 179
Х. ҖӘЛӘЛОВ. Ерак араларны якын итеп . . . 181

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

С. КАЛЬМЕТОВ. Дустымның фәрештәсе . . . . 186
Р. ШАҺГАЛИЕВ. Дуртьюллыклар . . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Шәукәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Ф. Кадыйрова*

Производствога бирелде 7/II-1979 ел. Басарга кул куелды 20/IV-1979 ел. ПФ 09014. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83744 экз. Заказ Ц-57. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

## Нури Арсланов

### Яшә, илем!

Картаямсың минем белән бергә,
Республикам... Сиңа да алтмыш?!
Чал улыңны —мине — туган җирдә
Моңлы итеп язмыш яратмыш.

Ә моңлылар белән яшәп була, —
Тугры була шагыйрь хисенә.
Ил язмышын үз язмышы кыла —
Бергә әрни, бергә кичерә.

Менә тагын түргә узды шатлык, —
Ни әйтсәң дә бәйрәм көннәре:
Без ирекне газапларда таптык,
Ничек кенә тәкъдир көлмәде!..

Нинди генә юллар үтмәдек без,
Нинди көннәр баштан кичмәде,
Күпме каннар, яшьләр түкмәдек без...
Онытыласы түгел истәге.

Бер сыныкны бүлгән чаклар булды, —
Юмарт илем, кызганмадың син,
Һәлакәтләр күргән чаклар булды, —
Кыйналсаң да сызланмадың син!

Яшә, илем! Ил картаймый, диләр,
Болай гына әйттем мин башта.
Туганнарың булсын азат илләр,
Күтәрел син күкрәп кояшка!

### Дөнья яшьләренә

Сөйләп китсәң әгәр — хәтсез яман!
Янар таудай кабынып идегез;
Үзегез дә мәңге инанмаган
Аллаларга табынып идегез.

Чәчләрегез үрә торып иде
Дәһшәтеннән авыр кыйссаның,
Күз алдында канга тулып иде
Дәүләтләре барлык кыйтганың.

Бомба болытлары каршысында
Калтыранып, каушап сәҗдәгә
Авар идегез, йотар иде шунда
Сезне сугыш дигән аждаһа...

Юк, боларны күздән кичерер өчен
Үзең сугышып карау кирәкми!
Башкага бор, кеше, акылың, көчең,
Уйнатма син тинтәк йөрәкне!

Җәһәннәмнәр бугазыннан чыккан,
Исән калган гаҗәп кешеләр,
Газапларны һәм үлемне еккан,
Ветераннар дигән көчлеләр —

Оран салабыз без: — Кирәк түгел
Сезгә безнең язмыш — ерткычлык,
Аяз итсен планетаның күген
Изге ният, хезмәт, тынычлык!

## Янудан

Төгәнмәстәй иде дәртләр күңелдә,
Җаным ялкын иде, төтенгә калдым.

Хыялымда аяз көннәрне уйлап,
Гүзәл таңнар көтеп тик төнгә калдым.

Йөгәнсез чапты да китте кичәгем,
Хәзер җәяү — бүгенге көнгә калдым.

Ширин төсле көлеп торган сылулар
Янында кем идем мин, кемгә калдым?!

Теләнмәдем илемнән сый да хөрмәт,
Утыр дисә түренә — түрдә калдым.

Көчем барда өйдем — таулар күтәрдем,
Хәзер үркәч кадәр бер үргә калдым.

Батыр Салсал дип уйладым үземне;
Чалып екты фәна — күлкегә калдым.

Үрел өскә диделәр кайберәүләр,
Үрелмәдем, гади төркемдә калдым.

Хәят ул мең дә бер җәфа кичәр юл, —
Авырлыклар белән гел бергә калдым.

Шулай да бер юаныч бар ки, илгә
Бәхет даулап янудан көлгә калдым.

## Аның күз яше

«Коеп куйган гына поэт»[1] лар бар,
Ни әйтәсең алар турында!
Һәркайсысы дәрәҗәле алар,
Һәрберсе һәртөрле «урын»да.

Кайсы үзен Дәрдемәндкә тиңли,
Кайсы Тукай булып кылана:
Берсенең дә ким буласы килми, —
Сәер язмыш диган шобага!

Халыкның тик шобагасы авыр,
Тартып кына чыкмый бүректән...
Өрекмәгән диләр яудан Бабур,
Шигърияттән ул да «өреккән»:

Үзен бөек шагыйрь санамаган.
Мин дә аның тик бер киздәше[2]:
Җырлыйм — халкым моңнарыннан алам,
Җылыйм, яшем — аның күз яше.

## Көзге төндә

Төн. Мин җылы өйдә бер ялгызым,
Кара җилән япкан көз тышта:
Узган гомер кебек төннәр озын,
Калган гомер кебек көн кыска.

Гомер кыска — яшәп туймаганга,
Бит яшәүдән туйганнар да бар:
Бу тук дөнья зар иткәнгә нанга,
Бу киң дөнья булган өчен тар...

«Тар дөнья»ны була киңәйтергә —
Күпме илләр инде ректә!
Тик озаймый гомер генә бер дә
Бөтен дөнья малы биреп тә...

Төн. Уйлар да уйлар... Салкын тышта,
Шыбыр-шыбыр яңгыр, караңгы.
Көзнең дә бит аның гомере кыска,
Калган гомер кебек санаулы.

## Язы да бар, көзе дә бар

Көз авыр саз итекләре
Алып кигән.
Болытларның итәкләре
Җиргә тигән.

---

[1] «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел...» Г. Тукай язган бер хаттан.
[2] Киздәш — очраучы, юлыгучы. Бу урында фикер киздәшлеге турында әйтелә.

Сибелә чәчәк керфекләре —
Сула гөлләр.
Кем җылый, яшь бөртекләрен
Түгә кемнәр?

Яңгыр пыскып ява, томан —
Төтен сыман.
Күңел сыкрый, тәмам туйган
Бу моңсудан.

Аңа булсын гел ал да гөл —
Язлар гына,
Бүтән берни кирәк түгел, —
Назлар гына!

Гомернең шул язы да бар,
Көзе дә бар,
Аннан килә кыш-салкыннар,
Түшәлә кар...

Ә бүген үз эшен кыла
Көз хәстәре.
Ачы була, татлы була
Күз яшьләре...

## Күгәрченнәр

Күк күгәрченнәр үбешә,
Күм-күк шул һавасы да...
Узган көннәр искә төшә:
Охшаган чаклар бар иде
Күгәрчен баласына...

Кагынышалар канатларын,
Башларны иеп кенә,
Алар шулай яратканын
Белдерәләр бер-берсенә
Томшыклар биреп кенә.

Я, раббым, ни кадәрле наз!
Кем дәртләрне тыяла?
И татлы бәхет! Тик бик аз...
Күгәрчен кебек гөрләшеп
Торсаң иде дөньяда.

## Күзләренә карап

Инәләре була гөлчәчәкнең,
Аңа карап өзми калмыйлар.
Кабул итми тыюын һич фәлакнең
Миңа охшаш уйнак җанлылар:

Күзләренә карап гүзәлнең
Дидем: «Бәгырем, барыбер өзәрмен!»

## Сез сорыйсыз

Сез сорыйсыз миннән: — Гомерегездә
Авырлыклар күргән мидегез?
— Күрмәү кая! Барысы кичте бездән,
Ни кичерсә туган илебез.

Ачлы-туклы йөргән чаклар булды...
Борын төшермәдек алай да,
Диңгез тездән иде «чарльстон»лы,
Озын чәчле, көләч малайга.

— Ә сугышта, ничек, булдыгызмы?
— Егет идем әле мин анда,
Безнең өчен бер генә юл узды,
Көрәш юлы — чыктык мәйданга!

Иманыбыз камил иде дауда,
Фатихасын бирде халкыбыз.
Гөрселдәде туплар булып яуда
Җиңелмәскә биргән антыбыз.

— Сез бәхетле, бөек язмышыгыз
Туры килгән батыр заманга! —
Дип йөдәтә яшьләр — егет тә кыз...
Аптырыйсың җавап табарга.

Яшь чагында алчак инде күңел,
Романтика һәрдәм аякта.
Бәхет — үлем белән уйнау түгел,
Зур бәхетләр фәкать хәятта!

## Исән калдыр

Итәгемне тетте — санап кара:
Нәкъ унсигез пуля.
Берәү шулай ансат исән кала,
Берәү шуннан үлә...

Кинәт җилен чәчләремә тидереп
Уклар үтте исеп,
Пилоткамны аркылыга кидереп,
Ике җирдән тишеп.

Кыл өстендә калдым шунда уктан.
Үз-үземне тиргим:
Нигә сакламадым шул пилоткам,
Шинелемне мин? — дим.

Ул чагында шатланырга моңа
Вакыт булмагандыр...
Мин хәзер шат, язмыш, моннан соң да
Шулай исән калдыр.

## Беренче кар

Кар керләрне, тузаннарны япкан,
Җирне алган сарып.
Бөтен дөнья купшыланган актан.
Карыйм мин таң калып!

Җан куана, ләкин нинди шатлык? —
Уйламый шул артын:
Ни кадәрле ак булмасын хаклык —
Акыл төсле салкын...

Эретерлек аны җирдә бер көч,
Берәр им бар микән,
Хакыйкатьтә шулай һаман да кыш,
Һаман да кар микән?!

## Бер манзара

Шау чәчәктә гүя язлар килгән,
Гүя дөнья — алма бакчасы:
Ак карларын ботакларга элгән,
Вакыт бераз уйлап баксачы!

Урамнарда юкса әле аңкый
Һаваларның көзге сулышы.
Бөек рәссам — табигатьнең андый
Эшләре бар! — кызык шунысы.

Күренеп тора ләкин карашыннан:
Сагышлы ул, моңсу, ялгызы...
Көтә, ак чәчәкләр арасыннан
Килеп чыгар төсле кар кызы.

## Бичара маэмай

Иртә-кич гел үз эшендә —
Һау да һау маэмай өрә.
Ул өреп шулай кешегә
Хезмәт итәм дип белә.

Йорт тулы төрле хуҗалар.
Күбесе яратмыйлар,
Маэмай мескенне куалар:
— Кит, әрәмтамак! — диләр.

Ырылдыйлар нәни эткә,
Өрәләр төрле яклап...
— Маэмай, кит, яхшылык көтмә,
Йөрмә шуларны саклап.

Курада ят кеше күрсә
Эт өрә — хәйләсе юк.
Ә кеше эт булып өрсә
Бер кемгә файдасы юк.

## Ят була

Кәкүкләр дә борчылмыйлар хәттә
Ят ояга күкәй салып та, —
Чөнки нәселе туа киләчәктә
Охшап кәкүк дигән «халык»ка.

Ә кешеләр —кеше була торып
Киресенә моның тап була:
Үз ояларында туа торып
Балалары бик еш ят була...

## Чыгар әле

Чәберчекләр инде китеп беткән,
Бакчабызда бер ямь калмаган.
Кем ул алтын тәңкәләрен сипкән
Карлыганнан, чия, алмадан?!

Көз кошының каурыйлары сары,
Әкрен искән җилдә җилпенә,
Тынган инде чикерткәләр шавы.
Сагышлар да монда мин генә...

Бер моң килә төсле бик ерактан,
Каерылган киек-каз микән?
Ничек икән таныш түгел якта,
Җәйләр микән хәзер, яз микән?..

Канат кагам, нигә моңга талып
Каерылган каздай калырга: —
Ал яулыгын иңнәренә салып
Чыгар әле каршы алырга!

## Яңа көй

Моңлы күңелем җырдан башка нишләр?! —
Урамнарда җырлыйм мин, өйдә...
Шигырьләргә сыялмагач, хисләр
Әвреләләр кайчак бер көйгә.

Шулай чыккандыр ул: «Кәләү Гайшә»,
«Урман кызы», «Сагыну», «Уел» лар...
Мин җыр көйлим — сабый чакка дәшә
Иртеш тугайлары, муеллар...

Ак чәчәктә алар күз алдымда.
Өзелеп сайрый очар-кош — йөрәк:
Сыза сагышым нечкә кылларында,
Яңа бер моң сыкрый мөлдерәп.

≈≈≈≈≈≈

**Вакыйф Нуруллин**

# АККАН СУ ЮЛЫН ТАБАР

ПОВЕСТЬ



Шулай итеп, станция начальнигы миңа шалтырата да, мин тиз генә ташыттырып куям ашламаны үзебезнең складка. Чөнки мин ташымасам, ул ашлама шунда, станциядә, бушатылып, барыбер әрәм-шәрәм булып бетәчәк. Ә ашлама хуҗасы станция начальнигына да, миңа да үпкәли дә, ачулана да алмый. Аннары килеп, мин аны штраф түләүдән дә коткарган бит әле. Ә ашлама өчен тиешле акчасын мин тиешле урынына тиенен-тиенгә шул ук көнне күчертеп куям. Нишлисең, тормыш дигән нәрсә әнә шулай инде ул. Бер үк мәсьәләне төрлечә хәл итәргә, бер нәрсәгә төрле яктан килеп карарга туры килә...

Ә алып кайткан ашламалар үз эшен эшли бирә безнең кырда. Аның файдасын хәзер «алла бирмәсә бер нәрсә дә булмый: хет син шунда ярылып кит, алла кушмаса, агачтагы яфрак та селкенми», дип йөргән, гел намазлык өстендә генә утыра торган авыл картларына кадәр таный инде...

Ләкин аларны шушы хәлгә китереп җиткерер өчен күпме көч куелганын мин үзем генә беләм дә, әлеге дә баягы, картлар әйтмешли, бер алла гына белә. Казаннан бер-ике көнгә килеп, инде әзер булган нәрсәләрне өстән-өстән генә карап китә торган журналистларга гына барысы да бик ансат эшләнгән шикелле тоела ул. Хәтта аларның кайберләре, синең инде житешмәгән нәрсәң юк бугай, иптәш Вәлиев, хәзер синә иркенләбрәк, тынычлабрак, үз-үзеңне саклабрак эшләргә дә була торгандыр, дип тә ычкындыралар. Читтән карап торганда, ихтимал, шулай тоеладыр да. Ләкин тормыш шундый нәрсә инде ул, алга яңадан-яңа мәшәкатьләрне өеп кенә тора. Аның шулай булуы гаҗәп тә түгел. Ни өчен дигәндә, без-кешеләр үзебез дә һаман үзгәрә барабыз. Бүген бик зур яңалык булып, камиллекнең соңгы ноктасы кебек күренгән нәрсәләр иртәгә, иртәгә булмаса бер айдан, бер елдан безнең өчен гел дә гадәти хәлгә әйләнеп кала. Алар урынына тагын да яңараклары, тагын да камилрәкләре барлыкка килә тора.

---

Ахыры. Башы журналыбызның дүртенче санында.

Әгәр син, председатель кеше, бер ирешкән ноктанда тукталып, шуның белән канәгатьләнеп каласың икән, ул чакта синең кирәген бер тиен. Ул чакта син житәкче булараk алга барудан туктыйсың гына түгел, ул чакта син бөтенләй тормозга әйләнәсең. Юк, безнең эштә, әгәр син тормыштан артта калмыйм дисең икән, бер көн дип әйтмим, хәтта бер сәгать тә туктап, тынычланып калырга ярамый. Тынычланырга тормыш үзе үк юл куймый!

Менә бүген январьның унтугызы. Кара кыш уртасы. Авыл халкының тынычрак, иркенрәк чагы. Борчылырга бернинди сәбәп тә юк шикелле. Колхозчыларның ягарына утыны бар. Малларына печәне-саламы житәрлек. Икмәген кем күпме алырга тели — чикләмәдек. Колхоз маллары өчен шулай ук кайгырасы түгел: сенажы да, печәне дә, фуражы да июнь башына тикле кар ятар булса да житәрлек әзерләнгән. Чәчүлек дип тә баш ватасы юк: Фәгыйт аларны йөз егерме процент итеп (егерме проценты ул-бу була калса дип) әзерләттереп куйдырды. Тракторларның да яртысыннан артыгы ремонттан чыкты инде. Бүтән эшләр дә зарланырлык түгел. Әмма мин күңелем тыныч дип әйтә алмыйм. Киресенчә, аеруча нык борчылып йөрим әле бу араларда.

Әйткән идем микән, үзебездә больница бар безнең. Быел июньдә ачылуына ун ел тула. Аның бездә ачылуына мин үзем «гаепле». Үзем теләп алган мәшәкать булды ул миңа.

Алтмыш тугызынчы ел башында, председательләрнең чираттагы район киңәшмәсеннән соң, райком секретаре безне — бер тирәдәге дүрт колхоз председателе белән район больницасының баш врачы Фарук Фәттаховны — үз кабинетына алып керде дә:

— Сезнең төбәктә участок больницасы ачарга дигән фикер бар. Башта үз ихтыярыгызга куймакчы булдым: кайсыгыз ул больницаның үз колхозында ачылуын тели, иптәшләр? — диде.

Дүртебез дә бертавыштан: «Мин телим!» дип җавап бирдек. Шуннан хәйләкәр генә итеп үз алдына елмаеп куйды да әйтә бу безгә:

— Ләкин, иптәшләр, — ди, — бу мәсьәләнең бер четереклерәк ягы бар: больница бинасын колхоз исәбенә төзергә кирәк булачак, — ди.— Бүтән якларын дәүләт тәэмин итә. Әмма бинасын үзегезгә житкерергә туры килә, — ди.

Ул шулай дигәч, гайрәте шиңде председательләрнең. Мин дә аптырап калдым. «Ярый, — дим күңелдән генә үз-үземә, — син ул больницаны салдырдың да, ди. Ул бит бер безнең авыл өчен генә булмый. Якын-тирәдәге алты-жиде авылга хезмәт күрсәтәчәк бит ул. Шулай булгач, нигә син генә төзеп азапланырга тиеш, ди әле аны?»

Шул фикеремне секретарьга да әйттем. Бүтәннәр дә төрле сәбәп табып баш тартты. Шуннан соң Гали Даутович артык кыстап тормады.

— Мин аның шулай буласын алдан ук сизгән идем. Азактан сүзе булмасын, ник миңа әйтмәдегез, мин аны үзебездә салдырган булыр идем, дип соңыннан үзегез миңа үпкәләп йөрмәсен өчен генә әйттем мин моны сезгә. Барыгыз, кайтыгыз да, бу турыда бөтенләй онытып, иркенләп йоклагыз! — дип, бүтәннәрне чыгарып җибәрде. Фарук Фәттахич белән мине алып калды да миңа әйтте: — Ә син, иптәш Вәлиев, давай, чыгымлама, алын бу эшкә! — диде. — Стоящий эш бу. Менә күрерсең, соңыннан сөенеп бетә алмассың әле шуңа. Үзең уйлап кара: сезнең колхоздан хәзер уртача алганда ике көнгә бер кешенең район больницасына йомышы төшеп тора. Син аларга больницага барырга я ат, яки машина, пычрак вакыт булганда, хәтта трактор да бирергә мәжбүрме — мәжбүр! Менә шуннан үзең исәплә кара: ел тәүлегендә синең ничә кешең һәм ничә машинаңның күпме эш вакыты юлда әрәм була? Икенчедән, больница үзеңдә булуның профилактик ягы да бар. Район больницасына, ун-унбиш километр арага, кеше

сыкрап-сыктап торганда гына чыгып китми. Ул анда авыру үзен тәмам баскач, тәмам хәлдән тайгач кына бара. Ә авылында больница булса, авырый башлау белән барыр иде дә, авыруы көчәйгәнче врач аңа тиешле ярдәмен күрсәтеп өлгерер иде. Синең колхозчың ун-унбиш көн больницада ятасы урында, колхозында файдалы эш эшләр иде, — ди. Кыскасы, сандугач урынына сайрый бу. Сүз әйтә торган түгел, белеп сайрый. Ә Фарук Фәттахич дәшми. Анысы белән безнең әлеге

**УНДҮРТЕНЧЕ ДӘФТӘР**

дә баягы шул колхозчылар аркасында бераз чәкәләшкән бар иде. Шуна шыпырт кына утыра анысы. Сүз әйтсә — мин чәчрәп кубар дип шикләнә. Үзе дәшүен дәшми, әмма баш кагып, секретарь сүзенә мөһер сугып бара үзе... Көндерде мине секретарь. Күнми ни эшлисең? Рас кеше акыллы киңәш биргән икән — нигә аңа каршы килергә?

Башта без ул больницаны сигез урынлы итеп салган идек. Штаты да бәләкәй: бер врач-невропотолог белән бер фельдшер-акушер гына иде. Аңа да сөенеп бетә алмый иде авыл халкы: авырган саен район больницасына барып йөрисе юк. Йөкле хатын-кызларга бигрәк тә җайлы: консультациясе дә үзебездә, балаларын да үзебездә генә табалар иде. Ләкин тора-бара ул больница да канәгатьләндерми башлады. Бердән, урын җитми. Чөнки күрше авыллардан да безгә киләләр. Икенчедән, больницасы зур булмаса да, бер генә врач — аз. Авырулар янында кайчакларда тәүлекләр буена торырга туры килә аңа. Аннары бер невропотолог белән генә эш бетми. Хирургын да үзебездә булдырасы, артык катлаулы булмаган операцияләрне үз больницабызда гына ясый торган итәсе килә иде.

Ниһаять, анысын да таптык. Безнең авылдан китеп хирургия факультетын тәмамлаган бер егет, Казан кызына өйләнеп, шунда эшкә калган да, кеше өстендә фатир торып, интегеп яталар иде. Хатыны рус теле укытучысы булса да, Казанда үз һөнәре буенча эшләргә урын таба алмыйча, бәләкәй генә бер китапханәдә эшли. Үзе — больницада. Читтә олтан булып йөргәнче, үзебезнең туган җирдә солтан булып яшәрсез, ичмаса, ятмагыз болай чиләнеп дип, тоттым да колхозга алып кайттым шуларны. Үзебезнең мәктәпнең рус теле укытучысы пенсиягә киткән иде, хатыны шуның урынына урнашты. Икесе дә сөенеп бетә алмыйлар хәзер авылга кайтканга. Шулай булмый хәле юк: хирургны бөтен тирә-як халкы хөрмәт итә. Яшь-яшь кенә булса да, Ринат Хафизыч та, Ринат Хафизыч дип кенә торалар үзенә. Ул операция ясаган кешеләр, кулы шифалы дип, мактап туя алмый. Хатыны да балаларны үз итә торган ягымлы нәрсә булып чыкты. Колхоз белгечләре өчен дип салынган өч бүлмәле финский йортка урнаштырган идек үзләрен. Рәхәтләнеп яшиләр, күңел биреп эшлиләр. Ә Казанга барырга кирәк булганда тимер юл станциясе, инде әйткәнемчә, орынып тора. Поездга утырасың да сәгать ярым — ике сәгатьтә — Казан.

Шулай да больница мәсьәләсендә эшләрне көйләп бетерә алган юк әле. Санитар машинасы кирәк. Инде менә елдан артык шуны юллау артыннан йөргән көн. Йөрмичә ярамый. Өченче ел тагын бер яңа бина салдырып, больницадагы урыннарны утызга җиткергәч, безнең участокка авырулар хәзер сигез авылдан килә башлады. Сигез авылга хезмәт күрсәтә торган больницада бер машина да булмау—бу инде безнең заманда һич ярый торган эш түгел. Моның шулай икәнлеген район начальствосы да, югарырактагылар да бик яхшы белә. Әмма машинага тиенә алган юк әле. Инде тәмам җилекләренә тигәч, ниһаять, вәгъдә иткәннәр иде. Казанга барып алырга дип телеграмма да килгән, акчасын да түләгән идек. Колхоз исәбеннән түләдек, әлбәттә. Кешеләрнең

сәламәтлегенә кагылышлы эштә акча белән артык вакланып торуны кирәк дип санамыйм мин. Шофер штаты бирмәячәкләр. Анысын да колхоз исәбеннән елларга исәпләп куйган идек. Ләкин шул машинага утырырга тиешле шоферыбыз Казаннан, коры барып, буш кайтты. Ни өчен дигәндә, район больницасының баш врачы Фарук Фәттахыч, шыпырт кына үз больницасыннан акча күчерткән дә, шоферын җибәреп, теге яңа машинаны алып кайттырып та куйган! Телефоннан шалтыратып, син ни кыландың анда, егетем, синең болай да бер «Волга»ң, бер «УАЗ»ың бар бит инде, дигән идем, уйламый да. «Курыкма, син дә машинасыз калмассың, мин сиңа үземнең «УАЗ»ны бирермен» — дип авыз ера бу. «Как это так? Син ничек алай безгә дигән машина белән шулай үзең теләгәнчә эш итмәкче булдың әле?» — дигәч, министрлыкта барысын да беләләр, барысы да сөйләшенгән, хәл ителгән, дип аяк терәп тартышмакчы бу.

Шуннан тиз генә машинага утырдым да — әйдә райкомга, Гали Даутович янына. Күрәсең, Фарук — шайтан аңа да кармак салып куйган булгандыр, Гали Даутович үзе дә: «Ярар инде, Вәлиев, алай тавыш кубарып йөрмә. Машинасыз калмыйсың ич, машина урынына машина бирә ул сиңа,— дип, тегенең ягын каерырга итеп маташа. Эшләр алайга киткәч, минем дә кан кызды хәзер. Кызмый хәле юк. Машина артыннан йөргәндә икесе дә бик үк ышанып җитмичә: «Айһай, булдыра алырсың микән? Авыл больницаларына түгел, район больницаларына да бик көттереп кенә бирәләр машина дигән нәрсәне»,— дип тордылар. Ә хәзер, минем мең бәла белән юллап тапкан машинаны үзләренә алып калып, миңа искене төртергә маташалар.

— Юк инде, Гали Даутович,— мин әйтәм. — Алай булмый ул. Алай булырга тиеш түгел! — дим. — Тартышка җибәрмик эшне,— мин әйтәм.— Алайга китсә, обкомга барып җитсәм җитәм, әмма машинаны Фарук Фәттахычка бирдем юк! Аңа бирер өчен дип елдан артык чабып йөредеммени мин ул машина өчен,— дим.

Күрәсең, сүземнән кире кайтмаячагым йөземә үк чыккан булгандыр, Гали Даутович синме бу, Вәлиев, әллә сине җен алыштырып куйдымы, дигән сыман итеп, беркавым карап торды да:

— Ярар, ярар, алайса, үзем сөйләшермен Фарук Фәттахыч белән. Бар, кайт та, тынычлап бүтән эшләреңне эшли тор,— дип кайтарып җибәрде.

Сөйләшкәндерме, юкмы — әлегә билгеле түгел. Шалтыратып-шалтыратып карадым, шушында ялга киткәнче һич туры китерә алмадым үзен. Шулай булгач, ничек итеп тыныч кына яшәмәк кирәк тә, ничек нервланмыйсың инде? Ә бит шуның өше эшләр бездә көн саен, сәгать саен чыгып тора... Әйтәм бит, ял алып санаторийгамы, курорткамы яки ял йортынамы чыгып китмәсә, председательгә бер сәгать тә тынгылык юк аңа.

Менә шуңа күрә дә әлеге җитмеш алтынчы елны көньяк санаторийларының берсендә, дөнья мәшәкатьләреннән котылып, ашыкмыйча гына, тәртипле генә ял итә һәм дәвалана башлаган идем мин. Бүлмәдә ике кеше идек. Шул минем бүлмәдәш аркасында көе китте ялның. Казанныкы иде ул. Әй, шома да кеше иде инде! Яшькә миннән күп олы — алтмышын тутырып килә. Әйбәт кенә корсак та бар моның. Матур гына булып, чәчләре агарып бетеп килә. Кыяфәт бик шәп моның: каратут түгәрәк йөз, таманча гына килешле борын, өстә энәдән-җептән генә чыккан костюм, ул елларда бик кадерле булган нейлон күлмәк. Муенда кызгылт фонга көмеш сыман ялтыравыклы сызыклар төшерелгән ун сумлык галстук. Бармакта зур асылташ кашлы алтын йөзек. Кулда алтын сәгать. Эш урыны алай шаккатмалы түгел түгелен: бер җиләк-җимеш кибетендә директор икән. Әмма үзен тотышы — гел министр инде. Телгә дә бик оста. Аеруча

анекдотка. Чит илләрдә булгандырмы, юкмы, ләкин сүз арасында «мин фәлән илдә булганда», «мин фәлән илнең фәлән шәһәрендә булганда» дип кенә җибәрә. Минем өчен тагы бер хикмәтле ягы шунда моның: Казаннан үзе белән бер яшь кенә нәрсә ияртеп алып килгән бу. Путевка белән түгел, болай гына. Аны шул санаторий тирәсендәге бер йортка фатирга урнаштырган. Инде әйткәнемчә, бу үзе алтмышын тутырып киләм ди, кем белә, бәлки инде тутыргандыр да. Ә алып килгән нәрсәсе күп куйганда утыз яшьләрдән ары түгел.

— Хатының дисәм, артыгын яшь күренә. Кызың дияр идем, үзенә охшаган җире юк. Кемең соң бу синең? Ул да авырыймыни?— дип сораган идем, кычкырып көлде дә әйтә бу миңа:

— Хатыным да түгел, авырмый да,— ди.— Авыру булса миңа ни пычагыма кирәк ул? Симезлектән йөрәген май баскан авыру хатыннан мин өйдә дә гарык. Миңа монда аның менә шушындый яше, чибәре, күз сирпеп бер караганда үзәкләреңне өздереп ала торганы кирәк,— ди.— Бу дөньяда ике яшисе түгел бит. Шулай булгач, шул бер гомернең кадерен белеп, берәгәйле итеп яшәргә кирәк! — ди.

Бәхәсләшеп тормадым: ял итәргә килгән җирдә дә нерв бозасым килмәде. Аннары, күрәм, бәхәсләшүдән мәгънә дә булмаячак.

— Ярый, алай булгач, Фәсхетдин агай. Җаны теләгән — елан ите ашаган, үзеңнекен үзең белә торгансыңдыр,— дидем дә, шуның белән ике арада сүз беткән безнең. Ләкин...

Килүләренә атна да тулмады, бөтенләй башкача сайрый башлады минем директорым. Эш менә болайракка әйләнеп киткән икән моның. Сөяркәсен санаторийга алып килеп йөрүне бик үк өнәми, аның фатирына үзе барып йөри иде ул. Чөнки сөяркәсе шундый шәп, шундый чибәр — киноактрисалардан бер дә ким җире юк. Шуңа аны чит күзләрдән ераграк тоту хәерле дип саный иде Фәсхетдин агай. Чибәрлеге өстенә, хәерче шикәре шикелле бик шома, кыю да нәрсә тегесе. Ир-ат янында күзләре уйнаклап кына тора. Кыскасы, ялгызын гына калдырып йөрмәле түгел, карап-күзәтеп кенә торсаң да таманга гына килә торган нәрсә иде ул. Әнә шул ягы шөбһәләндерә иде Фәсхи агайны. Шөбһәләнергә сәбәбе дә юк түгел. Килүләренең өченче көнендә үк, каефем китебрәк тора, йокларга ятам, дигән булып, сәгать кичке сигездә үк Фәсхи агайны санаторийга кайтарып җибәрә бу. Шуңа бик күңеле төшеп, сөмсере коелып кайта Фәсхи агай. Урынга ятып карый — күзенә йокы керми. Китапка тотынып карый — аны укый алмый. Бүлмә эчендә ишекле-түрле йөрүдән дә җанына тынычлык тапмый. Аптырагач, азрак һава сулап керим әле, дигән булып чыгып китте бу. Бер сәгать үтә — кайтмый. Ике сәгать үтә — юк. Инде мин берәр күңелсез хәлгә юлыкты микән әллә дип хафалана да башладым. Дөнья бит, кайчакта юктан гына да әллә ниләр килеп чыга...

Ниһаять, төнге уникедә тулып килгәндә кайтып керде безнең директор. Йөзе кызарынган-бүртенгән. Күзләрен кан баскан. Үзе дөньядагын калдырмыйча сүгенә. Ни булды, ник болай карганасың дип сорыйм — дәшми. Шулай да бераз тынычлангач сөйләп бирде. Күңеле хәвеф сизеп тынгысызланган булган икән. Йөреп керергә дип чыккан җиреннән, туктале, карап кайтыйм әле, ни эшләп ята икән дип, Диләрәсе янына янадан барган бу. Ә анда, ни күрсен — моның авырып калган Диләрәсе бик җилле генә бер ир-ат белән, дөньясын онытып, үбешеп утыра икән!..

Ул төнне Фәсхи агабыз йоклау дип әйтмим, хәтта керфек тә какмады. «Менә ышан син хатын-кызга! Бар, ышанып йөр син ул паразитларга!» — дип такмаклап, төн буе ишекле-түрле йөренеп чыкты. Бер уйлаганда ул да кызганыч иде. Өсләренә килеп кергәч тә, үбешүләрен дәвам иттерәләр икән теге хәерсезләр. Бу тамак кыргач кына ир-

аты күтәрелеп караган да, һич кенә дә исе китмичә: «Нәрсә, атакай, авызыңны ачып торасың? Үбешкәнне күргәнең юкмы әллә?»— дип сораган. Фәсхетдин агай гел дә коелып төшеп, ни дип тә әйтә алмыйча торган арада, ниһаять, Диләрә дә, үбешү ләззәтеннән айнып, күзләрен ачкан. Караган да әйткән теге ир-атка: «Ә-ә-ә!.. Бу минем этием, Нодар»,— дигән. Аннары ана арыслан җитезлеге белән Фәсхи агай каршына килеп баскан да, теш арасыннан гына: «Ни кирәк булды сиңа, карт алаша? Син әле шулай минем арттан шымчылык итеп тә йөрисеңмени? Бар, хәзер үк, менә шушы минутта ук югал минем күз алдымнан! Бүтән килеп йөрмә минем янга!»— дип куып кайтарып җибәргән...

Менә шунысына бик нык хәтере калган иде директор агайның. Шуна үрсәләнде ул. «Кара син ул юха еланны! Минем акчага килеп, ни кыланып йөри бит, ә? Болай булырын белсәм, очраганда төкереп киткән булыр идем. Ни тукмы шту монда алып килергә. Кара син аны, сволочьны! Ну, ярый, иртәгә акылга утыртырмын әле мин аны!»— дип пыр тузынды.

Тузынуын тузынды, әмма берни дә майтара алмады. Икенче көнне дә, өченче көнне дә, дүртенче көнне дә Диләрәнең фатирына барып караган иде. Үзе әйтмәсә дә белеп торам, ачуланып түгел, киресенчә, мөнәсәбәтләрен җайга салырга тырышып, гафу үтенеп барган иде. Ләкин тегесе бик үзсүзле нәрсә булып чыккан. Фәсхи агай белән бүтән күрешергә түгел, сөйләшергә дә теләмәгән.

Әнә шул хурлыкка түзә алмады Фәсхи агай. Тагын өч-дүрт көн башын югалтып, тамаклардан калып йөрде дә, миңа бер тиенгә дә кирәк түгел бу санаторий, мин монда авырганнан түгел, дәрман бар чагында типтереп кайтырга дип кенә килгән идем, дип Казанга кайтып китте. «Ат белән хатын-кызга гомердә ышанма дип, борынгылар бик белеп әйткән икән. Моннан ары тагын берәр тапкыр шул ахмакларның сүзенә ышансам, исемем Фәсхи булмасын! Аң бул, энекәш, син дә шушылай минем шикелле юләр булып кала күрмә шул хатын-кыз белән бәйләнеп»,— дип, мина да акыл биреп китте.

Үзенә әйтмәсәм дә, эчемнән генә мин аннан көлеп, курыкма, агай, мин инде яшь-җилкенчәк түгел, бер тапкыр акылга утырган инде мин, андый юләрлекне эшләмәм, дип уйлап калган идем. Әмма ул кайтып киткән көнне кичен үзем дә уразаны чак кына ычкындырмыйча калдым.

Адәмгә сөйләсәң адәм ышанмас, минем дә башны-күзне әйләндереп ташлый язды бит теге шайтан кавеменнән яратылган Диләрә. Фәсхи агай кайтып киткән генә иде, чибәрлеге белән бөтен дөньяны балкытып, минем бүлмәгә килеп керде бу.

— Кәефләрең ничек, Булат абый? Бер үзегез генә яшәү бик моңсу түгелме?— ди.

— Зыян юк,— мин әйтәм.— Түзәргә була әлегә. Ләкин артык шатланырга да урын юк. Бер тиен акча чыгармыйча, үзегезне шушындый әйбәт җиргә алып килгән кешенең хәтерен калдырып кайтарып җибәрү бер дә килешә торган эш түгел инде, сеңелем,— дим.

— Яхшы,— ди бу, иплән кенә минем янга килеп утырып,— минем бу эшем, сез әйткәнчә, бик үк әйбәт нәрсә дә түгел, ди. Килешәм. Ә аның, хатыны, миннән олы балалары була торып, мине менә монда алып килүен ничек дип санийсыз сез? Яхшымы бу? Әллә кабахәтлекме?

Дөресен генә әйткәндә, шул яшь кенә хатын-кыз менә шулай ук мәгънәле фикер йөртерлек кешедер дип башыма да китермәгән идем. Дөнья, тормыш турында, кешеләр хакында алай тирәнтен уйланып тормыйча, өстән-өстән генә, һәр нәрсәгә җиңелчә карап кына эш итә торган, иртәгә ни буласы белән бөтенләй кызыксынмыйча, тик бүген-

ге көн белән генә яши торган җиңел холыклы бер нәрсә дип кенә уйлаган идем мин аны. Аннары, соравына җавап биргәнемне көтеп тә тормастан, тагын эләп алып китте:

— Әллә ул мине үзе эшләп алган хәләл акчасына монда алып килгән дип уйлыйсыңмы? Алып килер, көт син аннан. Йөз дә утыз биш сум окладка алай сөяркәләр ияртеп йөреп булмый аңа. Дәүләтне, хезмәт иясләрен алдап тапкан акчага шулай иркенләп, бугаз киереп йөри. Харам акчага йөри. Җиләк-җимеш кибете, бик беләсегез килсә, иң доходлы урын. Анда алар юлда бозылган диган сылтау белән, тонналап-тонналап списать итәләр җиләк-җимешне. Так вот, шулай булгач, мин үземне бу очракта тырнак очы хәтле дә гаепле санамыйм. Мин килмәгән булсам, барыбер бүтән бер хатын-кызны алып килер иде. Шиш менә аңар бу юлы! Үзен төп башына утыртып кайтарып җибәрдем мин аның. Һәм моның өчен мине орышырга түгел, моның өчен миңа һәйкәл куярга кирәк, бик беләсегез килсә. Закон әле аны кайчан җәзага тарта? Әллә тарта, әллә юк — анысы да билгесез. Әллә ни гомер дәүләтне һәм халыкны алдап яшәп тә, исән-имин пенсиягә чыгучылар юк дип беләсезме әллә? Ә мин, ичмаса, аны менә хәзер үк җәзага тарттым. Тапкан, югыйсә, юләр! Гыжылдап беткән көенә үзенең кызыннан яшьрәк булган чибәр хатын белән типтереп кайтмакчы!..— Диләрәнең бу сүзләрен тыңлаганда ачылган авызымны ябарга онытып тора идем, ул никтер үзалдына кычкырып көлеп куйды да ары таба дәвам итте:— Теге ул күргән кеше белән дә кызык итеп, уен ясап кына йөрдем мин. Әкәмәт тә халык инде бу ир-атлар. Хатын-кыз күрсәләр — күзләре тона, дөньяларын оныталар. Әгәр инде ул хатын-кызның кыяфәте дә чибәр булса, бетте: тәмугның үзенә барып керергә әзер булалар аның артыннан. Берни белән дә исәпләшеп тормыйлар. Менә шул минем арттан чапкан Нодарны гына ал: өч көн бөтенләй эшенә бармады. Ни дип җавап бирерсең, диган идем, исе дә китми: «Синең өчен мин өч көн генә түгел, өч ай эшкә бармасам да үкенмим, — ди. — Ә бу өч көн — ерунда! Больничный алдым инде мин ул көннәргә»,—ди. Миңа менә шушы колагымдагы алтын алканы бүләк итте. Ике тапкыр ресторанга алып барды. Бер көн көне буе таулар арасында йөрдек. Теләсәң, бер кичне Мәскәүгә алып барып, Зур театрда спектакль дә карап кайтырга була, диган иде дә, теләмәдем генә. Ә бит үзенең өендә хатыны, өч баласы бар, кабихнең! Хатынына алтын алка алып биргәне юктыр әле шуның! И-и-их!.. Яратмыйм да инде сөйрәлчек ирләрне! Әгәр рөхсәт итсәләр, эһ тә итмичә, барысын да тотып атар идем. Честное слово атар идем менә. Кулыма пулемет алыр идем дә — тра-та-та-та-та!..

Ул боларны шундый ихластан сөйләде ки, мин хәзер буш килеп, коры кайтып киткән Фәсхи агайны кызганмыйм гына түгел, киресенчә, аңа карата күңелемдә нәфрәт хисе туган иде. Алымы бөтенләй үк гадел булмаса да, бу хатын дөрес эшләгән шикелле иде хәзер миңа. Мин аның шундый кыюлыгына хәйран калып утыра идем. Шул арада кинәт кенә бер сүз әйтеп салып, ул мине гел гипнозлап үк куйды:

— Ә менә сез, күрәм, андый түгел, Булат абый. Нәкъ менә шуңа күрә дә мин сезне тегеләргә караганда йөз тапкыр күбрәк ошатам,— диде ул, тагын миңа табарак елышып.

Шунда миңа я бөтенләй дәшми генә каласы, яки «комплиментыгыз өчен рәхмәт» дип кенә котыласы бит инде. Ләкин юк, телне тыеп калып булмады, әй:

— Сез алай бик үк җәелеп китмәгез, сеңелем. Ни әйтсәң дә, мин дә ир-ат затыннан бит әле. Минем дә, хисләнеп китеп, гайрәтегезне чигерүем бар,— дип ычкындырдым.

Шул житә калды теге шайтан кавеменнән яралган нәрсәгә.

— Юк, үтерсәгез дә ышанмыйм, булмый сездән, кулыгыздан килми сезнең андый эш!— дип тора бу, авызын ерып. Ә үзе, шә-әп, шайтан алгыры! Бер кашык су белән кабып йотарлык дип әнә шундый чибәрләр хакында әйтәләрдер инде ул. Чыннан да, кабып йотарга әзер мин тегене. Шулай да, ашыкма, Булат, юләрлеккә бирелмә, дип күңелгә килгән шашкын хисләрне тезгенләп торам. Дөресен әйтим, бик авырлык белән генә тезгенләп торам. Әнә шул шайтани хистән тизрәк котылу өчен әйтәм мин моңа:

## УНБИШЕНЧЕ ДӘФТӘР

— Шаярма, сеңелем, минем белән,— дим.— Мин алай бер борып җибәрү белән генә кабынып китә торганнардан түгел. Бар, сеңелем, кайт үз фатирыңа!— дим.

Шуннан теге хәерсез нишләде дисез? Маңгаена төшеп торган дулкын-кара чәчләрен башын селкеп кенә артка сирпеп җибәреп, горур гына итеп күзләремә карады да әйтә бу миңа:

— Ә мин беркая да китмим, Булат абый. Шушында гына кунам мин бүген. Бер караватыгыз барыбер буш тора ич,— ди. Очкынланган күзләреннән күреп торам: бу моны һич кенә дә уйнап әйтми. Ә мин, ул алай-болай куна калса, үземне гөнаһтан саклый алмаячагымны бик яхшы сизәм. Хәзер дә тегене куенга йомып алудан, антымнан язудан куркып кына тыелып торам бит инде. Шуңа күрә, тизрәк чыгарып котыласым килеп, әйтәм мин моңа:

— Ничек оялмыйсың син, сеңелем, атаң шикелле кешегә шундый тузга язмаган сүзләр сөйләп торырга? Бу бүлмәдә ни калган синә? Бар, бар, юләрләнмә, үз фатирыңа кайт та рәхәтләнеп ятып йокла яки берәр үзеңә тиң яшьрәк кеше тап,— дим.

— Әйтмәгез дә, кайтмыйм да! — ди теге шайтан.— Ул карчыкның өе тыныч түгел, килгәннән бирле юньләп йокы күргәнем юк минем. Ичмаса, сезнең бүлмәдә бер туйганчы йоклап чыгасым килә,— ди.

— Мин бит төнлә бик каты гырлыйм, сеңелем. Ә кайчакларда, ни эшләгәнемне үзем дә белештермәстән сикереп торып, бүлмәдәге кешеләрне кыйный торган гадәтем дә бар,— дип тә карыйм, аптырагач.

Юк, һаман үзенекен сукалый теге пәри әвәләгән нәрсә.

— Мин сездән барыбер курыкмыйм, чөнки сезне яратам, Булат абый!— ди бу, күзен дә йоммыйча.

Барыннан да гаҗәбрәге шул: моны ул чын күңеленнән әйтә шикелле. Чөнки ике бите әнис алмасы шикелле тимгел-тимгел булып кызарып чыккан. Димәк, үз сүзләреннән үзе дә ояла, кыенсына. Шундый чакта гына шулай тимгелләнеп кызара бит кыз баланың бите... Хуш. Нишләргә миңа хәзер? Тагын аз гына шулай дәвам итсә, минем хисләрнең дә тезгене кулдан ычкынып китүе бар лабаса!

— Нинди ярату ул тагын?— дим тегеңә, мөмкин кадәр житди, нык итеп.— Каян килгән сүз тагын анысы?— дим.

Ул да көлүдән туктады хәзер. Ул да житдиләнде. Һәм әйтә бу миңа:

— Әгәр беләсегез килсә, беренче күргән көнне үк яраттым мин сезне!— ди.— Фәсхи картны да шул сезнең аркада, сезне ратканга кайтарып җибәрдем, белдегезме?— ди.

Карыйм, алдашмый шикелле. Күзләре моңсу, йөзе оялчан-житди. Мин дә адәм баласы бит, агай-эне, минем дә күңел, минем дә җан дигән нәрсә бар. Түзмәдем, янымда сыланып утырган җиреннән кочакка йомып алып, күзләренә карадым да сорадым:

— Син моны чынлап әйтәсеңме, сеңелем? Акылың белән уйлап әйтәсеңме?— дидем.

Ул җавап бирмәде. Бик арыган, бик йокысы килгән шикелле итеп, озын керфекле күзләрен йомды да, сүзсез генә минем иңемә башын салып, әнисенең имиен эзләгән бала сыман итеп, иреннәре белән минем иреннәремне эзли башлады...

Юк, кагылмадым мин аңа. Әлеге шул күзләре йомык хәлендә үземнең караватка илтеп салдым да урамга чыгып киттем. Мин озак кына йөреп кергәндә ул изрәп йоклый иде инде.

Мин аны уятып тормадым, Фәсхетдин агай караватына яттым.

Ә иртән мин уянганда ул инде бүлмәдә юк иде. Соңыннан аның бүлмәдән генә түгел, үзе яшәгән фатирдан ук китеп барганлыгы һәм минем костюм кесәсеннән, андый-мондый күзгә күренерлек әйбер очраса кирәк булыр дип юлга алып чыккан, өч йөз сум акчаны да алып киткәнлеге мәгълүм булды.

Менә шундый хәлләр. Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк. Ләкин мин берни дә арттырмадым монда. Ничек булган — шулай сөйләп бирдем дә, шуның белән эшем бетте дип саныйм. Монысын да сүз җае чыкканнан, үзебезнең колхоз завхозы белән минем арада булган хәлне сөйләгәндә искә төшкәннән генә сөйләдем.

...Шул хәлне сизепме, Айсылу мине бик нык контрольгә алган иде. Шуңа күрә, завхоз апагыз үзе күрешергә бик теләсә дә, мин мәсьәләне кырт кисеп куйдым. И шуның белән исәп өзелгән иде безнең. Миңа ачу итеп, шуннан ары Шәйхи белән чуала башлаган иде теге хатын. Шәйхи белән минем арада булган хәлләрне белә иде ул. Аңа яхшы атлы булып күренергә тырышып, минем теге фуражга дип калдырган икмәк хакында Шәйхигә тишкән бу. Ул хатын пенсиягә чыккач, моның шулай булганын миңа үзе килеп әйтте:

— Көнчелек аркасында, телемне тыеп тора алмыйча, колхоз малларының никадәр ризыгын кистердем бит мин-ахмак! Шуларның каргышы төште, ахрысы, барыбер бәхетле була алмадым,— дип, күз яшьләре белән елап әйтте. Ләкин моннан аның үзенә дә, миңа да берниндн җиңеллек булмады — эш узган иде инде.

Ә Шәйхигә шул гына кирәк тә иде ул чакта. Шул ук көнне районга мине әләкләргә чапкан бу. Икенче көнне үк контроль җибәреп безнең бар булган ашлыкны һәм фуражны үлчәттеләр дә «артыгын» алып Шәйхигә бирделәр. Чөнки ул, план артыннан куып, үзләренә фуражга бер центнер әйбер дә калдырмаган иде.

Әнә шулай итеп, ул елны «Трактор»ның хутын арттырырга тырышуым гел бушка китте. Үзебезнең колхозчылар алдында да, Шәйхи алдында да мин ахмак булып калдым. Ул көннәрдә нияр уйлаулармны, ничәмә-ничә йокысыз төннәр үткәргәннәремне үзем беләм дә, Айсылу гына белә. Ярый әле, ул бар иде юатырга:

— Артык аһ орма, әтисе, дөнья булгач аның шикелле генә күңелсезлекләр булыр инде ул. Моннан авырракларын да кичергән кеше бит син. Ничек тә түз. Дөреслек беркайчан да җирдә ятмый. Менә күрерсең, бер вакыт килеп чыгар, Шәйхинең ул кыланышлары барыбер бер фаш ителер әле,— ди иде ул.

Ләкин барыбер кыен иде миңа. Эшләп-эшләп тә хезмәт җилгә очканга йөрәк әрни. Хәтта, бөтен дөньясына төкереп, председательлекне ташлап, тагын читкә чыгып китим микән әллә дип уйлаган минутларым да булгалады. Тик мин дә колхозны ташлап китсәм, бүтән дә китсә, кем калыр соң кырда иген үстерергә дә, кем көрәшер соң ул Шәйхи шикелле шома бәндәләр белән дип кенә үземне бераз юата идем. Әнә шул көннәрдә мин үзе-үземә, Шәйхине эш белән җиңеп чыкмыйча торып, председательлектән китмәскә сүз бирдем. Аннары әтинең васыятен дә үтисе бар иде бит әле.

Колхозның хәлен, колхозчыларның тормышын яхшырту өчен иң элек иген уңышын күтәрергә кирәк икәнен сез дә, мин дә бик яхшы беләбез. Тик ничек арттырырга аны? Вакытында чәчеп, вакытында югалтусыз җыеп алу әйбәт нәрсә, билгеле. Әмма бу бит уңышны арттыру дигән сүз түгел. Табигать биргән уңышны җыйнап алу гына бу. Ә миңа җирнең уңыш бирүен арттырырга, әйтик, гадәттә җиде-сигез центнер арыш бирә торган җирдән унҗиде-унсигез центнер уңыш алырга кирәк. Моңа ничек ирешергә икәнен үзем анык кына итеп күз алдыма китерә алмыйм. Чөнки минем, үзегез беләсез, агрономия өлкәсендә белемем дә, тәҗрибәм дә юк. Ә ансыз юньле эш эшләп булмаячак.

Районга барып, берәр әйбәт кенә агроном табып бирегез әле, дип сорап караган идем, анда да эш пешмәде:

— Артык дан булмаса да, синең анда агрономың эшләп тора әле. Ә безнең бөтенләй агрономы булмаган хуҗалыклар да бар. Житкереп булмый бит, каян аласың аның яхшыларын?— дип кайтардылар.

Ә безнең агроном нәрсә инде ул? Сугыштан соң өч айлык курста укып кайткан, барлы-юклы дүрт класс белемле, гап-гади бер колхозчы. Агроном булып үзе дә эшләмәс иде ул. Тик атка утырып йөрисе, кырдан кайтышлый арба төбенә печәндер, саламдыр салып кайтасы булганга кызыгып кына йөри. Әйтәм бит, безнең ул Исмәгыйль агайдан иген уңышын арттыруны көтү — аертылган сөттән май язарга азаплану белән бер булыр иде.

Агроном мәсьәләсен тәки рәтләп хәл итә алмагач, бүтән җирләрдә кешеләр иген уңышын арттыру өчен ниләр эшлиләр икән, нинди яңа ысуллар кулланалар икән дип, алардан гыйбрәт алырга ниятләп, авыл хуҗалыгына караган журналлар, китаплар укырга тотындым. Башта үзебезнең район китапханәсендәгеләрне укып чыктым. Аннары, китапханәчеләрнең киңәше белән, Казанның В. И. Ленин исемендәге республика фәнни китапханәсе белән элемтәгә кереп, китапларны шуннан сорап алдырып укый башладым. Укый торгач шуны белдем: иген уңышын арттыруның чаралары бик күп төрле икән. Ләкин ул китапларда язылганча эш итү өчен бездә тиешле шартлар да, мөмкинлекләр дә юк. Аннары тагын шунысы да өркетә: китапларда гектарыннан иллешәр, алтмышар центнер уңыш алдык дип язсалар да, ул галимнәр бу уңышны гектарлап чәчкән игеннән алмаган, үзләренең тәҗрибә участокларыннан гына алганнар бит. Әле шул кечкенә генә участокларына да безнең унар гектар җиргә дә эләкми торган төрле ашламалар кертеп алганнар. Ул уңышны алар менә безнең шартларда һәм безнең җирләрдә алып карасыннар иде!..

Ә шулай да үз алдыма куйган максатыма ирештем. Анысы хакында сүз аз гына соңрак булыр. Ә хәзер Шәйхинең тагын мине ничек итеп төп башына утыртып калдыруын әйтеп китмичә мөмкин түгел.

Ул мине фураж мәсьәләсендә ахмакка чыгарып калдыргач, мин киләчәктә акыллырак булырга, алдымны-артымны карабрак йөрергә һәм — монысы минем өчен иң мөһиме иде!— игенчелектә генә түгел, терлекчелек өлкәсендә дә «Таң»ны узып китәргә дип, үз алдыма катгый бурыч куйган идем. Шуңа ирешү өчен бөтен тырышлыгымны салдым. Сөтне күбрәк бирсеннәр дип, ферма сыерларын аерым һәм тәүлек буена көтүдә йөртүне оештырдым. Иткә тапшырырга дигән малларны өстәмә ашатуны гамәлгә керттердем. Халык та минем булсын дип йөргәнне күреп-аңлап тора. Миңа ышаналар: ни кушсам — шуны эшлиләр, кая кушсам — шунда баралар иде...

Тырышу бушка китмәде. Итне дә, сөтне дә ул елны, үткән еллардагыга караганда, шактый артык тапшырдык дәүләткә. Иген уңышы да начар булмады. Ләкин ул елны да Шәйхинең борынына чиертә алмадым. Киресенчә, ул үзе минекенә чиертте. Җәй көне, минем җан-фәр-

манга эшләп йөргәнне күреп: «Тырыш, тырыш, бәлки орден алырсың», — дип көлеп йөрде дә көз көне итен йөз дә егерме, сөт планын йөз дә унсигез процент итеп үтәде. Безнең «Трактор» йөз процентны да бик авырлык белән генә җиңеп чыкты. Мин бик яхшы белеп торам, намуслы хезмәт белән, гаделлек белән ирешмәде Шәйхи моңа. Ит йөкләмәсен бездән арттырып үтәү өчен, буаз таналарын, менә дигән савым сыерларын итлеккә илтте. Ә сөт планын, сөт биргән кешеләргә люцерна яки болыннан печәнлек вәгъдә итеп, колхозчылардан җыйган сөт хисабына арттырып үтәде.

Әмма, ничек итсә дә иткән, аның «Таң»ы безнең «Трактор»дан алга чыккан иде. Дөрес, Шәйхи урынында бүтән бер председатель булып, ул шулай эшләсә, хәзер аны күз буяуда гаепләп бик каты пешекләрләр иисә бөтенләй эшеннән үк алып атарлар иде. Әмма Шәйхигә ул яктан җил-янгыр тидерүче булмады. Хәтта ит белән сөт планын арттырып үтәде дип, өлкә газетасында аның турында зур гына мәкалә дә бастырып чыгардылар әле...

Шулай да түздем әле аның бу хикмәтләренә. Адәм баласы шулай яратылган инде ул: иң читен хәлдә дә өметен өзми, үзенә аклану, юаныч табарга тырыша. Ул елны мин дә үземне-үзем юаткан идем: «Сыер дигән хайван дуңгыз түгел, елына икешәр тапкыр бозаулап, берьюлы унбиш бозау китерә алмый, бер генә бозау китерә. Анысы да дуңгыз баласы шикелле тиз үсми. Сыер булып җиткәнче кимендә ике ел ярым көтәргә туры килә. Шулай булгач, киләсе елда Шәйхинең иткә тапшырырга артык сыерлары да, таналары да булмаячак. Сөт планын да колхозчылардан сөт җыеп үтәүгә һаман саен юл куймаслар. Менә шул чакта карап карарбыз әле без, ни эшләр икән ул Шәйхи», — дип уйлаган идем.

Әмма Шәйхи алдагы елны тагын миннән акыллырак булып чыкты.

Инде игеннәрне җыяр вакыт җитеп килә иде. Зур булмаса да, тәҗрибәм бар, белеп торам, безнең кырларның уңышы Шәйхинекенә караганда әйбәтрәк: башаклары да эрерәк, сабаклары да куерак. Анвары безнекеләр бик чиста: бер бөртек чүп үләне күрмәссең. Борчагыбыз аеруча шәп: кузак саен сигезәр дә унар бөртек. Сабагының метр ярымга җиткән урыннары бар. Читтән караганда яшел диңгез шикелле булып җәйрәп ята. Дәүләткә сөт тапшыру буенча да безнең «Трактор» «Таң»нан алда бара. Бер сүз белән генә әйткәндә, Шәйхине җиңеп чыгарга мөмкин икәнлеге көн кебек ачык. Күктән таш ук явып, безнең кырларны харап итеп китмәсә, ул быел безне уздыра алачак түгел. «Ниһаять, аңа да җиңелү ачысын татырга туры киләчәк!» — дип гаделлек тантана итәчәгенә чын-чынлап ышанып тора идем инде. Тик...

Уракка төшәргә әзерләнеп йөргән көннәрдә нигәдер, «Трактор»ны «Таң» белән кушып, бер колхоз итәргә булдылар. Дөрес, колхозларны эреләндерү яңалык түгел, киресенчә, гадәти нәрсә иде. Ләкин безнең районда инде ул эш төгәлләнде дип сөйлиләр, председательләргә бу хакта борчылмаска, тыныч кына эшли бирергә кушалар иде. Менә шундый чакта кинәт кенә безне берләштерергә кирәк табуларына мин аптырабрак калдым. Председательлектән төшеп калам дип түгел. Ул эшкә минем беркайчан да атлыгып торганым булмады. Шулай да эч поша башлады минем бу хәлгә. Мин бит ул елны «Трактор»ны «Таң»нан уздырып җибәреп, Шәйхине җиңеп чыгарга тиешле кеше идем. Шәйхи юләр түгел, эшнең шуңа таба барганын белә. Әлеге шул берләштерү мәсьәләсен дә, миннән котылу өчен, ул уйлап чыгаргандыр дип шикләнгән идем. Шигем урынлы булган икән. Соңыннан ачыкланды: чыннан да, Шәйхи инициативасы белән башланган бу эш. Ләкин ул, мин уйлаганча, мине председательлектән төшерүне түгел, киресенчә, үзенең йөген дә минем җилкәгә салуны күздә тоткан икән.

Башта Шәйхи белән мине районга чакыртып, колхозларны берләштерергә кирәк икәнлеген әйттеләр. Аннары миңа:

— Ә син, Вәлиев, председатель буласың. Колхоз үзәге Ыргада калачак. Сиңа шунда, үз авылыгызга кайтып эшләргә туры килер. Әзерләнә башла! — диделәр.

— Ә Шәрифуллин ни эшли?

— Ул укырга китә.

— Укырга мин дә китәр идем ул, Гали Даутович.

— Без сине җибәрмибез. Син монда, колхозда, кирәк.

— Ләкин минем белем җиде генә класс бит. Ә Шәрифуллин болай да урта белемле.

— Без аны институтка җибәрәбез. Син базарда түгел, Вәлиев, сатулашма. «Таң» хуҗалыгын кабул итәргә әзерлән!..

— Булмый, Гали Даутович, минем ул тикле зур хуҗалыкны алып барырга хәлемнән килмәячәк.

— Бу — партия заданиесе, Вәлиев!

Безнең секретарьның тоткан җиреннән ычкындыра торган гадәте юк икәнен инде әйткән идем шикелле. Аннары аның Шәйхи мәсьәләсен инде катгый рәвештә хәл итеп куйганлыгы да бик яхшы сизелеп тора иде.

## УНАЛТЫНЧЫ ДӘФТӘР

Колхозларны берләштерү җыелышын алып барырга Гали Даутович үзе килде. Эшне бик кызу тотты. Берләштерелгән колхозның председателе итеп куярга минем кандидатура тәкъдим ителгәч, Ырганың Габдрахман атлы бер карты: «Сезгә ансат ул, иптәш сиклитар. Сезгә кем прсидәтел булса да ярый, сез куясыз да китеп барасыз, ә чиләнергә безгә кала», — дип каршы чыккан иде чыгуын. Мин аны күңелемнән хуплап: «Бу кеше сүзен башкалар да күтәреп алсын иде!..» — дип теләп тә караган идем. Чөнки үзебезнеке өстенә тагын дүрт мең гектар җире булган, райком ярдәме белән генә очын-очка ялгап килә торган хуҗалыкның камытын да кияргә бер дә алай атлыгып тормый идем. Ләкин Гали Даутович теге агайга ник авыз ачканына үкенерлек итеп җавап бирде: «Гел шулай инде ул, абзыкай, — диде ул, — кеше тавыгы каз булып, кеше хатыны кыз булып күренә. Куясыз да китәсез, дисең син. Куясы да китәсе булса, мин монда килеп тә йөрмәс идем. Сез уйлаганча алай бик ансат кына түгел ул безнең эш. Әгәр бик беләсегез килсә, колхоз эшенең барышы өчен, аның председателе ничек эшләве өчен, хәтта һәр колхозчының, шул җөмләдән сезнең дә, ничек эшләвегез, ничек тормыш итүегез өчен, беренче чиратта, мин, райком секретаре, җавап бирәм. Менә шулай, абзый кеше! Әгәр мин бүген иптәш Вәлиевне председатель итеп тәкъдим итәм икән, аның өчен дә иң элек җаваплылык минем өскә төшә. Мин аны тәкъдим итәм икән, димәк, бу эшне алып бара алырына ышанам. Аңлашылдымы, абзый?

— Аңлашылуның аргы ягына чыкты! — дип җавап бирделәр залдан Габдрахман карт өчен...

Шулай итеп, мин моңарчы ике кеше шактый авырлык белән алып барган йөкне берүзем тарта башладым. Ә Шәйхи авыл хуҗалыгы институтына укырга китте. Анда да кешеләрчә әйбәт кенә саубуллашып түгел: «Әйдә, эшли тор. Рәткә сала алсаң, укып чыккач, сине алыштырырга возможно шушы үзебезнең колхозга да кайтырмын әле», — дип көлеп китте.

Күпме генә тырышсаң да, барыбер син ахмак булып калачаксың, дигән сүзе иде бу аның. Минем канатны сындырырга, күңелне төшерергә теләве иде...

Ә мин аңа ачу итеп, үҗәтләнеп эшли башладым. Югыйсә, инде әйткәнемчә, башта бер дә алай очынып тормый идем. Сәламәтлегем бар, кулым эш белә: тимерчелектә дә эшләргә мөмкин, хисапчы булып та эшли алам, нигә мин шул тикле зур җаваплылыкны үз өстемә алып, җан тынычлыгымны югалтып, көн-төн чиләнеп йөрергә тиеш әле, дип уйлый идем. Ә менә хәзер, Шәйхи җенемне чыгаргач исә, үлсәм үләм, ләкин шул явыз җанны үземнән көлдертерлек итмим, дип үз-үземә сүз бирдем дә җан-фәрман тырышып эшкә ябыштым.

Һәй, ул еллар!.. Бүгенге акылым ул чакта булган булса, аягымнан асып куябыз дип әйтсәләр дә йөрәгем җитеп ул эшкә алынмас идем. Шундый зур колхозга җитәкче булып җиде класс белем белән ничек алынмак кирәк?.. Ләкин мин моны хәзер шулай уйлыйм. Ә ул чакта мин әле яшь идем. Алай төрле яклап уйлый белми идем. Ләкин гайрәтле идем, тәвәккәл идем.

Кушылган колхозга исем бирү мәсьәләсе килеп баскач, Ырганыкылар үз колхозлары исемен калдырырга кирәк, Пәрәүнекеләр «Трактор» дип атарга кирәк, диделәр. Эш шулай бәхәскә киткәч:

— Яңа исем бирергә кирәк, бер якның да хәтере калмасын! — дип, Гали Даутович киңәше белән «Уңыш» дип атадылар. Бу хәл минем җаваплылыкны тагын да арттыра иде. Ни өчен дисәң, «Уңыш» исемен йөрткән колхозның уңышы түбән булырга тиеш түгел. Исемен аклар өчен, ул гел алдынгылар рәтендә барырга тиеш иде. Аннары әлеге шул ике колхозны берләштергән җыелышта Ырга халкы да: «Кара аны, прсидәтел, махы бирәсе булма, бөтен ышаныч синдә!» — дип искәртеп куйды.

«Махы» бирергә үземнең дә исәп юк. Тик ничек итеп бирмәскә ул махыны — хикмәт менә шунда. Инде әйткәнемчә, безнең як җирләре алай дан җирләр түгел. Хәзерге фән теле белән әйткәндә, безнең җирләрнең табигый уңдырышлыгы нибары кырык дүрт балл гына. Галимнәр бер баллны егерме кило ашлыкка тиңлиләр. Кырык дүртне егермегә тапкырлап карыйк әле, сигез йөз дә сиксән килеп чыгамы? Димәк, безнең җирләрнең бөтен табигый мөмкинлеге нибары сигез центнер да сиксән килограмм гына уңыш бирә ала дигән сүз инде бу. Анысы да җирне бик әйбәтләп эшкәртеп, елы әйбәт булганда гына әле. Ә Шәйхинең җир дип, уңышны арттырыйм дип алай баш ватып азапланмаганын инде әйткән идем шикелле... Дөрес, баллы безнеке шикелле кырык дүрт кенә булган җирләрдә дә кайбер колхозлар унбишәр, хәтта егермешәр центнер ашлык үстерә алуы турында газета-журналларда язгалыйлар язгалавын. Ләкин алар анда җиргә без гомер күрмәгән ашламалар кертәләр икән шул. Ә безнең хәтта юньле агрономыбыз да юк. Авыл хуҗалыгы техникумында укып чыккан кеше булса да, Ырганың үз агрономы күңел биреп, булсын дип йөрүче ышанычлы бәндә түгел. Хатын-кыз белән аракы күрсә күзе тона, дөньясы онытыла торган иләс-миләс бер буйдак иде. Колхозларны кушкач, шуңа күрә агроном итеп аны түгел, махсус белеме булмаса да, хәл кадәренчә миңа ярдәм итәргә тырыша торган үзебезнең Исмәгыйль агайны калдырырга туры килде. Ләкин ары таба болай яшәү мөмкин булмаячак, агроном мәсьәләсен ничек тә хәл итәргә кирәк иде.

Урып-җыю эшләре җиңеләеп, әзрәк кенә сулу алырга мөмкинлек булу белән Казанга, авыл хуҗалыгы министрлыгына киттем. Ике зур мәсьәләне хәл итеп кайтырга иде исәп. Колхозның өч автомашинасы бар. Шәйхидән калган мирас. Шул өч машинаның тик берсе йөреп торган була. Анысы да бер көн йөрсә, ике көн ремонтта ята. Ә икесе гел дә ватык. Төзәттерергә запчастьлар юк. Машина мәсьәләсендә минем эшләр шул чиккә барып җиткән, авыл хуҗалыгы министрлыгында рәт чыгарып булмаслык булса, Министрлар Советы Председателенең үзенә кереп карарга иде ният.

Ә икенче мөһим мәсьәлә — әлеге шул агроном мәсьәләсе. Башта ук әйтеп китәм: машина мәсьәләсен тәки хәл итә алмадым мин ул чакта. Министрлыкта, без монда запчасть өләшеп утырмыйбыз, иптәш Вәлиев, ул эш планлы рәвештә «Сельхозтехника» линиясе аша эшләнә, дип, миңа әллә кайчан мәгълүм булган нәрсәләрне әйтеп, акыл өйрәтеп чыгарудан башка бернинди дә ярдәм итә алмадылар. Ә Министрлар Советы Председателе белән гел сөйләшеп үк булмады: өйдә юк, Мәскәүгә киткән чагы иде.

Шулай да агроном табып алып кайттым мин ул чагында. Ниндиен генә таптым әле! Аның белән очрашу гел көтмәгәндә килеп чыкты безнең. Әлеге шул машиналарга запас частьлар юллый алмаган ачудан, ишекләрен шакып та тормыйча, министрлыкның кадрлар бүлегенә барып керсәм, кадрлар бүлеге башлыгы бер кеше белән сөйләшеп утыра икән. Шулай да ул мине кире борып чыгармады. «Здрастуйте» дигәнемә каршы баш кагып кына җавап бирде дә, кулы белән ишарәләп, утырып көтеп торырга кушты. Ә үзе теге кеше белән кызып-кызып гәпләшүен белде. Иң элек мин аларның сүзенә түгел, бәлки мөдир белән тарткалашучы кешегә игътибар иттем. Чөнки ул шундый бәләкәй, утырган урындыгының аркасыннан башы чак кына күренеп тора, ә тавышы шундый калын, мичкәдән чыккандай яңгырап чыга иде. Шалкан шикелле түгәрәк, сипкелле битле, аксыл-сары чәчле, төсе нинди икәнен һич тә күреп булмаслык бәләкәй кысык күзле, егерме-егерме бишләр тирәсендәге ул егетне мин мари яки мукшы егете булса кирәк дип уйлаган идем. Юк икән, үзебезнең татар малае булып чыкты ул. Әнә шул карап торырга бер дә алай искитмәле булмаган кеше министрлыкның бүлек мөдире белән якага-яка килеп тарткалашып утыра бит, мин сиңа әйтим. Мөдир дә бик каты сөйләшә:

— Миңа председатель ошамый, миңа тегесе ошамый дип, һәр яшь белгеч, синең шикелле, эшен ташлап китеп бара башласа, кая китә ул аннары? — ди. — Ошыймы-ошамыймы сиңа председатель, билгеләү комиссиясе тарафыннан җибәрелгән урыныңда син барыбер ике елың эшләргә тиешсең!

Ә тегесе гел үзенекен тукый:

— Мине колхозга комиссия җибәрмәде. Мин анда фәкать үз теләгем белән киткән кеше, — ди. — Мин әле дә колхоздан качарга җыенмыйм. Мин сездән икенче бер колхозга җибәрүегезне генә үтенәм! — ди...

Байтак тарткалашты болар. Берсе дә үз сүзен бирергә теләми. Мене шунда тыңлап утыра торгач, ошатып куйдым мин теге калын тавышлы бәләкәй егетне. Үз сүзен өздереп, батыр итеп сөйләве ошады. Шуннан соң түзмәдем, гафу үтенеп, тегеләрнең сүзен бүлдем дә мөдиргә әйттем:

— Сезнең янга мин нәкъ менә шул агроном мәсьәләсендә кергән идем. Күрәм, бу иптәш агроном икән. Әгәр сездән рөхсәт булса, мин аның белән үзем сөйләшеп карар идем.

Күрәсең, мөдир бу үҗәт егеттән тәмам туйган иде булса кирәк, миннән хәтта син кайсы районнан, кем син, дип тә сорашып тормады.

— Бар, зинһар, алып кит! Хәзер үк алып кит! — дип кулын гына селекте.

Егет тә карышып тормады. Шундук миңа ияреп коридорга чыкты. Какраз төшке аш вакыты да җитеп килә иде. Әйдәле, энекәш, шунда иркенләп сөйләшербез дип, мин аны Ленин урамындагы студентлар ашханәсенә алып киттем. Ашханәгә барышлый ук бөтен автобиографиясен сөйләп бирде ул миңа. Исеме Фәгыйт. Фамилиясе — Фәтхуллин икән. Балык Бистәсе районының Әшнәк авылында туып үскән. Әтисе сугышта вафат булып калган. Әнисе исән, колхозда эшли. Яше егерме алтыда. Өченче ел Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаганнан

соң институтта аспирантурада калдырганнар. Анда дүрт ай укыгач, авыл җирендә эшләп, тәҗрибәләр алып бармыйча торып нинди авыл хуҗалыгы галиме булырга мөмкин, ди дә бу, укуын ташлап, Арча районының бер колхозына агроном булып китә. Әмма анда эшли башлагач колхоз председателе белән борчагы пешми. Председатель моның белән бөтенләй исәпләшми. Йомышчы малай шикелле итеп, агроном эшенә һичнинди катнашы булмаган җыен вак-төяк артыннан йөгертә. Ә егетнең җирне, үсемлекләрне яхшылабрак өйрәнәсе, чәчүлек орлыкларны тиешле конденциягә җиткерү артыннан йөрисе, кыскасы — үзенең төп эше белән шөгыльләнәсе килә. Институтта башлаган фәнни эшен дәвам иттереп, колхоз кырында тәҗрибәләр алып барырга да ниятли. Тик председатель бу турыда ишетергә дә теләми. Шулай да елдан артык түзә Фәгыйт. Председатель белән ничек тә аңлашырга, уртак тел табарга өметләнә. Әмма теләгенә ирешә алмый. Узган атнада тагын бер тапкыр хуҗа белән каты гына сүзгә килешә дә, бөтенләй өметен өзеп, колхоздан гел китеп үк бара...

Әнә шул кыюлыгы, берәүләр җан-фәрман тырышып та керә алмаган аспирантураны ташлап, үз теләге белән авылга китеп баруы, анда күңелсез хәлләргә юлыкканнан соң да күңелен төшермичә, һаман үз максатына ирешергә омтылуы ошады миңа ул егетнең. «Ни булса — шул, тәвәккәлләргә кирәк. Һәрхәлдә, безнең Исмәгыйль агай шикелле генә булмас. Люцерна орлыгы белән алабута орлыгын гына аера белә торгандыр әле», — дигән нәтиҗәгә килдем мин.

Болай уйлавымның хикмәте бар. Бер елны, «Трактор» әле үзенә аерым, «Таң» үзенә аерым колхоз булган чакта, утыз гектар чамасы җиргә чәчәргә люцерна орлыгы җитми калды безнең. Беләм, Шәйхидә люцерна орлыгы бар. Үзем сорап барудан мәгънә юк — миңа бирмәячәк. Чукынса чукына, ләкин бирми. Ә безнең агроном Исмәгыйль агай аларга чыбык очы тиешле кеше. Хәтта кунакка да йөрешкәлиләр. Шуңа Исмәгыйль агайны җибәрергә булдым. Бәясеннән тормабыз: арыш сораса — арыш, бодай сораса — бодай, акчалата сораса — акчалата түләрбез хакын, дип сөйләшергә әйтеп җибәрдем.

Килешкән болар. Акчага килешкәннәр. Тик банк аша күчертеп бирергә түгел, кулдан кулга бирергә сөйләшкәннәр. Андый чакта вакланып торып булмый. Акчага булгач — акчага. Кулдан кулга икән — кулдан кулга!..

Икенче көнне үк алып кайтты Исмәгыйль агай утыз гектарлык орлык. Шул ук көнне чәчтереп тә куйды ул аны. Тишелеп чыгуын көтә башладык. Анысы да озак көттермәде. Шундый куе булып, шундый тигез булып бөркелеп тишелеп чыкты — просто ислэр китәрлек иде. Ләкин ул... люцерна түгел, ә алабута иде шул. Шәйхи, хәерсез, миңа үч итеп, тавыкларына ашата торган чүпле бодаен суыртып, люцерна орлыгы урынына алабута орлыгы биреп җибәргән. Ә безнең Исмәгыйль агай шуны аера алмаган иде... Менә шуңа күрә дә, укыган кеше укыган кеше булыр — алабута орлыгын гына таный торгандыр әле, дип уйладым да, әйттем Фәгыйткә:

— Мин сине агроном итеп алырга каршы түгел. Тик син ике шарт куймакчы идең. Нинди шартлар икән ул. Берсе хезмәт хакын акчалата түләү мәсьәләседер инде, шулаймы? — дидем. Ни өчен дигәндә, ул елларда председательләргә һәм агрономнарга акчалата түләү гамәлгә кереп килә, бу егет тә шуны сорар дип көткән идем. Юк, мин уйлаганча булып чыкмады.

— Мине, — диде ул, — ничек түләү мәсьәләсе артык кызыксындырмый. Әлбәттә, акчалата түли алсагыз, бик әйбәт булачак. Түли алмыйсыз икән, хезмәт көненә эшләргә дә риза. Ә минем шартларым менә болай: беренчедән, агроном вазифасын үтәүне тулысынча тик минем

үземә тапшырасыз. Ул өлкәдә эшнең торышы өчен мин үзем җавап бирергә тиеш. Икенчедән, миңа фәнни-практик эш алып барырга мөмкинлек бирәсез. Моның өчен минем шәхси карамакка бер гектар җир кирәк булачак. Курыкмагыз, ул җирдән алынган уңышны мин тулысынча колхозга тапшырып барачакмын. Ул уңыш колхозның уртача уңышыннан ким булмас. Менә шуларга риза буласыз икән, мин сезнең колхозга бүген үк барып эшкә башлыйм.

Нигә риза булмаска ди? Болай да агроном вазифасына кирә торган нәрсәләрне генә сорый иде ләбаса ул егет! Тоттым да үзем белән ияртеп авылга алып кайттым мин аны. Иртәгәсен иртүк эшкә кереште бу. Әйтергә кирәк, шактый зур тәвәккәллек белән һәм шактый сәер итеп керештe. Нидән башлаганын үз җае белән аңлатырмын. Башта автомашиналарыбызны ничек итеп сафка бастыру хакында әйтеп китәсем килә.

Әйе, ватык машиналарыбызны ничек итеп булса да сафка бастырырга кирәк иде безгә. Шул хакта киңәш-табыш итеп карар өчен, бер көнне, идарә члennарын җыеп, идарә утырышы үткәрдек. Идарә члennары бөтенесе дә машиналарны язга тикле ничек тә ремонтлап куярга кирәк дигән фикерне куәтләде. Тик ничек итеп төзәттерергә соң аларны? Колхоз кассасында анлык акча юк. Уйлаша-сөйләшә торгач колхозның дүрт карт сыерын суеп сатарга кирәк дигән тәкъдим керттеләр. Ревком председателе Сәлимҗан агай тәкъдиме иде бу.

— Сатуын сатасы да бит, Сәлимҗан агай, — мин әйтәм тегеңә, — ләкин мөгезле эре терлекләрнең бер генә башын да киметмәскә дигән катгый күрсәтмә бар ләбаса.

— Анысын ничек тә җайларбыз, Булат олан, — ди тегe. — Тамакларына бәрәңге тыгылып дипме, чи люцерна ашап кубенүдән дипме, тагын шундый берәр төрле сәбәп табыпмы, кисәк кенә суеп калырга туры килде, дип шул хакта үзем белешмә алып кайтырмын мин сиңа. Ветпункт мөдире Фидыр Иваныч, шәт, кире борып җибәрмәс. Кулга килә торган адәм, үзебезнең керәшен ул, — ди. — Түлке ул майлаганны җарата, берәр яртылык акча кирәк булыр, — ди.

— Ярый, — мин әйтәм. — Эшең барып чыгардай булса, анысыннан гына калмас...

Сыерларның итен Казанга алып барып йөрисе дә булмады: колхозчылар исеменнән (колхоз исеменнән ярамый, чөнки акчасын кулга бирмиләр) берсен район больницасына, өчесен райпотребсоюзга илтеп тапшырдык та — вәссәләм!..

Акчалы булуын булдык. Инде машиналарга кирәкле әйберләрне каян табарга? Бу юлы да әлеге шул ревком председателе Сәлимҗан агай акыл бирде.

— Машиналар ясап чыгара торган җиргә — Гүрки тирәләренә барып карарга кирәк, — диде ул. — Минем кияү тора анда. Әле узган кыш кына янына барып, кунак булып кайтканыем. Шунда бер көнне сөйләшеп утырганда Казанның талчук базары хакында сүз чыкты да әйтә миңа кияү: «Их, атакай-атакай! — ди. — Сезнең ул талчук базарыгызда чүпрәк-чапрактан башка рәтле нәрсә юк бит анда. Беткән икән ул сезнең Казан талчугы! — ди. — Вәт безнең Гүркинең талчук тек талчук, ичмаса! Анда машина часларының җаның теләгәнен табарга була. Хәтта шуннан часлап сатып алып кайтып, үзләренә яңа машина җыйган кешеләр бар бездә, — ди. — Акчам гына юк. Берцәк акчам булса, мин дә үземә машина кораштырыр идем», — ди. Үзе шүфир кеше ул. Шуңа бик кызыга машина дигән нәрсәгә.

— Ул сиңа җиңел машиналар турында әйткәндер, Сәлимҗан абый. Безнең бит йөк машиналарына кирәк, — дим тегеңә.

— Ашыкма, — ди бу. — Рас мин әйтәм икән, имеш-мимеш белән генә эш йөртмим инде. Наруш сорадым кияүдән: анда суң грузавай машиналарга да кирәк-яраклар табарга буламы, әллә лухки машина часлары гына саталармы дип. Кәнкерит итеп, аерып сорадым. Кияү дә кәнкерит итеп әйтте: «Бөтенесенә дә бар. Грузавайларга чәс табу ансатрак та әле», — диде. Бик кәнкерит исемдә, ап-аек чагында, әле шешәдән рүмкәләргә сала гына башлаган чагында әйтте ул моны. На всяки случи дип, мин аңа дажы калхуз машиналарына бирәр төрле чәс кирәк була калса, шушы Гүркигә генә килергә була икән алайса, дип тә әйттем әле. «Пажалысты, атакай, пажалысты, прәме үземә килергә мужыш. Любуен табып бирәм», — дип калды кияү.

Сәлимҗан агайны мин яхшы беләм: алдаша торган кеше түгел ул. Ышанырга була иде аңа.

— Алайса, болай итәбез, Сәлимҗан абзый: бар, өеңә кайтып җыен да иртәгә үк Горькийга чыгып китәрсең!

— Мин баруын үзем барып тормам, — ди теге. — Сәламәтлегем дә чамалы. Аннары минем анда барудан юл расхутыннан башка ни файда? Шүфир түгел ич мин — ни кирәген дә, ничек аласын да, алгач ничек апкайтасын да белмим. Син лутчы зафхузың белән бер шуфиреңне җибәр. Мин кияүнең әдрисен биреп җибәрермен. Минем кияү бик ипле мишәр ул. Мин әйтте дип әйтсәләр, кирәк әйберне җир астыннан табып бирер. Ә минем анда барып йөрү кирәк түгел. Баручылар артыннан кучтәнәч итеп ярты түш сарык ите биреп җибәрермен. Кияү дә, кыз да үзем килгәннән дә артыграк сөенерләр, — ди...

Сәлимҗан агай барысын да бик белеп сөйләгән икән: Горькийдан алып кайткан запчастьлар белән төзәтелеп, январь башыннан ук сафка баскан иде безнең машиналар. Ул елларда кышын авыл юлларында машина белән йөрү гамәлдә түгел, чөнки колхозның үз бульдозеры юк, юлдагы карны чистартып тормый идек. Машина тикле машинаны кыш буе тик яткыруы да кызганыч. Шуңа күрә Казанга баргач бер завод директоры белән сөйләшеп, язга тикле машиналарны шунда эшләтеп торырга килешү төзеп кайттым. Безнең машиналар анда дүрт айга якын эшләде. Шоферлары да хәйран гына акча төшереп кайтты, колхозга да машиналар эше өчен завод шактый акча күчергән иде. Ул акчага теге дүрт карт сыер урынына биш яшь сыер сатып алдык...

Хәзер инде Фәгыйт турындагы бая бүленеп калган сүзне дәвам итәргә дә була. Шәп кеше булып чыкты ул егет. Һич курыкмыйча әйтәм, бүтән барлык агрономнар да аның шикелле җирне яратып эшләсә, безнең илдә ел саен җыелып алына торган иген уңышы аз куйганда да егерме процентка артыграк булыр иде. Инде егерме ел тоташтан эшли ул бездә. Һәр ел безнең «Уңыш» игенне, күрше колхозларга караганда, гектарыннан биш-алты центнер артыграк алып килә. Нигә болай бу?

Бөтен хикмәт — җиргә мөнәсәбәттә.

Җирне газиз анабыз шикелле итеп хөрмәт итүдә.

Җирнең холкын, хаҗәтләрен аңлый белүдә.

Күпме тырышсалар да, мәңгелек двигатель уйлап таба алганнары юк әле галимнәрнең. Таба алмаячаклар да. Чөнки двигатель хәрәкәткә килсен, эшләсен өчен аңа ягулык, ягъни «ризык» кирәк. Аны ремонтлап торырга кирәк. Җир дә шулай. Югары уңыш алыйм дисәң, аңа «ягулык» биреп тор, аны «ремонтлап» тор. Шунсыз ул искерә, ябыга, хәлсезләнә. Шунсыз аны тирән итеп сөрү дә, күп еллык үләннәр чәчү дә коткара алмый...

Ә без аны коткарып калырга гына түгел, без аны яңартырга, ях-

шыртырга тиеш идек. Безгә килеп эшли башлау белән Фәгыйт миңа менә шушы фикерләрне кат-кат тукырга тотынды.

— Җирне яңартырга кирәк икәнен мин үзем дә беләм, — мин әйтәм. — Син миңа шунысын әйт: ничек итеп гамәлгә ашырабыз соң моны?

— Ничек итепме? — ди бу, бер дә алай исе китмичә генә. — Кырга тирес чыгарудан башлыйбыз без аны, Булат абый, — ди.

Бик очынып-очынып сөйләгәч, мин аннан зуррак, минем өчен яңарак тәкъдим көткән идем.

— Соң бит, — мин әйтәм, — кырга тирес чыгару ата-бабадан калган, гомер-гомердән килә торган нәрсә ич ул, энекәш!

— Анысы шулай,— ди бу.— Тик без аны бүтәнчәрәк итеп чыгарачакбыз. Гадәттәгечә, кайда туры килсә — шунда, күпме туры килсә — шулай түгел, бәлки билгеле бер җиргә, билгеле бер күләмдә чыгарачакбыз без аны. Мәсәлән, быел ике йөз гектар җирне шулай ашлап карарга исәп...

Нишлисең, тыңламыйча булмый иде, чөнки аның эшенә каршы килмәскә үзем риза булып алып кайттым.

Көзге кыр эшләре тәмамлану белән җилкенеп-җилкенеп «тирес операциясе»нә тотындык, шулай итеп. Ә тирескә кытлык юк иде. Ырга фермасында сугыш елларында тиресне кырга ташып тормаганнар, ферма янындагы елгага гына түгеп барганнар. Бер өйрәнелгән гадәт буенча, сугыштан соң да шулай дәвам иткән бу. Шәйхи председатель булып эшләгән елларда мәсьәләне тагын да ансатлаштырган: тиресне түгеп тә мәшәкатьләнмәгәннәр, кыш буе фермада гына җыя килгәннәр дә язга чыккач, район юл эшләре бүлегеннән бульдозер чакырттырып, шуның белән генә эттереп чыгарганнар елгага. Бер фермада гына түгел, атлар абзарында да шундый ук хәл иде.

Эшкә ярардай тракторларны, машиналарны, бар булган атларны, бөтен халыкны кушып, башта әлеге шул елгалардагы тиресне кырга ташыттык. Аннары ике авылның да фермаларын, ат абзарларын чистарттык. Шуннан соң Фәгыйт күрше Корноух совхозы директоры белән сөйләшеп кайтты да шул совхозның хан заманыннан бирле җыелып килгән тиресен үз кырыбызга ташырга тотындык. Совхоз директоры сөенеп бетә алмады безнең бу эшкә. «Минем тирес артыннан йөрергә вакыт та юк, эшчеләрем дә җитми иде. Рәхмәт, иптәшләр, безгә бер зур ярдәм иттегез!» — дип, кат-кат рәхмәтләр укыды. Тирес түгүдә эшләгән колхозчыларга совхоз исәбеннән хезмәт хакы да түләде хәтта. Акчалата түләде! Әле дә хәтеремдә, тирес түгүдә эшләгән кешеләргә көненә ун сум да утыз җидешәр тиен (иске белән) акча төшкән иде. Безнең колхозчылар куанып бетә алмады шуңа. Чөнки ул чакта әле колхозда акчалата түләү юк. Кайдадыр башка өлкәләрдәге алдынгы колхозларда акчалата түләү кертелә башлау хакында газеталардан укып, радиолардан тыңлап кына беләбез. Колхозчыларына аена өчәр-дүртәр йөз сум эш хакы түләп бара торган колхозлар турында укыганда шаклар катып, телләр шартлатып куя торган идек. Шулай булуы гаҗәп тә түгел. Сугыш еллары белән, сугыштан соңгы еллар белән чагыштырганда, чыннан да, бик зур яңалык, бик нык алга китеш иде бу. Ә хәзер?.. Уйлый китсәң гел дә шаклар катмалы инде колхоз тормышындагы үзгәрешләр. Үзебезнең «Уныш»ны гына алыйк. Узган ел, мәсәлән, безнең колхоз буенча уртача хезмәт хакы туксан өч сум да җитмеш ике тиен чыкты. Ә быел йөздән артыграк булыр дип торам. Почти инженер хезмәт хакы бит инде бу! Әмма, шулай булса да, халык эш дип алай атлыгып тора димәс идем. Дөрес, колхозда эшләргә кеше җитми дип зарлана алмыйм. Бездә ул яктан әлегә кытлык юк. Ә бит кайбер колхозларда хәзер үк инде бу мәсьәлә бик җитди тора. Тракторчылары җитмәгәнлектән, язгы чәчү өстендә өчәр тракторы

эшсез торган колхозлар булды районда. Газета-журналлардан күренә, бер бездә генә түгел, бу проблема ил күләмендә шулайга әверелеп бара икән хәзер. Нилектән болай бу? Үсеп канатлану белән нигә авыл яшьләре шәһәргә очып китү ягын карый? Ничек итеп аларны туган җирләрендә — авылда калдырырга?...

Бу сорауларның берсенә дә әлегә анык кына итеп җавап биргән кеше юк. Моннан ун-унбиш еллар элек мәсьәләне бик тиз генә хәл итмәкче булганнар иде. Авыл яшьләре авылда калсын өчен, аларның культура-көнкүреш шартларын яхшыртырга: клублар, культура йортлары салдырырга, стадионнар төзергә, китапханәләр булдырырга, үзешчән сәнгать коллективлары тупларга кирәк, диделәр. Әнә шулар булмаганга китә яшьләр авылдан, шулар тарта аларны шәһәргә, диделәр... Бүген культура йорты яки клубы булмаган авыл, белмим, бармы икән? Безнең районда, мәсәлән, андый колхоз гел дә юк. Күбесендә Мәскәүнең Зур театры спектакльләрен рәхәтләнеп куеп булырлык зур-зур сәхнәләр, алтышар йөз кеше сыешлы тамаша заллары, тынлы оркестрлар, үзешчән ансамбльләр бар. Йорт саен — телевизор. Унбишәр-егермешәр мең китаплы китапханәләр — авыл саен. Атнага икеөч тапкыр киносын күрсәтеп торалар. Шашка, шахмат, бильярд шикелле нәрсәләр турында әйткән дә юк инде. Көнкүреш мәсьәләсенә килгәндә шулай ук зарланасы түгел. Авыл егетләре-кызлары, шәһәрнекеләргә караганда, һич кенә дә ким киенми. Хәтта бераз арттырып та җибәрмиләр микән әле. Ашау-эчү мәсьәләсенә килсәк, шулай ук авыл ягы басарак төшә: кышка ике-өч сарык, тугыз-ун каз-үрдәк, бозау янсә тана суймый калган хуҗалык юк хәзер. Хезмәт хакы турысында инде әйттем. Ләкин, шулай да, авыл яшьләре һаман шәһәргә китә тора. Ни җитми аларга авылда? Нинди магнит тарта аларны шәһәргә?..

Әле күптән түгел генә үзебезнең Ырганың бер егете белән сөйләшергә туры килде. Колхоздан җибәрүне үтенеп, гариза язып килгән бу. Армия хезмәтеннән кайткач, төзүчеләр бригадасында эшли иде. Күтәреп алып мактарлыгы булмаса да, урта куллар рәтендә чутлана. Хезмәт хакы да әйбәт: аена йөз туксаннан ким төшми. Семьясы да бар. Хатыны китапханәдә эшли. Көндезге уникегә тикле өйдә. Уникедән дүрткә тикле китапханәдә. Аннары тагын кичке җидегә кадәр өендә була да, җидедән унга кадәр китапханәгә барып кайта. Күтәреп эшлисе түгел. Хезмәт хакы — йөз дә егерме тәңкә. Туксанын дәүләт түли, утызын колхоздан түләп килабез. Йорт-җирләре — гүрнәчә. Малтуар — ишегалды тулы. Ни җитте кызларына алыштыргысыз япь-яшь кайнанасы бар. Анысы йорт эшләрен гөл итеп алып бара. Әйтәм бит, рәхәтләнеп яшисе дә эшлисе инде. Моннан да рәхәт тормышның булуы мөмкин дә түгел шикелле. Онытып торам икән: узган җәй генә алган бишекле «Урал» мотоцикллары бар әле үзләренең. Берәр җиргә барасы килә икән — выжт! — утырасы да чабасы...

Менә шулар колхоздан китәргә ниятләгәннәр. Чынлап әйтүедерме, КамАЗга барабыз, ди. Ә КамАЗга барырга теләгән кешеләрне без тота алмыйбыз. Тотарга хакыбыз юк. Анда эшләргә дә кешеләр кирәк. Гаризасына кул куйдым, билгеле. Анда түгел мәсьәлә. Хикмәте шунда: нигә китә ул шушы җәннәтен ташлап? Колач җәеп каршы алсалар да, КамАЗда башта тулай торакта яшәргә туры киләчәген, өч-дүрт елсыз квартира ала алмаячагын белә бит ул. Эшнең колхоздагыдан җиңел булмаячагын да белә.

— Ни җитми сиңа авылда?

Бу сорауны мин аны авылда калдырырга тырышудан түгел, болай гына, ни әйтер икән дип кенә бирдем. Ә ул уйлап та тормады:

— Заманча яшисе килә, Булат абый! — ди.

— Ничегрәк була икән инде ул синең заманча яшәү дигәнең, энекәш? — дим тегеңә.

— Улмы? — ди бу. — Кыска тына итеп әйткәндә, көнгә сигез сәгать эшләп, атнага ике тапкыр ял итеп яшәү була ул, — ди. — Ә озынрак итеп әйткәндә, мәсьәлә менә болайрак тора. Хәзер, сүз дә юк, тормыш әйбәт. Житешмәгән нәрсәбез юк. Минем бүген дисәң бүген «Жигули» алырлык рәтем бар. Ләкин ни эшлим мин аны алып? Кая бара алам мин аңа утырып та, ни рәхәтен күрә алам мин аның. Жәй буе ходаның һәр бирмеш көнендә көнозын эштә ич мин. Шулай булгач, ул машинаның миңа ни кызыгы кала? — ди. — Ә менә шәһәрдә эшләсәм, миңа атнага ике көн ял булачак. Шул ял көннәрендә мин хатынны утыртып я берәр елга буена балыкка барып, кояшта кызынып кайта алам. Яисә жиләккә. Яки гөмбә жыярга бара алам. Менә бу инде заманча, замандашларча яшәү була: эш тә эшләнә, кешеләрчә ялы да була. Ә син әле бу араларда гына колхозда андый нәрсәне гамәлгә кертергә жыенмыйсың шикелле, — ди.

Менә эшләр кая таба китте хәзер. Бар, каршы килеп кара син аңа! Моннан дүрт-биш ел элек ул бу сүзләрне әйткән булса, мин аны рәхәтенә чыдый алмый сикерә башлаган дияр идем. Ә бүген, юк, гаепли алмыйм мин аны. Киресенчә, бүген мин аны хаклы дип саныйм. Әйтик, машина мәсьәләсе. Кыш көне йөреп булмый бит әле безнең якларда аның белән. Димәк, машина алырга мөмкинлек тудырганбыз икән, без аңа ул машинада йөрергә дә мөмкинлек тудырырга тиешбез. Моңа ничек итеп ирешергә соң? Минемчә, бердәнбер юл — авылда да, шәһәрдәге шикелле, сменалап, атнасына ике көн ял итеп эшләүгә күчү. Дөрес, колхоз малларын, сез дә ял итегез дип, ашаудан туктатып торып булмый. Көн саен вакытында ашатып-эчертеп барырга кирәк аларны. Урак өстендә шулай ук ял көне дип торып булмаячак. Ләкин аңысы вакытлы эш бит аның. Күп куйганда да бер айдан артыкка сузмыйбыз без аны хәзерге техника белән. Ә башка вакытта авылда да шәһәрдәгечә халыкка атнага ике көн ял бирүне мин үзем булмастай нәрсә дип уйламыйм. Сүз дә юк, жиңел генә хәл итәлә торган мәсьәлә түгел бу. Бигрәк тә механизаторлар белән эш кыен булачак. Хәзер безнең илдә бер тракторга уртача бер бөтен уннан бер тракторчы туры килә. Сменалап һәм атнасына ике көн ял итеп эшли башлар өчен бер тракторга кимендә ике бөтен уннан ике тракторчы кирәк булачак. Димәк, механизаторлар санын бермә-бер арттыру таләп ителә. Шунсыз бу хакта сүз алып бару нәтиҗә бирмәячәк. Шулай да мин үзем, мәсәлән, киләсе ел башыннан механизаторларны шәһәрдәгечә эшләүгә күчереп карарга ниятләп торам әле. Чөнки безнең «Уңыш»та бу яктан эш жиңелрәк тора: бүгенге көндә бер тракторга бер бөтен уннан сигез кеше туры килә бездә. Механизаторлар училищесында уналты кешебез укып ята. Язгы чәчүгә алар да укуларын тәмамлап чыгачак. Алар да килеп кушылгач, бер тракторга ике кешедән артып китәчәк. Шулар янына комбайнчыларны ярдәмгә жибәреп була бит әле. Дөрес, бездә бүтән колхозларга караганда механизаторлар мәсьәләсе жайлырак: механизаторлар училищесы безнең үз авылыбызда. Училище хакында сүз чыккан икән, аның тарихына да кыскача гына кагылып үтми булмый инде. Чөнки ул тарих минем үземә килеп бәйләнгән.

Бервакыт райкомда председательләр киңәшмәсендә Гали Даутович әйтә:

— Районда механизаторлар училищесы оештырырга рөхсәт бар, иптәшләр. Кайсыгыз шуны үз территориясендә оештыруны тели? — ди. Беркем бер сүз дәшми моңа. Теләмәүдән түгел. Үз колхозында тракторчылар, комбайнчылар укыта торган училище булуга кем каршы килсен инде? Тик ул училищены ялан кырда ачып булмый лабаса.

Бина кирәк аңа, җир кирәк. Курсантларга хезмәт күрсәтә торган кешеләр кирәк. Менә шулары өркетә председательләрне. Хуш. Көтеп тора безнең Гали Даутович.

— Я, кайсыгыз тәвәккәлли? Ул кеше отачак кына. Киләчәктә авыл җирендә механизаторлар иң кадерле, иң кирәкле һөнәр ияләре булачак, — дип тә әйтеп карады.

Юк, дәшми председательләр. Минем исемне атамаса ярар иде дип шүрләп, башларын аска иеп, бер-берсенең җилкәсе артына шыгаешып, тын да алмыйча утыралар. Шунда мин тордым да әйттем:

— Мин риза, Гали Даутович.

Ни өчен алай эшләдем? Чөнки уйлап алдым: училище оештырырга рөхсәт бар икән, димәк, дәүләт аңа тиешле средствосын да бирәчәк. Аннары килеп, безнең Ыргада бина да табарга була. Ике катлы зур гына мәчетебез бар. Барыбер буш, тәрәзәләре кадакланган килеш тора. Егерменче елда манарасын кискәч, авыл халкыннан беркем эченә аяк атлап кермәгән. Керергә җыенмыйлар да. Чөнки изге дип саныйлар мәчетне. Яңа бина салгалаганчы, училище «шәкертләрен» шунда укыта торырга булыр...

Гали Даутович миңа шундый җылы, шундый йомшак итеп карап куйды да әйтә:

— Молодец, Вәлиев, тәвәккәллегең өчен! Риза булып бик шәп иттең, молодец! — ди. — Менә мин әйткән иде диярсең, киләчәктә сөенеп бетә алмассың әле шушы тәвәккәллегең өчен, — ди

Бик акыллы, иртәгәге көнне күреп эш итә торган кеше иде ул безнең Гали Даутович. Бу юлы да сүзләре дөрескә чыкты.

Әнә шулай итеп оештырылган иде безнең ул училище. Дөрес, мин башта уйлаганча, бөтенесе дә ипле генә, шома гына бармады баруын. Мәсәлән, авыл картлары мәчетне училище итеп файдаланып торырга категорически каршы чыктылар. Аның каравы, аларның шулай үҗәтләнүе икенче яктан файдага булды. Тегеләр мәчетне биреп торырга каршы килгәч, мәсьәләне мин үзем дә бик текә китереп куйдым:

— Алайса, — мин әйтәм, — бер ай эчендә училищега яңа бина салып бирәсез!

Ил төкерсә, күл була дигәннәре дөрес икән. Ырга белән Пәрәүнең балта-пычкы тота белә торган ир-атлары ябырылып, егерме җиде көндә училищега яңа бина төзеп бирделәр. Шул эш өчен мин колхоз исеменнән училище белән договор төзеп куйган идем. Училищедан акчаны колхоз кассасына күчерттердем, ә балта осталарыбызга хезмәт көне генә түләдем дә төзелеш барган көннәрдә колхоз исәбеннән бушлай ашау оештырдым аларга. Төзелеш өчен кергән теге акча бик тә ярап



куйды: колхозга бер комбайн белән бер чылбырлы трактор сатып алдык. Артып та калды әле бераз. Менә шулай булган иде ул училищеның оештырылу тарихы.

Ярый, инде бүгенге көнгә кайтып, бүленеп калган сүзне дәвам итик. Читкә барып, семьядан аерылып йөрисе булмагач, безнең авыл яшьләрен училищеда укыту әллә ни кыен түгел, шунлыктан бездә механизаторларга кытлык булганы юк.

Әмма һәр колхозда училище була алмый бит инде. Шуңа күрә район колхозларының күпчелеге бер тракторга бер механизатордан арттыра алганнары юк. Бер безнең районда гына түгел, инде әйткәнемчә, бөтен ил күләмендә механизаторлар мәсьәләсе әнә шул тирәдәрәк тора икән. Ә бит укытуын кеше күп укытыла ул һөнәргә. Әле шушы араларда гына Юрий Черниченко дигән бер журналист-язучының

«Яровой клин» дигән китабын укып чыктым. Анда менә мондый мисал китерелгән: алтмыш алтынчы елдан алып җитмешенче елга кадәр, ягъни сигезенче бишьеллыкта, безнең илдә механизаторлыкка өч миллион алты йөз дә ун мең кеше укып чыккан. Җитмеш беренче елны язгы чәчүдә исә өч миллион биш йөз дә өч мең генә, ягъни укып чыкканнан йөз дә җиде меңгә ким кеше катнашкан. Ә бит шул өч миллион биш йөз дә өч мең исәбенә алданрак укып чыкканнары, инде унар-унбишәр ел эшләгәннәре дә кергән әле аның! Әнә ничек гаҗәп хәл килеп чыга: укытабыз-укытабыз кешеләрне, ә колхоз кырында эшләүче механизаторлар артмый гына түгел, киресенчә, кими бара икән. Ник кимегәне аңлашыла, әлбәттә. Укып чыгып, берәр җәй авылда эшләп йөриләр дә, шәһәргә, бүтән эшкә китеп бара алар... Уйландыра торган, хәл итүне сорый торган факт бу. Борчый торган факт. Ник дигәндә, алга таба авыл җирендә эшләү өчен механизаторлар тагын да күбрәк кирәк булачак. Галимнәрнең исәпләвенчә, безнең илдә кыр эшләрен тиешле вакытында һәм тиешенчә югары сыйфатлы итеп эшләп бару өчен, бүгенге көндә өч миллион ике йөз мең трактор, сигез йөз сиксән мең ашлык комбайны, ике миллион йөк машинасы кирәк. Әлегә алар кирәк булганнан шактый ким. Ләкин алар артачак. Кирәк кадәргә барыбер җиткереләчәк. Димәк, механизаторларны да арттырырга һәм бермә-бер диярлек арттырырга кирәк булачак. Колхоз председательләре һәм, гомумән, авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек итүче кешеләр алдында торган җитди мәсьәлә бу. Аның әле тора-бара тагын да катлаулана төшүе бик ихтимал. Нигә дисәгез, менә болай: әлегә безнең республикадагы бар халыкның утыз тугыз бөтен уннан җиде проценты авылда яши. Ә киләчәктә аның кимүе, егерме процент чамасы гына калуы көтелә. Димәк, кырык кеше арасыннан механизаторга укырга биш кеше табуга караганда егерме кеше арасыннан биш кеше табу, әлбәттә, җиңелрәк булмаячак...

... Әнә кайларга алып кереп китте мине колхозчыга акчалата түләүдән башланган сүз. Ул елны без теге ике йөз гектар җирнең һәр гектарына егерме сигез тонна тирес керттек. Аңарчы кукурузның гектарыннан алтмыш-җитмеш центнер яшел масса алсак, алдынгылар чутында күкрәк киереп йөри торган идек. Ул елны әлеге тиресләнгән җиргә чәчкән кукурузның гектарыннан ике йөз дә унҗиде центнер уңыш җыеп алдык.

Ә саламны колхозчыларга хезмәт көненә бүлеп бирдек. Кайбер хуҗалыкларга икешәр тонна салам тиде. Механизаторларның, ферма эшчеләренең вакытын салам ташуга әрәм итмәс өчен, аларга саламны өйләренә тракторлар белән кайтарттык. Шул көннәрдә булган бер мәзәк хәл һаман онытылмый әле.

Бер көнне иртән иртүк идарәгә барып керсәм, анда мине сарык караучы Маһисорур апа көтеп утыра. Болай да юаш, оялчан гына кеше иде, бу юлы гел дә аптырап калган. Хәтта каушавы йөзенә үк чыккан.

— Нихәл, Миһисорур апа, — мин әйтәм. — Ни йомыш белән йөрү болай иртүк?

— Йомышым шул, наным, — ди бу, — кичә мин эштә чакта кайсыларыдыр, юри кызык итептер инде, минем абзар артына бер чүмәлә салам китереп аударган. Берүк, наным, бу эш өчен мине бинават итә күрмәгез, жарыймы?! Шушы урынымда җир йотсын дип әйтәм, мин күргәндә эшләнгән эш тә, мин кушып эшләткән эш тә түгел.

Соңыннан ачыкланды: моңа тиешле унөч центнер саламны үзе өйдә юк чагында трактор белән китереп киткән булганнар да, бу шуңа аптырап калган икән.

— Бик шәп иткәннәр, Сорур апа. Бар кайт та әйбәтләп лапасыңа ташып куй син ул саламны! — дигәч елый-елый рәхмәтләр укып кайтып китте.

Теге ике йөз гектар җирнең йөз илле гектарына бодай чәчкән идек ул елны. Бодайның һәр гектарыннан 22,1 центнер уңыш җыеп алдык. Бу — безнең җирдә гомердә күрелгән нәрсә түгел, иң әйбәт килгән елларда да безнең кырларның бодайны 13—14 центнердан арттырганы юк иде.

Фәгыйть тырышлыгы нәтиҗәсендә килгән бу уңыш безнең халыкка берьюлы өч яктан гыйбрәтле булды.

Беренчедән, җирдән күбрәк алыйм дисәң, башта аның үзенә күбрәк бирергә кирәк икәненә колхозчылар үз күзләре белән күреп ышанды.

Икенчедән, безнең якларда яманаты чыккан кукуруздан да, рәтен белеп эш иткәндә, хәйран әйбәт уңыш алып булуы расланды.

Өченчедән, агрономның үзенә колхозчылар күңелендә ышаныч туды. Бу соңгысы, минемчә, аеруча мөһим. Әгәр җитәкче кешегә аның кул астында эшләүчеләр ныклап ышанмаса—бетте инде. Ул чакта син нинди генә акыллы сүзләр сөйләмә, нинди генә әйбәт планнар корып, нинди генә зур эшләргә тотынма—берни дә майтара алмыйсың. Чөнки җитәкчеләренә ышанмаган халык беркайчан да юньләп эшләми. Дөрес, каршы килми ул килүен. Кушкан җиргә бара. Тик кинәндерерлек итеп, янып эшләми... Әгәр инде сиңа ышанса — ике көн эшлисе эшен бер көндә эшләп чыга. Чөнки белә: аның хезмәте бушка китмәячәк. Аның хезмәте үзенә дә, кешеләргә дә файда китерәчәк. Адәм баласы акча өчен генә тырышмый бит. Ул, барыннан да элек, үз эшенең нәтиҗәсен күрергә, аны бүтәннәргә дә күрсәтергә, шулай итеп, күңеленә рухи канәгатьлек алырга тырышып эшли. Башкарган эше никадәр мөһимрәк, никадәр җаваплырак, никадәр читенрәк булса — аның ул эштән алган рухи канәгатьлеге дә шул кадәр зуррак. Ләкин, кабатлап әйтәм, җитәкчене кешеләр хөрмәт итсен өчен, иң элек алар аңа ышанырга тиеш. Әнә шул җәһәттән караганда, безнең Фәгыйть колхоз өчен дә, колхозчылар өчен дә, минем өчен дә бәһаләп бетерә алмаслык зур табыш булып чыкты.

Ул чакта торф компосты белән җир ашлау дигән нәрсә безнең якларда ныклап торып гамәлгә кермәгән иде әле. Югары уңыш алуның бөтен хикмәте күп басулы чәчү әйләнешендә дә язын кар суларын күбрәк тотып калуда дип кенә беләбез, чөнки шулай өйрәтәләр иде. Ә менә Фәгыйть дигән яшь агроном килде дә, гел үзенчә, гел яңача эш итә башлады. Әлеге «тирес операциясе»ннән соң «торф операциясе» планын төзеп кергән бу минем янга. Биш йөз гектар җирнең һәр гектарына иллешәр тонна исәбеннән торф кертмәкче. Ырга болынындагы торфлыкны тикшереп, анда күпме торф бар икәнлеген дә ачыклаган. Казанның фәнни институты лабораториясенә алып барып, ул торфның составын да тикшертеп кайткан.

— Составы отлично безнең торфның, Булат абый! — ди бу миңа. Үзе шул тикле куанган, бөтен йөзе балкып тора.— Күпме кертсәң дә җирне боза торган түгел. Ә запасы бөтен колхоз кырына биш сантиметр калынлыгында итеп тоташ җәеп чыгарга җитәрлек! — ди.

Карап торышка йолкыш кына кеше инде үзе. Ләкин фикерен шундый дәлилле итеп яклый белә, ул фикеренә сине шундый итеп ышандыра — син аңа берничек тә каршы килә алмыйсың. Ул көнне дә берсүзсез ризалаштым, мин Фәгыйтьнең бу тәкъдименә. Ә «торф операциясе»нең нәтиҗәсе менә болай булды: торфланган җирләребезнең һәр гектары бүтән җирләргә караганда бодайны — сигез дә алты, борчакны — ун да өч, солыны — җиде дә ике центнерга артыграк бирде.

Бу дөньяда күпме яшәп, җиргә безнең Фәгыйть шикелле мөкиббән киткән бүтән кешене күргән юк әле минем. Хәзер дә нәкъ безгә килгән яшь чагындагыча дәртләнеп эшләп йөри ул. Җитмеш икенче елдан бирле авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Диссертациясен шул үзебезнең колхозда алып барган тәҗрибәләре нигезендә яклады. Шәп

итеп яклады. Монографиясен шундук аерым китап итеп бастырып чыгардылар. Яклау белән Казан авыл хуҗалыгы институтында эшкә калырга да өндәгәннәр иде үзен. «Җирне күрмичә җир турында акыл өйрәтүчеләр анда миннән башка да житәрлек. Җир белгече җирдән аерылырга тиеш түгел!» — дип якын да килмәде. Аннары Авыл хуҗалыгы министрлыгына эшкә чакырып карадылар. «Җитәкчелек эшенә ходай биргән сәләт кирәк, ә миндә ул нәрсә юк», — дип, анысына да риза булмады. Бик дөрес итте дип уйлыйм. Ни калган аңа шәһәрдә? Шәһәр уңайлыклары дияр идең, монда аның ул яктан шәһәргә караганда да яхшырак: шыңгырдап торган нарат бүрәнәдән салынган сиксән квадрат метрлы өе бар. Газы, суы үзендә. Шәһәрдә эшләсә, күп дигәндә ике йөз житмеш сум оклад алыр иде. Ә монда без аңа өч йөз дә илле сум түләп киләбез. Миңа караганда житмеш сум артыграк ала. Шулай түләргә үзебез карар кылдык. Чөнки берьюлы ике өлкәдә, һәр икесендә зур эш алып бара: колхозның баш агрономы һәм фәнни-практик эш. Аның хезмәте — колхозга китергән файда — әйтеп бетергесез. Инде менә ун-унбиш ел буена безнең кырлар икмәкне күршеләрнекенә караганда биш-алты центнер артыграк биреп килүен әйтеп киткән идем. Әйткәндә генә ансат бит ул «биш-алты центнер» дип. Ә ныклап уйлап карасаң... Әйтик, колхоз ике мең гектар бөртекле ашлык чәчкән икән, күршеләрдән бишәр центнер гына артык алганда да ун мең центнер уңыш дигән сүз ләбаса ул!..

Фәгыйтне бездә җир профессоры дип йөртәләр. Бик дөрес әйтәләр. Кодрәтемнән килә торган булса, мин аңа профессор гына түгел, академик дигән исем бирер идем әле... Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә безнең җирләрнең уңыш бирә торган катламы ел саен ике-өч миллиметрга арта килә. Моннан ун-унбиш ел элек авылдан киткән кеше хәзер кайтып безнең җирләрне күрсә, таный да алмас иде. Бик нык үзгәрде безнең җирләр: каралды, йомшарды, матурланды... Менә ни өчен икмәкне күршеләрдән биш-алты центнер артык алабыз без.

Ә безнең Фәгыйт җирнең серләрен өйрәнүен, игеннәрнең сортларын яхшырту юлларын эзләүне һаман дәвам итә. Үзенә бирелгән ун гектарлы тәҗрибә участогында ул хәзер безнең шартларда җирдән тагын да күбрәк уңыш алу ысулын камилләштерү өстендә эшли. Аның берүзе хакында гына да зур бер китап язып булыр иде. Ул шуңа тулысынча лаек. Ләкин бу очракта минем максат ул түгел. Минем максат гадирәк. Бу язмаларымда мин тик үземнең баштан кичкән кайбер хәлләрне аңлатып бирергә генә теләгән идем. Ләкин председательнең эше шундый, син ул турыда сүз башладыңмы, бер үзең белән генә чикләнеп булмый икән. Менә хәзер дә үземнең ул чактагы хәлләрне аңлату өчен, сүзне янә шул Шәйхигә китереп тоташтырмыйча мөмкин түгел.

Тагын очрашырга туры килде миңа аның белән. Бөтенләй көтмәгәндә. Бу юлы да башлап ул миңа «сукты». Шундый итеп сукты, мин тынсыз-өнсез калдым. Дөрес, бөтенләй үк җиңелү түгел иде бу. Боксчылар теле белән әйтсәк, нокаут түгел, нокдаун гына иде. Ләкин моның шулай икәнлеген мин үзем генә беләм. Ә «судьялар» нокаут алды дип исәпләп, мине рингтан төшереп җибәргәннәр иде инде... Шулай да нык нокдаун булды ул, каһәр. Җиде айга якын интектем мин шуның зәхмәтеннән котыла алмыйча...

Һич онытасым юк, сентябрьнең тугызы иде. Рәшә тирбәлеп торган кояшлы, җылы көн. Әбиләр чуагының иң кызган чагы. Безнең «Уңыш»ның кырлары комбайннар, тракторлар гөрелтесеннән тынып калган. Җиңүле сугыштан соң була торган мәһабәт, тантаналы тынлыкны хәтерләтә иде ул. Салам үмтләре сафтан чыгарылган танклар, самоходкалар кебек торып калган... Ә сугыш кырында бер генә тере җан нясе дә күренми: әйтерсең безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам

итеп, алга киткән... Моторларының тавышы ишетелмәсә дә, еракта, күрше колхоз кырларында әле анда, әле монда артларыннан соргылт тузан болытлары калдырып баручы самоходкалар, комбайннар, автомашиналар, тракторлар шактый ачык шәйләнә — һөҗүм, чыннан да, дәвам итә.

Ләкин бу һөҗүм кан койгыч һөҗүм түгел.

Җир йөзендәге бар нәрсәдән кадерлерәк булган икмәк өчен бара торган һөҗүм бу.

Кешелеккә үлем түгел, тереклек алып килә торган һөҗүм...

Ә безнең колхозның «солдатлар»ы — механизаторлар бүген ялда. Алар үз алларына куелган бурычны тулысы белән үтәде: кичә колхоз урып-җыюны тәмамлады. Шул зур җиңү хөрмәтенә бүген аларга урманда, үз колхозыбыз көче белән ясалган Түгәрәк күл буенда бәйрәм табыны әзерләнә. Икмәк үстерүдә катнашкан кешеләр барысы да шунда җыйналачак. Ике йөздән артык кеше. Шуларның туксан өч проценты — ир-ат. Нәкъ фронттагы кебек. Ә бит бар иде заманнар, киресенчә, хатын-кызлар туксан өч процент була торган иде кыр эшләрендә. Игеннәрне чәчү дә, урып-җыю да алар җилкәсенә төшә иде. Хәзер без егермеләп комбайн, утызлап трактор, егермегә якын автомашина белән эшкәртә торган җирләрне алар кул белән чәчеп, урак белән җыялар иде. Әмма мин аларның эштән зарланганнарын хәтерләмим. Дөресен генә әйткәндә, сугыш елларында фронттамы, әллә менә шушы кырларда икмәк үстергән хатын-кызларыбызга кыенрак булгандырмы — анысын мин үзем кенә әйтергә дә кыенсынам. Әмма шунысын кистереп әйтә алам: бүтән мең төрле хатын-кыз мәшәкатьләреннән тыш, фронтны икмәк һәм корал белән дә ул елларда нигездә шул ук хатын-кызларыбыз тәэмин итте.

Әтиләре сугыштан кайтмаган балаларны шулай ук алар тәрбияләп үстерде. Сугыш алды елларында туган һәм әниләренең сыңар канаты астында үскән ул балалар — бүген тормышны төпкә җигелеп алып баручылар. Барыбыз да күреп торабыз: әйбәт алып баралар, зарланырлык урын юк. Ә менә әти-әни тигезлеге белән үсә торган бүгенге яшь буын алар эстафетасын шушы безнең замандагыча югары темпта дәвам итә алырмы — монысы минем өчен бик үк ачык түгел. Һәр хәлдә, уйландыра мине бу мәсьәлә. Шуңа уйландыра, чөнки без балаларыбызны артык нык иркәлибез. Ә аларны эшкә чыныктырып тәрбияләү ягына тиешенчә әһәмият биреп җиткермибез шикелле. Бәлки мин ялгыша торганмындыр. Бәлки, үзең олыгайгач, яшьләр тормышын тиешенчә аңлап бетереп булмый торгандыр. Чөнки алар без яшь чакларда җырлаган җырларны җырламый. Без уйнаган уеннарны уйнамый. Уйлары, дөньяга карашлары — башка. Шуңа күрә алар безнең өчен сәеррәк, безгә караганда алар ничектер ваемсызрак, җавапсызрак, мин-минлекне яратучанрак, дорфарак шикелле тоела торгандыр. Кем белә, бәлки заман үзе алардан шуны таләп итә торгандыр. Ләкин, ничек кенә булмасын, мин үз фикеремдә калам: яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсендә без барыбер тиешенчә үк эш итә алмыйбыз, кайдадыр, нәрсәнедер күреп-белеп җиткермибез шикелле... Әле күптән түгел генә безнең авылның бер агае, алтынчыда укый торган малаен ияртеп, йөгән тотып конюшнига бара. «Кая барыш?» — мин әйтәм. «Ат алып кайтырга», — ди бу. «Ә нигә малаең гына алып кайтмый соң аны?» Беләсезме, ул ничек дип җавап бирде? «Яшь бит әле, атка йөгән кидерә алмас», — ди бу. Ә малае, инде әйткәнемчә, алтынчыда укый һәм буйга атасын куып җитеп килә. Аның әле иң кызыгы шунда, менә шушы Галиәхмәт, үзе инде дүртенчедә укыган чагында, җәйге каникул көннәрендә кырда бер ялгызы колхоз атларын көтеп йөргән кеше бит! «Шул чакларыңны искә алыр идең, ичмаса, Галиәхмәт!» — дим тегеңә, оялтмакчы булып. Ә ул әйтә миңа: «Ул чакта заманасы

шундый иде бит. Аннары ул чакта без, яшь булсак та, елгыр идек. Хәзерге балалар бәдәнгә шәп булса да, буынга сыеграк», — ди. «Бу сүзең хак, Галиәхмәт. Ләкин нык булсын өчен, ул буынны чыныктырырга кирәк ләбаса. Егет булып килә торган малаең кәнүшнидән ат алып кайтырга ярамагач, аның буыны кайчан ныгыр икән соң?». «Әй, — ди бу миңа. — Бер минеке генә түгел, бөтенебезнеке шундый бит хәзер. Заманасы шул ич инде аның...» — ди...

Менә ничек! Үзебезнең җитмәгән нәрсәләребезне күреп тә торабыз. Әмма «бүтәннеке шулай», «заманасы шулай» дип, үзебез шул кимчелекләребезгә юл куя киләбез...

## УНТУГЫЗЫНЧЫ ДӘФТӘР

Ә сугышка кадәр туган һәм сыңар канат-әниләре тәрбияләп үстергән, бүгенге тормышыбызда юл ярып баручы буын — уку белән бергә эшен дә эшләп үскән буын ул. Шуңа нык аның мускуллары. Димәк, әниләре аларны илгә-җиргә тугрылыклы итеп, эш сөяр итеп үстергән... Билләһи дип әйтәм, әгәр миннән генә тора торган булса, мин ул аналарның барысына да Ватан Сугышы Герое дигән исем бирер идем... Ә бүген алар ике йөз кеше арасында нибары ундүрт. Алары да механизаторларга аш пешереп, төрле ярдәмче эшләрдә эшләп йөргән кешеләр. Минемчә, бу шулай булырга тиеш тә. Иген үстерүне мин үзем ирләр эше дип саныйм. Хатын-кызларыбызга болай да эш җитәрлек безнең...

Әлеге уңыш бәйрәме буласы көнне бәйрәмдә катнашырга тиешле кешеләрнең исемлеген карап утырганда минем башка әнә шул уйлар килде. Ә шул бәйрәмне үткәрү өчен сайланган комиссиянең председателе мин исемлекне нигә шулай озаклап карап утыруның сәбәбен белми. Ул: «Бәйрәмгә килергә тиешле кешеләр барысы да җыйналган. Әзерлек чаралары күрелгән. Тик безне генә көтеп торалар», — дип, мине ашыктыра иде. Без аның белән идарәдән чыгып, машинага кереп утыруга, идарә янына «Волга» килеп туктады. Шундук танып алдым: районның авыл хуҗалыгы идарәсе машинасы иде бу. Ә машинада Шәйхи Шәрифуллин утыра иде.

Мине «Таң»да үз урынына калдырып киткәннән бирле бу якларда күренгәне юк иде. Әмма авыл халкы аркылы кайларда йөрүе, ниләр эшләве ишетелгәләп тора. Теге бездән киткәч, чыннан да, авыл хуҗалыгы институтына укырга кергән. Әйбәт кенә укып, агрономия факультетын тәмамлагач, зур гына бер совхозга директор итеп билгеләнгән. Анда өч ел эшләгәч, тагын укырга киткән. Бу юлы ике еллык партия мәктәбенә. Аны да гел яхшы билгеләренә генә тәмамлап чыккан. Шуннан соң ул райкомда бүлек мөдире булып эшләгән. Ә менә хәзер аны безнең районга авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы итеп билгеләгәннәр иде.

Башлык башлык инде. Теләмәсәң дә, син аның янына барырга тиеш. Кул бирешеп, ләкин кулларны кысышмыйча гына күрештек. Тикмәгә генә шактый еллар укып йөрмәгән икән: кыяфәте тагын да солидныйланып киткән. Өстендә — үзенә сылап кына тегелгән аксылсоры яңа костюм, әле генә яуган кар шикелле ап-ак күлмәк, салават күперенең бөтен төсләре дә булган нәфис галстук, башында — җәйге җиләс эшләпә, аякта — костюмына пар килеп тора торган җиңел җәйге туфли. Бер сүз белән генә әйткәндә, киемен карап аны авыл хуҗалыгы белән алыш-биреше бар кеше дип түгел, сәхнәгә чыгарга әзерләнгән артист дип уйларга мөмкин иде.

— Авылга сугылып китәргә булдым әле, — диде ул, сораулы кара-

шыма җавап итеп. — Күптәннән кайткан юк бит инде. Давай, күрсәт хуҗалыгыңны! Миннән соң ниләр тожырдың икән, карыйк.

— Бүген безнең механизаторларның бәйрәме иде. Халык инде җыелып беткән. Бәйрәмне башларга мине көтеп торалар икән. Әйдә, башта шунда барып, тантананы ачып җибәрик тә, хуҗалыкны аннары иркенләп карарбыз.

Шәйхи миңа ниндидер бер юләргә карагандай карап куйды:

— Бәйрәм? Нинди бәйрәм ул көпә-көндез?

— Урып-җыюны тәмамлау хөрмәтенә бәйрәм оештырырга ниятләгән идек бүген.

Шәйхинең гаҗәпләнүе тагын да артты.

— Нука-нука, что за бәйрәм ул синең? Әйдәле, карыйк!

Бәйрәм шунда үткәреләэ дип уйлады булса кирәк, ул урамның тегеге ягында гына булган культура йортына таба бара башлады. Әле узган ел гына төзеп бетергән идек без ул культура йортын. Ике катлы итеп. Үзебез махсус проект эшләттереп төзегән идек. Авылга ямь биреп, әллә кайдан күренеп, күңелне үзенә җәлеп итеп тора ул. Колхозга килгән кешеләрнең берсе дә аңа игътибар итмичә, аның хакында сораштырмыйча калмый. Һәркайсы ошатып китә. Шәйхинең дә культура йортын беренче күрүе. Безнең культура йорты Шәйхигә дә тәэсир итмичә калмагандыр. Ни генә әйтсәң дә, шушы авылда туып-үскән, шушында председатель булып эшләгән кеше бит. Ләкин ул бу хакта актан да, карадан да дәшмәде. Үзе төзетеп калдырган таныш бинага баргандай, туп-туры шунда таба китте...

Без Түгәрәк күлгә килеп җиткәндә, халык, сабан туе мәйданындагы шикелле зур түгәрәк ясап, табынга урнашкан. Аш пешерүчеләр ак халатларын киеп, аш өләшә башларга «команда» көтеп тора. Зур-зур казаннардан күңелне рәхәт кытыклап хуш исле куе пар күтәрелә. Ә авылның атаклы шоферы Озын Тәхәү шеф-поварга әверелгән: башына ак кәпәч кигән, өстендә ак халат. Кулына үзенең ярты метрлы фирменный сугым пычагын тоткан да, янында торган пешекчеләрне нидер сөйләп көлдерә-көлдерә, шушы бәйрәмгә дип махсус симертеп суелган елкы итен турау белән мәшгуль иде.

Мине, гадәттәгечә үз итеп, шаулашып каршы алмакчылар иде дә, минем газикка ияреп чит «Волга» да килеп туктагач, тынып-тыйлыгып калдылар. Тик ул машинаның хуҗасы шулай ук үзләренә таныш кеше икәнен белгәч кенә хисләренә ирек биреп:

— Ай-яй, прсидәтел, озак көттерәсең!

— Ну, зарыктырдың да соң, парин!

— Болай булырыңны белгән булсак, өйдә әзрәк авыз чылатып килгән булырыек! — диешеп, дуызгы килә башладылар.

— Һо-о, безнең Шәйхулла да әйләнеп кайткан икән!

— Кара син аны, танырлык та түгел, чистый министр булган!

— Әйдә, әйдә, бәхетле авыз икәнсең, нәкъ дуенына туры килдең! — дип, кунакны да үз итеп табынга кыстарга керештеләр.

Әмма Шәйхи аларга гел дә игътибар бирмичә, тик миңа гына мөрәҗәгать итеп:

— Карале, бу синең нинди комедия монда? — диде.

Үз чиратымда, мин дә аның соравын ишетмәмешкә салыштым: аңа җавап бирә башласаң, халык алдында тарткалашып китүебез мөмкин иде.

— Хәзер, Шәйхулла Шәрифуллович, хәзер барысы да аңлашылыр,— дип сөйләнгәләп табын янына килдем. Партком секретаре мәҗлесне ачып, мәҗлестәгеләрне партком һәм колхоз идарәсе исеменнән урып-җыюны уңышлы тәмамлау белән тәбрик итте. Аннары, бәлки сез дә берничә сүз әйтерсез, дип Шәйхигә дә сүз бирмәкче иде, ләкин тегс кулын гына селтәде дә миңа:

— Давай, киттек! — диде.

Әмма миңа әле китәргә ярамый. Партком секретаре унбиш минутлык әйбәт кенә нотык әзерләгән, аны тыңламый китеп бару әдәпсезлекнең дә әдәпсезлеге булыр иде. Мин шул хакта әйткәч, Шәйхи ризасызлык белдереп борынын җыерды да:

— Минем сезнең нотыкларны тыңлап торырга вакыт юк! — дип, машинасына утырып китеп тә барды.

Бәлки миңа да аның белән китәргә, аны колхоз хәлләре белән яхшылап таныштырырга кирәк булгандыр. Ихтимал, аның вакыты, чыннан да, бик тыгыз, ихтимал, аның бүтән берәр җирдә бик мөһим, бик ашыгыч эше булгандыр. Шуңа бик ашыгып китеп баргандыр. Ләкин мин бармадым. Чөнки, бердән, ул шушы авылда үзе эшләп киткән таныш кеше, икенчедән, бик ашыгыч, бик мөһим эше бар икән, шушында да әйтә алган булыр иде, ашыгыч эше юктыр, үтеп барышлый сугылып китүе генә булгандыр, дип уйладым. Шуңа аның бәйрәмне ташлап китүенә әллә ни зур игътибар бирмәдем. Аннары килеп, алай артык шөбһәләнерлек эш тә юк: колхоз районда беренчеләрдән булып урып-җыюны төгәлләгән. Уңышыбыз — безнең яклар өчен моңарчы беркайчан да күрелмәгән әйбәт уңыш: бодайның гектарыннан уртача егерме дүрт тә ике, арыштан унтугыз да җиде, борчактан егерме бер дә тугыз центнер җыеп алынган. Икмәк планыбыз арттырып үтәлгән. Дәүләткә сөт, ит сату буенча шулай ук алдынгылар рәтендә барабыз. Шулай булгач, нигә миңа Шәйхи китте дип хафаланырга да, нигә дип әле мин, шундый зур уңыш үстергән, ул уңышны тулысынча җыйнап алган механизаторларыбызның бәйрәмен ташлап, Шәйхи артыннан китәргә тиеш ди! Аннары килеп, шушы бәйрәм тантанасында алдынгыларның да алдынгылары булган механизаторларга бүләкләр тапшырылырга тиеш, ә ул эш миңа йөкләтелгән иде. Ике кешегә телевизор, берсенә келәм, берсенә баян тапшырырга тиеш идем мин...

Ул көнне мин бәйрәмнең тантана өлешеннән соң башланган күңел ачу өлешендә дә калып, беренче тостлар әйтелеп, халык әйбәт кенә гөрләшә башлаганчы, Түгәрәк күл буенда булдым.

Ә икенче көнне иртән идарәгә килгәндә, минем өстәлемдә авыл хуҗалыгы идарәсенә чакырган телефонограмма ята иде. Аның бүген килер арасы юк, чөнки сәгать әле иртәнге биш кенә. Димәк, телефонограмма кичә кичтән тапшырылган. Һәм ул Шәйхи измасы белән җибәрелгән иде. «Күрәсең, берәр киңәшмә уткәрергә булганнардыр», — дип уйлаган идем мин. Әмма анда бернинди җыелыш юк. Мине Шәйхи кичәге илтифатсызлыгым өчен аңлатма бирергә чакырткан иде. Бик текә тотынды ул миңа:

— Мин сиңа, Вәлиев, шуны әйтеп куярга тиешмен: әгәр син, әлеке хәлләр өчен үч итеп, минем белән исәпләшми башласаң, без синең белән эшли алмабыз! — диде.

— Ачыграк итеп сөйләшеп булмыймы?

— Ә син аны үзең аңламыйсыңмы?

Аңлыйм, әлбәттә, бик яхшы аңлыйм мин аның тел төбе кая таба барганын. Ләкин кирелеккә китсә, миндә дә җитәрлек бит ул кирелек дигән нәрсә. Аннары килеп, мин инде председатель булып байтактан эшлим. Ә Шәйхинең башлык булып кайтканына ай да тулмаган. Шулай булгач, нигә дип мин аңа баштан ук ләббәйкә дип кенә торырга тиеш әле. Беренче аңлашу — бик күп нәрсәне хәл итә. Әгәр син шул беренче аңлашуда баш биреп читкә китәсең икән — ул чакта син инде беттең! Я гел теге кешенең мөрите булып, ул ни кушса, шуны эшләп, ул ни теләсә, шуңа риза булып йөриячәксең. Яки гел мәйданнан китеп барырга тиеш булачаксың. Ул чакта инде син, гәрчә потенциаль

көчең булса да, чын көрәшче түгел. Теләсәң дә була алмыйсың. Чөнки синең рухың сынган була...

Әнә шуңа күрә аяк терәп сөйләшергә булдым мин Шәйхи белән:

— Юк, — дидем мин аңа. — Мин бер нәрсә дә аңламыйм. Чөнки минем сезнең тарафтан дәгъва куярлык хилаф эш эшләгәнем юк. Әмма киләчәктә бер-беребезгә дәгъва белдерерлек хәлләр килеп чыгуы мөмкин. Мөмкин генә түгел, хәтта безнең эштә бу — котылгысыз. Чөнки безнең авыл хуҗалыгы эшендә четерекле мәсьәләләр адым саен чыгып тора. Әйдә, алдан ук шуны килешеп куйыйк, Шәйхулла: элек ике арабызда булган нәрсәләрнең бөтенесен дә онытыйк та үзара гаделлек белән эш итә башлыйк. Аяк чалмыйк бер-беребезгә. Без икебез дә җаваплы эштә эшләүче, йөзләгән халык белән җитәкчелек итә торган кешеләр. Дәүләт кешеләре без. Эшебезне дә әнә шул дәүләт күзлегеннән карап алып барырга тырышыйк. Әгәр минем кайдадыр, нәрсәнедер тиешенчә эшләмәвемне күрсәң икән, туп-туры үземә әйт. Ә минем сиңа беркайчан да хөсетлек эшләгәнем булмавын үзең беләсең.

Мин боларны чын күңелемнән, бернинди риясыз әйткән идем. Тик Шәйхи аларны аңламадымы, әллә аңларга теләмәдеме — кистереп кенә әйтә алмыйм. Әмма шунысы факт: ул миңа отыры катырак бәйләнергә тотынды:

— Карале, — диде ул кызарынып. — Син, әйдә, конкрет мәсьәлә турында сүз барганда демагогия белән шөгыльләнмә, ярыймы! Нигә дип син кичә мине бөтен авыл халкы алдында игнорировать итеп, минем белән китмичә калдың, ә?

— Туктале, Шәйхулла, алай бик текә алма әле син. Беренчедән, син бит миңа үзең белән барырга кирәк икәнен ачык кына итеп әйтмәдең. Шулай да мин гаепне үз өстемә алырга әзер. Чыннан да, миңа сине озатып кую кирәк булгандыр. Аның өчен чын күңелемнән гафу үтенәм. Икенчедән, мин җыелышның официаль өлешен ташлап китә алмадым. Чөнки мин анда ярышта җиңеп чыккан иптәшләргә бүләкләр тапшырырга тиеш идем әле. Ышан, сине санга сукмау турында гел башыма да китермәдем.

Шәйхи үзенекен сукалавын дәвам итте:

— Ярый, шулай булсын да ди. Ә менә урак өстендә көпә-көндез җыйналып эчү оештыруыңны ничек итеп аңларга һәм ничек итеп акларга кушасың? Бу бит беләсеңме нәрсә?.. — Нәрсә икәнен ул үзе дә анык кына белми иде булса кирәк, тотлыгып калды. Гасабиланып, миңа карап торды. Тик шуннан соң гына үз соравына үзе җавап бирде: — Бу бит корткычлык хәзерге вакытта!

— Мин монда бернинди дә корткычлык күрмим, — дидем мин. — Урып-җыюны тәмамлау хөрмәтенә шул эштә катнашкан кешеләрне ярты көн ял иттереп, күңел ачтырып алганбыз икән, моның файдадан башка һичнинди зыяны булмаячак. Ай буена рәтләп ял да, туйганчы йокы да күрмәделәр бит алар. Ә шул бер көн ялдан соң аларның янә рухланып эшли башлаячагына минем шигем юк.

— Нигә син гел үз колхозың турында да, үз колхозчыларың турында гына уйлыйсың, Вәлиев? Районда бит әле синең колхоздан башка да колхозлар җитәрлек. И ул колхозларда да нәкъ синең колхозыңдагы шикелле үк кешеләр эшли. Алар да нәкъ синең кешеләрең шикелле үк тырышалар. Ә синең кичә үз халкың алдында куштанланып, очсызлы авторитетка исәп тотып оештырган «сабан туең» аларга никадәр тискәре йогынты ясавын беләсеңме?

Күрәсезме кайларга борып җибәрде Шәйхи абзагыз?! Шуннан соң ничек итеп кешеләрчә сөйләшмәк кирәк ул адәм белән?

— Карале, Шәйхулла, зинһар дип әйтәм, юк нәрсәләр белән үзеңнең башыңны ватма, мине дә тинтерәтмә әле. Әгәр игеннәрне әйбәт кенә

үстереп, түкми-чәчми вакытында җыйнап ала алсак, урак беткән көнне уңыш бәйрәме үткәрәбез дип, идарә утырышында яздан ук карар чыгарып куеп, шул карар нигезендә эшләнгән эш ул безнең. Ә күршеләргә аның берниндн зыянлы йогынтысы булырга тиеш түгел. Киресенчә, аларга гыйбрәтле үрнәк булыр дип уйлыйм мин аны. Бездән күреп, алар да киләсе елда шундый бәйрәм үткәрү өчен тырышыбрак эшләрләр.

— Син һаман әле үз глупостеңне танымыйча, акланырга маташасыңмы? Бар, хәзер үк югал күз алдымнан! Без синең белән икенче урында сөйләшербез! — диде Шәйхи. Миннән алдан кабинетыннан үзе чыгып китте...

Ә бер-ике көннән «урак өстендә бәйрәм оештырып механизаторларны әчергән өчен» миңа райкомда аңлатма бирергә туры килде.

Бу хәл миңа тагын бер зур сабак булды: шуннан соң мин Шәйхинең миңа беркайчан да гадел була алмаячагына, җае чыккан саен тибеп китәргә тырышачагына тулысынча инандым. Шуңа күрә ничек тә аның белән низагка кермәскә, хәтта тегенең хаксызлыгы шар ярылып күренеп торган чакларда да мөмкин кадәр дәшми калырга тырыштым. Болай эшләү җиңел түгел иде миңа. Әмма бүтәнчә ярамый. Бүтәнчә эшләсәм, мин Шәйхигә «азык» бирәчәкмен дә, ул мине юлыннан алып ташлаттырачак. «Күрдеңме инде Шәйхинең кем икәнен, шулай була ул аңа карашы килсәң», дип күңеленнән тантана итәчәк иде. Шуңа ирешер өчен ул кулыннан килгәннең барысын да эшли: бәләкәй генә мөмкинлек килеп чыкканда да, җыелышларда «Уңыш» председателе Вәлиев» дип, берәр төрле кимсетү сүзе кыстырып китә. Колхоз техникасына кагылышлы мәсьәләләр хәл ителгәндә гел безне кыерсытырга тырыша. Ә булган уңышларыбызны күрмәмешкә салыша. Моның шулай икәнлеген колхозчылар да сизә. «Нигә каныга ул сиңа? Синең нинди явызлыгың тигәне бар аңа?» — дип гаҗәпләнәләр. Айсылу, бичара, аеруча нык хәсрәтләнә. «Гел председатель булып эшләргә димәгән, дөньяда бүтән эшләр дә бетәсе түгел. Әллә ташлыйсыңмы шушы эшеңне дә котыласыңмы шул кансыздан?» — дип елаплар җибәргән чаклары була иде.

Инде әйткәнемчә, ул елны районда иң югары уңыш алган колхозларның берсе — безнең колхоз булды. Безнеке генә түгел, бездән кимрәк уңыш алган колхоз председательләре орден, медальләр белән бүләкләнде.

## ЕГЕРМЕНЧЕ ДӘФТӘР

Төрле премияләр бирелде. Мин үземә андый нәрсәләр булыр дип көтмәдем дә. Ләкин колхозчылар да бәр бит әле. Медальгә генә түгел, орденга лаеклы колхозчылар да бар иде безнең. Тик аларның берсенә дә бүләк булмады.

Монысы инде Шәйхинең минем авторитетка читләтеп суктыруы, мәкер белән эш йөртә башлавы иде. Монысы минем өчен аеруча хәтәр нәрсә. Чөнки кеше синең үзеңә генә дошман булса, синең үзең белән генә тартышса — ул чакта әллә ни куркыныч түгел. Чөнки син аның кайда нинди явызлык эшләргә тиешлеген сизенәсең, сакланырга мөмкинлек була. Ә инде ул сиңа үчлек белән синең якыннарыңа, син җитәкли торган коллектив кешеләренә дә начарлык эшли башласа — хәлләр яман. Чөнки син аның кай яктан китереп суктырырын чамалый алмыйсың. Иң әшәкесе шул: ул сиңа карата син җитәкләгән коллективта да ризасызлык, ачу уята...

Тege елны безнең колхозчыларны бүләксез калдыру — Шәйхинең нәкъ әнә шуңа исәп итеп эшләгән эше иде. Ләкин бу очракта мин аның

белән тартыша алмыйм, чөнки аның кулында власть дигән авыр чукмары бар. Шул чукмары белән ул миңа теләсә кайчан китереп орырга мөмкин иде... Шулай да бер көнне кабинетына кереп:

— Нигә шулай ямьсез эшләдең, Шәйхулла, синең мине куралмавыңа бүтән беркемнең дә катнашы юк лабаса, нигә кимсеттең безнең колхоз алдынгыларын? — дип сорашып карадым каравын. Исе дә китмәде.

— Нәрсә син миңа бәйләнеп йөрисең? Буләкләнүчеләр исемлеге югары оешмаларда расланганын белергә тиеш инде. Күптән балигъ булган кеше! — дип тиргәп тә чыгарды әле үземне.

Шулай бер ел үтте. Тагын көз килде. Тагын игеннәрне районда беренчеләрдән булып урып-җыйдык. Бөртекле культураларның барлык төрләре буенча да уңыш узган елдагыга караганда да шәбрәк булды. Димәк, иң тырыш колхозчыларны бүләккә тәкъдим итәргә мөмкин булачак. Мин шулай уйлап, шуңа ышанып йөрим. Ишетәм, бүтән колхозлардан исемлекләр сорап алгалый башлаганнар. Ә безгә ын да, тын да бирүче юк бу хакта. Тоттым да бер көнне өченче секретарьга шалтыратып сораштым. Шулай-шулай дип ишетәм, дим, чыннан да шулаймы, әллә имеш-мимеш сүз генәме, дим. Чыннан да шулай, ди бу. Авыл хуҗалыгы идарәсенә бу хакта инде унбиш-егерме көн элек үк әйтелгән иде бит. Сезгә һаман хәбәр итмәделәрмени әле, ди.

Менә шуннан минем бөтен тормозлар ычкынды инде. Алайса, телефоннан гына булмый, алайса, мин үзем сезнең янга барам хәзер, дидем дә районга үзем киттем. Хәзер миңа диңгез тубыктан, хәзер мин беркемнән дә курыкмыйм. Картлар әйтмешли, муены булса, камыты табылыр, председательлектән китсәм китәм, әмма Шәйхине дә бер дер селкеттереп китәм. Башкача булмый. Була алмый башкача. Мин дә адәм баласы. Минем дә нервым бар. Шушылай итеп үземне, үземнән дә бигрәк менә дигән колхозчыларны кимсеттереп йөргәнче, ичмаса, Шәйхинең кем икәнен фаш итеп, җанымны тынычландырып китәм, дип бик каты гайрәтләнеп, Гали Даутовичның үзе белән сөйләшмәк булып барган идем. Әмма анда барып кергәч, гайрәт бик тиз сүнде. Ни өчен дигәндә, Гали Даутович урынында юк, колхозларга киткән иде. Шуңа өченче секретарьга гына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Ә ул, мин кызып-кызып зарымны сөйли башлагач, иң элек:

— Сез, иптәш Вәлиев, кыз-катын түгел бит, нигә шолай тырпылдыйсыз? Нигә пожар чыккандай кабаланасыз? — дип, тезгенемнән тартып куйды. Аннары: — Бөтен хәсрәтегез шушы гына идеме? — дип сорады.

— Ничек инде «шушы гынамы»? — дидем мин, аның шулай тыныч булуына шаккатып. — Моннан да зур тагын нинди гаделсезлек булуы мөмкин инде? Мин бит миңа ачу итеп бөтен колхоз алдынгыларын Шәйхи инде икенче мәртәбә кимсетү хакында сүз алып барам. Неужели шушылар аз инде сезнең өчен?

Секретарь сәер генә итеп, үзе өчен генә елмаеп куйды. Аннары әйтә бу миңа:

— Юк, сез сөйләгәннәрне аз дип атьмим мин. Сез дөрес итәсез. Ләкин шылай да монда караул кычкырырлык нәрсә юк. Дөньяда моннан катлаулырак эшләр дә бетәсе түгел, иптәш Вәлиев. Ярый, Шәрифуллин белән мин үзем сөйләшермен. Бер-ике көннән звонить итегез үземә. Мәсьәләне аныклап куярмын. По-моему, ул тоже не во всем прав. Атербез, аңлатырбыз. Ә сез, Вәлиев, тоже артык цәбәләнмәгез. Кытегыз да тыныч кына эшли бирегез.

Менә шул булды минем ул көнне дөньяны айкап ташлардай булып ашкынып йөрүнең нәтиҗәсе!

Бер караганда, секретарь да хаклы иде. Көн саен гына түгел, сәгать саен әллә нинди катлаулы мәсьәләләр чыгып тора бит аларга

да. Кайда нинди гаделсезлек булган, кайда кемне урынсызга кимсеткәннәр, барысы да, хаклык эзләп, райкомга килә. Минекеише зарларны күп ишеткәндер инде ул... Ләкин, ничек кенә булмасын, менә бу конкрет очракта мәсьәләне ул күңеленә якынрак алырга тиеш иде, минемчә. Ни өчен дигәндә, Шәрифуллинның гаделсезлеге системага әйләнеп баруын, ә моның җитәкче кеше өчен бик хәтәр нәрсә икәнен ул, идеология секретаре, аңларга тиеш иде бит инде...

Әмма мин ашыгыбрак үпкәләгәнмен икән секретаребызга. Ул әйткән көнне көтеп, аңа шалтыратып торуның кирәге дә булмады. Секретарь белән сөйләшкәннең икенче көнендә үк Шәйхи миңа үзе шалтыратып:

— Алдынгыларыгызның исемлеген нигә җибәрмисез, нигә сузасыз анда? — диде. Әллә кайдан сизеп торам, үз теләге белән шалтыратуы түгел, мәҗбүр булганга шалтыратуы иде бу. Шул ук вакытта ул хаклы булып калырга да тели, инде әллә кайчан әйтеп куйган кеше шикелле, «нигә сузасыз» дип, мине гаепле итеп калдырырга маташуы иде. Эшләр болайга киткәч, мин дә аның ни әйтүен аңламаганга сабыштым.

— Нинди исемлек ул? Нинди сузу турында сүз алып барасыз сез? — мин әйтәм.

— Ничек инде ул «нинди исемлек?». Бер алдынгы колхозчыгызны хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итү өчен документлар әзерләп китерергә дип әллә кайчан әйтелгән иде бит инде! Үзегез онытасыз да, аннары райкомга жалоба белән чабасыз.

— Ә кем хәбәр иткән иде соң безгә?

— Кем булсын, мин үзем!

— Язма рәвештәме, телефоннанмы?

— Анысы не важно!

— Юк, важно! Бик тә мөһим бу минем өчен.

— Нәрсә син, хатын-кыз шикелле һаман бер нәрсәне чәйнисең? Ну, телефоннан мин үзем шалтыратып әйттем, ди. Шуннан?

— Кемгә әйттегез? Кем белән сөйләштегез?

— Карале, мин сине үзеңнән сорашырга дип шалтыратам, ә син миннән сорау алырга җыенасыңмыни әле?

— Сорау алу түгел бу, ә мәсьәләне ачыкларга тырышу.

— Тагын бер тапкыр әйтәм: әйдә, телеңә салынма, ярыймы. Үткән — беткән. Миңа көненә йөзләрчә кеше белән сөйләшергә туры килә, аларның барысын да шайтан үзе дә хәтерли алмас иде. Син, әйдә, бүген үк бер алдынгы механизаторыңа тиешле документлар әзерләтеп җибәр.

Мин аның белән, нигә әле бер генә кеше, нигә ике яки өч кешегә документ әзерлисе түгел, безне бит инде ике ел рәттән читләтеп үтеп бардыгыз, дип тарткалашып карармын дип тора идем. Ләкин ул трубкасын куйды.

Әмма мин барыбер үземнекен иттем. Кайтып партком белән бергәләп идарә утырышы уздырып, ике кешегә документлар әзерләттек тә, аларны үз кулым белән Шәйхигә илтеп бирдем. Биргәндә әйтәсе сүзләремне әйтеп, әгәр безнең кандидатураларны исемлектән төшертеп калдырсагыз — эшне зурга җибәрәчәкмен, дип кисәтеп кайттым.

Әнә шул каты сөйләшүнең нәтиҗәсе булды булса кирәк, ул елны безнең механизаторларның икесенә дә бүләк — берсенә орден, берсенә медаль бирделәр.

Моңа мин үзем бүләкләнгәннән дә болайрак куандым. Чөнки бу бүләкләр гади бүләк кенә түгел, бәлки Шәйхи миңа каршы куйган киртәне җимереп, димәк, аны җиңеп, алынган бүләкләр иде.

Әмма бу аны бөтенләй үк җиңү дигән сүз түгел иде әле. Аны тәмам җиңеп чыгар өчен, миңа үзебезнең «Уңыш»ны районда гына түгел, бөтен республика колхозлары арасында беренчеләр рәтенә чыгарырга

кирәк иде. Шул чакта гына мин үз алдыма куйган бурычымны үтәлгән дип санаячакмын. Шул чакта гына йокысыз төннәремне, тынгысыз көннәремне заяга үтмәгән дип исәпләргә мөмкин булачак. Тик шул чакта гына мин хезмәт фронтындагы көрәштә дә Шәйхине тулысынча җиңеп чыктым дип әйтә алачак идем.

Ә моңа ирешү җиңел булмаячак, чөнки Шәйхи миннән югарырак урында утыра, миңа ул башлык. Миңа һәм безнең колхоз эшенә кагылышлы мәсьәләләргә теләсә кайчан катнаша ала иде. Шуңа күрә мин эшемне аерата сак, аерата төгәл, аерата гадел алып барырга тиеш идем.

Дөресен әйтергә кирәк, теге тартышта мин җиңеп чыккач, Шәйхи алай вакланып йөрмәде. Хәтта «берьюлы ике бүләк алуыгыз белән», дип, котлап кулымны да кыскан булган иде әле. Мин үзем дә, ниһаять, минем дә бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел икәнне үзе дә аңлады бугай, ниһаять, дөньяның кендеге гел аның үзенә генә килеп тоташмавы моның да башына барып җитте булса кирәк, ярый инде, соңлабрак булса да, аңлавы бик әйбәт дип куанган идем.

Шулай бер ел үтте. Ике ел үтте. Колхозның эшләре әйбәт кенә гел алга бара. Үзем дә заманадан һәм тормыштан артка калмаска тырышам. Яшем иллегә якынлашса да, читтән торып авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым. Унны утыз алты яшемдә кичке мәктәптә укып тәмамлаган идем дә, шуннан соң бик арып, укыган кадәресе дә җитеп торыр дип, берничә ел тукталып торган идем. Ләкин аннары күрәм: председательләр арасында минем шикелле урта белемлеләр бармак белән генә санарлык калып бара. Яшьләр килә мәйданга. Югары белем алган яшьләр. Сүзен дә чатнатып сөйли ала. Эшен дә бик белеп алып бара болар. Карап-карап тордым да, юк, мин әйтәм, болай булмый бу, Булат, дим үз-үземә. Болай булырга тиеш түгел, дим. Эшне алып бару ягыннан әлегә башкаларны алга бик чыгармыйсың. Анысы әйбәт, анысы өчен молодец! Ә менә уку ягыннан махы биреп барасың. Дөрес, теге югары белемлеләрнең байтагы читтән торып укыган кешеләр генә. Читтән торып укып кына син дә әллә ни зур белем ала алмассың. Ләкин, ни генә әйтсәң дә, уку уку булыр әле. Дипломга читтән торыпмы яисә стационарда укыды дипме аерып язып тормыйлар ди бит анда. Дипломың булса, ичмаса, башкалар арасында йөзең ак булыр. Аннары килеп, институт тәмамлаган Шәйхи дә бар иде бит әле дөньяда. Аңа бу яктан минем белән авыз чайкарга урын калдырмаска кирәк иде. Аннары читтән торып югары белем алган председательләр әйтеп тора: институтта уку мәктәптә укуга караганда читен түгел, киресенчә, җиңелрәк тә әле, диләр. Ә инде синең председатель икәнеңне белгәч, укытучылар сиңа үзләре сәлам бирә башлыйлар, тик сиңа да аларга карата игътибарлы булырга — сораган әйберләрен табып бирергә тырышырга кирәк, диләр. Ә алар алай синең хәлдән килмәслек нәрсә сорамыйлар, дачаларына тирес китертү, кирәк чагында ит, бал шикелле әйберләр җибәргәләп торуны гына сорыйлар ди. Аларын да бушка түгел, бәясен түләп алалар ди. Болары да минем өчен әллә ни зур яңалык түгел, чөнки колхозга килгән артистыдыр, журналистыдыр, врачыдыр — барысы да шулай соранырга ярата. Һәм аларны ачуланып та булмый. Кирәккә сорыйлар бит. Кирәк булмаса әйләнеп тә карамаслар иде. Кыскасы, ул яктан да алай куркырлык нәрсә юк иде. Һәм мин, тәвәккәлләп, укырга кергән идем.

Вакыт дигәнең, тишек капчыктагы борчак шикелле, бертуктаусыз ага да тора. Институтны тәмамлаганга да байтак гомер үтеп китте инде. Теге председательләр хаклы булган: институтта уку мәктәптә укудан кыен түгел икән. Һәр хәлдә, минем өчен бу шулай булды. Ни өчен дигәндә, анда укыганда, кичке мәктәптәге шикелле, атнага дүрт тапкыр дәрескә барып йөрисе түгел. Үз җаең белән үз өеңдә укыйсы.

Ә мәктәптә үземнең малай яшендәге егетләр-кызлар белән бер партада утырып укырга туры килгән иде миңа. Хәтта сигезенче-унынчы классларда без малай белән бергә укыдык. Тик ул мәктәпкә көндез йөри, мин кичен бара идем. Икебезне дә бер үк укытучылар укыта. Кайчакларда алар миңа: «Бу теманы улыгыз яхшы үзләштергән иде», — дип тә ычкындыргалыйлар иде. Ә бит шул ук укытучылар көндез минем күзгә карап кына торалар. Шулай булмыйча хәле юк. Чөнки һәркайсының үз хуҗалыгы, терлек-торышы бар, һәркайсының колхоз председателенә йомышы төшә: я машина, я ат, я салам-печәне, я тегесе, я монысы кирәк. Бер сүз белән генә әйткәндә, колхозсыз бер атна да яши алмый алар. Ә син мәктәптә әнә шулар карамагында, шуларга буйсынырга мәҗбүр: алар утыр ди икән — утырасың, бас ди икән — басасың. Тели икән, алар сине хәтта дәрестән куып чыгара да ала. Чөнки син алар каршында бу очракта — фәкать укучы гына... Ә институтта уку, шуның өстенә тагын читтән торып уку, ул якларыннан караганда гел дә җәннәт икән ул. Елына ике тапкыр институтка барып, лекцияләр тыңлап, зачетлар, имтиханнар биреп кайтасың да — син үз иркеңдә. «Иркеңдә» дигәч тә, укысаң ярый, укымасаң ярый, дигән сүз түгел, әлбәттә. Укырга, өйрәнергә кирәк программада күрсәтелгән материалларны. Укырга мәҗбүрсең. Укымасаң, ничек итеп имтихан бирмәк кирәк? Ләкин, кабатлап әйтәм, монда син үз вакытың белән, үз җаең белән укыйсың. Аннары институтта уку мәктәптә укуга караганда кызыграк та. Чөнки анда нәкъ сиңа эшең буенча кирәк булган фәннәрне укыталар, нәкъ сиңа эшең буенча кирәк булган нәрсәләрне өйрәтәләр.

Менә шуңа күрә дә бер дә авырыксынмыйча укыдым мин институтта.

### ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ ДӘФТӘР

Мин шулай алга таба атлаганда, Шәйхи дә тик кенә утырып тормаган, җитәкчелек итү өлкәсендә ул да үскән, ул да ныгый барган булса кирәк. Мин моны шуннан чыгып әйтәм, җитмеш беренче елның көзендә аны авыл хуҗалыгы идарәсеннән райкомның беренче секретаре итеп күчерделәр. Бу урында тагын төп мәсьәләдән бераз читкә китеп торып, кайбер нәрсәләрне ачыклап китмичә мөмкин түгел, чөнки шунсыз мин алда сөйләячәк хәлләр аңлашылмаячак.

Сизеп торам, укучы күңелендә инде хәзер үк, нигә шулай кинәт кенә күчереп куйдылар соң аны? дигән бик урынлы сорау тугандыр. Әйе, райком секретарьлары районның партконференциясендә сайланып куела. Әмма җанлы тормыш шул тикле катлаулы, анда шул тикле көтелмәгән хәлләр килеп чыга ки, аларны алдан билгеләп куйган кысаларга гына сыйдыру һич мөмкин булмый. Алыйк әлегә шул Шәйхи белән булган очракны. Аңа кадәр райкомның беренче секретаре булып Гали Даутович эшли иде бездә. Илледән узган булса да, яшьләрчә җитез. Эшнең рәтен, сүзнең кадерен белә. Вәгъдә иткәнен җиренә җиткермичә калмый. Булмастайны вәгъдә итми. Таләпчән, җитди кеше иде ул. Секретарьларның, шөкер, төрлесен күргән булды. Кайберләрен бары тик ул секретарь урынын биләп торганы өчен генә тыңлыйсың, тик шуның өчен генә аның белән исәпләшергә мәҗбүр буласың. Акыл — яшьтә түгел, башта, дип тикмәгә генә әйтмәгән борынгылар. Гали Даутовичны без, председательләр, нәкъ әнә шул чын мәгънәсендә эшлекле һәм чын мәгънәсендә кешелекле булганы өчен хөрмәт итә идек. Әлеге шул акыллы булуы, сабырлыгы, иң кыен чакларда да, югалып-каушап калмыйча, дөрес, гадел карар кабул итә алуы белән ул безнең барыбыз өчен дә үрнәк иде. Фән теле белән әйтсәк, чын-чынлап зур шәхес, көчле шәхес иде ул. Районны һәм кешеләрне үзенең биш бармагы ке-

бек белә иде. Райком секретаре нинди булырга тиеш дип сорасалар, мин, һич икеләнмичә, менә шушының шикелле булырга тиеш, дип иң элек Гали Даутовичны күрсәтер идем. Дөрес, безнең хәзерге беренче секретаребыз Азат Миңнуллович та алай яманларлык түгел. Ул да эшне конкрет эшләргә ярата. Бүтәннәрдән дә шуны ук таләп итә. Әмма, ничек кенә булмасын, минем өчен иң идеальный секретарь — Гали Даутович иде. Без, колхоз председательләре, аны секретарь урынын биләп торганы өчен түгел, бәлки акыллы һәм чын мәгънәсендә Кеше булганы өчен хөрмәт итә идек. Ул үзе дә безгә шулай хөрмәт белән карый торган иде.

Мине аеруча якын итә иде бугай ул. Җыелышларда, киңәшмәләрдә еш кына мактап телгә ала иде. Бервакыт шулай, гадәтенчә, мине әйбәт яктан телгә алып киткәч, бер колхоз председателе, күрәсең, көнләшеп, эче пошыптыр инде: «Бигрәк тә яратасыз инде шул Вәлиевне!» — дип реплика ташлады моңа. Гали Даутович, беләсезме, аңа ни дип җавап бирде? «Әйе, — диде ул, — мин «Уңыш» колхозын, аның председателе Вәлиевнең исемен бик еш телгә алам. Нигә болай соң бу? Шул хакта уйлаганыгыз бармы сезнең, иптәш Хәбибрахманов? Әгәр уйлаганыгыз булмаса, әйтәм: Вәлиевнең колхозы барлык күрсәткечләре белән дә гел алдынгылар рәтендә бара. Чөнки ул эшен күңел биреп, булсын дип эшли! Әгәр минем аны еш мактауга эчегез поша икән, әгәр үзегезне дә шулай мактатасыгыз килә икән, әйдәгез, рәхим итеп, барлык күрсәткечләре ягыннан да колхозыгызны «Уңыш» дәрәҗәсенә җиткерегез! Ул чакта мин Вәлиевне түгел, ә сезне рәхәтләнеп мактармын. Ә хәзергә, гафу итегез, аны мактарга, аны сезгә үрнәк итеп куярга туры килә! Ярату дигән нәрсә ике яклы ул: үзеңне яратсыннар дисең икән, син дә кул кушырып көтеп кенә утырма, яраттыра торган итеп эшли дә бел! Яраттырырга тырыша да бел! Кызганычка каршы, сездә әнә шул соңгысы — иң мөһиме һәм иң кирәклесе юк».

Кирәк булганда әнә шулай кистереп, бүтән чакта уйламыйча авыз ачмаслык итеп җавап бирә дә белә иде безнең Гали Даутович. Әмма берәүне дә урынсызга кимсетми. Хәтта эшеннән алынган кешеләр дә аңа үпкәли алмый. Чөнки ул ашык-пошык, уптым илаһи гына эш йөртми: гаепле кеше үзенең гаебен тулысынча танымыйча торып, мәсьәләгә нокта куймый. Ил, дәүләт күзлегеннән карап фикер йөртә. Аның белән сөйләшкән чакларда күңелләрең яктырып, дөньяда яшәүнең мәгънәсе тирәнәеп, әһәмияте артып китә торган иде...

Алтын бәһасенә тиң шул кеше бер дә истә-оста юк чакта кинәт кенә вафат булды да китте. Инде урып-җыю тәмамланган, кырда саламнар үмитләргә салынып куелган, уҗымнар яшел келәм булып бөркәлеп чыккан, тик бәрәңге аласы калган иде дә, тунга сөреп бетерәсе бар иде. Уңыш та начар түгел: бөртеклеләрдән район буенча гектарыннан унтугыз да ике центнер уңыш җыеп алынган. Безнең район җирләре өчен әйбәт иде бу. Шул уңай белән райком, район алдынгыларын җыеп, уңыш бәйрәме үткәрергә әзерләнә. Ул бәйрәм тантанасына өлкә комитеты секретаре белән авыл хуҗалыгы министры да килергә тиеш, үзләре вәгъдә биргәннәр иде. Андый зур житәкчеләр безнең якларга ялан саен килеп тормый, гомумән, андый иптәшләрнең килүе район өчен һәр вакыт зур вакыйга. Гали Даутович шуңа бик куанып-канатланып, нигаять, безне дә орышырга түгел, мактарга киләләр дип, кунакларны лаеклы каршылау хәстәре белән мәшгуль иде. Бер яктан, мул уңыш җыеп алу шатлыгы, икенче яктан, кадерле кунаклар катнашында үткәреләчәк тантана куанычы — шулар икесе бергә килеп кушылгач, түзмәгән Гали Даутовичның йөрәге: иртәгә уңыш бәйрәме дигән көнне инфаркт булып, тибүеннән туктаган иде...

Менә шундый аяныч хәлдән соң күтәргәннәр иде Шәйхи Шәрифуллинны райкомның беренче секретаре итеп. Райком тикле райкомның

беренче секретаре булу — зур дәрәҗә, әлбәттә. Әмма хикмәт дәрәҗәгә ирешүдә генә түгел. Хикмәт — ул дәрәҗәне саклый белүдә. Шәйхинең гадәт-холкын, мөмкинлекләрен электән белгәнгә, бу кадәр зур йөкне тартып бара алыр микән, сөрлегеп китмәс микән, дип шикләнеп куйган идем мин. Үткәннәрне янә исенә төшереп, тагын мина каныкмас микән дип тә хәвефләнгән идем. Күңел дөрес сизенгән икән. Баштан ук бик текә тотынды Шәйхи. Үзе секретарь булгач үткәргән беренче җыелышка бер колхоз председателе ике минутка соңга калып килгән иде, Шәйхи аны, трибуна янына чакырып китереп, башта бик каты орышты. Аннары:

— Бар, синең ише ваемсыз кеше белән минем сөйләшер сүзем юк! — дип куып кайтарып җибәрде.

Мине алай җыелышларда тиргәмәде тиргәвен. Әмма башка яктан шундый итеп китереп сукты, ул көннәрне искә төшергәндә хәзер дә тәннәр эсселе-суыклы булып китә әле.

Районыбыз зур уныш җыеп алган шул елны безнең колхоз тагын да күбрәк: бөртеклеләрнең гектарыннан уртача егерме тугыз центнер уныш алды. Моңа минем үземнән дә артык Гали Даутович куанган иде:

— Молодец син, Булат Вәлиевич! Барлык председательләр дә синеке хәтле уңыш үстергән булса, безнең район республикада гына түгел, бөтен Идел буе зонасында беренче урыннарның берсен алыр иде. Молодец! Быел обязательно Геройга тәкъдим итәбез сине. Син аңа тулысынча лаек! — дип йөри иде.

Хәтта инде кирәкле документларын да әзерләттереп куйган иде.

Яшереп торуны кирәк тапмыйм, аның бу ниятенә мин үзем дә каршы түгел, киресенчә, куанып, өметләнеп тора идем. Эшләгән эшең бар икән, синең ул эшеңне җитәкчең шулай зурлап тәкъдим итәргә җыена икән — нигә аңа каршы килергә? Инде ничә ел рәттән председатель камытын киеп, председатель арбасын тартып барулары җиңел дип уйлыйсызмы әллә? Гел шул колхоз эше артыннан йөреп, гел шул колхоз мәшәкате белән мәшәкатьләнеп узган бит ул еллар. Хәзер мин кайбер көннәрне идарәгә сәгать алтыларда-җиделәрдә генә киләм дә әллә ни югалтмыйм. Диңгездә йөзә торган корабны гел капитан гына түгел, капитан ярдәмчеләре дә алып бара лабаса. Колхозны мин тормыш диңгезендә йөзеп бара торган корабка тиңлим. Председатель — ул корабның капитаны. Капитанның ярдәмчеләре булган кебек, минем дә ярдәмчеләрем бар. Алар барысы да — партком секретаре да, баш агроном Фәгыйть Фәтхуллин да, баш зоотехник та, баш инженер да, баш бухгалтер да — булсын дип эшли торган кешеләр. Мин аларга үземә ышанган кебек ышанам. Чөнки алар, агроном Фәгыйттән башкалары, барысы да минем күз алдымда үскән, аннары колхоз исеменнән укырга җибәрелеп, колхоз стипендиясенә югары уку йортларында укып кайткан, яшь, энергияле белгечләр. Безнең «Уңыш» бүген дә гел алдынгылар рәтендә йөри икән, бу бер минем тырышлык җимеше генә түгел. Бу, барыннан да элек, әнә шул ярдәмчеләрнең һәркайсы үз урынында яхшы эшләү нәтиҗәсе. Безнең заман шундый заман, җитәкче кеше нинди генә акыллы булмасын, ничек кенә тырышмасын, әгәр ышанычлы ярдәмчеләре юк икән — аның эше алга китә алмаячак. Ә минем инде, әйткәнемчә, ул яктан, шөкер, борчылырлык урын юк...

Ләкин бу бит хәзер шулай. Ә теге елларда эш мактанырлык түгел: ярдәм итәрдәй белгечләр дә юк, колхозның экономик хәле дә бик чамалы иде. Шуңа күрә иртәнге сәгать дүрттән өйдән чыгып китеп, кичке тугыз-уннарга тикле колхоз эше артыннан гел үзеңә чабарга туры килә, анда да әллә ни майтарып булмый торган иде. Ә бит минем дә, нәкъ бүтән кешеләрнеке шикелле үк, семьям, бала-чагам,

йорт-җирем, мал-туарым бар. Балаларга тиешле тәрбия бирү — шулай ук минем өстәге бурыч. Бу мәсьәләдә минем өскә төшкән җаваплылык зуррак та әле. Председатель балаларына, председатель хатынына, гомумән, председательнең тормыш-көнкүрешенә авыл халкы аеруча таләпчән, аеруча игътибарлы. Әйтик, гади бер тракторчы малае берәрсенең бакчасыннан бер-ике кыярын яисә берничә алмасын чәлдереп чыкканда тотыла икән, бакча хуҗасы, житешә алса, теге малайның арт ягына берәрне сыптырып, житешә алмаса, бер-ике тозлы сүз әйтеп, йодрык селкеп калу белән чикләнә. Ә менә синең малаең шундый берәр төрле шуклыкка барган икән, ул чакта бу хәл бөтен авылга таралып өлгерә... Яки алыйк укуны. Гади бер колхозчы баласы өчле-дүртле билгеләренә генә укыса, хәтта икеләләр алгаласа да, моңа бер дә алай шаккатып карамыйлар. Ә инде председатель баласы икеле яки өчле алып кайтса — зур бер гайре табигый вакыйгага әйләнә. Бу хакта сүз атна буена сузыла. Әле ул шулай сүз килеш кенә дә калмый, ул әле, ахыр килеп, синең авторитетыңа да сугарга мөмкин. Озынга сузмыйча гына әйткәндә, четерекле колхоз председателенең хәлләре, ай-һай, четерекле.

Әмма, бәхеткә каршы, семья, бала-чагалар ягыннан мин үзем зарлана алмыйм. Минем Айсылу белән ничек танышканны, ничек кавышканны инде беләсез. Без Кемероводан кайтканда авыл мәктәбендә укытучылар штаты тулы, Айсылуга укытырга сәгатьләре юк иде. Үз һөнәре буенча эш килеп чыканны көтеп ятмыйча, фермада сыер сава торырга булды ул. Дөресрәге, мин аңа үзем шулай киңәш иттем. Ул елларда әле фермаларда бернинди дә техника-мазар юк, сыерларны кул белән савалар, сыер асларын сәнәк белән җыештыралар, печәнен күтәреп ташып ашаталар, суын чиләкләп ташып эчертәләр, шуңа күрә сыер савучылар бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр фермада эшләргә мәҗбүр иде. Ул чакта аларны сыер савучылар дип тә түгел, просто ферма эшчеләре дип кенә атыйлар. Фермада эшләргә берәү дә алай атлыгып тормый, кешеләрне җайлап-көйләп кенә эшләтергә туры килә иде. Айсылу да минем сүзне тыңлап кына, теләр-теләмәс кенә тотынган иде. Әмма тора-бара ул бу эш белән шул тикле мавыгып китте, мәктәптә урын бушап, укытырга мөмкинлек булгач та:

— Адәм балаларына белем генә түгел, эчәрләренә сөт тә кирәк,— дип фермадан китмәде. Шул калудан берөзлексез житмеш алтынчы елның сентябренә — пенсиягә чыкканчы эшләде. Шөкер, председатель хатыны эшләми, председатель хатыны фәлән дә төгән дип миңа бер кем бер сүз әйтә алмады. Ул яктан минем йөзем ак булды.

Әйткән идем микән, эшебез күп, эшебез авыр дип тормадык, өч бала да үстердек әле без. Ике малай, бер кыз. Малайларның, үзем шикелле, җиргә береген калуларын: авылда эшләүләрен һәм авылда яшәүләрен теләгән идем мин. Ләкин мин теләгәнчә булып чыкмады. Икесе дә минем гел башыма да килмәгән нәрсәләр белән мавыгып китеп, мин уйлап та карамаган һөнәрләрне сайладылар.

Наиле Казан медицина институтын тәмамлагач, Мәскәүгә барып, аспирантурага керде. Шунда укыганда ук кандидатлык диссертациясен яклап, өйләнгән генә иде, киленне дә, үзен дә Бирмага ике елга эшкә җибәрделәр. Аннан кайткач, үзебезнең Казан тирәләрендә төпләнерләрме әллә дип өметләнеп торган идем. Юк, булмады. Бирмадан кайтуларына ук өч бүлмәле менә дигән фатир биреп, икесен дә Мәскәүдә эшкә калдырдылар. Наилем хәзер медицина фәннәре докторы. Докторлык диссертациясен узган көз яклады. Бер генә атнага килен белән кунакка кайтып киткәннәр иде, шунда сорадым мин моннан:

— Булдымы инде күңелең, улым, туйдыңмы инде укудан? Академик булырга исәбең юктыр бит? — мин әйтәм. Беләсезме, ни дип җавап бирде ул малай миңа?

— Академик булу-булмау мәсьәләсен хәзер үзеп кенә әйтә алмыйм, әти, — ди. — Ләкин член-корреспондент булырга исәп юк түгел. Мин хәзер бик зур, бик җитди тикшеренү алып барам. Әгәр шуны әйбәт кенә башкарып чыксам, Академиянең член-корреспонденты итеп сайлаулары бик ихтимал, — ди. Яман шешкә каршы дәва эзләү белән мәшгуль ул. Күрәсең, эше өметле барадыр. Өметле бармаса, алай ышанычлы итеп сөйләшмәс иде. Минем Наил буш сүз сөйли торган егет түгел ул. Кече-кечкенәдән үз дигәнен итмичә туктамый торган иде.

Олы малай хакында сүз кузгалган икән, килен турында да әйтеп китми булмый инде. Мәскәүдә туып үскән анысы. Мишәр кызы — Алия исемле. Төскә-биткә алай күтәреп алып мактарлыгы булмаса да, бик уңган кыз булып чыкты. Мәскәү университетының чит ил телләре факультетын тәмамлаган. Инглиз, француз телләрен су урынына эчә. Анысы Патрис Лумумба исемендәге институтта инглиз теле укыта. Аның урынында бүтән бер хатын-кыз булса, ирем доктор булгач бик җиткән, миңа институтта гади бер, укытучы булып эшләп торсам да әйбәт инде, дип тыныч кына яшәр иде. Ә бу — юк. Бу үзе дә әлеге шул тел мәсьәләләре буенча кандидатлык диссертациясе якларга җыенып йөри.

— Инде яклаган да булыр идем, балабыз яшь булганга һәм Наил докторлык диссертациясе белән мәшгуль булганга гына тоткарланып торылды, — ди.

Икенче малаебыз Шамил, үзебездә урта мәктәпне алтын медальгә тәмамлагач, Ленинград университетына барып кергән иде. Анысын шунда аспирантурада калдырдылар. Анысы — физик. Эше космос белән бәйләнгән. Анысы да буш кеше булырга тиеш түгел. Аспирант кына булса да, хәйран зур-зур ике фәнни мәкаләсе чит ил журналларында да басылып чыккан инде. Берсен хәтта рәсеме белән үк бастырганнар. Белмим, кемгә охшап алай зиһенле булгандыр, үзлегеннән инглиз һәм немец телләрен дә өйрәнгән. Шул телләрнең һәр икесендә дә чатнатып сөйләшә дә, укый да, яза да ала. Үзенең фәнни эше белән шул тикле «җенләнгән», өч елга бер тапкыр авылга кунакка кайтып китәргә дә вакыт таба алмый. Бик сагынгач, быел март аенда үзебез аның янына Ленинградка барган идек, шунда үзенең фәнни җитәкчесе, аныңча итеп әйтсәк, шефы белән таныштырды безне. Шеф дигәне атаклы академик Константин Михайлович Харитонов икән. Танышу дигәнем шул: Константин Михайлович Айсылу белән мине үз өенә кунакка дәште. Яшерен-батырын түгел, Константин Михайловичларга барганда мин: «Андый зур кеше белән сөйләшер сүз таба алырбыз микән? Сөйләшсәк, нәрсә турында сөйләшербез икән? Бер-беребезне аңлый алмыйча утырмабыз микән?» — дип шүрләп барган идем. Юкка хәвефләнгәнмен икән. Константин Михайлович безне шундый ачык йөз белән, шундый ягымлы итеп каршылады, әйтерсең ул безнең инде күптәнге танышыбыз, әйтерсең без заманында аның белән бергә яшәгәнбез дә соңгы елларда бераз аерылышып кына торганбыз шикелле иде. Ә иң гаҗәбе менә кайда: ул агай авыл хуҗалыгына кагылышлы мәсьәләләрне шул тикле әйбәт белә, безнең сүзне читтән тыңлап торган кеше академик белән колхоз председателе сөйләшә дип түгел, бәлки колхоз председателе белән колхоз председателе сөйләшә дип уйларга мөмкин иде. Яше алтмыштан ашкан булса да, яшьләрчә җитез хәрәкәтле, үзендә һавалану дигән нәрсәнең эзе дә юк. Өстендәге киеме дә шул без кия торган шикелле гап-гади, йорт-җир җирбиясы да бер дә алай шаккатмалы тү-

гел. Тик кабинетындагы китапларның күплеге генә йорт хуҗасының, чыннан да, галим икәнлеген «әйтеп» тора. Ә башкалары барысы да бик гади, барысы да кешеләрнекечә. Хәтта сөйләшү рәвеше белән дә безнең як русларына тартым. Шуңа күрә миңа аеруча якын тоелды ул. Шул хакта мин аның үзенә әйткән идем, мыек астыннан гына көлеп куйды да:

## ЕГЕРМЕ ИКЕНЧЕ ДӘФТӘР

— Ә сез шактый сизгер кеше икәнсез, Булат Вәлиевич. Әйе, мин сезнең якташыгыз: Ильиновка авылында туып-үскән кеше. Элегрәк ел саен диярлек авылга кайтып килә торган идем. Ә менә соңгы алты-җиде елда, картаела булса кирәк, кайта алган юк әле, — диде.

Якташ икәнен дә белгәч, мин Константин Михайловичның академик булуын гел онытып, үземнең бертуган абыем белән сөйләшкәндәй, рәхәтләнеп сөйләшеп утырдым. Шунда, сүз арасында:

— Ничегрәк соң минем ул малай, кулыннан эш килердәй төсле ме? Укып-укып та буш куык булып чыкмасмы икән? — дип, Шамил турында да сораштым.

Константин Михайлович кулын минем иңгә салды да:

— Ул яктан тыныч бул, Булат Вәлиевич, менә дигән галим чыгачак синең Шамилеңнән. Раз мин аны үземнең шәкертем итеп алганмын икән, димәк, сәләтенә ышанып алганмын. Шамилгә өметем зур минем. Үземә алмашчы итеп әзерләмәк булам, — диде.

Академик тикле академик шулай зур ышаныч баглап тора икән, күрәсең, нәрсәдер бардыр инде ул малайның башында...

Ә төпчегебез Тәнзилә әле унынчыда гына укый. Унны бетерәм дә авылдан беркая да китмим, әнием шикелле сыер савучы булам, ди. Яшьлеге белән генә, модага ияреп кенә шулай йөрүедерме әллә, чыннан да, сүзендә торырмы — анысын әйтә алмыйм әлегә. Ни өчен дисәгез, мәктәптә укыган чакларында малайлар да шул фурмырак сөйләнә: олысы «синең шикелле, председатель булам» дип, кечесе «шоферлыкка укып чыгам да авылда шофер булып эшлим» дип йөргәннәр иде. Ә үзләре әнә кайларга китеп бардылар!

Шулай да мин аларга үпкәләмим. Турысын гына әйткәндә, күңелемнән хәтта горурланып та йөрим әле мин алар белән. Гап-гади бер татар авылында, гап-гади бер татар семьясында туып-үскән, гап-гади бер татар мәктәбен тәмамлаган малайлар бернинди протекциясез, тик үз көчләре, тик үз белемнәре белән шундый дәрәҗәгә ирешкәннәр икән, ул малайлар синең улларың икән — ничек горурланмыйсың? Бу урында мин үзем бик мөһим дип санаган бер мәсьәләгә кагылып китмичә булдыра алмыйм.

Бер безнең якларда гына түгел, гомумән, татар халкы арасында менә мондый фикер йөри: имеш, югары уку йортларына рус мәктәбен тәмамлаган татар балалары татар мәктәбен тәмамлаган татар балаларына караганда җиңелрәк үтәләр. Шуңа күрә күп кенә ата-аналар үз авылларында татар урта мәктәбе була торып, балаларын сигезенче класстан я район үзәгендәге рус мәктәбендә яки якын-тирә авыллардагы рус мәктәпләрендә укытырга тырышалар. Мин үзем русча укытуга да, чувашча укытуга да каршы түгел. Ләкин минем бер нәрсәгә иманым камил: баланың югары уку йортына керү-кермәве аның нинди телдә укуына гына бәйле түгел. Әгәр аның башында белеме бар икән, русча укыганмы ул, татарча укыганмы ул, марича укыганмы ул — барыбер рус балалары белән бергә үк укырга керә ала. Чөнки рус урта мәктәбендә дә, татар урта мәктәбендә дә, мари һәм удмурт урта мәктәбендә дә укыту программалары — бер төрле.

Ә югары уку йортларына укырга керү мәсьәләсе, кабатлап әйтәм, баланың нинди телдә урта мәктәп бетерүенә бәйләнмәгән. Мин моны шуңа шушылай бик ышанып әйтәм, чөнки кызыксынып, белешеп караганым бар. Рано мөдире Андрей Ефимович Читров белән күптәнге танышлар инде без. Безнең якларга килеп чыкса, ул минем өйгә кермичә китми. Районга барсам, вакыт булганда мин дә аңа сугылып чыгам. Шулай үзе бер тапкыр безгә килгәндә сорадым мин аннан:

— Районда ничә татар урта мәктәбе, ничә рус урта мәктәбе бар? — мин әйтәм.

— Русныкы тугыз, татарныкы җиде,— ди бу.

Шулай булуы бер дә гаҗәп түгел, чөнки безнең якларда рус авыллары элек-электән күбрәк булган. Хуш.

— Быел урта мәктәпне тәмамлап, югары уку йортларына кергән студентлар саны рус мәктәпләренә уртача ничәшәр кеше туры килә дә, татар мәктәпләренә ничәшәр кеше туры килә? — дим тегенә.

— Хәзер ачыклыйбыз аны, — диде дә, үзләренең кадрлар бүлегенә шалтыратып, мин сораган мәсьәләне ачыклап та бирде: ул елны татар мәктәпләрен тәмамлап югары уку йортларына кергән укучылар саны рус мәктәпләрен тәмамлап кергән укучыларга караганда биш процентка гына кимрәк иде... Алтмыш бишенче елларда, халык арасында йөргән сүзләргә карап, җидене бетергәч, малайларны мин дә рус мәктәбенә бирим микән әллә дип әүле-тәүле булып йөргән чакта сорашкан идем мин моны. Тик Андрей Ефимович җавабыннан соң гына үзебезнең татар мәктәбендә калдырган идем. Күрәсез, ялгышмаганмын. Башы эшләсә, мәктәптә биргән белемне тиешенчә үзләштереп барса, татар мәктәбендә укыган булса да, үзе теләгән вузга керә, үзе теләгән белгечлеккә өйрәнә ул бала. Әнә минем малайларны гына карагыз. Ә теге «рус мәктәбен тәмамлаган булсам, мин дә вузга кергән булыр идем, татарча укыганга гына конкурстан үтеп булмады», дип имтихан бирә алмыйча борылып кайткан балалар һәм «баланы русча укытмыйча ялгыш иттек, русча укыган булса, институтка кергән булыр иде», дип йөргән ата-аналар — үзләренең наданлыкларын аклар өчен генә шулай сөйләнә алар. Кайсы мәктәптән югары уку йортына күпме бала укырга кергәнен Андрей Ефимович хәзер дә ел саен исәпкә алдыртып килә һәм бу мәсьәләдә әллә ни үзгәреш юк: русча укыганнар да, татарча укыган балалар да нигездә шул бер чама үтәләр, ди.

— Хикмәт баланың нинди телдә укуында түгел, хикмәт ничек укуында, аны ничек укытуда, аңа өйдә нинди тәрбия бирүдә, — ди ул. Мин аның белән тулысынча килешәм...

Ярый, минем максат мәгариф мәсьәләләрен тикшерү түгел. Анысын үз белгечләре, социологлар карар. Мин тик үз күзәтүләрем нәтиҗәсендә туган фикерләрем белән уртаклашып китүне кирәк дип таптым да, семья башлыгы буларак та балаларым өчен йөзем кызарырлык түгел икәнлегеен искәртеп үтәргә генә теләдем. Минем төп сүз — мине Геройга тәкъдим итү мәсьәләсе хакында иде бит.

...Әйе, Гали Даутовичның миңа Герой исеме бирдертергә ниятләвенә һич тә каршы түгел идем мин. Ул елны безнең районга бер Герой бирделәр бирүен. Тик ул исем миңа бирелгән икән дип уйласагыз — бик нык ялгышасыз. Һәм иген уңышы ягыннан, һәм дәүләткә ит-сөт сату ягыннан безнең «Уңыш»тан шактый кайтыш булган икенче бер колхоз председателенә — Сафин Мостафага бирелде ул исем.

Ничек алай килеп чыкты соң бу? Геройга сине тәкъдим итәргә документлар да әзерләнгән иде бит инде? дигән сорау туарга мөмкин. Шуңа күрә алдан ук әйтеп куям: теләгәндә законны бозмыйча да законсызлык эшләп була икән, агай-эне! Бик ансат, бик гади генә эшләнә икән ул. Ничек итепме? Юллары бик күп төрледер инде аның.

Минем белән булган конкрет очракта, мәсәлән, менә болай иткән Шәйхи. Бер дә бер көнне бюро членнарын чираттан тыш утырышка җыеп ала да:

— Вәлиевтән башка безнең районнан тагын бер кешене Геройга тәкъдим итәргә кирәк. Әйдәгез, шул турыда сөйләшик. Кемдә нинди тәкъдимнәр бар? — ди.

— Мөмкинме? — дип, шундук район газетасы редакторы сүз ала.— Минемчә, «Очкын» колхозы председателе Сафин Мостафаны тәкъдим итәргә кирәк. Председатель булып алтынчы елын гына эшләсә дә, эшен әйбәт алып бара. Шуның өстенә үзе яшь, перспективалы иптәш,— ди.

Шуннан ары, ичмаса, күңел өчен генә булса да, тагын кемдә нинди фикерләр бар, дип сорап та тормый Шәйхи.

— Ярый, эшлекле тәкъдим. Минемчә, моңа башка иптәшләр дә каршы килмәс, — ди дә мәсьәләне тавышка куя.

Рас беренче секретарь шулай дип әйткән икән, кем аның белән бәхәсләшеп торсын ди инде. Барысы да, ризалык белдереп, кул күтәрәләр. Шулай да бюро членнарының берсе, әлеге шул роно мөдире Андрей Ефимович:

— Без тәкъдим итүен итәбез дә, тик бер районнан ике председательгә бирерләрме соң? — дип, шөбһәсен сиздереп карый каравын. Әмма Шәрифуллин аңа:

— Анысы өчен борчылмагыз, иптәш Читров. Мәсьәлә югары оешмалар белән дә килешенгән! — дип кырт кисеп җавап бирә.

Шуннан соң ниләр булганын тәфсилләп торуның кирәге бар микән?

Шактый авыр кичердем мин бу хәлне. Читтән карап торганда бу, ихтимал, сәер дә тоела торгандыр. Нигә шул тикле аһ орырга инде. Герой исеме бирелмичә калганга карап кына дөньяң җимерелмәгәндер бит диюләре мөмкин. Ләкин андый кешеләргә мин үзләрен минем шул чактагы хәлгә куеп, руслар әйтмешли, минем тире эченә кереп карарга киңәш итәр идем. Дөрес, Герой исеме бирелү болай карап торышка адәм баласына берни дә өстәми: акылын да арттырмый, эшен дә җиңеләйтми, материаль ярдәм дә китерми. Әмма шул ук адәм баласының, матди интересларыннан тыш, рухи интереслары, ягъни күңел дигән нәрсәсе дә бар бит әле! Бар гына түгел, шунысы мөһимрәк тә әле аның. Мин һәр вакыт эшемне кешеләргә охшасын дип, кешеләргә файдалы булсын дип эшләргә тырышам. Дөресен генә әйткәндә, шуның өчен яшим, тик шул чакта гына эшләгән эшемнән тәм алам мин. Әгәр син чын күңелеңнән тырышасың икән, хәтта ният иткән гамәлең бик үк уңышлы барып чыкмаган очракларда да, кешеләр сиңа үпкәләми. Киресенчә, андый чакта алар синең өчен борчылалар, сине юаталар, сине рухландыралар. Бу очракта мин авыл халкы турында сүз алып барам. Һәй, барометрдан да сизгеррәк ул авыл халкы! Синең күңелеңдә нәрсә ятканын, синең теге яки бу эшкә нинди ният белән тотынганыңны, синең теге яки бу кешегә нинди мөнәсәбәттә булуыңны, сиңа кемнең (бигрәк тә начальствоның) нинди мөнәсәбәттә булуын — барысын да белеп-күреп тора алар...

Теге елны миңа буласы Йолдызның Шәйхи аркасында эләкми калуын да белә иде алар. Беләләр һәм үземнән дә бигрәк, алар борчыла, алар кимсенә иде. Әлбәттә, мин үземне бик тыныч тотам, бер дә исем китмәгән булып кыланам, хәлемә керергә, юатырга теләп сүз әйткән кешеләрне ачуланган булам. Ләкин, ни эшләтәсең аны, күңел рәнҗи, гаделсезлек өстен чыкканга күңел өзгәләнә иде. Бигрәк тә әлеге шул миңа карата яхшы ниятгә булган колхозчылар алдында кыен иде миңа. Аннары килеп, мәсьәләнең менә бу ягы да бар иде әле: безнең барлык колхозчылар да миңе хөрмәт итә, барысы да ми-

на хәерхаһ кешеләр дисәм, үтә дә беркатлы кеше булыр идем. Ир белән хатыннан гыйбарәт булган ике кешелек семьяда да бер-берсенә үпкәләшеп йөргән вакытлары була диләр. Ә колхоз тикле колхозда кемнәр генә юк анда?

Бар шундыйлары, тезгеннәрен гел кулында тотып, тиешле якка тарткалап тормасаң, хәзер онытылып китеп, кайда үзенеке, кайда колхозныкы икәнен аерып тормыйча, күзләренә чалынган, кулларына эләккән бар нәрсәне, йомран шикелле, үз куышларына гына ташу ягын чамалыйлар.

Бар шундыйлары, колхоз милкенә кагылуын кагылмый, әмма тикшереп-күзәтеп кенә тормасаң, үзенә тапшырылган эшне аннан-моннан, эттем-төрттем генә эшлиләр дә күбрәк хезмәт хакы каерырга тырышалар...

Бар чамадан тыш куштаны, бар әләкчесе...

Андыйларны, билгеле, катырак кул белән, аерым бер кысага кертебрәк тотарга туры килә. Ә алар, әлбәттә, моны өнәми. Чөнки алар үзләренең хилафлык эшләвен танырга теләмиләр. Председатель безне яратмый, шуңа безгә каныга, шуңа гел безне генә күреп-тикшереп тора, дип уйлыйлар. Синең эшең әйбәт баруы аларны сөендерми. Киресенчә, алар синең ялгышлык җибәрүеңне көтеп йөриләр. Синең уңышсызлыкка юлыгуың алар өчен бәйрәм.

Әнә шундыйлар минем Йолдызсыз калуыма бик нык куанышкан иде. Җае туры килгән саен: «Менә күрдегезме инде! Булат та Булат дип авыз суларыгызны корытып йөри идегез, ә бит Геройны аңа бирмәделәр! Ник бирмәделәр? Патамушты эшен гадел алып бармый! Патамушты бөтен кешегә дә бертөрле итеп карамый: берсен яклый, берсен талкый. Һи, җаным, райкумда җүләрләр утырмый анда, кемнең кем икәнен бик әйбәт беләләр анда!» — дип, миңа хәерхаһ булган, минем өчен борчылып йөри торган колхозчылар күңеленә дә шикшөбһә сала иде алар. Әнә шунысы аеруча әрнетә иде йөрәкне. Хәтта шундый минутлар була, барысына да төкереп, семьяны, бала-чагаларны алып, авылдан чыгып олагасылар килеп китә. Син көнне-төнне белмичә тырышып эшлә-эшлә дә, синең хезмәтеңне зурлап, сине Геройга тәкъдим итсеннәр дә, шул чакта сине күралмый, синнән көнләшә торган берәү килеп чыгып бөтен эшеңне бутап бетерсен дә — шуңа түзеп торып кара әле син!..

Мостафа Сафинга документлар әзерләргә кушылгач та, Герой исеме аңа булачагын аңлаган идем инде мин. Ә Шәйхинең безгә ике кандидатура күрсәтергә кирәк, мәсьәлә югарыда килешенгән дип әйтүе — күз буяу, ялганга законлылык төсе бирергә тырышу гына иде. Мин моны шуңа бик яхшы белеп торам, чөнки таныш алым иде бу минем өчен.

Заманында Хәбиб Хәлилов дигән берәү эшләгән иде безнең районда. Культура бүлеге мөдире иде ул. Яшькә минем тиреләр чамасы, күпме ашаса да, тәненә ит кунмый торган чандыр гына, чәүчәләк кенә, үзеннән югарырак урындагылар кушканны башы белән таш ярып булса да үти, әмма үзеннән түбәнрәк утырганнар алдында үзе дә начальник булырга үлеп ярата торган иде. Сөзгәк сыерга мөгез бирмәс, дип бер дә юкка гына әйтмәгән шул безнең халык. Әлеге шул культура бүлегеннән югарырак урынга күтәрелергә күпме генә тырышса да, тәки булдыра алмады шул Хәлилов. Алай гына да түгел, торабара иплән кенә культура бүлегеннән дә шудырттылар үзен. Район газетасына әдәби хезмәткәр итеп куйганнар иде. Анда да эш майтара алмагач, газетаның корректоры итеп күчерделәр дә, әле хәзер дә шунда эшләп йөри. Ярый, бу очракта безгә аның хәзер кайда ни эшләве түгел, безгә аның культура мөдире чагында ничек эшләве мөһим. Ул елларда, ай-һай, гайрәтле иде ул! Телефоннан шалтыраткан

чакларында, исәнләшеп тә тормастан: «Хәлилов сөйли, кем әле бу?» — дип кенә җибәрә. Нәрсә турында гына сүз бармасын, «мәсьәлә райком белән килешенгән», «бу нәрсә райкомда хәл ителгән», «моны райком фикере дип аңларга кирәк» дип искәртеп куймыйча калмый иде ул.

Баштарак мин аның нигә алай дип әйтүе хакында уйлап та тормыйм, ул кушканнарның барысы да райком күрсәтмәсе нигезендә эшләнә торган эш дип кабул итә идем. Тора-бара сизәм: райкомга бөтенләй кагылышы булмаган нәрсәләрне дә райком яки райком секретаре исеменнән таләп итә башлады бу. Хәтта шуңа барып җитте, бер дә бер көнне шалтырата да әйтә бу миңа:

— Хәлилов сөйли. Кем әле анда, Вәлиевме? — ди.

— Ачуланмасагыз, әйе, мин идем, — мин әйтәм.

— Карале, — ди бу шуннан ары, — синең анда ашаганда теш арасына кысыла торган әйбер мәсьәләсе ничегрәк? Бик свежие генә ун кило кирәк иде,— ди. Ягъни ит сорый бу миннән. Итебез бар иде барын. Шул көнне иртән генә сыер суйдырган идек. Ун килодан дөнья харап булмас, бирергә дә булыр иде. Бушка алмый, дәүләт бәясеннән түләп ала ич ул аны. Ләкин бу юлы бер хикмәте бар иде мәсьәләнең: әле өченче көн генә бездән сигез кило ит алып киткән иде шушы Хәлилов. Шуңа аптырабрак калдым мин:

— Неужели көненә икешәр кило ит ашыйсыз сез, иптәш Хәлилов? — мин әйтәм гаҗәпләнеп. Гаҗәпләнми хәл юк, чөнки тең икәү — хатыны белән үзе генә тора болар. Бүтән бернинди туган-тумачалары юк. Булса шул бер мәчеләре бардыр инде. Шуннан, беләсезме, нәрсә ди бу миңа? Шуннан әйтә бу:

— Слушай, Вәлиев, — ди. — Әйдә, сүз озайтып тормыйк. Табыйк бер ун кило. Мәсьәлә райком белән килешенгән, — ди.

Кунаклар килеп төште дип, яки анда җәйгә казылык ясап куярга кирәк иде дип, кешеләрчә берәр сәбәп тапкан булып сораса, ачуың да килмәс иде. Ә бу... райком белән килешенгән, имеш!

— Кем белән килешенгән соң ул анда? — дим тегеңә. Секунд та уйлап тормады:

— Кем белән булсын, беренче секретарь белән, әлбәттә! — ди. Минем дә үҗәтлек кузгалды хәзер:

— Шулаймы? — мин әйтәм. — Каяле, алайса, мин аның үзеннән сорыйм әле шалтыратып!

Шулай дидем дә трубканы элеп тә куйдым. Куеп кына өлгергән идем, тагын шалтырата бу.

— Булат Вәлиевич, Булат Вәлиевич! Зинһар, райкомга шалтырата күрмәгез?! Мин болай гына, шаяртып кына әйткән идем, — ди. Шул тикле курыккан, бичара — тавышлары нечкәреп, мескенләнеп калган.

— Ярый, Хәлилов,— мин әйтәм.— Мин алай хөсетле кеше түгел. Бер юлга кичерәм. Ләкин, кара аны, тагын шулай һич кирәкмәгәндә райком исеменнән сөйләнә торган булсаң — яхшылыкка илтмәс!

## ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ ДӘФТӘР

Шуннан соң ул райком исеменнән ит сорамады. Әмма эш буенча сөйләшкән чакларында райком исеменнән сөйләү гадәтен тәки ташламады. Инде әйткәнемчә, хәзер ул газетада корректор. Газета корректурасын укыганда берәр җирдә берәр өтернең тиешле урында булмавын яки тиешле булып та куелмыйча калуын тотып алса, әле дә я газетаның җаваплы секретаре, я редакторы янына керә икән дә: «Менә бу өтерне алып ташлыйсы иде бит. Райком белән сөйләшенгән», — дип әйтә икән...

Мин ул Хәлилов турында шуңа шушылай шактый иркенләп сөйләдем, чөнки безнең Шәрифуллин, бик үк нигезле булмаган, әмма үзе кирәк дип тапкан фикерне үткәрәсе яисә үзе кирәк дип тапкан эшне эшләтәсе килгән чакларда: «Мәсьәлә югарыда хәл ителгән», «Моны югарыдан күрсәтмә дип аңларга кирәк», — дип әйтергә ярата иде.

Әгәр кодрәтемнән килә торган булса, андый кешеләрне житәкчелек эшенә якын да китермәс идем мин. «Үзеңне кимсеткәннәр синең, шуңа болай чәпчисең инде син», — дип әйтүегез мөмкин. Яшермим, анысы да юк түгел. Минем урында булсагыз, андыйларга үзегез дә рәхмәт әйтмәс идегез дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, әлеге шул Шәрифуллиннар, Хәлиловлар бер миңа гына түгел, бөтен җәмгыятебез өчен зыянлы кешеләр алар. Чөнки аларның үз инициативалары, үз фикерләре юк. Шуңа үзләре житәкләгән коллективта аларның абруйлары да булмый. Ә абруйсыз һәм инициативасыз исә безнең заманда ерак барып булмый. Ә барырга кирәк! Әнә шуңа күрә дә алар бик бәләкәй генә мәсьәләләрне хәл итәр өчен дә югары оешмалар һәм абруйлы житәкчеләр исеменнән эш йөртергә мәҗбүрләр. Шуның белән алар ул оешмаларның һәм ул житәкчеләрнең авторитетын төшерәләр. Мәсәлән, теге елны Герой исемен Сафинга биргәч, ни өчен миңа түгел, ә аңа бирүләрен бик яхшы белеп торсам да, ни әйтер икән дип, юри Шәйхинең үзеннән сораган идем мин.

Кызармады да теге. Чын күңеленнән минем өчен борчылган булып:

— Да, күңелсезрәк килеп чыкты шул. Ләкин ни эшлисең, обком белән бәхәсләшеп булмый бит. Анда шулай кирәк тапканнар, — дип тора. Күзгә карап алдаша. Үзебезнең партком секретаре Казанга барып, мине Геройга тәкъдим итәргә дигән документларның өлкә комитетына кермәвен, гомумән, анда минем хакта сүз бөтенләй булмавын ачыклап кайткан иде инде. Ә Шәйхи әнә нәрсә дип ялганлап маташа. Шуннан соң түзә алмадым:

— Мин синең мәкерле һәм көнче кеше икәнеңне белә идем, Шәйхи. Шулар өстенә син әле ялганчы һәм куркак та икәнсең! — дидем дә, тегенең үзенә барысын да әйттем дә бирдем.

Ачуыннан кара янып чыкты да әйтте бу миңа:

— Шулай-мы? Син әле минем ни эшләгәнне дә тикшереп йөрисеңме? Ярый! Вакытың алай бик күп булса, табармын мин сиңа эш!

Шул көннән безнең моңарчы да бик үк ныкъ булмаган «дипломатик» бәйләнешнең соңгы җепләре өзелде. Без инде сөйләшмибез генә түгел, хәтта маңгайга-маңгай очрашкан чакларда да бер-беребезне күрмәгәнгә салыша идек. Ул үзен ничек хис иткәндер — әйтә алмыйм. Әмма болай йөрү миңа ифрат кыен иде. Бер чишмәнең суын эчеп үскән, бер-беребезгә туган тиешле кешеләр лабаса без. Икебез дә җаваплы эшләрдә эшләүче житәкче кешеләр. Теләсәк-теләмәсәк тә, бер-беребезгә бәйле, үзара мөнәсәбәткә кермичә булдыра алмый торган кешеләр. Шул ук вакытта безнең арада аерма да бар. Ул миннән югарырак урында утыра. Миңа күрсәтмә бирә ала. Кушканын үтәмәсәм, җавапка тарттыра ала... Мин аңа бернинди начарлык эшләмәгән чакларда да ул миңа гомер буе аяк чалып килде. Ә хәзер тагын ныграк каныгачагы көн кебек ачык иде инде. Әнә бит, «мин сиңа эш табармын» дип, үзе үк янап куйды... Мин боларны бик сизеп торам, шуңа күрә ул бәйләнерлек сәбәп чыгармаска тырыша идем. Ләкин бәйләнергә теләгән кеше сәбәбен тапмый каламы соң? Шәйхи дә озак көттермәде.

Әлеге шул соңгы сөйләшүдән ары ике ай үтте микән, райкомга чакырттылар мине. Шәрифуллинның үзенә түгел, икенче секретарь Имам Хәсәновка. Бардым. Имам Хәсәнов бездә өченче елын гына эшли. Әмма авыл хуҗалыгы мәсьәләләрен бик шәп белә. Заманында

агрономия факультетын тәмамлаган кеше. Шул ук вакытта үзлегеннән дә күп укып, авыл хуҗалыгына кагылышы булган яңалыклар белән танышып бара. Кыскасы, ул нәкъ үзенә муафыйк урында утыра. Теләсә кайсы председатель белән аяк терәп сөйләшә ала торган компетентлы кеше иде. Кунакка ук йөрешмәсәк тә, үзара мөнәсәбәтләребез начар түгел. Һәрхәлдә, бер-беребезгә фикерләребезне ачыктан-ачык әйтә алыр дәрәҗәдә танышлар идек без. Бу юлы да якты йөз белән, кул биреп исәнләшеп каршылады ул мине. Ләкин, шул ук вакытта, бүген аның үз-үзен тотышында ничектер табигыйлек җитеп бетми, ниндидер үзгәреш тә сизелә иде. Бүтән вакытларда берәр эш белән дәштерә икән, кайбер начальниклар шикелле бер дә алай читләтеп-уратып тормый, турыдан-туры төп мәсьәләгә күчә торган иде. Бу юлы исә, гәрчә бөтенесен дә бик әйбәт белеп торса да, башта колхоз хәлләре, аннары семья, бала-чагалар турында сорашты. Бүтән чакларда тәмәкене сирәк-мирәк кенә тарта торган кеше бу юлы ун-унбиш минут эчендә берсен тартып бетереп, икенче сигарет алып кабызды бу. Ә үзе әйтәсе сүзен һаман әйтми әле. Түзмәдем, үзем ярдәм итәргә булдым:

— Әйдә, Имам Хәсәнович,— мин әйтәм.— Көттереп интектермәгез. Миңа күңелсез хәбәр әйтәсегезне күзегездән үк күреп торам. Барыбер бер әйтәсе бит инде аны, әйтегез!

— Алайса, менә болай...— диде дә мәсьәләне аңлатып бирде бу миңа.

Безнең районда механикалаштырылган куян фермасы оештырырга ниятләгәннәр икән дә, шул эшне безнең «Уңыш»ка йөкләргә булганнар икән.

Бер караганда, алай коточарлык хәбәр түгел иде бу. Оештыруга килгәндә, шөкер, тәҗрибә бар. Заманында тавык фермалары да, каз-үрдәк фермалары да һәм әлеге шул куян фермалары да тотып караган кешеләр без. Суыгыз бармы, тәрбияли алыр чамагыз бармы дип сорап тормыйлар, өстән йөкләмә китерәләр дә, теләсәк-теләмәсәк тә, шул йөкләмәне үтәргә тиеш була идек. Бездә су мәсьәләсе шактый четерекле, ике-өч чишмәдән башка, авыл тирәсендә һичнинди елга-күл булмаганга, үрдәк-каз үстереп котая алмадык. Тиешле шартлар тудыра алмау аркасында, куян фермасын да әллә ни үрчетеп булмады. Шулай да аларны бөтенләй ук бетермәгән идек әле. Йөз-йөз егерме башлап асрап килә идек. Сатар өчен түгел. Колхозның кунак өен ел буе эшләтеп торырга туры килә. Безнең заманда колхоз эшен алып бару өчен йөз төрле оешма, мең төрле белгеч белән хезмәттәшлек итәргә кирәк. Шуның өстенә, инде әйткәнемчә, еш кына артистлары, журналистлары, район начальствосы да килгәләп тора. Аларның барысын да кешечә итеп урнаштырырга, әйбәтләп ашатырга-эчертергә кирәк. Колхозга килеп тә свежий ит ашатып җибәрмәсән — нинди кунакчыллык була инде ул? Ә безнең сарык фермабыз юк. Көн дә саен сыер яки тана гына да суеп торып булмый. Дөрес, тулаем, алганда, елына житмеш биш-сиксән сыер суймыйча калган юк безнең. Уртача алганда, дүрт-биш көнгә бер сыер туры килә. Ләкин бу шулай тигезләп бүленеп, график белән эшләнми. Язгы чәчү көннәрендә, урып-җыю чорларында, мәсәлән, кимендә ике көнгә бер сыер суярга туры килсә, кышкы айларда аена ике белән калган чаклар була. Менә шундый чакларда килгән-киткән кунакларга куян ите дә бик ярап куя. Шуңа асрата идем мин теге йөз-йөз егерме баш куянны. Ләкин алар колхозга табыш китерми, мин куян фермасы ачарга һич тә җыенмый идем. Дөрес, тиешле шартларын тудырып, чын-чынлап тотынганда куян асрап та табыш алырга мөмкин икәнлеген белә идем мин белүен. Питрәч районының Кощак совхозына махсус барып, моның шулай булуын үз күзем белән күреп кайткан бар иде. Ләкин ул сов-

хоз — республикада куян асраудан табыш алуга ирешкән берданбер совхоз. Алар дәрәҗәсенә ирешү өчен өр-яңа таш биналар төзергә, дөнья кадәр акча тотарга кирәк иде. Ә безнең ул чакта андый мөмкинлек юк. Чөнки без алты йөз баш сыерга комплекс төзеп ятабыз, аның әле яртысы да эшләнеп бетмәгән иде. Шушындый хәлдә тагын куян комплексы төзергә дә алыну һич тә файдалы булмаячак иде.

— Кем башына килгән уй бу дип сорамыйм, чөнки моның Шәйхулла Шәрифуллович идеясе икәненә шигем юк,— дидем мин Имам Хәсәнович кә.— Әйтегез әле, минем урында булсагыз, сез ни дияр идегез хәзер? Неужели ул бер колхозда берьюлы ике зур комплекс төзү мөмкин булмавын белми инде?

Имам Хәсәнович минем хәлне аңлый иде булса кирәк, тавышын бер дә күтәрмичә генә:

— Анысын, әйдә, без тикшереп тормыйк инде. Ә мин синең урында булсам, мин бу очракта карышып азапланмас идем. Бер авылда туып-үскән кешеләр, беләсең бит аның холкын. Болай гына риза булмасаң, ул сине бюро карары белән мәҗбүр итәчәк, — диде.

Шушыннан соң сүз көрәштерүдән мәгънә чыкмаячагын белсәм дә:

— Чак кына булса да кешелеге булган кеше, минемчә, аңа ук барып җитмәс, — дидем дә авылга кайтып киттем.

Ә берничә көннән райком бюросының районда елына егерме биш тонна куян ите җитештерә торган механикалаштырылган куян фермасы төзәргә һәм аны «Уңыш»та төзергә дигән карары килде.

Әйтеп кенә кушылган эшне соңрак калдырып үтәп була. Яртысын гына үтәп калырга була. Кайбер очракларда хәтта вәгъдә биргән килеш кенә котылырга да мөмкин. Дөрес, андый чакта баштан сыйпамыйлар. Берәр киңәшмәдә я бик әйбәтләп, тир бәреп чыкканчы тиргиләр. Яки шелтә бирләрәләр. Болары да күңелле хәл түгел, әлбәттә. Болары да нервны какшата, иптәшләрең алдында, халык алдында йөзне кызарта торган нәрсәләр. Ләкин, шулай да, гаеп үзеңдә булгач, боларына ничек тә түзәсең. Ә минә бюро карары белән йөкләтелгән эш — анысы инде җитди әйбер! Анда инде тартып-сузып, ярым-йорты эшләп кенә котыла алмыйсың. Чөнки эшләнергә тиешле эшнең күләме дә, вакыты да карарда конкрет күрсәтеп куела. Андый чакта эшнең барышын даими тикшереп торалар.

Безлә куян комплексы төзү турындагы карарда да барысы да конкрет билгеләнгән: без аны бер ел эчендә төзеп бетерергә тиеш идек. Ә бит ул гади корылма гына түгел, махсус проект белән эшләгән, ел буе гел бер төрле температура саклана торган микроклиматлы, тулысынча механикалаштырылган корылма булырга тиеш. Ә безнең кулда аның ни проекты, ни төзү материалы юк. Җиһазлар турында әйтеп тә тормыйм, чөнки аларын Татарстанда бөтенләй чыгармыйлар, аларын каяндыр Чиләбе өлкәсеннәнме, Магнитогорск тирәсеннәнме юллап алып кайтасы диделәр. Юк, көн-төн гел шуның артыннан гына йөргәндә дә бер елда башкарып чыга торган эш түгел иде бу.

Моның шулай икәнлеген Шәйхи бик яхшы белә иде, әлбәттә.

Карарга каршы килеп булмый. Ләкин, инде әйттем, аны үтәү дә мөмкин түгел иде. Ни эшләргә? Югарыга мөрәҗәгать итеп караудан мәгънә чыкмаячак. Бу юлы анда мине хаклы дип табып, мәсьәләне үзгәрттерсәләр дә, Шәйхи миңа бәйләнергә тагын әллә нинди сәбәпләр табачак... Уйладым-уйладым да каршы да килмәскә, эшкә дә тотынмаска булдым. Кайчан төзи башлыйсың дип сораганда, җавабым әзер:

— Кыш өстеннән фундамент сала башламыйлар. Карлар китеп, җирләр эресен инде. Ә әзерлек эшләре бара: төзү материаллары ташыйбыз! — дим.

Материалны, чынлап та, ташыйбыз. Тимер-бетон әйберләрне Ка-

заннан, кирпечен каян таба алсак, шуннан: я район үзәгендәге кирпеч заводыннан яки күрше өлкә заводларыннан. Ләкин алар берсе дә куян комплексы өчен түгел, барысы да төзелеп ята торган сыерлар комплексы өчен ташыла иде.

Ул арада вакыт һаман үтә торды. Көзен җылы якларга киткән кошлар әйләнеп кайтып, оялары сакланганнары — ояларын яңартты, оялары булмаганнары — яңа оялар корды. Кичке тынлыкларда көмеш шөлдер тавышлары чыгарып, гөрләвекләр акты. Җир үзенең кышкы ак мамык юрганын ачып ташлап, җәйге яшел хәтфә юрганын ябынырга кереште. Дөнья сайрар кошлар тавышы, ярылган бөре, шомырт чәчәге исе белән тулды. Каеннар үзләренең сыек яшел өрфия бөркәнчекләрен иңнәренә элде. Язгы ташу сулары, җир йөзен генә түгел, әйтерсең күктәге болытларны да юып алып китте — һавалар чистарды, биегәйде. Сулыш алулары җиңеләйде. Табигатьнең бу бөек үзгәрешен кешеләр генә түгел, хайваннар да сизенә: көтүгә — иркенлеккә чыкканнарына куанып, сыерлар-таналар я койрык чәнчеп чабышып китә, яки туктап үзара сөзешеп-шаярышып ала; аларның шулай җиңеләешеп китүләренә ачуланган атлы булып та, шулай ук куанып та, күкрәк түреннән чыккан калын тавыш белән «ууу-ы, ууу-ы» дип үкереп, ара-тирә тукталып, берсе-берсе яртышар потлы каты тояклары белән җирне тырнап, колхозның нәсел үгезе йөри; ишегалларында тавыклар кытаклаша; берсеннән-берсе уздырырга тырышып, әтәчләр кычкыра..

Ләкин авыл халкының табигатьтәге хозурлыкларга сокланып утырыр чагы түгел иде бу. Вакытны минутлап санып торган көннәр иде. Кая анда куян комплексы турында уйлау, хәтта сыерлар комплексын төзүдә эшләүче кешеләрнең дә байтагын алып торып, кайсын чәчүлек ташырга, кайсын орлык салып барырга чәчкеч артына бастырып куярга туры килгән иде.

Әнә шундый уттай кызу эш барган көннәрдә дә Шәйхи Шәрифуллович мине онытмый. Үз холкына тугрылыклы калып, гел искә алып, гел борчый тора иде. Аның хакында сүз болай да шактыйга сузылды. Шуңа күрә аның вак-төяк хикмәтләренә тукталып тормыйм. Әмма әлеге шул язгы чәчү вакытында булган бер вакыйганы сөйләмичә үтә алмыйм

Безнең якларда карабодайның гомергә дә мактап телгә алырлык уңыш биргәне юк. Бирмәячәк тә. Җирдә дә, кешеләрдә дә түгел моның сәбәбе. Тишелүен әйбәт булып, бөркелеп тишелә ул. Үсүен дә шәп үсә. Чәчәк аткан вакытларында бөтен кырны ап-ак итеп, диңгез булып утыра. Орлыклануына да зарлана торган түгел. Ә менә орлыгы тиешенчә тулып, өлгереп җитә алмый. Чөнки безнең якларда җәй җитеп бетми кала аңа. Менә шуңа күрә дә карабодай белән артык мавыкмый идек без. Чәчүен чәчәбез. Ләкин ассортимент тутырыр өчен, ник чәчмәдегез дип әйтмәсеннәр өчен генә чәчәбез. Күп дигән елны да җитмеш-йөз гектардан арттырмыйбыз.

Ул елны да шул чамадан арттырырга исәп юк — йөз гектар планлаштырган идек.

Язгы чәчүгә чыгар көннәрдә республика җитәкчеләреннән берсе карабодайның кирәкле һәм файдалы азык икәнлеген әйтеп, аны күбрәк чәчәргә һәм уңышын арттырырга чакырып, газетада зур гына мәкалә белән чыккан иде.

Ул мәкалә Шәйхи Шәрифуллович күңеленә бик тә хуш килгән иде булса кирәк, шул көннәрдә үк председательләрне җыеп, районда карабодай чәчү мәсьәләсе буенча семинар-киңәшмә уздырдылар. Төп докладны Шәйхи үзе ясады. Доклады газетада басылган мәкаләгә нигезләнеп язылган иде. Әмма ул аны шундый итеп сөйләде ки, әйтерсең карабодай мәсьәләсе тик аның шәхси инициативасы белән генә

күтәрелгән, әйтерсең кешелек дөньясының ары таба яшәү-яшәмәве тик шул бер карабодайга гына бәйле иде.

Шул ук киңәшмәдә кайсы колхозга күпме карабодай чәчәргә конкрет заданиеләр дә бирелде. Безнең колхоз үзебез планлаштырган йөз гектар урынына ике йөз гектар чәчәргә тиеш икән...

Кайтып агроном Фәгыйть, партком секретаре белән өчәүләп киңәштек тә, без үзебезнең планны үзгәрешсез калдырырга булдык.

Чәчү беткәннең икенче көнне үк, безне фаш итеп, мәсьәләне бюрога куйдылар. Учет карточкасына язып, миңа шелтәнең катысын чәпеделәр. Тагын бер генә тапкыр шуңа охшашлы хәл булса партиядән чыгарырга, дип соңгы тапкыр кисәтеп куйдылар. Гаеп үземдә булгач, кешегә үпкәләр урын юк иде. Ләкин, шул ук вакытта, үземне алай бик зур гөнаһлы итеп тә саный алмыйм. Чөнки Шәйхи урынында бүтән бер кеше секретарь булган булса, әлбәттә, баштан ук ачыктан-ачык сөйләшеп эш иткән булыр идем. Ә Шәйхигә ничек әйтәсең?..

Шуннан ары мин үземне төпсез упкын буендагы тар гына сукмактан баргандай хис итә башладым. Чөнки куян комплексы төзү махсус карар белән минем өскә йөкләтелгән. Ул карарда күрсәтелгән срокның инде яртысы үтеп бара. Ә безнең әле аны төзергә керешкән дә юк. Сыерлар комплексы белән дә башлар катып беткән: әле тегесе, әле монысы җитешми иде.

Колхоз эшенә зыян килмәсен дигәннәрдерме, әллә кызу эш барышында үзе чиләнсен әле дигәннәрдерме, урак өстендә ул мәсьәлә белән борчымадылар. Игеннәрне җыеп бетереп, көзге чәчүләрне тәмамлагач кына чакырттылар мине райкомга. Куян комплексын төзү барышы турында отчет белән. Ләкин эшләмәгән эшкә ничек итеп хисап бирмәк кирәк? Ә алдашуның яхшыга алып бармавын мин инде беләм. Аннары теләсәң дә алдашу мөмкин түгел: иртәгә бюро буласы дигән көнне райком инструкторы, колхозга махсус килеп, барысын да үзе тикшереп-күреп киткән иде...

Бюрода бу юлы миңа сүз биреп тә тормадылар. Теге инструкторның информациясен генә тыңладылар да «бюро карарын үтәмичә, район күләмендә мөһим эшне — куян комплексы төзүне өзгән өчен» партиядән чыгарырга карар кылдылар. Ә эшемдә калдыру-калдырмау мәсьәләсен хәл итүне колхоз идарәсенә йөкләргә булдылар.

Әнә, шулай итеп, минем ничә еллык хезмәтем бик ансат кына, нибары берничә минут эчендә бөтенләй сызылып ташланды.

Моның белән килешү, әлбәттә, мөмкин түгел.

Моны хәтта күз алдына да китереп булмый иде.

Минем бит беркайчан да партиягә хилафлык итү уем булмады. Һәр эшемне әйбәт итеп, илгә, кешеләргә файдалы булсын дип эшләргә тырышып йөргән кеше ләбаса мин. Ә хәзер... төпсез упкынга тәртеп төшерелүдән дә яманрак иде бу. Упкынга төшкән кеше, ичмаса, ташка бәрелә дә шунда бетә. Ә болай син үзең турындагы бөтен гайбәтне ишетеп, моңарчы сине яратмаган, синең егылуыңны көтеп йөргән адәмнәрнең тантана итүләрен күреп торырга мәҗбүр булачаксың. Әгәр үзеңнең гаепле булуыңны танысаң, бер хәл. Ул чакта кешеләргә күренүе оят булса да, түзәр идең ничек тә. Ләкин менә күңелеңдә һичнинди явыз ният булмаганда, бөтен җаның-тәнең белән гомуми эш өчен тырышып йөргәндә шушы хәлгә калу...

Мин хәмер белән беркайчан да мавыккан кеше түгел. Дөрес, бәйрәм-сәйрәмнәрдә, мәҗлесләрдә тоткалыйм. Ә болай тиктомалга эчүгә үземнең дә исем китми, бүтәннәр эчкәнне дә яратмыйм. Ә менә ул көнне гомеремдә беренче тапкыр нык итеп эчтем мин. Аек килеш кайтсам, Айсылуга да, авыл халкына да күренергә йөрәгем җитмәячәк иде. Әйткән идем микән, минем бер вакытта да шофер белән йөргәнем юк. Машинаны үзем йөртәм. Ул көнне дә райкомга ялгызым

гына килгән идем. Кибеткә кереп бер шешә коньяк алдым да, район үзәгеннән чыгуга машинаны туктатып, тутырып бер стакан җибәрдем. Башка чакта бер стакан түгел, бер рюмка эчсәң дә шундук башка китә торган иде. Ә бу юлы әллә эчтем, әллә юк. Нинди зәһәр нәрсә үзе, ләкин зур кайгыны ул да тиз генә алмый шул! Ә алдырып торасы килә. Һич югы, өйгә кайтып, Айсылуга барысын да аңлатып биргәнчегә тикле генә булса да онытылып торырга кирәк иде миңа.

Тагын бер стакан салып эчтем. Тик шуннан соң гына таш булып каткан күңел бераз йомшап китте. Тик шуннан соң гына баш миен туктаусыз бораулап торган «Ни эшләргә?» дигән уйны читкә куып, юанычлы уйлар агыла башлады: «Ул кадәр үк хафаланма, Булат. Баш ярылып, күз чыкмаган бит. Намусың чиста синең!..» Бөтен тәнгә ниндидер бер рәхәт изрәү җәелде. Эссе булып китте. Күлмәк изүенең өске сәдәфен ычкындырырга һәм машинаның ян тәрәзәсен төшерергә туры килде. Сулыш иркенәйде. Дөнья киңәйде... Ләкин болай онытылып озак утырырга ярамый, теләсәң-теләмәсәң дә, авылга Айсылу янына кайтырга кирәк иде. Тагын башка килеп кергән «Ни эшләргә?» дән котылып торыр өчен, кычкырып җырлый-җырлый кайтырга чыктым:

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелсә калыр әле.
Дошманнар утка салса да,
Дусларым алыр әле.

Районнан безнең Ыргага кайтышлый урман буеннан үтәсе. Үзе безнең колхоз урманы ул. Зур түгел, ләкин гаҗәеп матур. Алда әйткән Түгәрәк күлебез дә шул урманда. Эшемдә күңелсезлек килеп чыгып, кәефем киткән чакларда мин шунда барып, җәй көне булса — күлдә су коенып, яз булса — кошлар сайравын тыңлап кайтам да, борчуларым басылып, күңелем тынычланып китә торган иде. Бүген дә шунда сугылып китәргә булдым. Күл өсте көзге шикелле тип-тигез иде. Тик ара-тирә балыклар сикергәләп кенә ул көзге өстен бераз шадралатып куйгалыйлар. Урман тып-тын. Әле кайчан гына агач яфраклары бар да яшел иде. Бүген әйтерсең сабан туена җыйналган авыл кызлары: һәркайсы үзенә бер төрле матур итеп бизәнгән. Өрәңгеләр алтын таҗ сурәте төшерелгән өр-яңа «күлмәк» кигән. Карама һәм әлмәләр кызгылт-шәмәхә шәл бөркәнгән. Ә каеннар су коенып чыкмакчы булып күлмәкләрен салганнар, алтын белән өртелгән толымнарын таратып җибәргәннәр дә, алдан суга керергә берсенең дә йөрәге җитмичә, чирканышып, бер-берләренә сыенып, туктап калганнар. «Агай, әйдә, башта син кереп кара әле!» — дип, мине көтеп торалар шикелле. Көне шактый салкын булса да, ул сылуларның «сүзен» тыңламыйча булмый иде: чишендем дә күлгә чумдым. Башта бер өтеп алды да, йөзә башлагач алай түзә алмаслык-ук салкын түгел иде. «Әйдәгез, чибәрләр, курыкмагыз! Төшегез күлгә дә коеныйк бергәләп! Көннәр җылыга таба бармый, бәлки быел бүтән коенырга да туры килмәс, юынып-чистарып калыгыз!» — дип чакырып карасам да, каен кызлары, бик салкын шул дип, суга кермәде. «Син дә озак торма, агай. Салкын тияр, я буыннарыңны көзән җыерып да батып китәрсең», — дип, мине дә тизрәк чыгарга өндәделәр. Ләкин мускулларның көзәнгә бирешергә исәбе юк. Ә үз ихтыярым белән батасы килми. Алай батарга ярамый иде. Чөнки аңлы рәвештә үз-үзеңне үтерү, минемчә, егетлек түгел. Куркаклар гына шулай үз-үзенә кул сала. Ә мин үземне беркайчан да куркак дип санамадым. Курыккан, каушабрак калган чакларым булгандыр, әмма куркак кеше түгел идем мин. Һәрхәлдә, үземә-үзем кул салырлык ук куркак җан түгел идем. Иртәгә ни эшләргә, алга таба ничек яшәргә икәнен, дөрес, белмим. Алары минем өчен караңгы төн. Әмма үзем теләп бу дөньядан китәсем дә килми иде...

Су коенып чыгу ярады: әйтерсең авыр кайгымның да бер өлеше шул күл суында юылып калган иде. Суга чумганда, шунда батып калсам иде, дип теләгәнем өчен, миңа хәзер оят булып китте. «Нигә шул тикле аһ орасың син, Булат! Кеше үтермәгән. Җәмәгать милкен урламаган. Берәүне дә нахакка рәнҗетмәгән. Ә бит заманында урлап тотылган, гомер буе сине рәнҗетеп килгән Шәйхи дә яши әле бу дөньяда», дип юатырга тырыштым мин үземне.

Су коенганда хәмер парының да байтагы юылып калган иде бугай: фикерләрем яктырып, башым сафланып киткән иде. Хәзер инде миңа өйгә кайтырга да ярый, хәзер мин шактый тынычланган идем. Алай гына да түгел, хәзер мин үземне җиңелгән итеп түгел, җиңүче итеп, батыр итеп хис итә башлаган идем.

Түгәрәк күл буеннан кайтырга кузгалганда, минем ул хисләрем, күңелемә генә сыешып тора алмыйча, җыр булып тышка бәреп чыккан иде инде:

> Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
> Селкенмәгән агач калмасын.
> Урамнарда йөрсәң, өздереп йөр,
> Өрекмәгән дошман калмасын!..

Юлы да тар түгел, теләсә нинди йөк машинасы белән рәхәтләнеп йөрерлек. Кояшлы булмаса да, көне дә яп-якты. Машинаны да алай артык куып бармый идем. Ләкин шул чак, мин килеп җиткәнче юлны аркылы чыгып калырга теләп, әмма бер дә алай ашыкмыйча, салмак кына чабып барган аналы-балалы пошиларны күреп алгач, шуларны таптатмас өчен, тормоз саласы урында, каушап калып, машинаны читкә бордым. Ә анда, үлән арасында, юан гына имән төбе булган икән...

Рульгә бәрелеп, үземнең бер кабырга сынган, ә машинага әллә ни зур зыян булмаган: алгы уң канаты яньчелгән дә бер фарасы гына ватылган иде.

Шулай да бу нәрсә минем язмышны Шәйхи теләгәнчә хәл итү өчен тагын бер саллы сәбәп булды: «Үзенә йөкләтелгән эшне үзе өстенә, колхоз машинасы белән пошилар куып, авария ясап йөргән кешенең колхоз җитәкчесе булырга хакы юк», — дип, мине эшемнән дә чыгардылар.

* * *

Шуннан ары ниләр булганын, үземнең нинди хисләр кичергәнемне тәфсилләп язып торуның кирәге юктыр дип саныйм. Рас мин бүгенге көндә шул ук «Уңыш» колхозының председателе булып эшлим, партиягә кире кайтарылганмын икән, хөкүмәтебез мине орден белән бүләкләргә лаеклы дип тапкан икән, димәк, безнең партия кемнең кем икәнен аера белә. Димәк, безнең илдә хезмәт кешесенә кадер-хөрмәт зур, димәк, ничек кенә тырышса да, Шәйхи мине таптап китә алмаган дигән сүз бит инде бу. Шулай булгач, эшнең ничек итеп партиянең өлкә комитетына барып җитүен, аны тикшерү өчен нинди комиссияләр төзелүен, ул комиссияләрдә кемнәр булганлыгын сөйләп вакыт әрәм итүнең хаҗәтен күрмим. Тик шунысын гына искәртеп китәм: барысы да гадел кешеләр иде алар. Миңа кагылышлы бөтен нәрсәне бик җентекләп, инәсеннән җебенә кадәр тикшерделәр. Шуңа күрә, ни булыр икән дип көтеп, эшсез йөргән көннәрдә егерме бер килога кимедем мин. Үземнең күзгә күренеп торган гаебем юк икәнен дә сизеп торам бит инде, югыйсә. Ә шулай да, ай-һай, нык уйландыра һәм шөбһәләндерә икән ул андый чакта!..

Бик белеп торам: ә Шәйхине нишләттеләр, дисез инде сез. Үзегезгә мәгълүм, беренче секретарь итеп аны вакытлыча гына билгеләп торганнар иде. Чираттагы партконференциядә аның урынына бүтән кеше — Азат Миннулловичны сайлап куйдылар...

## Зәки Нури

# ЯЗ ДӘФТӘРЕННӘН

### Мәхәббәт

Аның серен хәтта фән дә белми...
Аяз көндер, якты таңдыр ул.
Көтмәгәндә килеп ява торган
Ап-ак кар ул, ләйсән яңгыр ул.

Мәхәббәт ул — яшен ялтыравы,
Аңа җыр тиң, аңа тиң буран...
Мәхәббәт ул — зур юл! — Безне таңга
Алып бара торган киң урам.

1976

### Ераклардан кайткан җыр

Ничек матур сибелә анә
Еракта кыш үткәргән җыр.
Шул зур йөкне канатларың,
Кошкай, ничек күтәргәндер?!

Яз сулышы. Тамчы чыңы.
Җиләс җил һәм бөре исе...
Шундый җыр ул — туган якны
Яратуның тере хисе.

Чү, куакка кунып нинди
Кара шәүлә ялтырады?
Чү, анда нинди гөсләнең
Нечкә кылы калтырады?

Тукта, бу бит... бу — сыерчык!
Килгән икән, кайткан икән.
Биеп-биеп сайрый анә —
Үз оясын тапкан икән!

1978

## Кырларга карап

Яз кояшы алып килгән
Кызу көннәр башлана.
Самолетлар кырга оча,
Кырга ява ашлама.

Буленә озын төннәрнең
Кышкы әкият сөйләве.
Тынгысыз җырларны көйли
Инде мотор гуләве.

«Өлгерәм инде, кибәм!» дип
Җир гүя антлар итә —
Җылы куенына тук бөртек
Аласы чаклар җитә.

Җитә, яшь бөре, елмаеп
Ачылыр вакытларың.
Куанып котлый йөрәкләр
Мул уңыш походларын.

1977

## Бөрене котлау

Куанып котларга
тиешсең син, күңел,
Нәп-нәни, йом-йомшак
бу бөре эчендә
Яфраклар шавын да,
чәчәкләр ямен дә,
Көзнең мул сыен да,
күкрәуләр көчен дә.

Ул — бәбкә мамыклы.
Ул —елтыр соры күз.
Карашын юнәлтә
гел кояш ягына.
Ул — тере:
тылсымлы көйләрен тын көйли,
Җир көчле булсын дип
күкләргә табына.

Әйт, күңел, бөрегә:
— Кодрәтең кадерен бел,
Һәр вакыт бул кыю,
һәркайчан — мул, эре!..
Җырыңа исә әйт:
— Бул син дә бөредәй —
Көч тудыр, нур балкыт,
ил буйлап юл йөре!

1978

## Күрендең шомырт булып

Яраттым шомырт чәчәген —
Әмерне йөрәк бирде.
Балкып аткан шул ак чәчәк
Кап-кара җиләк бирде.

Күрендең син ап-ак шәлле
Шул шомырт булып миңа.
Бетмә син, чәчәк, бетмә син
Шиңеп тә сулып кына.

Ак чәчәкне койган җилләр
Өзделәр үзәгемне.
Ә көзләр җиткәч куандым
Хәтерләп күзләреңне.

Әйтерсең алар теп-тере,
Кап-кара җиләк иде.
Күрәсең, миңа шомырттан
Шул гына кирәк иде.

1977

## Гашыйклар дуэты

— Ал яулыкка аксыл җеп белән
Исемемне минем ник чиктең?
— Йөрәгемә сүнмәс ут ягып
Тәрәзәмне минем ник чирттең?

— Йолдыз булып күңел күгемдә
Син ул, син ул балкып кабындың.
— Таң җилләре булып истең дә
Минем җанга син ул кагылдың.

— Булыр иде юлым маяксыз
Күзләреңне синең күрмәсәм.
— Куандырмас иде мине таң
Төшләремә төнлә кермәсәң...

— Бергә бизи җирне чәчәкләр.
— Ә йолдызлар күктә ярәшә.
— И мәхәббәт! Якты юлыңда
Ике йөрәк типсен янәшә!

1978

## Тәрәзәңдә синең ак пәрдә

Тәрәзәңдә синең ак пәрдә.
Мин торган йорт яшел түбәле.
Язын гына әле очраштык,
Без җырлыйсы җырлар күп әле.

Минем шәүләм — синең күзеңдә,
Минем кулда — синең кайнар кул.
Өстә әнә тургай талпына,
Безнең өчен бары сайрар ул.

Минем яктан җилләр иссен дә,
Пәрдәләрең куйсын тирбәлеп.
Ай балкымый күктә Чулпансыз —
Шундый булсын безнең бергәлек.

Серле юл ул, җырлы юл икән
Йөрәк белән йөрәк арасы.
Без узасы юллар ераклар, —
Барасы да бергә, барасы.

1978

## Үзбәк кызлары

Биек баскычларга менеп
Алар виноград бәйлиләр.
— Әле апрель. Ләкин бу эш —
Безнең көз, безнең җәй! — диләр.

Куе яфрак, татлы җимеш
Булачак бу куакларда...
Шулай куела безнең сый
Сезгә, дуслар — кунакларга.

1975

## Атла, түз син, җиңелмә!

Тау башына алып менгән юлның
Бер нәрсәсе авыр, катлаулы:
Биеккәрәк үрмәләгән саен
Кыенайта синең атлауны...

Кем дә булса шулай дисә, әйтәм:
— Тик шул юлны сана җиңелгә!
Ул җиңүгә сине күтәрә бит,
Ә син атла! Түз син! Җиңелмә!

1976

## Кичә, бүген, иртәгә

*Диалог*

— Нигә миңа алга ашыгырга?
Каршыма бит килә бүтәннәр!
Мин ышанам, киләчәккә юлны
Сала бары безнең үткәннәр.

— Йолдызлары көн дә атыла торып
Кимемәсен дисәң күгеңнең,
Күңел күзен син еракка төбә,
Адымын син тизләт бүгеннең!

1978

## Ышан, иркәм

Кизләүләрдә тонык су бар,
Җир астында йомык су бар,
Тау-таш ишкән шаулы су бар,
Диңгездә чал яллы су бар,
Уй-давылдан көчле су бар,
Хәтта алтын төпле су бар,
Шифалы-сихәтле су бар...
Кыскасы, нихәтле су бар —
Барсы бергә җыелса да,
Өстебезгә коелса да,
Аера алмас безне сулар! —
Ышан, иркәм, мәңге шуңар!

1978

## Игезәкләр җыры

Күз дә кара, каш та кара,
Буй да тигез, чәч тә бер —
Без икәү — игез туганбыз,
Язмыш та бер, яшь тә бер.

Барча дусларыбыз уртак:
Мин танышка — ул таныш.
Тик көн саен чыга тора
Кызык хәл, я буталыш.

Бала чакта безне бергә
Дәваларга алдылар.
Һәм шунда аның уколын
Көн дә миңа салдылар.

Бәхетне көт тә, көтмә дә,
Теләмә дә, телә дә:
Мин бер начарлык эшләсәм,
Каеш аңа эләгә.

Мин дәресләр хәзерләдем
Тырышып та, шәпләп тә.
Ә миңа дигән бишлене
Гел ул алды мәктәптә.

Мин дә шактый шук Вәлимен,
Ул да шактый шук Кәли.
Ул көткән сәламне кызлар
Миңа биреп китәли.

Мин атна саен хат язам —
Чамага чама килә.
Ә кызның җавабы исә
Еш кына аңа килә.

Бер кичне хәтта шундый бер
Зур бәхеткә тарган ул:
Мине көткән кыз янына
Очрашуга барган ул.

Бер җырны икәү җырлыйбыз:
«Юлны кыю сызып бар!»
...Сагынып сөйләргә калды
Инде безнең кызыклар.

Бер төрле путевка белән
Килсәк тә бергә эшкә,
Ул көнчыгыш БАМга китте,
Мин калдым — көнбатышта.

1977

## Шамил Маннапов

# ЧЕХОЛДАГЫ РАКЕТАЛАР

хикәя



Көтмәгәндә Галимҗанны штабка чакырып алдылар. Ул килеп керүгә, майор Ненадышин кулындагы кәгазьне аңа сузды:

— Нәрсә бу?

— Кәгазь, иптәш майор,— диде Галимҗан елмаеп.

— Кәгазь? Син үзең кәгазь! Ә бу — бомба! Я сине шартлата, я мине...

— Аңламыйм, иптәш майор.

— Укы, аңларсың.

Шакмаклы дәфтәр битендәге язу таныш та, таныш түгел дә кебек. Ләкин кем кулы — Галимҗан хәтерли алмады.

«Без, «Марс» колхозы комсомол-яшьләре, — дип әчтән генә укый башлады ул, — сезгә шуны хәбәр итәбез: Варисов Галимҗан элек үзе белән хезмәт иткән Миначев Габдуллага мыскыллап хат язган. Үчлек белән. Армиягә киткәнче үк ул Габдулла белән кызлар бүлешеп йөрде, сугышты. Вәшшым. Варисовның сугыш чукмары булуын үзегез дә беләсездер инде. Хезмәтенең беренче көннәрендә үк спортзалда рядовой Гнеденковны кыйнарга ябышкан. Аны бу очынуыннан Миначев кына аралап калган. Инде килеп, иптәшенә рәхмәт әйтәсе урынга, хат аша мыскыл итә. Ышанмасагыз, менә хатын җибәрәбез һәм рядовой Варисовка бу поступкасы өчен тиешле чара күрерсез дип ышанабыз. Кеше мыскыллау гадәте Варисовның канына сеңгән.

Шикаять-хат азагында Гаптук имзасы. Менә кем язган икән бит! Шул, турниктан егылып, баш мие селкенгән, хезмәттән азат ителеп, күптән түгел кайтып киткән Гаптук кулы иде бу. Гаптук артыннан камыт сыйрак Гата, аннары икенче битнең башында ук... Галимҗан үз күзенә үзе ышанмады: Сәйдимә дә кул куйган! Аның кагыйдәгә туры китереп язылган почта-җыйнак хәрефләрен Галимҗан берәүнеке белән дә бутый алмый. Нәкъ шундый хәрефләр белән язылган хатлары әле дә гимнастерка кесәсендә. Ничек моңа имзасын куярга кулы барды икән? Мөмкин түгел бу эш, мөмкин түгел!

Кулын пешереп торган хаттагы сүзләрне шундук инкарь итәсе, үзен яклыйсы, аклыйсы килде егетнең, әмма кибеп аңкавына ябышкан теле әйләнмәде. «Кара син аны, дөресне ялган белән ничек оста буташтырып була икән бит».

— Әйе, сезнең өчен дә, безнең өчен дә күңелле хәбәр түгел бу, Варисов, — диде бераз тынычлана төшкән майор һәм «Беломор» кабызды. — Зур ЧП бу.

Ненадышинның «син»нән «сез»гә күчеп, коллектив мәнфәгатьләрен өскә күтәреп куюы Галимҗанны тагын да зуррак шөбһәгә салды.

— Әлеге хатны карарга мөмкин булмасмы, иптәш майор?

Ненадышин папиросын көл савытына басты.

— Ул хат лейтенант Галимовта әле. Соңыннан танышырсыз. Хәзергә китәргә мөмкин.

— Тыңлыйм.

Галимҗан честь биреп, кырт борылды.

«Соңыннан танышырсыз» дигән сүзләр аның эченә бераз җылы кергкәндәй булды. Әгәр Галимҗан язган дип ышанса, «танышырсыз» дияр идеме? Үзең язган хат белән танышалармыни?..

Кара син, нинди усал була ала икән бит майор Ненадышин. Ә бит ничек дусларча карый иде ул Галимҗанга. Бәладән йолып калган чаклары да булгалады. Егетнең хәтеренә кылт итеп майор белән урмандагы очрашу вакыйгасы килеп төште.

Быел язын булган иде ул. Дежурдан соң иртәнге урман аша казармага кайтышы иде Галимҗанның. Солдатка үз-үзе белән генә калырга алай бик еш туры килми. Ни әйтсәң дә, казарма тормышы казарма тормышы инде. Син һаман күз өстендәге каш. Ә кешеләр арасында никадәр күбрәк булсаң, ялгызлык шул хәтле тансыклата икән. Уйланыр-хыялланыр өчен, иркенләп сагыныр өчен дә кирәк аулакта калу.

Ландыш чәчәкләренең хуш исе бик еракта калган туган-үскән Чирмешән якларын исенә төшерде. Каршысына ландышлар түгел, ап-ак күлмәген кигән Сәйдимәсе килгәндәй тоелды. Эх, шушы хуш исле ландышларны Сәйдимәгә бүләк итәсе иде. Ул бит чәчәк дигәндә үлепләр китә иде. И-и, тиле дә булган инде Галимҗан. Ник инде кызга һәр көнне бер кочак чәчәк илтмәскә иде?! Чәчкә белән болын тулы, урман тулы иде бит туган якта. Күп булганга кадере беленмәгәндер, күрәсең. Хәзер бик бүләк итәр иде дә, Сәйдимәсе генә янында юк... Ярый, шушы чәчәкләрнең берсен генә булса да хатка салып җибәрер ул. Әнисенә дә бер тәлгәш чәчәк салыр. Галимҗан аның чәчәк кебек вакытларын хәтерләми. Ул белә-белгәннән әнисенең йөзе җыерчыклы. Сугыш елларында сулган чәчәк. Тик дугаланып торган кара кашлары гына аның кайчандыр чибәр булганлыгы турында сөйли... Сәйдимә кебек булгандыр ул. Ә менә Сәйдимә аның әнисе кебек булмас. Юк, бер дә картаймас, гел яшь булып калыр ул...

Чәчәкләр аны кызыктыра-кызыктыра чәнечкеле тимер киртәләр янына кадәр озата килде. Ә киртә аръягындагы чәчәкләр тагын да хуш исләрәкләр кебек. «Безне дә калдырма, егет!» — дигәндәй, чыклы күзләрен мөлдерәтеп карыйлар. Җитмәсә, киртәдә кеше сыешлы ара да бар икән. Тиз генә өзеп кергәннән әллә ни булмас. Урманда аны кем күрер дисең. Һоп-ла! Ләкин киртәне атларга гына өлгергән иде, җир астыннан килеп чыккандай, куаклар артыннан майор Ненадышинның зур гәүдәсе калыкты. Качып калу турында уйларга да өлгерерлек түгел иде инде. Галимҗанга сынын төз тотып, сәлам бирүдән башка чара калмады:

— Сәламәтлек телим, иптәш майор!

— Исәнмесез, исәнмесез, — диде Ненадышин, беләгендәге кызыл бантны төзәткәләп. — Тик ни өчен территориядән читкә чыгып сәлам бирергә булдың әле, Варисов?

«Бетте баш, — дип уйлады Галимҗан, — часть дежурныеның нәкъ үзенә килеп каптым. Самоволкага бармый идем дип, ышандыр инде менә хәзер».

— Чәчәкләр чакырып чыгарды, иптәш майор.

Ненадышинга егетнең риясызлыгы ошады булса кирәк, чәчәкләренә карап алганнан соң, тырпайган мыеклары шиңә төште.

— Ә менә мине чәчәкләр арасында яткан шушы нәмәрсәкәйләр кызыксындырды, — диде ул учын ачып. Анда вакытлар узудан күгәреп беткән патрон гильзалары иде. Майорның кем беләндер серен бик уртаклашасы килгән вакыты иде бугай:

— Сугышчан дан музеена менә дигән экспонатлар. Минем эти дә шул тирәдә сугышкан иде бит...

— Кайта алдымы соң ул, иптәш майор?

— Кайту кая, каберен белсәк тә, үкенечле булмас иде әле... — дип көрсенде Ненадышин. — Хәбәрсез югалды.

— Ә минем бабайга фашист ядрәсе Кенигсберг янында эләккән... Эти белән әни еш искә алалар иде үзен.

Галимҗанның чәчәкләре дә никтер моңсуланып калды шикелле. Майор һәм гади солдат үзләренең монда ни өчен басып торуларын бер мизгелгә оныттылар кебек. Алар гүя ки сугышта һәлак булган газиз кешеләренә чәчәк бәйләме китергәннәр дә, кая куярга белми аптырашта калганнар иде...

Бу очрашу турында берәү дә белмәде, шулай узган иде. Беренче күрүдә үк ничектер яраткан укытучысы Бостан абыйны хәтерләткән майорны әлеге вакыйгадан соң Галимҗан аеруча якын күрә башлады. Политинформация сәгатьләрендә аның сөйләвен ихлас бирелеп тыңлый, һәр сүзен зиһен тартмасына салып бара. Хәер, Ненадышинны башка солдатлар да гадилеге, гаделлеге өчен ихтирам итәләр. Команда тавышлары еш яңгырап торган солдат хезмәтендә ягымлы мөнәсәбәт, йомшак сүз җаңга аеруча кадерле... Ә бүген майор, ай-һай, кырыс булды. Шуңа карап, Галимҗан хәлнең җитди булуын аңлады.

Шикаять-хатка Сәйдимәнең кул куюыннан зиһене томаланганга гына моны бөтен тирәнлеге белән төшенеп бетерми иде әле ул. Юк, ул моны башына сыйдыра алмады. Ничек кулы күтәрелде икән? Ничек?!

Гаптукның рәсми кәгазьләр белән шаяруы да аңлашылып бетми иде Галимҗанга. Авылда Сәйдимә өчен сугышкан булсалар да, бергә хезмәт итә башлагач килешкәннәр иде шикелле. Читтә авылның эте дә якын була дип, юкка гына әйтмәгәннәр, күрәсең. Ярты елдан артык янәшә караватта йокладылар. Бергә дежур торган вакытлар да аз булмады. Иптәшлек өчен Гаптук ярамаслык егет түгел иде. Тик сәер бер гадәте бар: Галимҗан ни эшләсә, шуны кабатлый. Галимҗан частьның волейболчылар командасына язылса, Гаптук та шунда. Галимҗан өченче классны оператор булырга әзерләнә башлый, Гаптук та сызымнар өйрәнә. Ял итмәсә итми, әмма Галимҗаннан калышмаска тырыша. Артка калган очракта ничек тә Галимҗанның башкалар алдында дәрәҗәсен төшерергә маташа, һич югында, авылдашы уңышын күрмәмешкә салыша.

Озын буйлы, атлет гәүдәле булганга Гаптук спорт буенча Галимҗаннан калышмады гына түгел, аны уздыргалады да. Җиңел атлетиканы беренче разрядка тапшырды. Ул көнне Гаптукның яшькелт күзләре авылдашына мыскыллы карадылар. Галимҗан моны сизде. Әмма сынатмаска тырышты.

— Котлыйм, авылдаш, молодец! — диде.
Ләкин озак та үтмәде, күнегүләр вакытында Галимҗан булдыра алмаган «кояш»ны ясап күрсәтергә теләгәндә, кулы ычкынып китеп... фаҗигага дучар булды. Гаптук госпитальдә озак ятмады. Тиз чыкты. Аның йөзе борчулы иде.
— Мине комиссовать итәләр, егетләр, — диде ул.
Ләкин кайтып киткәндә Гаптук сер бирмәскә тырышып:
— Авылның иң чибәр кызлары абыегыз кулында булачак хәзер, — диде.
— Бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый шул. — Монысын Галимҗанның икенче авылдашы Нигат әйтте. Юаштан юан чыгар дигәндәй, Нигат саллы сүзен шулай һәр вакыт иң кирәк җирдә генә әйтеп куя ул. Башы артык зургамы, күзләренең аптыраулы карашымы, аз сүзлелегеме — нәрсәдер Нигатны хезмәт итүенең беренче көннәреннән үк мәзәк-көлке өчен мишеньгә әйләндерде.

...Төнге нарядтан соң ял итүче солдатлар төшке ашка барыр алдыннан курилкада тәмәке көйрәтәләр, мәзәк сөйләп, гөрелдәп көлешәләр иде. Галимҗанны күргәч, аңа ябырылдылар:
— Ник чакырганнар, Галич? (Аның исемен кыскартып шулай диләр.)
— Әллә бер-бер хәл булганмы?
«Атом» дип аталган махорка сигареты тартып торучы шадра солдат:
— Эшеңне сизгәннәр, значитсы, кирәгеңне алырсың! — дип чәнчеп куйды.
— Син, Гнеденков, башта ук яратмадың Галимҗанны, һаман кыралмыйсың. Кешегә баз казысаң — үзең мәтәлерсең, онытма шоны.
Моны әле генә иптәшләрен авызына каратып, көлдереп торган Чистай мишәре Кәлиф әйтте. Аннары гадәтенчә уенга сапмак булды:
— Берегез дә этә алмады. Галичка краткосрочный ял бирмә келиләр. Сәйдимәсенең сагынудан йөзе саргая башлаган ди. Шоны дәвалау өчен ебәрмәкчеләр.
Башкаларга кушылып, Галимҗан үзе дә елмаймакчы булды, ләкин елмаю килеп чыкмады, йөзе генә чытылды.
— Шәхси мәгълүматларны тәгаенләргә чакырганнар, — диде ул сүрән генә.
Җим өмет иткән күгәрченнәрдәй, әйбәт яңалык көткән солдатлар, өметләре акланмауга нәүмизләнеп, беравык тын тордылар да, өзелгән сүзгә яңадан тотындылар.
— Сөйләп бетермәдең бит әле, Кәлиф.
— Нәстә сүли идем соң әле, мин — дивана?
— Соң, Нигат турында инде.
Кызык сөйләргә дисәң пилоткасын кыңгыр салган Кәлифкә бир. Ул үзе бервакытта да кычкырып көлмәс, кызыкны башкаларга калдырыр, үзе исә, бу юләрләр ник авыз ералар инде дигәндәй, иреннәрен салам калынлыгы гына итеп елмаер.
— Ә-ә, әйе. Безнең Нигат политзанятиедә йоклап утыра. Гадәттәгечә инде. Нечкә муены зур башын күтәрә алмыйча янтаеп төшкән, авызы ачылган. Занятиене үткәрүче Ненадышин күреп ала моны.
— Рядовой Касыймов, встать! — ди. — Син йокламыйча тыңлап утыра аласыңмы, юкмы?
Әле сүзне юньләп төшенмәгән дә Нигат:

— Никак нет, иптәш майор, — дип әйтеп салмасынмы.
Майор да аптырап калмый:
— Алайса, баскан килеш тыңла! — ди.

Солдатларның көлүеннән казарма янындагы тирәкләрнең сары яфраклары шыбырдап коелды. Һәр сөйләвендә яңа бизәкләргә баета барганга, Кәлифнең мәзәкләре ялыктырмый. Ул бигрәк тә Нигат турында сөйләргә ярата, Нигатны частьта шул мишәр Кәлиф кенә танытты да инде.

Янәсе, беренче вакытларда Нигатның тамагы туймый. Ашханәдә кем дисәң, ДП сорап, «амбразура»ны Нигат томалый. ДП дигәне, солдат телендә, өстәмә паек, амбразурасы — кухня тәрәзәсе инде аның. Шул тәрәзәдә Нигатның әүвәл калай табагы, аннары табак кебек бите күренә. Пешекчеләре дә күнегеп беткәннәр. Нигат бер көн генә килмәсә дә: «Безнең дус кайда, әллә нарядтамы? Ул булмаса, монда биш кешелек ботка әрәмгә кала», — дип шаярталар.

Магазиннан кесә тутырып ак күмәчтер, перәннектер ташый бу. Бер көн шулай кайтып килгәндә ни күрсен: казарма каршындагы юлның ике ягында ике офицер сөйләшеп тора. Әйләнечтән китәр иде, юл юк. Спорт мәйданчыгы рәшәткәләп алынган. Кайсына честь бирергә дип, аптырабрак кала малаең. Гадәттә, дәрәҗәсе өлкәнрәккә бирелә. Ә боларның икесе дә бер дәрәҗәдә — икесенең дә погоннарында өчәр йолдыз. Нигат юлны таба: ике кулын козырегына күтәрә дә, алга туп-туры караган килеш, уза да китә. Офицерлар елмаешып калалар. Казармага кайтып җиткәч, тагын эләгә Нигат.
— Кесәңдә нәрсә? — дип сорый ефрейтор Пенягин.
— Берни дә юк, — ди Нигат түбән карап.
— Ну-ка, әйләндереп как әле.
Нигат кесәсен әйләндерә башлый. Аннан перәннекләр коела.
— Яңадан тутыр да, кесәңне шәпләп тегеп куй һәм минем рөхсәттән башка сүтәсе булма!

Нигат шул перәннекле кесәне айга якын күтәреп йөри. Бәрәңге җирендә бик ачыккач ,кесәсенең читеннән генә сүтеп ашыйм дисә, перәннекләр укмашып, таш булып кипкән...

Үзе турында сөйләп көлешкәнгә Нигатның бер дә исе китми. Борынын тарткалап, ни кызыгы бар инде моның дигән сыман, битараф тыңлап тора. Аны гадәттә Юра аралап ала. Бүген дә Кәлифне ул бүлдерде:
— Я, нәрсә кешегә бәйләндегез. Әйт әле шуларга русча саллырак сүз, Касыймов!

Юраны, Урал ягыннан булганга, «сибиряк» дип йөртәләр. Ул уен-мәзәкне яратса да, кешедән көлгәнне өнәп бетерми. Шуңа микән Галимҗан белән аларның серләре аеруча килә. Җыр, музыка ярата Юра. Подразделение стена газетасының редакторы ул. Иптәшләренә дә үткен-үткен эпиграммалар язып куйгалый. Хәтта ниндидер көйгә яраштырып, старшинага да җыр чыгарган. Җырның эчтәлеге болай: бер солдат самоволкага барып кайта. Старшина аның әзенә төшәргә тели. «Кайда булдың?» — дип сораштыра. Ә солдат: «Старшина Крючков, не найдешь среди нас дурачков», — дип уйлый.

Гомере озын булыр, Галимҗанның уена килү белән, старшина үзе дә казармадан чыкты.
— Перекур тәмам. Дежурный, личный составны тез, — диде ул гадәтенчә коры гына.

Болай кырыс күренсә дә, старшина Крючков солдатларны аталарча кайгыртучан кеше. Күңел йомшаклыгын сиздермәс өчен генә кырыс булырга тырыша кебек тоела ул Галимҗанга. Исемен шаян җырга кертеп җибәрүне дә дошманлык белән түгел, киресен-

чә, аны үз итүнең бер билгесе дип кабул итте булса кирәк, артык төпченмәде, сизсә дә, үч алып маташмады.

Ә бәйрәмдә Крючковның күкрәге тулы орден, медальләрне күреп, Галимҗан гаҗәпкә калды. «Үзе өлкән дә түгел, кай арада шул кадәр бүләкне алырга өлгергән? Аны яшьли фронтта булган диләр шул...»

Төшке аштан соң, старшина Крючков, Галимҗанны үз бүлмәсенә чакырып, штабта ни булганын сорашты. Тыңлагач:

— Ничего, бар да ачыкланыр, кайгырма,— диде.— Синең тәртипле солдат икәнеңне әйтеп, кирәксә, үзем дә сүз катармын.

*
* *

Икенче көнне штабка чакыручы булмады. Галимҗанны берничә иптәше белән «төп бинага» дежурга билгеләделәр. Арада Юраның да булуы сөендерде аны.

«Төп бина» дигәннәрендә ракеталар белән идарә итү пульты урнашкан. Частьның күзе-колагы, нерв системасы — барысы да шунда. Эше җаваплы булса да, тыныч үзе. Аппаратларга күз-колак буласы да, катлаулы техниканы туктаусыз өйрәнәсе. Дивизионда хезмәт итүчеләрнең эш урыны — ачык һавада. Ракеталарны старт «өстәленә» кую, техник хезмәт күрсәтеп, очыртып җибәрү алар өстендә. Хезмәтләре кыен булса да, һәр вакыт саф һавада йөргәнлектән, дивизион егетләренең йөзләре алма кебек алланып тора. «Төп бина» да хезмәт итүчеләрне алар «аксөякләр» дип йөртә.

Корал-яракларын әзерләгән арада, Галимҗан Юрага әйтеп куйды:

— Сибиряк, синең белән киңәшеп аласы бар иде.

Юра гадәтенчә кыска гына итеп:

— Хуш, сөйләшербез, — диде.

Ул һаман «хуш, сөйләшербез» ди. Шикаять-хатта телгә алынган бәрәңге җиренә баргач та шулай «хуш, сөйләшербез» дигән иде. Галимҗан да дуамаллык күрсәтте шул, авыл гадәте чыгып бетмәгәнлектән, әлбәттә. Инде ул турыда онытканнар иде. Ә Гаптук хәтерле егет икән.

... Яшел гимнастеркаларын яңа гына кигән, инкубатор чебешләре төсле егетләрне, сафка тезеп, күрше колхозның бәрәңге басуына алып киттеләр. Яшь солдат курсын — карантин үткәнче аларга билгеләнгән ефрейтор Пенягин алып барды. Нечкә иренле, тулы алсу битле ул ефрейтор галәмәт усал булып чыкты. Сафта тамак кырган өчен дә кисәтү ясый, сөйләшсәң, бөтенләй харап: чираттан тыш наряд чәпи дә куя. Башкалар рәхәтләнеп ял иткәндә идән юып, туалет чистартып йөр аннары. Әнә шул «явыз» ефрейтор күрше авыл басуына чаклы ике-өч чакрым араны гел юыртып алып барды, кичкә кадәр эшләтте. Эштән кайтканда да йөгертә башлады бу. Галимҗан кирза итекләренең авырайганнан-авырая баруын тойды. Аның артка калуын күргән Пенягин чыелдап кычкырды:

— Тиз бул, тиз! Наряд аласың киләме әллә?!

Ефрейтор стройны туктатты. Аның тавышы инде ысылдап чыкты.

— Чиратсыз өч наряд сиңа!

Шул вакыт алдан йөгерүче Юра Галимҗанга шыпырт кына:

— Минем бил каешына тотын, — диде. — Без бу хәчтерүш белән кайчан да булса бер сөйләшербез әле. Хуш, сөйләшербез!

Контроль-үткәрү пунктын узуга, аларны беләгенә кызыл бәйләгән майор туктатты:

— Болар нинди партизаннар? — дип сорады ул, ачулы күзләрен Пенягинга кадап.

Озак йөгерүдән ефрейторның сулуы капкан иде. Шулай да үзләренең кайдан кайтуларын хәбәр итә алды.

— Нигә төшке ашка алып кайтмадыгыз? — дип сорады янә майор.

— Кайтып-китеп йөрергә ерак бит, иптәш майор.

— Ерак?! Ә сез солдатларның кыяфәтен күрәсезме, кем сезгә хокук бирде солдат белән шаярырга?!

Галимҗан иптәшләренә күтәрелеп карады. Чыннан да, кыяфәтләр шәптән түгел иде шул. Гимнастеркалар каралып эштән чыккан. Алгы рәттә басып торган Гаптукның озынча аксыл бите буйлап әллә тир, әллә күз яше тәгәри...

— Хәзер үк ашатыгыз солдатларны һәм минем янга — штабка! — диде майор.

Юра Галимҗанның кабыргасына төртте: «Әйттем бит мин сиңа...»

Шул вакыйгадан соң Пенягинны син күр дә мин күр. Аның урынына сержант Савоськин килде. Ә Пенягинны утка бастырган майор турында: «Ул подразделение командирының политик эшләр буенча урынбасары, фамилиясе Ненадышин икән», — диделәр.

Савоськин теге ефрейтор белән чагыштырганда бөтенләй башка егет булып чыкты. Солдатлар белән үз итеп сөйләшә, хәл-әхвәл сораша, үзенең дә «яшел» вакытларын искә алып, көлә-шаярта, башкалар сүзенә колак сала белә иде.

Сержант Савоськинның карантиннан соң да Галимҗан хезмәт итәчәк отделениенең командиры булып калуы гаять шатландырды егетне.

Була бит шундый кешеләр: бер-ике кәлимә сүзеннән, хәтта сүзеннән дә түгел, күз карашыннан, үз-үзен тотышыннан ук аны үз күңеләңә якын итәсең. Андый кешенең янәшәңдә булуы җаныңны тыгызламый, киресенчә, бу янәшәлектән икеңә дә яхшы, рәхәт. Ә кайбер кеше... Ул сиңа әйбәт мөнәсәбәттә дә шикелле, югыйсә. Тик барыбер җаның кабул итми, йөрәгең аңа ачылырга ашыкмый. Әйтик, Нигатның ни зыяны тигәне бар Галимҗанга? Һич юк. Үзләре авылдашлар да әле, җитмәсә. Ә шулай да, кем әйтмешли, дус та түгел, дошман да түгел...

Алар гигант тегермән канатларыдай антенналы «төп бина»га килеп җиттеләр.

Җир куенына подвал булып сыенган бу куышка кергән саен ис-акылга сыймаслык гаҗәп автоматлар каршында бер мәл югалып калгандай буласың. Беренче көннәреңдәгечә: «Ай-һай, моннан башкайлар исән-сау чыгармы...» — дип шүрләмисең инде шүрләвен, шулай да барыбер каушата. Бу акыллы автоматлар, лампочка күзләрен елтыратып, сине туктаусыз күзәтәләрдер, хәтта ни уйлавыңны да белеп торалардыр шикелле. Бу техниканы бик кыйммәт диләр. Шуларга сылу ракеталарның бәясен дә кушсаң... Менә кайда ул байлык! Бу галәмәт техниканы тыныч хезмәткә җиксәң, тормышыбыз тагын да яхшырак булыр иде. Юк шул, ярамый. Майор Ненадышин әйтә бит, җирдә ике система яшәгәндә ракеталар чехолда әзер булып торырга тиешләр, ди...

Чехолда гына торсалар, ярый инде...

Ә үзебез шул ук чехолдагы ракеталарга охшамаганмыни? Сукса тимер өзәрдәй күпме егет станокларда, колхоз-совхоз кырларында эшлисе урында, монда торырга мәҗбүрбез...

Узган сменадан дежурлыкны кабул итеп алгач, Савоськинны ял итәргә җибәрделәр. Ул дүрт сәгатьтән егетләрне алыштырырга тиеш. Шуннан соң Галимҗан Юрага әйтте:

— Кая, тартыйк әле бер.

Юра, күзләрен кыса төшеп, иптәшенә карады:

— Шаярма, син тартмыйсың ич.

— Тәмәке түгел, аннан да яманрагын кабарсың бу дөньяда.

— Мәйлең, алайса. Әйдә, бераз егетләр исе килер үзеңнән.

Алар «Шипка» кабызды.

— Юра, сиңа... Сәйдимә белән ничек танышуыбыз турында сөйлимме?

— Кызлар турында сөйләгәнне яратуымны беләсең бит, ник сорап торасың. Кызларның үзен күреп булмаса да, хет аларны сөйләп юаныйк.

Галимҗан тәмәкесен чытырдатып суырды да ютәлләп алды. Аннан сөйләп китте:

— Район үзешчәннәренең йомгаклау концертында булды бу. Һинд кызларыныкыдай кара-тут йөзле, болан күзле бу чибәрнең сәхнәдә җырлавы күпләрне әсир итте.

Сәхраләрдә ялгыз йөргән чакта
Җилләр исеп чәчем тарата.
Мәхәббәт ул, дуслар, шуны онытмагыз:
Ул саф йөрәкләрне ярата...

Ул шулай җырлады. Ә мин Такташ шигырьләрен укыдым.

Концерт беткәч тә, без авылларыбызга таралыштык. Монда мин әлеге чибәрнең Сәйдимә исемле булып, Чирмешән аръягындагы Карамалы авылыннан икәнен генә белә алдым. Азмы була яшьлектә мондый очрашу, озатулар. Син гашыйксың, ут йотып йөрисең. Була да, уза да. Бу да шулай үтеп китәр иде бәлки. Әмма язгы каникулда язмыш безне янә очратасы итте.

Кичкырын китап укып утыра идем, Нигат килеп керде: «Түбән очның Фәридә апаларга Карамалыдан кунак кызы килгән икән. Егетләр шуңа шаккатканнар», — ди.

Юра көлемсерәде:

— Кызлар булгач, Нигатның да йокысы качканмыни?

Нигатныкы түгел, минем йокы качты. Күңелне кытыклады ул әлеге хәбәр белән. «Исеме ничек ул кызның?» — дип сорадым. «Саймәме шунда, Сәйдиләме», — ди. «Сәйдимә!» — Мин урынымнан ничек сикереп торуымны да сизми калдым. «Киттек клубка!» «Әй, кирәге бар, — ди Нигат, — әйдә, лутчы берәр партия шахмат уйныйк та, мин кайтып китәрмен. Йокы килә.» Шулай да күндердем моны. Киттек.

Без клубка килеп кергәндә, кызлар, егетләр түгәрәк уйныйлар иде. Карасам, уртада ул — Сәйдимә. Бөтерчек кук әйләнә. Ул да мине таныды, ахры, карап елмайды. Уймак кебек алсу иреннәре арасыннан ландыш чәчкәсе кук ап-ак тешләре күренеп китте. Бу — аның кара тутлы түгәрәк йөзенә гаҗәеп матурлык бирә иде. Кыз мине уртага алды. «Сез кичләрен сирәк чыгасыз, ахры», — ди. «Ник алай дисез?» — мәйтәм. «Узган кичләрдә күренмәдегез ич», — ди. «Бүген дә чыгарга исәп юк иде дә, бик чибәр кунак кызы килгән, диделәр — шуңа чыктым». Кыз да җавап эзләп күршегә керә торганнардан түгел икән: «Инде үзен күргәч, ник чыкканыгызга үкенәсезме?» — ди. «Үкенергә дә туры килмәгәе шул». Сәйдимә сагайды: «Ни өчен икән?» «Әлегрәк чыкмавым өчен». Ул көлде. Көлгәндә дә җырлагандагы кебек матур иде аның тавышы.

Ул кичне без гел бергә булдык. Башкаларның күзенә бу хәл чалынмый калмады, билгеле. Без уртага чыккач, кинаяле җыр яңгырады:

Әй, икегез-икегез,
Икегез дә бертигез.
Икегез дә пар килгәнсез,
Дуслар булып китегез...

Гаптук кына озын муенын сузып, әлеге җырның соңгы сүзләрен үзенчә борып, «Шайтаныма китегез!» дип кычкырды.

Юра бүлдерде:

— Теге, турниктан егылган Гаптукмы?

— Шул үзе. Әйе, ул кичне Гаптук ашка төшкән таракан булды тәки. Сәйдимәне кат-кат биергә чакырды, төртмәле сүзләр әйтеп я минем, я кунак кызның кәефен кырырга азапланды. Таралыр вакыт җитәрәк Сәйдимәгә:

— Әйдә кайтабыз, — дип бәйләнде.

— Мине Галимҗан озатырга вәгъдә бирде, — диде кыз, — шулай бит, Галимҗан?

Мин, «әйе» дигәнне белдереп, баш кактым.

Гаптукның болай да ач яңагы тешен кысудан уртына ябышты. Ул, кырт борылып, чыгып китте. Ә без Сәйдимә белән Төпе елгасына җитеп барганда каршыбызда янә Гаптук калыкты.

— Бармак очларыбыздан гына тотышып кайтабыз диген, ә? — Аның тавышындагы мыскыллауны сизми калу мөмкин түгел иде. — Кайтыгыз, кайт. Заманында безнең дә шулай кайткан чаклар булды.

Мин бармакларымның учыма кысылуын тойдым:

— Ни дип юлга аркылы төшәсе иттең әле син, Гаптук?

— Һе. Мин түгел, син ул минем юлда — кара мәче. Башкалар салган эздән йөрисең, егетем.

— Ялган! — диде Сәйдимә өзгәләнеп. — Ничек телең бара, оятсыз!

Гаптукның «черт» итеп төкерүе ишетелде:

— Беләбез без елап котылучыларны. Һе.

Мин Гаптукның ялт кына изүеннән борып алдым.

Сәйдимә шашынып беләгемә ябышты:

— Кирәкми, егетләр, кызмагыз!

Арттан кайткан егетләр безне аердылар. Аннан соң инде килешкән идек шикелле. Ә ул шуны онытмаган булып чыкты.

Юра сигаретын сүндереп, буш консерва банкасына ташлады.

— Соң үзең дә онытмагансың ич.

— Минем бит Гаптук өстеннән шикаять язганым юк.

— Аның язганы бармыни?

— Хикмәт тә шунда шул менә.

Һәм Галимҗан штабта ишеткән-күргәннәрен кыскача гына сөйләп бирде.

Теге хатка кул куючылар арасында Сәйдимәнең дә булуына Юра артык гаҗәпләнмәде.

— Хатын-кызга ышанып буламыни?! — диде ул. — Минем әни дә, әтине ташлап, базарда кара җимеш сатучы торгашка тагылып китте.

— Беләм, — диде Галимҗан, — тик син бөтен хатын-кызны да бер аршин белән үлчәмә!

— Ә син юкка кызасың. Үзең сөйләп торасың лабаса, Сәйдимәнең сиңа хыянәт иткәнен.

— Хыянәт дип, бик үк күпертмә син алай. Бәлкем аның гаебе дә юктыр. Дөньяда азмы андый хәлләр. Сөйлимме?

Әмма Галимҗанга сөйләргә туры килмәде. Кинәт яңгыраган тревога тавышы икесен дә сискәндереп җибәрде. Генератор артында черем иткән Савоськин йөгереп чыкты.

— Аппаратларны кабызырга!

«Төп бина»ның тимер идәнле коридоры кирза итекләрдән дөбердәп башлады.

Галимҗан йөгереп барып сиренаны туктатты. Солдат тормышының күп якларына күнекте ул, ә менә сирена улавына, тревога яңгыравына һич кенә дә күнегеп җитә алмый. Бу тавышлар аның күңеленә шом сала. Һәр тревога аңа чын-чынлап сугыш мәхшәре башлану хәбәре буып тоела. Тьфү-тьфү! Авызыннан җил алсын.

Тик бу юлы Галимҗанның «авызыннан җил алмады». Расчет башлыгы лейтенант Галимов ишектән керә-керешкә:

— Бу — өйрәнү тревогасы гына түгел, иптәшләр. Һавада — чик бозучы! — диде. — Ул көнбатыштан безгә таба оча.

Менә сиңа мә! Майор Ненадышин әйткәнчә, ике система арасында идеология көрәше бару белән бергә, көрәшнең менә мондые да очрый икән әле! Тик шунысы аңлашылмый: ни дип керә ул ялгыз самолет? Ялгыз очучы? Ул җирдә безнең ракеталар барын белми микәнни соң? Әлбәттә, беләдер. Әллә биектән очкач эләктерә алмаслар дип өметләнәме? Чыннан да, чикне исән-имин узган бит, инде япа-ялгызы әнә кая кадәр килеп җиткән. Ялгызын ялгыз. Әмма атом заманында бер самолет та күз күрмәгән, колак ишетмәгән бәла-казалар китерергә мөмкин. Хиросима, Нагасаки шәһәрләрен дә кайчандыр нибары ике самолет бомбага тоткан...

Дошман базасыннан чебен очып күтәрелгәнне дә безнең сизгер ракетачылар күреп тора, диләр иде бит. Күргәч, нигә шулай якын җибәрәләр соң әле ул һава пиратын? Һәр минут, һәр секунд саен һаман илебез түренәрәк уза.

Менә ул тизлеккә өйрәтүләрнең кирәге кайчан чыга икән. «Төп бина» тулысынча сугышчан әзерлектә булып, чик бозучы «мушкага» алынган иде инде. Ул арада частьтан тирләгән-пешкән төп көчләр дә килеп җитте. Микрофонда командирның ышанычлы тавышы ишетелде:

— Игътибар! Группа командирларына әзерлек турында белдерергә!

Рапортларны тыңлаганнан соң боерды:

— Һава пиратын бәреп төшерергә. Игътибар! Биш секундлык әзерлек белдерәм. Биш, дүрт, өч, ике, бер. Пуск!

Зәңгәр экраннарда самолетлардан тыш тагын бер нокта пәйда булды. Эх-ма, әкиятләрдәге канатлы ат очамыни! Ул экранның түбәнге өлешеннән югарыга таба хәрәкәт итә. Экранны күзәтеп торучы командир кинәт кычкырып җибәрде:

— Операторлардан кайсыдыр ялгыша. Карагыз!

Ул арада Галимҗан атылып Нигат янына килде:

— Нишлисең син, гыйбад?! — диде ул ачулы тавыш белән. Каушап калган Нигатның кулыннан ручканы алып, үзе боргалый башлады. Ул арада Галимов та килеп җитте: экрандагы нокта алдагы ялгыз ноктага таба юнәлеш алды. Ул аңа якынлашканнан-якынлашты һәм алар бергә кушылып, юкка чыктылар.

— Молодец! — диде эфирдагы тавыш. — Беренче ракета белән үк! Отбой. Самолет бәреп төшерелгән районга разведка җибәрергә!

Бераздан часть командирына бәреп төшерелгән самолетның очучысы тере килеш әсир төшүе, кулга алганда каршылык күрсәтмә-

ве турында хәбәр иттеләр. Ә солдатлар арасында «У-2» маркалы Америка самолетының очучысы Пауэрс исемле икән, чик бозу максаты — безнең хәрби урыннарны фотога төшереп кайту булган икән, дип сөйләделәр...

Батя (часть командирын солдатлар шулай атыйлар иде), частьны тезеп, уңышлы аткан өчен барысына да рәхмәт белдерде.

— Аеруча яхшы әзерлек һәм булдыклылык күрсәткән кайбер иптәшләргә кыска сроклы ял бирү буенча аерым приказ әзерләнер, — дип, бик күпләрне өметләндереп тә куйды.

Галимҗанның гына башы түбән иелгән иде. «Әллә ниткән хатлар килеп торганда миңа ялы түгел, койрыгы да тәтемәс шул инде», — дип уйлады ул.

*

* *

Бу юлы Галимҗанны штабка отделение командиры Савоськин белән бергә чакырып алдылар. Штабта, Ненадышиннан тыш, лейтенант Галимов та бар иде. Галимҗанның эченә җылы йөгергәндәй булды.

Галимов аны яхшы белә. Аңа «якташ» дип йөри, хәл-әхвәлен сорашып тора. Гомумән, Галимов гади кеше. Солдатлар белән шахмат уйный, үзе язган шигырьләрен укып, солдатларның фикерләрен сорый. Шуңа аны Татарстан егетләре генә түгел, башка солдатлар да үз итәләр. Үз күңелен аңлаган кешене кем яратмасын.

Җәй көне мондый бер хәл булган иде. Әрмән егете Саркисян суга батып үлгәннән соң, солдатларга офицерлардан башка елгага бару тыелды. Ләкин якында гына көмеш сулы елга агып ятканда күңел ничек түзсен. Солдатлар берәм-берәм дә, төркемләп тә коенырга шылалар. Җәза бирүләр дә куркытмый. Дежурга барышлый бишенче группа егетләре дә юл уңаенда елгага таба борылдылар. Тик ерак китә алмадылар, лейтенант Галимов очрады.

— Кая киттек, якташлар? — диде ул хәйләкәр елмаеп.

Юра әйтеп салмасынмы:

— Галәмәт эссе бит, чыдар әмәл юк, иптәш лейтенант. Көне — тәмуг кебек...

— Әмма ләкин коену өчен берәр сылтау кирәк, якташлар. Болай тиктомалга елгага бару әйбәт түгел.

Кәлиф үзсенеп үк китте:

— Һәй, иптәш лейтенант, сезнең белән ич без.

— Сәбәпсез-нисез коендырып йөргән өчен мине ачуланмаслар дисезме? — Галимов бераз уйналып торды. — Беләсезме, нишлик? Башта «төп бина»да уборка ясыйк, аннан юынырга дигән булып — елгага. Килештекме?

Килешмиләрме соң? Шунда ук риза булдылар. Башка вакытта көне буена җитәрлек эш бер-ике сәгатьтә ялт итте.

Ул көнне коену гаҗәеп рәхәт булды. Галимов шәп йөзә икән. Кама-Чулман суында коенып үскән Чаллы егете шул. Ул егетләрне, хезмәтне тәмамлагач, КамАЗга эшкә китәргә димләде. «Менә шулай, якташ», — дип, Галимҗанның иңбашыннан да каккалап алган иде...

Бүген исә Галимов җитди күренә. Галимҗанның аңлатмасын укып чыкканнан соң, аны алдында яткан дәфтәр бите янына куеп, нидер чагыштыргандай итте. Ненадышин белән күзгә-күз карашып алдылар. Галимҗанга икенче кәгазьне суздылар.

— Инде шуны ук сул кулыгыз белән күчереп языгыз, — диде.

Сулагайлап язу җиңел булмаса да, Галимҗан ничек кирәк алай күчереп чыкты.

Офицерлар аңлатманың монысын да бик җентекләп карадылар. Майор күзлеген бер киде, бер салды. Галимовка әйтте:

— Юк, бүтән кул бу... — Папиросына ут элдерде. — Иптәш Варисов, бәлки ачыкларга үзегез ярдәм итәрсез... Кемнең язуы мөмкин моны?

Таракан йөргәндәй тигезле-тигезсез хәрефләргә карау белән, танып алды Галимҗан. Нигат! «Син авылда мир үгезе булып йөрер өчен хезмәттән качып киттең, — дип язылган иде хатта, — Нигатның Нәркизен, минем Сәйдимәмне озатып йөрүеңне ишетсәм, кайткач үпкәләмә, каланча. Минем бу хатым кисәтү ракетасы гына әле...» Бу юлларны укыгач, Галимҗан пырхылдап җибәрә язды. Хат ахырында үз фамилиясен күргәч кенә, эшнең бер дә көлке түгел, киресенчә, бик җитди икәнен уйлап тынды.

— Танышмы әллә? — диде Галимов.

— Мм... Юк, иптәш лейтенант, таныш түгел.

— Алай икән. — Бәлки, иптәш сержант, сез таный алырсыз?

Савоськин күзләрен кыскалап хатка карап торды да:

— Так точно, таныйм! — диде. — Нигат Касыймов язган моны.

Галимов ялт кына Галимҗанга карады. «Эх, син, дусны яклый, имеш», — ди иде аның карашы.

— Рядовой Касыймов Нигатны бирегә чакыртыгыз, — диде Ненадышин. — Живо!

Штаб йомышчысы казармага чапты. Бераздан тынына кабып Нигат килеп җитте.

— Моны сез яздыгызмы?

Нигат капыл гына бирелгән сорауга ни диярге дә аптырап калды. Муенын сәер сузгалап, гөнаһсыз күзләрен әле Галимҗанга, әле Савоськинга төбәде. Аннары гадәтенчә сузыбрак, өметсез тавыш белән:

— Так точно! — диде.

— Үзегез генә яздыгызмы, әллә башка берәү беләнме?

— Үзем генә.

— Ник яздыгыз?

Нигат тирләп чыккан маңгаен сыпырып алды да, беткән баш беткән дигәндәй, кулын селтәде:

— Ачуымны басу өчен. Без хезмәт итәбез, ә ул анда безнең кызларны озатып йөри. Миңа сеңелкәш язды...

Мәгънәле көлемсерәү майорның мыек чылгыйларын кузгатты:

— Шулай да хатны үз исемегездән язарга шүрләгәнсез, ә? Солдат кешегә куркаклык бер дә килешми.

— Курыкмадым мин, иптәш майор. Гаптук мине санга сукмаганга Галимҗан исеменнән яздым.

— «Ракета җибәрдем», дисез инде, ә? — Нигат дәшмәде. — Ләкин сезнең ракеталар никтер дошманга түгел, үзебезнекеләр өстенә оча...

Майорның кинаясын аңлап елмаештылар.

— Шәп түгел бу, егетләр, — дип дәвам итте Ненадышин. — Берегез тиешле-тиешсезгә «ракета җибәрә», икенчегез аны яклап калырга маташа. Иптәш сержант, сез комсомол оешмасы секретаре бит әле?

— Так точно!

— Бер җыелышта дуслык-иптәшлек турында сөйләшерсез бәлки. Чын дуслык турында.

Ненадышинның мыек чылгыйлары хәрәкәтләнә башлады. Уттан алып суга салырга җыена микәнни?

— Варисов, без сиңа чик бозучы самолетны бәреп төшергәндә күрсәткән тапкырлыгың өчен кыска сроклы ял бирергә ниятләп тора идек. Нишләргә икән соң инде?

— Мин — «за», — диде Савоськин елмаеп.

— Шулай да бит, менә хатны кем язганын танымыйм дип, тәртип бозучыны яшереп калырга маташа егетең.

— Мин гаепле, төзәлермен! — диде Галимҗан.

Майор елмайгандай итте:

— Ярый, уйлашырбыз. Ә сезгә, рядовой Касыймов, бер атна гауптвахтада утырырга туры килер.

Нигат әллә аңлап җитмәде, әллә Галимҗан өчен сөенүе көчле иде, күтәренке тавыш белән:

— Тыңлыйм, бер атна гауптвахта! — дип куйды.

... Казарма шау-гөр килә. Почта кайткан. Хат ташучы Кавальчукны уратып алганнар. Тегесе хатны тапшырыр алдыннан я җырлата, я биетә. Шигырь сөйләсәң дә ярый. Инде бер һөнәре дә булмаганнар хат белән чиертер өчен борыннарын сузалар.

— Әә-ә, Галич-Галимҗан! — Кавальчук кыр капкадай сирәк тешләрен күрсәтеп елмайды. — Побачешь, Соня-Сәйдимәнән хат. Әйдә, бие әле бер «Эпипәгә».

— Биеттеләр инде... — Галимҗан зәңгәр конвертны тартып алды.

Ул, читкә китеп, конвертны илтифатсыз гына ертты. Кара капларын усал җыергалап, укый башлады. Ләкин укыган саен, аның кашлары языла бардылар. Ул гитара чиертеп солдатларны биетеп-җырлатып торучы Юра янына йөгереп килде:

— Уйна «Эпипәне», Юра дус!

Галимҗанның очына-очына биюенә иптәшләре аптырабрак карап тордылар. Кавальчук кына авызын ерып:

— Бачешь, ничек баса. Чү, чү, казарма идәнен сындырма, — дип сөйләнде.

Биеп туктагач, Галимҗан Юрага:

— Комсомол җыелышы беркетмәсе дип кул куйдырганнар бит Сәйдимәдән, авырып ятканда... Укый алмаган, ышанган. Аңлыйсыңмы, алдалаганнар аны! — дип кычкырды.

Кәлиф шунда ук эләп алды:

— Вәт, дивана, кызны алдаганнар, ә ул шуңа куана!

Барысы да шаркылдап көлештеләр. Галимҗан үзе дә көлүчеләргә кушылды.

1977—1978

## Рәшит Әхмәтҗанов

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

### Хат

Җирне, илне сөеп янган йөрәгемә
Өметсезлек булып берүк килеп кермә.
Тамчы булып тамма син хет елга бер дә,
Өметем бул — чәчәк атам декабрьдә.

### Сугыш

Канлы көннәр артта калган... Кырыс ирләр
Байрак тотып дошманнарны җиңеп кайта.
Ә бер ана белми әле, учак яккан...
Һәлак булган баласына аш кайната.

### Шатлык

Чияләргә төшкән шатлык төсе...
Яртысы ал, ә соң яртысы?
Бөтенләйгә алсу булыр өчен
Җәй үткәнен көтә, ахрысы.

### Кем үпкәли?..

Кем үпкәли һаман яшел үләнгә —
Күңеленең тәрәзәсен күмгәнгә.
Исәннәргә күпме әйтте үлгәннәр:
«Үсә инде, күмә инде үләннәр».

### Сабырлар

Сабырсызның казанында яшь кайный,
Ә башкалар сабыр итә — саргаймый.
Сабырлар сагына белеп сагына —
Һәм баралар кавышыр көн ягына.

## Шакыма әле...

Мин бүген ярым янында,
Борчыма әле, дөнья!
Борчыма! Я бер дә ачмам,
Ишекне ябармын да...

## Күзәтсәң

Күзәтсәң, күрерсең — офыкта
Ни генә кабынмый ут булып.
Ни генә гаҗәпкә калдырмый,
Бер минут эчендә юк булып.

## Тавыш

Уяныгыз, уяныгыз,
Яшәмибез — янабыз!
Йоклар өчен тудырмаган
Җиргә безне анабыз!

## Этюд

Канат чыкты... Оясыннан очты,
Күтәрелде бөркет баласы.
Җилләр очрашты — давыл купты,
Һәм кушылды аңа... яңасы.

## Тугры булды

Сөю миңа тугры булды —
Беркайчан да алдамады.
Булды өмет өзелгән чак —
Ялгамады.

## Гөл үстердем

Таш өстендә гөл үстердем илдә,
Күз яшьләрем тамды шул гөлгә.
Кайда да мин шушы гөлләремне
Тилмерермен кебек күрергә.

## Бүленмим

Күп тә бит шатлыклар йөрәктә —
Кайгылы дөньяның яртысы.
Бүленмим — кайгыны таратсын
Гомернең бар булган яктысы.

## Әзер бул син...

Һәрнәрсәгә әзер бул син, күңел,
Синең дә бар очар кошларың...
Кем әйтәлә, кошлар булмаган дип,
Диңгезнең бу чуерташларын?!

## Диңгез ярында

Кеше балык түгел ласа,
Ә батармын димәгән...
Кешедән түгелдер, диңгез
Үч алгандыр көймәдән —
Ярга бәргән...

## Кем?

Кем чорнарга тели мине
Үзенең карасына?
Ышанып килсен яныма...
Утларда янасына.

## Гүзәл чор

Иртә кабынмасаң да син,
Илеңдә кабын икән.
Яшьлегеңнең гүзәл чоры
Әнә шул чагың икән.

## Тамчы

Соңгы тамчы су саркыды
Җир астына — тамырга.
Һәм шул җитте язга кадәр
Яшәргә... сау калырга.

## Сагыну

Һәрбер сүзем бер матурлык сорый,
Мин фәкыйрьмен — алыйм кайлардан?..
Ярый килдең син: кояштан тамдың,
Шигыремә төштең айлардан.

## Оча

Иртән үләр күбәләктә —
Мәңгелек биргән канат.
Кайгырмый, оча... иртәгә
Туам, ди, гүя кабат.

## Гомерлерәк икән...

Очрыйлар да, шамаилләр укыйм.
Анда Тукай язган шигырьләр.
Аллалардан гомерлерәк икән,
Кадерлерәк икән шагыйрьләр.

## Вакыт

Уятыйм әле талларым сезне,
Вакыт, бик вакыт яфрак ярырга.
Сандугач килеп кунар чак җитте
Җир астындагы һәрбер тамырга.

## Шуңа күрә

Куркаклыкның хурлыкларын куркак күрде,
Батыр булып яшәү җирдә, я, җиңелме?!
Шуңа күрә мәхәббәттән туган көндә
Нәфрәт белән буып куйдым мин билемне.

## Узып бара

Узып бара егерменче гасыр.
Эзләгәнем — тарих эзләре.
Байрак тотып барыйк гасырларга,
Эзләп йөрер, юкса, үзләре.

## Сандугачлар

Сандугачлар диңгезләрдән түгел,
Чишмәләргә килеп су эчә.
Тагын сайрап үзәк өзәр өчен,
Моң эчәләр алар, минемчә.

## Яу кузгалса...

Яудан алда кузгалалар байраклар.
Күтәр аны... Кылычыңны кайрап ал.
Каберең булу мөмкин дошман җирендә,
Тик дошманнар йөрмәсеннәр илеңдә.

## Безнең батыр

Соңгы сүзе — фашист аткан чакта:
«Күзләремне минем бәйләмәгез!»
Шул карашны эзләп, без Җир белән
Көн дә бер кат галәм әйләнәбез.

Роберт Миңнуллин

# МӘҢГЕЛЕК СӘФӘР

## Учак монологы

Утны өреп сүндергәнне
Әйтмәсәгез дә беләм.
Тик... өргәнгә шәмнәр генә
Сүнәләр берәм-берәм...

Ә мин — учак! Сүндерергә
Теләсәгез, өрегез!
Ләкин ялгышканыгызны
Аңлар өргән берегез.

Мин бит очкынланам гына,
Дөрлим генә өргәнгә.
Өрегез, өр! Миңа әле
Дөрләргә дә дөрләргә...

Мин — дуамал: кирәк чакта
Түземсез дә... түзем дә...
Ярсытмагыз! Вакыт җиткәч,
Мин сүнәрмен үзем дә.

Сезнең өрү миңа инде
Кирәк булмас ул чакта...
Тик мин сүнмим! Сез, фәкыйрьләр,
Мохтаҗ әле учакка.

## Арба җырын тыңлап барам

Миннән бәлки көләрсез дә,
Ышанмассыз да, беләм —
Җәйге ялда урап кайттым
Актаныштан... ат белән.

Көне — шифа, өстә — кояш,
Юл буенда — игеннәр.
Янда — кәләш, энекәшләр,
Тулып пешкән киленнәр...

Элек шулай йөри идек
Сабан туйга, базарга.
Ә минем уй — ат турында
Шәп бер шигырь язарга.

Арба җырын тыңлап барам —
Борынгы заман җырын.
Келтер-келтер җырлый арба,
Сагынадыр үз чорын.

Машиналар уза тора,
Чаптар да чаба гына.
Без, чаптар, ашыкмыйк инде,
Барыйк бер чама гына.

Син — узган чор машинасы!
Машиналар үтәрләр...
Алар инде Киләчәккә
Сезсез генә китәрләр.

Анда инде яланнарда
Ялкынланмас ялыгыз.
Ат халкыннан Киләчәккә
Сәлам әйтеп калыгыз!

Безнең бүген бүтән максат.
Барыйк әле бер килеш.
Без бит яңа заманнарга
Юл да бирергә тиеш.

Ашыкмыйк. Әнә безгә ул
Тук башаклар бил бөгә.
Бер барып җитәрбез әле,
Минем кулда — дилбегә...

## Сөн дулкыны

Яраттым диңгез һавасын,
Ул дулкынын, ул комын...
Шул дулкыннар арасында
Таныдым Сөн дулкынын.

Таныдым. Ул үзе килеп
Сыенды аягыма.
Язмыш инде дулкынны да
Ташламый кая гына!

Тулды күңел. Сиздермәдем
Яшь килсә дә күзләрдән.
«Әй, дулкыным, кыяфәтең
Ник бу кадәр үзгәргән?

Хәтта төсең, тәмең, гамең
Түгел бугай элекке.

Син, дулкыным, монда инде
Булалмассың Сөннеке».

Дәшмәде дулкын. Яңадан
Диңгезенә күмелде.
Китте дулкын... Китте тып-тын...
Аңламады күңелне.

Ә диңгез — зур! Сөн дулкыны
Югалды, тынды анда.
Тик тозы калды — ирендә,
Ачысы калды — җанда.

## Мәңгелек сәфәр

Шулай язган инде безгә —
Җирдә гомер итәбез.
Дөнья буйлап, гомер буйлап
Сәфәр чыгып китәбез.
Көннән-көнгә, айдан-айга,
Елдан-елга күчәбез.
Әкияттәге шикелле
Утлар-сулар кичәбез.
Юллар — озын, юллар — тайгак,
Гел алга таба юллар.
Чак-чак кына чәкәшмибез —
Юл биреп кала еллар.
Арттан дөнья куа килә,
Әлегә тоттырмыйбыз.
Атлыйбыз да йөгерәбез,
Чабабыз — тик тормыйбыз.
Ай китәбез, ел китәбез,
Гомер буе җир китәбез.
Кешелекне айлап, еллап
Киләчәккә илтәбез.
...Шулай гомер итәбез.

## Алар мине ташламас...

Кояшлы көн өчен,
Айлы төн өчен...

*(Кулъязулыкка чигелгән сүзләр)*

Мин туугa көннәрем дә,
Төннәрем дә аязган:
Көннәремә Кояш тигән,
Төннәремә Ай язган.

Шатлыкларым — Кояштандыр,
Сагышларым — Айдандыр.
Кайгыларны, хәсрәтләрне
Әйтә алмыйм — кайдандыр?

Мин, мөгаен, Ай-Кояшның
Туганыдыр, улыдыр...
Шуңа күрә җаным Ай һәм
Кояш белән тулыдыр.

...Хыянәтне белми алар:
Ташламаслар алда да.
Кояш һәм Ай булса, миңа
Кыен булмас кайда да.

## Давылдан соң

Тамырлар, кара тамырлар,
Кап-кара җирдән чыгып,
Диңгез җанварлары кебек
Яталар тыпырчынып.

Ботаклар дип хис итәдер
Үзләрен алар өстә,
Хәтта яфрак ярмакчыдыр
Кызыгып яшел төскә...

Юк... ят итәр яктылыкны,
Кояшны да талымлар
Иманнәрне ничә гасыр
Тотып торган тамырлар.

Алар бит бүтән дөньядан —
Караңгыдан, тирәннән.
Аларга кояш кирәкми:
Алар төнгә өйрәнгән.

Көйрәячәк, кибәчәкләр
Алар кояш утында.
Ә аннары берәр абзый
Төяп китәр утынга...

Алар инде яфрак ярмас,
Тамыр килеш калырлар.
Кара ялкын телләредәй
Ята кара тамырлар!

## Туган җиргә ялвару

Туган җирем! Синең җылың
Кирәк бит миңа — аңлыйм.
Мин дә бит каен шикелле —
Кайда да үсә алмыйм.

Үзем — юләр! Сине ташлап
Китмәскә кирәк булган.
Ул чакта әле, күрәсең,
Миндә таш йөрәк булган.

Каһәрлим, тиргим, кичермим
Синнән киткән чагымны.
Шул кирәк миңа, шул кирәк —
Елат, сызлат җанымны!

Гарьлек түгел — әрнет мине,
Сызлауларга карама.
Төзәлмәсен — газаплап тор,
Тоз сибеп тор ярама!

Синдә — җырым, синдә — моңым:
Аерма мине моңнан,
Җибәрмә мине, туган җир,
Җибәрмә мине моннан!

Туган җирем! Өр-яңадан
Гашыйк булдым сиңа мин.
Сызландыр зинһар, сагындыр —
Шәфкатьле бул син. Амин!

## Сабырлык

Әнкәйнең алтын сүзе бар,
Җанга уеп салырлык:
Авыр чакта, улым, сиңа
Бирсен ходай сабырлык.

Булды еллар: ил өстенә
Килгән чакта авырлык,
Ничә тапкыр саклап калды
Нәкъ әнә шул сабырлык.

Без дә үсеп җитмәс кебек
Киләчәккә сарылдык.
Түздек, үстек тәгәрәшеп...
Ярдәм итте сабырлык.

Туза-туза еллар уза,
Җаннарны моң сарырлык
Һәм үксерлек... Ярый әле,
Канга сеңгән сабырлык.

Ә чорыбыз сабыр түгел,
Аннан сабак алырлык.
Мондый чакта безнең өчен
Иң кирәге — сабырлык.

Хәтәр заман! Бер минутта
Җиреңнән көл калырлык.
Калмас... калмас... Кешелекне
Саклап калыр сабырлык!

## Кайда сайраса да...

*Мостай Кәримгә*

Сандугач җырын тирәктә
Яки талда сузамы,
Кайда гына сайраса да,
Тиргәмәгез сез аны.

Сайламагыз аңа урын:
Үзе сайлар оясын.
Моңы йөртә сандугачны —
Аны ничек тыясың?!

Үз биләмәсе — талы да,
Үзенеке — тирәк тә.
Теләсә куна тирәккә,
Талда сайрый кирәктә.

Сандугач — таҗ, моңнар таҗы,
Андагы моң — мең таҗлык!
Торган саен арта гына
Сандугачка мохтаҗлык...

Сандугач сайраган җиргә
Якты моң кунып кала.
Кайда сайраса да, ул бит
Сандугач булып кала!

## Хәмит Төхфи

### Робагыйлар

●

Хезмәт бөек, әгәр анда заман чагылса,
Хезмәт гүзәл йөрәктәге дәрткә кагылса,
Үзенең бар хасиятен югалта хезмәт,
Әгәр дә ул кешеләргә көчләп тагылса.

●

Бер шигырем гүя алтын, бер шигырь көмеш,
Бер шигырьдә ашкынам мин, бердә талпыныш.
Бер шигырьгә бөтен йөрәк сыймый, билгеле,
Зур кояштан анда фәкать кәррәдәй өлеш.

●

Соң көнеңдә дуга кебек бөгелдең, әни,
Касәдәге судай кинәт түгелдең, әни.
Ни булды соң, нәрсә булды, сүндеме кояш?!
Шул хәтле тиз туфрак булып күмелдең, әни!

●

Никадәрле яшьләр акты көйдереп күздән!
Никадәрле эзләр калды китмичә йөздән!
Мин күрмәгән инде берни калмады дисәм,
Күргәннәрем тамчы гына икән диңгездән.

●

Дөнья матур, күрә алсаң матур ягын.
Мин сокланып карыйм аңа тагын, тагын.
Гөлләр гүзәл, таллар нәфис, аларның бит
Әрәм кебек сындырсаң да бер ботагын.

•

Син юк булсаң, кара төндәй булыр көндезем,
Бер күзем яшь, кап-кара кан булыр бер күзем.
Син юк икән — гомер буе яшәргә әзер,
Нәвоидай буйдак булып, ялгыз бер үзем.

## Дүртлекләр

•

Шатлык көчлеме, көчлеме кайгы?
Үлчәп карыймчы мизанга салып.
Алар бертигез — көн белән төндәй,
Алар икесе — ике зур Алып.

•

Шактый белдем дигән идем шигырь һөнәрен,
Инде сере мәгълүм дидем шигъри дөньяның.
Беләм дию никадәрле наданлык икән!
Кәбестәдәй кат-кат икән яфрагы аның.

•

Мин заман дигәнчә йөрмәдем гомер,
Ә минем фикерчә йөрмәде заман.
Килешеп булмаслык шушы низагда,
Билгеле, мин генә, мин күрдем зыян.

•

«Мәңге» сүзен комга яздым диңгез буенда,
Мәңгелеккә калсын дидем «мәңге» дигән сүз.
Тик дулкыннар юып торды комнарны ялап,
Язганымнан калдырмыйча бернинди дә эз.

•

Дусларым хисапсыз бәхетле көндә,
Дусларым миңа яхшы теләктә.
Телдә — һәммәсе ярдәмгә әзер!
Гамәлдә, беркем юк янда — кирәктә!

•

Бәлки мин синнән дә авыр хәлдәдер.
Түзәмдер, чыдыймдыр барына бәлкем.
Нигә мин аңларга тиеш тә барын,
Ник мине аңларга теләми беркем?!

●

Һәр вакыт дошманлык уйлар дошманың...
Файдасы булмаса, зарар юк дустан.
Дошманың үзенә дус күбәйткәндә,
Син исә күбәйтмә үзеңә дошман.

## Фәрдләр

●

Тормыш йөген тарта-тарта кабарды арка.
Җиңеләер дигән саен ул йөк гел арта.

●

Эшеннән таныйлар һәр вакыт аны, —
Югыйсә кешенең юк һич яманы.

Фоат Садриев

# ГАДӘТИ ИРТӘ

хикәя



Совхоз директоры Вәли Гаязович ниндидер бер аңлаешсыз күтәренкелек белән уянып китте. Үзен бер дә төнлә бөтен гәүдәсе ватылып яткан димәссең. Ул маңгаена, битләренә төшкән җылылыктан кояш чыкканлыгын сизде. Ләкин күзләрен ачмады, кояшны куркытыр кебек тоелды аңа. Бик тә кадерле иде шул кояш. Күпме көннәр җәфалады яңгыр. Сенаж салырга да, урырга да юньләп ирек бирмәде. Инде менә озын гомерле генә була күрсен, көн кичә аязды, бүген кояш елмая...

Бөтен тәнгә ниндидер бер рәхәт җиңеллек, кымырҗу таралган. Шулай да кымшанасы, хәтта күзләрне ачасы килми. Сәгать ничә икән? Әле иртәдер, кояш сүрән җылыта. Ул кояш төшкән күз кабакларының кызганлыгын тоеп берничә минут ятты да акрын гына күзләрен ачты.

Шундый да рәхәт булыр икән. Гәүдәнең авырлыгы бөтенләй сизелми дә кебек. Төшеп биисе килә. Тукта, нәрсәдән соң әле бу күңел күтәренкелеге? Ай буе чабып юллаган панельләр кайткандыр бәлкем? Шул каһәр төшкән панельләрне срогыннан алда кулга төшерә алмау аркасында сыерлар өчен комплексның беренче корпусын төзү күпме тоткарланды. Ниһаять, ул заводтан «әйе» дигән хәбәр алды, урып-җыюга килгән автоколоннаның начальнигын кара таңнан барып әләктерде. Дәүләткә икмәк илтүче унбер машина панель алып кайтырга куелды. Чак кына өлгереп калды бит, чак кына! Бүген завод ремонтка ябыла. Аннары көт син аны панельне.

Чыннан да, шушы сәбәпчеме соң бу татлы изрәүгә? Әллә кояшмы? Тукта, ә ни өчен ниндидер сәбәпнең булуы мәҗбүри ди әле? Болай гына шатланырга ярамыймыни бәндәгә? Яшәүнең һәр көне зур шатлык түгелмени? Һәм шушы мизгелдә Вәли Гаязович үзе өчен бер ачыш ясады. Гаҗәеп кызыклы да, зур да кебек тоелды аңа бу ачыш. Хикмәт шунда, кеше гомере буе яшерен бер хыял белән яна: үлгәчтен бик күп еллар үткәч, терелсәң иде дә, дөньяга күз чите белән генә булса да бер карасаң иде, ди. Кешенең әнә шул теләген күпмедер канәгатьләндерергә теләптер инде, җирдәге тормыш тәүлекләргә бү-

ленгән. Тәүлек — ул кеше гомеренең кичерәйтелгән копиясе. Һәр иртәдә безне күпме үзгәреш, күпме яңалык каршылый! Кабат шашып яратасың, кабат үз-үзеңне онытып эшлисең, кабат арыйсың... Һәм кайнар уй-тойгылар вакытлыча сүнә — йокыга таласың... Ә иртән — тагын уяну — терелү шатлыгы. Яшәешнең бу гаҗәеп механизмы теге яшерен хыялның күпмедер дәрәҗәдә чынга ашуы түгелме?

Вәли Гаязович таң белән шундый ярым фәлсәфи, ярым романтик уйларга бирелүенә эчтән үз-үзен мактап та, үзеннән әз генә көлеп тә куйды. Ни әйтәсең, җиңел тәндә — җиңел уй. Шулай да каян туды соң бу очыну? Панель сәбәпче дияр идең, кирпеч белән эш пешмәде. Йөз мең кирпечне билгеләнгән сроктан әй ярым-ике ай алдан алу уен түгел шул. Кичә автоколонна начальнигы янынннан чыгу белән ашап та тормыйча Чаллыга җилдерде ул. Әмма планнары барып чыкмады, бүген тагын китәргә кирәк.

Ул сәгатенә күз төшерде. Әле бишенче генә иде. Айсылу изрәп йоклый. Чем-кара чәчләре җәймәгә таралып киткән, ап-ак муен, йомшак кына сөзәкләнеп төшкән түгәрәк иңбашлар... Вәли Гаязович аны шушы ак муеныннан үбәргә, иякләре белән кытыкларга ярата. Хәзер дә хатынына сокланып карап торды ул. Аннары әкрен генә аның өстенә иелде, иреннәре белән кайнар сулышын тоеп, кабат турайды. Шушындый татлы йокысын бүләргә кыймады. Баксаң, төнге берсез ятмагандыр әле ул. Кичә алар юньләп сөйләшә дә алмадылар. Бик тә, бик тә арыган иде Вәли Гаязович. Арырлык та иде шул. Комплекска быел үлеп-җитеп булса да сыерлар кертергә кирәклеген озын көн буе кемнәргәдер исбатлап, кемнәргәдер ялварып, кемнәргәдер янап озын инстанцияләрне кичкәч һәм кулына тәкъдир каләме тоткан кешегә килеп җиткәч, барысы да чәлпәрәмә килде: әлеге кеше Мәскәүгә очкан булып чыкты.

— Иртәгә иртән кайтырга тиеш, — диде аңа озын буйлы, зәгъфран сары күлмәк кигән, иреннәрен җете-кызыл итеп буяган секретарь ханым. Аның гардин бөҗрасыннан зуррак алкаларына, песи тарысының яшь яфрагы төсле озын алсу тырнакларына, өстәлдәге эре генә апельсинына күз ташлады да чыгып китте Вәли Гаязович. Шул хатынга әллә нишләп ачуы кабырды аның. Фуражкасындагы тузанны ялтыравык өстәленә кагасы килде. Тик кире юлга чыгып бераз суына төшкәч кенә ул үзен тирги башлады. Секретарь ханым бернинди каты сүз әйтмәде, елмаеп кына сөйләште, югыйсә. Чыгып киткәндә ул ханым белән саубуллашмады да, ичмасам. Гаеп йөз проценты белән Вәли Гаязовичның үзендә булып чыга түгелме соң?

Ашамыйча гына кузгалганнар иде, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, юлда «Волга»лары ватылды. Эт булып кайтып ишек шакыганда сәгать уникe тула иде инде. Чите генә башланган бер бәлешне шофер белән икесе ялмап кына куйдылар. Аннан биш йөз километрдан артык юл йөреп кайткан Вәли Гаязович йокы бүлмәсенә кереп тахтага ауды.

...Вәли Гаязович төш күрде. Имеш, Айсылу белән Вәли өстәл янында чәй эчеп утыралар. Шул чакны капкадан әнисе килеп керде. Исәнләшмәде, дәшмәде, елмаймады, көлмәде — акрын гына килде дә уң кулын икесенең уртасына салды... Нәкъ шул чакта ул дерт итеп уянып китте. Сизелер-сизелмәс кенә йөрәге чәнчеп алды. Күңелен әллә нинди тәпсез, бер генә секундка да китми торган хәвефләнү биләде. Ул болай төшкә ышанмаса да, хәвефләнүнең сәбәпләре бар иде.

Аларның авылы совхоз үзәгеннән өч кенә чакрымда. Әнисе шунда ялгызы яшәде. Бирегә күчеп килеп, бергә яшәргә кыстап карадылар — туган нигеземнән аермагыз, диде. Хәтта яңа өй дә сал-

дырттырмады. Тели икән, яшәсен, диделәр. Беркөн, таш кебек йөргән җиреннән кинәт кенә йөрәге тотып, әнисе урынга яткан. Шуны ишетүгә, Вәли белән Айсылу кайтып та җиттеләр. Түшәктә ятып торудан башка әнисенең йөзендә бернинди авыру билгеләре күренми иде.

— Китәрмен, ахры, балалар, күңелем шулай сизә,— диде ул гадәти әйбер әйткән төсле.

— Юкны сөйләмә, әнкәй,— дип юаттылар аны Вәли белән Айсылу. — Әш күп, арыгансың гынадыр.

Әнисе хәлсез генә елмаеп куйды да болай диде:

— Кичә төш күрдем. Өчәүләп бәрәңге алабыз. Сез икегез казыйсыз, мин чүплим. Әллә каян гына әбиегез мәрхүмә килде дә сезнең белән минем арага кулын салды, мине сездән аерды да куйды... Китәргә хәбәр инде бу...

Вәли Гаязович көлде.

— Күргән бер төшкә ышана башласаң соң, әнкәй!

Ләкин әнисе җитди иде.

— Безнең нәсел алтмышны үткәч әллә ни яши алмый шул, улым, — дип, үкенгән сыманрак өстәп куйды.

Алар аны төрлечә юаттылар, әнисе тынычланды, йөрәкнең авыртуы да бетте, диде. Түр тәрәзәне ачтырды, Вәли үзен белгәннән бирле шунда үсеп утырган сәрби куакларына озаклап карап ятты.

Ул көнне Вәли Гаязович Казанга киңәшмәгә чакырылган иде. Шикләнерлек әйбер күренмәгәч, китеп барды. Икенче көнне трест, совмин юлын таптап тагын көн үтте. Ул төнлә генә туры әнисе йортына кайтты, берни уйламыйча, әнисе инде аягына баскандыр, күчтәнәчләр белән чәй эчәр дип кайтты. Апельсин тутырылган зур полиэтилен капчыкны күкрәгенә кыскан хәлдә, әнисен куандырачагын уйлап, ашыга-ашыга ишек алдына кергәндә аның йөрәге нидер сизенде. Өйнең пәрдә тартылган тәрәзәләрендә гөлт итеп утлар балкый һәм үтә тын иде. Тик ул боларны юньләп күңеленә алырга теләмәде, төшенеп җитмәде, нииндидер вак, әһәмиятсез нәрсәгә санады. Инде күңелен утлы хәнҗәрдәй айкап нииндидер бер ачы нәрсә тышка ябырыла башласа да, Вәли Гаязович аны томалады, ирек бирмәде, чынга алырга теләмәде, чөнки ул коточкыч иде, аны өскә чыгарсаң, аның иң газиз, гомер буе үзен җылытып торган кешесе югалачак, тормышлары ятимләнәчәк иде. Бусагадан ул әнә шундый халәттә атлады.

Әнисенең караватына ак җәймә ябылган, аның астында җансыз гәүдә ятканы сизелә: баш турында мендәр батып кергән, борын очы төртеп тора кебек, күкрәгенә, гәүдәсенә аркылы итеп, агач саплы чалгы пычак куелган. Өй тулы карчык-корчык, хатын-кыз... Теге утлы хәнҗәр бөтен җанын көйдереп йөрәгенә кадалды һәм Вәли Гаязович хәлсезләнүдән ишек яңагына сөялде. Шул чак кыйшайган капчыктан бер апельсин төшеп китте һәм түргә таба тәгәрәп, әнисенең караваты янында торган артсыз урындык аягына сыенып туктап калды. Барысы да тын да алмыйча шуңа төбәлделәр. Әйтерсең лә бу минутта дөньяда шул апельсиннан да мөһимрәк нәрсә юк иде... Аннары әнисенең йөзен ачтылар һәм ул сабый бала кебек кычкырып елап җибәрде, идәнгә дөпе-дөпе апельсиннар коелды...

Бүген әни каберенә барырга кирәк дип уйлады Вәли Гаязович. Чаллыдан иртәрәк кайтырга да, бернигә карамастан барырга. Үләренә бер атна кала гына әнисе ак балчык белән сылаган өе күз алдына килде. Балчык стенада бармак эзләре... Кайбер урыннарда ул эзләр тирән булып төшкән, кайбер җирдә исә иркәләп сыпыргандай йомшак, сизелер-сизелмәс кенә. Әлеге эзләргә карагач, Вәли Гаязович-

ның күз алдына әнисенең җылы куллары — гомер буе чүп утаган, урак урган, печән чапкан, бәрәңге алган куллары килә. Шул куллар кайчандыр аның аркасыннан сөйгән, иркәләп чәчен сыпырган иде бит... Шуңа күрә өйне сатмады да, сүтмәде дә Вәли Гаязович. Газаплы авыр чакларында ул шунда кайта, сәрби агачлары каплаган өй артына чыгып, нигез буендагы көлсу туфракка утыра, теге эзләрне бармаклары белән иркәли, әнисенең җылы кулларына кагылган кебек була. Эзләр инде юкка чыкты, ә менә әнисе сылаган балчык исә шактый купшакланса да, әле һаман тора. Бу аның өчен иң кадерле истәлек.

Торырга вакыт. Сәгать җидедә кузгалырга кирәк. Нибары ике сәгать вакыт калып бара. Ул тахтадан тавыш-тынсыз гына төште дә майка-трусиктан килеш залга чыкты. Буялмаган нарат идәнгә ялан аяк басуы рәхәт иде. Трельяж яныннан үткәндә туктап калды. Я, ходай, шушы да булдымы совхоз директоры! Гәүдә дисәң гәүдә, корсак дисәң корсак юк. Кара инде бу сыйракларны! Җитмәсә ботта чәүкә ояларлык чокыр. Немец кыйпылчыгының эзе. Ул ашыга-ашыга көзгедән читкә тайпылды һәм зәңгәр трикосын киде. Картайдың, Вәли. Ике потлы герне сыңар кулы белән ут уйната торган чүкечтәй Вәли юк инде хәзер.

Аның йөрәге кискен генә чәнчеп куйды. Ул хәрәкәтсез катып калды. Бәлкем әнисенең Айсылу белән ике арага кул салуы юкка гына булмагандыр? Сүзләре дә истән чыкмый: «Безнең нәсел алтмышны үткәч әллә ни яши алмый шул, улым...» Моны әнисе нигә генә әйтте икән? Шуңарчы эшлисе эшләреңне тәгәлләп диюе иде микәнни? Юк, җитте, пенсиягә китәргә вакыт. Бераз эшләп диючеләр булыр ул. Ләкин йөрәк болай шаяргач буламы соң? Ул трест әһелләренә дә, район җитәкчеләренә дә шушы сүзләрне әйтте. Бүтәнчә җае да юк иде. Врач кат-кат кисәтте: тынычлык, җиңелчә физик хезмәт, диде. Икенче төрле әйткәндә, өйдә яту була. Түшәмгә төкереп ятмас иде әле ул! Их, ярата Вәли Гаязович җирдә казынырга, салкынча туфракны бармаклары белән актарырга! Тирә-юньдә бер итеп яшелчә, җиләк-җимеш үстерер иде, дүртесе дүрт җирдә оя корган малайлары, кызлары янына барып-кайтып йөрер иде...

Пенсиягә чыгарга тугыз көн генә калды. Әллә шуңа ашыгуы, быел яздан бирле эләктерә дә ала, бөгә дә сала бу йөрәк. Мондый чакта аның аксыл юка иреннәре тагын да кысылалар, уң каш очыннан киң маңгаена күтәрелгән тирән җыерчыгы тирәнәя... Гомер елгасы салган бу ерганакның кайчан барлыкка килүен дә хәтерләми Вәли Гаязович. Сугыштан яраланып кайтканда бар иде инде ул. Шул елдан бирле совхоз директоры. Әйтергә генә җиңел, ә җилкәң белән күтәрә, күкрәгең белән яра башласаңмы!.. Күпме сулар акмаган да, күпме җилләр исмәгән. Ул дәвердә кемнәр генә гүргә кермәде дә, кемнәр генә туып, үсеп җитмәде. Ә Вәли аксаклап чапты да чапты, дөнья куды. Сугыш кырында, ят җирләрдә мәңгегә ятып калган газиз әтисе, ике абыйсы өчен чапты. Дошманга үзебезнең кем икәнлегебезне, беркайчан да баш имәслегебезне күрсәтер өчен үҗәтләнеп чапты. Күзләренә кайнар яшь булып тулган нәфрәткә, әтисен һәм абыйларын югалту ачысын беркемгә дә күрсәтмичә ялгызы йотып чапты. Шуңадырмы, үтә усал, каты куллы булды. Коңгырт бөдрә чәчләре сирәгәйде, дөя йоны кебек төссезләнде, сугыштан кайткандагы таза, базык ир-егет сизелеп ябыкты. Әмма көнен-төнен онытып һаман да чаба бирде.

Чыннан да, җиткәндер, Вәли. Синең бит бәйгедә йөрәге ярылып, халык диңгезе уртасына ухылдап ауган һәм кешедән дә кызганычрак ыңгырашып җан биргән аргамакны үз күзләрең белән күргәнең бар...

Ә турысын гына әйткәндә, һич кенә дә китәсе килми аның. Соңгы вакытларда бу хис аны бик тә борчый иде. Утыз елдан артык бөтен гайрәтеңне, сәламәтлегеңне биргән олы хуҗалыкны ташлау, ай-һай, авыр икән! Совхоз аның шатлыгы да, күз яшьләре дә, бөтен тормышы да. Сәламәтлеге булса, комплексның беренче корпусын бетерми китмәс иде. Йөрәкне иң яндырганы шул. Төзүчеләр бетерәбез, диярләр, төзелеш буенча урынбасар Гайнетдинов, гадәттәгечә, йомшак кына басып, ашыккан кыяфәттә йөри бирер, ә эш шулай сузылыр, сузылыр һәм калыр кебек. Аннары стадион борчый. Комсомол җыелышында быел өлгертергә сүз биргән иде Вәли Гаязович. Гөрләтеп кул чапмаган булсалар да, сүзендә торыр иде. Тукталды стадион. Бөтен көчне, бөтен материалны комплекс суырды. Яшьләрнең күзенә ничек карарсың? Берәр озын чәчлесе: «Пенсиягә китәсе булганга гына вәгъдә биргәндер ул»,— дип тә җибәрсә... Тагын бер хыялы кала — халыкның шәхси малларын бергә җыеп асрауны башлады, тик төгәлли алмады. Аннары... Хәер, күп инде ул андый кул җитмәгән эшләр!

Ишекне ачып чыгуга верандадан ук борынга өлгергән кыяр, чия, карлыган, яшь алма исе бәрелде. Күк йөзе чалт аяз. Йортның урам тәрәзәләре кояш чыгышына карый. Шуңа күрә веранда ягында төшлеккә кадәр салкынча күләгә тора. Вәли Гаязович ишегалды ясамады. Йортның әйләнә-тирәсе бөтенләе белән бакча: анда җиләк-җимеш агачлары үсә, шулар арасында кыяр, помидор, суган түтәлләре, бәбкә үләне, ромашкалар...

Урам яклап кояш инде шактый кыздырса да, баскыч төбендә салкынча иде әле. Вәли Гаязович аягына галошлар гына элде дә кояшлы урынга атлады, үзе аеруча яраткан әнис алмагачын әйләнеп чыкты, вакытсыз коелган берничә алманы кулына алып карады. Аннары тар сукмак буйлап бакчаның түренә үтте, чалбар балакларына сырпаланып калган ромашкаларның ап-ак таҗлары сизелер-сизелмәс кенә тирбәлештеләр. Вәли Гаязович тирән итеп тын алды, борынына, сулыш юлларына йомшак-ачкылт хуш ис килеп керде.

...Бераздан ул сул кулын биленә салып урамнан атлый иде инде. Алгарак иелгән гәүдәсе, уң кулын кызу-кызу селтәве нәрсәнедер ярып-аралап баруны хәтерләтә. Көлделәр, әйтеп карадылар, үзе күпме тырышты — тәки шушы гадәтен ташлый алмады Вәли Гаязович. Кулларын кесәсенә тыгып йөреп тә карады — барасы җирен буташтырды, кая ник килгәнен оныткалады. Шулай итеп, гадәт җиңде, аңа күнектеләр.

Капкадан чыкканда ук күңеленең кайсыдыр бер почмагында канәгатьсезлек уяна башлады һәм адым саен үсә барды. Ниһаять, моның сәбәбен аңлады: өйдә нидер онытылып калган булырга тиеш. Нәрсәсен онытты соң ул? Хәтеренә төшерә генә алмый бит, әй. Ул инде адымнарын бөтенләй акрынайтты һәм туктап ук калды. Әллә Чаллыга алып китәсе документларын оныттымы икән? Вәли Гаязович кабаланып күкрәк кесәләрен актара башлады. Бусы акча, бусы адреслар блокноты. Бусы... Ах, шайтан! Олы малае Илдуска яза башлаган хат һаман бетмәгән килеш кесәдә йөри икән ләбаса! Озак язылды бу хат. Ай тула торгандыр. Юк, вакыт җитмәүдән түгел. Илдус хәрби самолетлар сыный. Узган җәй катастрофа була язып берничә ай больницада ятып чыккан иде. Шуннан бирле Айсылу һәркөн сүз чыгара: баланы харап итәбез, бу эшен ташларга үгетләп хат язйык, ди. Хат саен Илдусның хатыны да шуны үтенә. Аларның ялваруына түзә алмыйча, шуның белән бергә Илдусның әлеге хәтәр эшеннән китүен үзе дә теләп, хат яза башлаган иде ул. Ничәне язып ертты икән? Айсылуга да укып күрсәтте, салам диде, ә салмады. Нидер тыйды аны. Әлеге хатларны яза торгач, соң син, карт тиле,

гомер иткән кеше шундый хат язарга тиешме офицер малаеңа дип сүкте ул ахырда үз-үзен. Сиңа кадерле булган бала башкага кадерле түгелмени? Ә кемнең газизе сынарга тиеш ди ул реактив самолетларны? Әллә НАТО штабы берәр очучысын җибәрерме? Һәм ул тегеләренә бөтенләй капма-каршы рухта бүтән хат яза башлады. Хатны бүген төнлә йокламыйча булса да төгәлләп салырга кирәк. Бүгеннән калдырырга ярамый. Вәли Гаязович хатны иң өскә салып куйды...

Тагын нәрсә соң? Барлык документларын алган. Һәммәсе дә тәртиптә. Ә шулай да нидер борчый аны. Онытылса, кадалыплар гына китсен инде! Вәли Гаязович сул кулын биленә салды да адымнарын кызулатты. Менә үзәк урамның асфальт тротуарына да басты... Тукта, бу ни лаштыр-лыштыр килә соң әле. Шул чак аның күзе аякларына төште: я, ходаем, чуман кадәр ике галош аяк очына чак эләгеп торалар! «Ах, анаңның койрыгы!» — дип, бик ачуы килгән чакларда гына әйтә торган сүзләре ычкынды.

Муеныңа галстук такмаган булсаң бер хәл иде әле. Вәли Гаязович бур кебек куркынып тирә-ягына күз ташлады — бәхетенә, якында беркем дә юк иде. Ул бәбкә үләне белән капланган эт тыкрыгына (аны халык тар булганга һәм кеше йөрмәгәнгә шулай атый) кинәт борылды да, башын аска иеп, өенә лаштыр-лыштыр элдерде. Юл буе үзен-үзе тиргәде. Берәрсе күрсә, дивана диячәк, валлаһи. Склероз шушы инде, картаю шулдыр. Җитте, Вәли. Заманында чаптың, инде кеше көлдермә. Ял кирәк, ял. Карар бик дөрес кабул ителгән.

Ул туфляларын киеп дирекциягә якынлашканда инде алтынчы ярты булып килә иде. Аны ишек төбендә җиде-сигез әрмән каршылады. Директор белән барысы да бердәм исәнләштеләр, ә бригадирлары килеп кул бирде.

— Хәерле иртә, Вәли Гаязович!

— Исәнме, Григорян.

— Сез алдады,— диде Григорян үпкә белдереп.

— Ничек алдадым?

— Алдады. Сказали панель будет. Йок панель.

— Ничек юк? — Вәли Гаязович тавышын күтәргәнен сизми дә калды.

— Йок и все.

— Алып кайтмадыլармыни?

— Йок.

Вәли Гаязович берни дә аңламады. Панельнең кайтмый калуы мөмкин түгел иде.

— Панель бар, китерерләр. Эшли торыгыз,— диде ул.

Бригада шаулашып комплекска кузгалды.

Ул тиз-тиз атлап икенче катка күтәрелде. Болар нидер бутыйлар. Кайтырга тиеш панельләр. Кабул итү бүлмәсеннән узганда ул тагын күзгә каршында туктап калды. Ничек кырыс карыйлар бу яшькелт күзләр. Тирәләрендә вак-вак җыерчыклар күбәйгән. Кызларны һуштан яздыра торган йомшак караш, һәр вакыт шуклык-шаянлык белән нурланып торучы күзләр юк шул инде. Алар хәзер озакка сузылган зилзиләдән соң тынып калган диңгез төсле... Картайдың, Вәли. Ниятләгән эшләрең дә барып чыкмый башлады. Әгәр, чыннан да, панельләр кайтмаган булса? Ул чакта бөтен планнарның асты өскә киләчәк. Үзенчә барысын да хәл иткән кебек иде бит. Әллә аңа шулай тоелган гынамы? Әллә берәр нәрсә онытылганмы?

Ишекне ачкан гына иде, телефон тавышы ишетелде.

— Тыңлыйм, Әкмал Әнвәрович.

Ул трубканы колагыннан алмыйча гына аппарат янына иелгән хәлдә өстәлне әйләнде һәм урындыгына утырды. «Сөт турындадыр, артка тәгәрәдек, бүтәнгә булмас»,— дип уйлады ул сводка кенәгәсен ачып. Тәрҗеманов тегесен дә, бусын да сорашты. Аның ни сөткә, ни уракка, ни төзелешкә тәфсиллэп тукталмавыннан тел төбендә башка нәрсә ятканлыгы ачык иде. Көмеш чәчле, тирән җыерчыклар белән капланган ап-ак чырайлы бу кешене Вәли Гаязович чын йөрәктән хөрмәт итә. Күп еллар бергә эшләгәнгә генә түгел, кешелеклелеге өчен хөрмәт итә ул аны. Әле бүгенгедәй хәтерендә: әнисенең үле гәүдәсе янында сабый бала кебек үксегәндә җилкәсендә кемнеңдер авыр кулын тоеп борылып карады һәм аптырап китте — артында Тәрҗеманов басып тора иде. Шул төнне ул Вәли Гаязович белән бергә утырып уздырды, икенче көнне күмешергә дә килде.

— Яра-ар, алайса-а,— диде Тәрҗеманов тавышын бик нык сузып.— Урак та үтәр, кышы да килеп җитәр. Истә чакта сөйләшеп куйыйк әле, сине хөрмәтләүне алтмыш яшең тулган көнне эшлибезме, әллә креслоңны тапшырган көнне генәме?

Кара син аны, карт төлкене! Вәли Гаязович елмаеп куйды.

— Ул көннәрнең аерылмаячагын сезгә әйттем кебек мин.

— Бер ел көтәм дисең инде, алайса.

— Юк, тугыз көн.

Тәрҗемановның авызы чәпелдәгәне ишетелде. Ул нидән дә булса канәгать булмаса, шулай итә иде.

Шул чак ишек ачылды, совхозның баш бухгалтеры Рәхимов күренде. Аны Вәли Гаязович бүген Чаллыга алып китә. Шоферына иртүк әйтергә кушкан иде. Бухгалтер артыннан рабочком председателе Кәлимуллин, төзелеш буенча урынбасар Гайнетдинов, баш агроном Ленар Маликов һәм пенсионер Закир ага керде. Бүлмә өзек-өзек әйтелгән сүзләр, урындык шыгырдаган тавышлар белән тулды. Гайнетдинов директор өстәленә «Т» хәрефе ясап куелган озынча өстәл буена Вәли Гаязовичка яны белән утырды. Калган өчесе кояш якка караган зур тәрәзәләргә арка биреп урнаштылар. Өчесенең дә җилкә, баш шәүләләре идән буйлап сузылды.

Ниһаять, Тәрҗеманов сүзен дәвам итте:

— Авызыңны да ачма. Елны тәгәллибез әле. Аннары шаулатып-гөрләтеп озатырбыз.

— Булмый, Әкмал Әнвәрович. Инфарктның уен түгеллеген син яхшы беләсең. Больницадан качып кына йөрү.

— Зарланма. Икебез ике тастымал тотып көрәшергә чыгыйк, валлаһи дип әйтәм, син җиңәсең.

Вәли Гаязович бер секундка үзләренең тирләп-пешеп көрәшүләрен күз алдына китерде, кызык булып китте.

— Юри егылыр идегез бугай...

Ул башын өстәлгә иеп иреннәрен кысты, елмаюын яшерергә тырышты, йөзе бурлаттай кызарып чыкты, әмма тыела алмады — пырхылдап куйды. Гомере буе тойгыларын кешеләр алдында тыярга, йөгәнләргә гадәтләнгәнгәме — ул бервакытта да җәелеп торып көлми, соңгы чиккәчә түзәргә тырыша иде.

— Димәк, элек әйткәнеңчә — архивка? — диде Тәрҗеманов.

— Башкача булмый.

— Тузан басмасмы?

— Себереп, селкеп торырсыз әле.

Тәрҗеманов хушлашып трубканы куйды.

Вәли Гаязович каршысында утырган Гайнетдиновка төбәлде. Ул, гадәттәгечә, шикәрдәй ак нейлон күлмәктән, җете кызыл галстук-

тан, стрелкаларына кулыңны кисәрлек итеп үтүкләнгән зәңгәр чалбардан иде.

— Панельләр белән ни булды? — диде директор.

— Булмады, барысы да кайтты.

— Алайса, нишләп аларны Григорян күрмәгән?

— Григорян?

— Панельләр юк ди бит.

— Белмим, алайса...

— Ничек — белмисең? Үзең бушаттырмадыңмыни?

— Хантимергә әйттем.

Вәли Гаязовичның йөзе тәмам бозылды, борын яфраклары дерелдәп куйды.

— Ник үзең бушаттырмадың?

Ул усал карашы белән Гайнетдиновның кабак астына яшеренгән күзләренә кадалды. Әмма урынбасар башын аңа таба әз генә борган килеш тып-тыныч калды.

— Районга бардым. Колхозара төзелеш бүлегенә керергә кушкан идегез бит.

Директорның урындыгы шыгырдап куйды.

— Соң анаңның койрыгы!

— Әллә, ялгышып, дуңгызчылыкка илттеләрме икән?

— Урынын да күрсәтмәдеңмени?

— Сез әйткән җиргә бушатырга куштым.

Вәли Гаязович телефоннан дуңгызчылык фермасын җыйды.

— Гарипов, исәнме? Кичә сезгә панель бушатмадылармы? Белеп әйтәсеңме? Аңлашылды...

Ачу белән ыргытылган трубка телефон аппаратына шартлап килеп утырды. Бүлмәдә күңелсез тынлык урнашты.

— Хантимерне алып кер. Хәзер үк!

Гайнетдинов ашыкмый гына чыгып китте. Вәли Гаязович бүлмәдәгеләргә күз төшереп алды. Кәлимуллин борчулы кыяфәттә Закир абыйга нидер аңлатып маташа иде. Директорга да әллә ничек итеп карап куйды. Гел башын иеп йөрүче бу кешегә ни булгандыр — белмәссең.

— Ни йомыш, Закир абый? — диде ул пенсионерны шул гомер көттерүенә кыенсынып.

— Үзебез салкын суы, кайнар суы краннан килеп тора торган йортларда яшәсәк тә, Чаллы дигәннәрен дә бер күреп кайтасы килә бит, Вәли Гаязович. Үзегез белән алып барып кайтмассызмы дигән идем.

Директор елмаеп куйгандай итте.

— Аңа гына булса, барырсың...

Уе белән һаман панельләрдән аерыла алмый иде әле ул. Чаллыга киткәнче тагын нәрсә генә хәл итеп була соң әле?

— Теге участокны бетердегезме?

Кисәк бирелгән бу сораудан агроном Ленар Маликов утырган урынында яшь тал кебек чайкалып куйды.

— Аңа ике-өч көнсез комбайн кертерлек түгел...

— Мена сиңа мә! Агроном хәтле агроном боерыгыңны үтәмәсен инде. Бер караганда көләч, икенче караганда кара коелып йөрүче бу егет беренче көннән үк Вәли Гаязович өчен табышмак булды. Быел яз килде Ленар Маликов. Ул ишектә күренүгә Вәли Гаязович сискәнеп китте. Агрономның колгадай озын буе, эчкә яшеренгән зур зәңгәр күзләре, алгарак чыгып торган киң ияге аңа бер егетне хәтерләтте. Ул егет Вәли Гаязовичны дошман пулясыннан үз гәүдәсе белән каплап һәлак булды. Ленар Маликов шул солдатка бер тамчы су төсле охшаш иде. Шуңадырмы, беренче очрашудан ук

Вəли Гаязовичта аңа карата яшерен симпатия уянды. Тик эшләвенең беренче атнасында ук яшь агроном үзенең бик үзсүзле һәм дөртләп кабынучан булуы белән күпләрдә тискәре фикер тудырды. Иң элек ул теге яки бу культура өчен чәчү мәйданы дөрес билгеләнмәгән, үзгәртергә кирәк, дип Вəли Гаязовичка килеп керде. Аңлаша алмадылар. Агроном директорга аяк терәп каршы торды. Ахырда дулап район авыл хуҗалыгы идарәсенә китте. Анда баш агрономның чак кына якасыннан алмаган. Өч көн дәвам иткән шау-шудан соң, планга барыбер күпмедер үзгәреш керттеләр. Димәк, Маликов юкка чәпчемәгән булып чыкты. Инде шушыннан соң симпатия арта гына башлады дигәндә, агроном чәчү буенча югарыдан бирелгән рекомендацияләрнең һәрберсен үзенчә җимерә башлады. Аз гына арада барлык белгечләр белән конфликтка кереп бетте. Яшьлек дуамаллыгымы бу? Үзен күрсәтергә теләүме? Беркемне дә санга сукмаумы? Әллә институтта алган белемнәрен чынчынлап, үзе белгәнчә, үзе теләгәнчә кулланырга омтылуымы? Әлеге сорауларның берсенә дә әле җавап таба алган юк Вəли Гаязовичның. Ләкин шунысы ачык, агроном төрле яклап мушкага алынган иде.

Вəли Гаязович аңа сынап карады.

— Кичә мин нәрсә дигән идем?

— Комбайн кертергә куштыгыз...

— Кушкач?

— Мин басуны аркылыга-буйга йөреп чыктым — тигез өлгермәгән.

Ул кесәсеннән бер уч башак алып директор өстәленә салды. Вəли Гаязович «ә» дә димәде, «я» дә димәде. Чөнки ни әйтсен, басуда соңгы вакытта үзенең булганы юк, бүлекчә агрономы Сабировка карарга кушкан иде. Ул: өлгергән, иртәгәдән суктырырга кирәк, диде. Вəли Гаязович гомер буе агроном булып эшләгән кешегә ышанды. Әллә басу читеннән генә караганмы картлач? Директор башаклардан бөртекләрне алып, тырнагы белән баскалап-баскалап карады. Әгәр мондый урыннар күп икән, әлбәттә, иртәрәк. Ул бер нәтиҗәгә дә килергә өлгерми утырганда, бүлмәдә баш зоотехник Котдус Мирзаяновның мәгарәдән чыккандай көчле тавышы яңгырады.

— Исәнмесез. Гафу итегез, бер генә минутка.

Мирзаяновның ашыкмаган чагы юк. Шуңа күрә кайчан гына булмасын — утырыш барамы, бик җитди җыелышмы — аның теләсә кая бәреп керүенә күнегеп беткәннәр. Ишеге ярым ачык калды, өч атлауга ул Вəли Гаязович янында иде инде.

— Берсекөнгә трестка семинарга чакыралар, — диде ул, телефонограмма сузып. — Барырга булса, иртәгә китәргә туры килә.

Вəли Гаязович телефонограмманы ашыгып кына укыды, «обеспечьте» дигән сүзнең «ч» хәрефеннән соң кызыл карандаш белән йомшаклык билгесе төшерде. Зоотехник авыз эченнән гөрелдәде:

— Ашыгыч алынды...

— Ә мин берни дә әйтмим бит, Котдус.

— Аннары сыерларга ике йөз грамм булса да фураж арттырырга иде. Сводкада унбишенче урынга тәгәрәдек...

Вəли Гаязовичның иреннәре дерелдәп куйды. Моннан соң директордан уңай сүз чыкмасын һәркем яхшы белә иде. Ахры, шуңа күрә, зоотехник уңгарак янтайган кебек булды. Алар икесе дә нәрсәдер әйтергә теләп авыз ачмакчылар иде, шул чак телефон шалтырады.

— Нихәл, әтисе? — Аның йомшак кына көлгәне ишетелде. Вəли Гаязовичның тәненнән бер җылы агым узды. — Көтәм. Самавар белән икебез зарыгып көтәбез.

— Унбиш минуттан, — диде Вәли Гаязович хатынына, ягымлы булырга тырышып. Һәм трубканы куеп зоотехникка борылды.

— Фуражга исәп тотма, Котдус. Нокта фуражга. Егетләр белән фикерләшегез, тәкъдимнәреңне иртәгә планировкада әйтерләр. Ә семинарга килгәндә... барырга кирәк.

Зоотехник кергәндәгедән дә зуррак итеп ике атлады да юк булды. Вәли Гаязович тагын башакларны кулына алды. Сортлы бодай... Ике-өч көн көтәргә. Ышанып әйтәме соң ул моны? Бу минутта директор өчен шушы сорауга дөрес җавап табу сортлы бодайга караганда мөһимрәк иде. Ахыргача тора алырсыңмы, егеткәй?

— Директорга буйсынмыйм, дисең инде, агроном?

Ленарның бугаз төене хәрәкәтләнеп куйды.

— Әгәр алдан суктырсак, орлыкның яртысы гына чәчәргә яраклы булачак.

— Син иртәгә тагын яңгырлар башланмас дип уйлыйсыңмы?

— Аны түкми-чәчми урып-җыюны мин үз өстемә алам.

— Үкенмәссеңме?

— Үкенмәм!

— Ә мин тагын бер уйлап карарга киңәш итәр идем.

Бу юлы агроном дәшмәде. Тынлыкны Гайнетдинов белән Хантимернең керүе бозды. Гайнетдинов баштагы урынына үтте, тегесе ишек янында басып калды. Совхозда Хантимерне кыска буйлы булганга Хантиметр дисәләр, бераз «төшерергә» яратканы өчен Хантилитр дип йөртәләр. Аның чырае — кып-кызыл һәм каз мае сөрткәндәй ялтырый, шуңадырмы — анда сакал-мыекның әсәре дә юк. Гадәттәгечә, пожарныйда эшләгән вакыттан калган гаять зур размерлы галифеен кигән. Аның да төбе тезгә кадәр асылынып торганлыктан, нык кыршылып шомарган, төссезләнгән иде.

— Утырыгыз, — диде Вәли Гаязович, тыныч булырга тырышып.

Хантимер кыска тәпиләрен бөгеп ишек янындагы урындыкка түнтәйде.

— Сезгә кичә панель бушатырга әйтелгән идеме?

— Әйтелде...

— Бушаттыгызмы соң?

— Эш көне беткән иде бит инде.

Гайнетдинов бармак янап куйды:

— Алдашма, ярты сәгатьтән артык вакыт бар иде әле.

— Шул арада җитешеп була идеме соң? Мин татарча әйттем: бушатмыйм дидем.

— Ә мин бушатырга куштым.

— Сәгать чыккач, телим — эшлим, теләмим — юк. Закон бар, — бу сүзләрне ул туп-туры директорга карап әйтте.

«Нишләп соң әле ул Гайнетдинов белән сөзешәсе урында мөгезләрен миңа бора? Моның нигезендә нәрсә ята?» Вәли Гаязович менә шушы нәрсәгә һич тә төшенә алмады.

— Соң шуннан? Ә машиналар? — диде ул, тыныч калырга тырышып.

— «Урожай»га киттеләр.

Директор ашыгып бөтен гәүдәсе белән уңга — тумбочка өстендәге телефон аппаратларына борылды. «Урожай» колхозы председателен алды.

— Шамил Хәрәвиевич? Хәерле иртә. Кичә сиңа панельләр килдеме?

— Килде.

— Бушаттыгызмы?

— Әлбәттә. Әллә бер-бер хәл бармы?

— Заводтан без алган панельләр иде бит алар.

— Ә мин белмәдем. Ялгыш икән — алып китәрсез...
— Калсыннар. Эш бөтенләй башкада.
— Вәли Гаязович, миңа ачуланасыз, ахрысы?
— Юк...
Сөйләшү шуның белән тәмам булды.
Вәли Гаязович керфек тә какмыйча билгесез бер ноктага төбәлеп хәрәкәтсез калды. Ул күз чите белән генә Гайнетдиновка карап алды һәм аның йөзендә ниндидер шатлык галәмәтенә тап булды. Әллә ялгышамы? Шуңа ныклап ышану өчен башын боруга, Гайнетдинов җитди-кайгыртучан кыяфәт алган иде инде. Ләкин шул мизгелдә Вәли Гаязович Гайнетдинов белән Хантимернең, берберсенә карап, сизелер-сизелмәс елмаюын абайлап калды. Гайнетдинов карашын яшен тизлегендә читкә күчерде, тегесе исә астыртын елмаюын тиз генә җыярга өлгерми калды... Менә эш нәрсәдә. Димәк, болар икесе бергә аны мәче тычканны уйнаткандай уйнаталар. Ул ачуыннан сикереп торды, яңадан утырды, аннары Кәлимуллинга карап:
— Бу бит оста кранчы... Ни әйтәсең? — диде.
— Җыелышта тикшереп тә туйган инде, Вәли Гаязович, — диде Кәлимуллин, тагын нидер өстәргә җыенды — өлгерә алмады.
— Бүген үк рабочкомда аны кранда калдыру-калдырмау мәсьәләсен карарга кирәктер, минемчә.
— Анысын карарбыз...
— Сезгә чыгарга мөмкин, — диде Вәли Гаязович Хантимергә.
Хантимер бер сүз дә әйтмәде, ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып китте.
— Я, Гайнетдинов, нишлибез? Завод ай ярымга ремонтка ябылды.
— План буенча комплексның беренче чираты декабрьда гына файдалануга бирелергә тиеш иде бит әле. Без болай да дүрт айга алда барабыз.
Гайнетдинов берни булмагандай утыра. Әнә ул күлмәгенең җиң очындагы нечкә кара сызыкны баядан бирле тырный: тукымага нәрсәдер ябышкан, күрәсең дә, аның өчен бу минутка шуннан да мөһимрәк нәрсә юк иде.
Тынлыкны бозып, Кәлимуллинның дулкынланулы тавышы ишетелде:
— Вәли Гаязович, бер генә сүз... — ул урындыгыннан күтәрелде.
— Сабыр, — диде аңа директор кырыс кына. Аннары Гайнетдиновка төбәлде.
Гайнетдинов, күлмәген тырнаудан туктап, башын директорга борды. Зур театрларның бәрхет пәрдәләрен хәтерләтә торган шешенке күз кабаклары яртылаш күтәрелделәр. Аларның шуннан артык ачылганы да юк.
— Мин сезне аңлап бетермәдем.
— Әллә үз гомереңдә берәр мәртәбә борчылып карыйсыңмы, диюем.
— Һәркемнең үз характеры. Темперамент күрсәтеп кенә эш барса икән...
— Ә эшләнмәгән эшкә ялган наряд тутырырга каян килде темперамент?
— Үзебез гаепле: төзүчеләрне эш белән тәэмин итә алмадык.
— Ник тәэмин итмәдең соң? Мәшәкатьләнәсең килмәде, шулай бит? Ә болай тавышланасы да юк, җитмәсә, төзүчеләр табан астында туфрак булырга әзер. Акча — дәүләтнеке.
— Шуннан дәүләт бөлә иде инде...

— Дәүләт түгел, ил бөлә!

— Нигә инде шундый югары материяләргә күтәрелергә? Ил, Ватан... — Ул көлемсерәп башын чайкап куйды.

— Ә син ирония белән әйтмә бу сүзләрне! Юкса, бәреп теш сындыруың ихтимал. Син башта ил өчен берәр тамчы каныңны тамызып кара. Синең өчен ил — үзеңә умырып алырга тиешле ләззәтләр булса, безнең буынга ул — карыныбыз белән кар ярып, борыныбыз белән боз ярып тергезгән иң изге әйберләр. Безгә илдә нәрсә баруы да, без кан коеп төзегәннәрдән кемнәрнең ничек файдалануы да барыбер түгел! Юк, түгел!

Гайнетдинов ике алтын тешен күрсәтеп, авыз чите белән генә елмайды:

— Сез үзегезчә яшәгәнсез, без үзебезчә яшәрбез. Тормыш бара бит әле...

Ул Вәли Гаязовичның күзләренә туп-туры карап елмайды. Бу елмаюда: син тиреңнән чык, мин барыбер шушылай йөриячәкмен, дигән нәрсә ярылып ята иде. Хәлләрең мактанырлык түгел, шуңа күрә үз җаеңны чамала, ә син киткәч... без үзебез карарбыз инде монда, ди иде төсле бу караш...

Тукта, каян килгән моңа бу кадәр кыюлык? Ике елдан артык төлкедәй астыртын гына карап йөрүче, һәр вакыт күзләрен яшерүче Гайнетдинов түгел бит бу. Әйтерсең, алыштырып куйганнар үзен. Хантимергә артык гаҗәпләнмәде дә Вәли Гаязович. Аңардан башканы көтеп булмый. Ә бу соң, кем соң бу? Бу ачыктан-ачык оятсыз караш Гайнетдиновныкы түгел иде. Димәк, элек ул алданып йөргән. Чыны — бусы. Ә ник масканы кинәт алып атты соң әле ул? Ни булды? Нигә бу кадәр туры һәм оятсыз карый бу күзләр? Ни өчен кимсетүле елмая соң әле ул? Ник Вәли Гаязовичка үзеннән ким, көчсез кешегә караган кебек елмая?

Вәли Гаязович аның сабый балаларныкы кебек алсу бит очларына, крахмаллы ак якадан ташып торучы муенына нәфрәтләнеп карап торды. Туры борын, кап-кара каш. Йөзен әлеге күз кабаклары гына боза, боза гына түгел, ниндидер тәннәрне чымырдаткыч җирәнү уяталар алар... Яртылаш та күтәрелмәгән күз кабагы читеннән күренеп алган зәңгәр күз бер караганда каһкаһә белән көлә, бер караганда винтовка көпшәсен хәтерләтә. Ә колак төбендә әлеге сүзләр: «Сез үзегезчә яшәгәнсез, без үзебезчә яшәрбез. Тормыш бара бит әле». Көлү катыш яңгыраган бу сүзләр Вәли Гаязовичның йөрәгенә таш булып утыра.

Телефон тавышы. Бер, ике, өч... Вәли Гаязович, өстенә коточкыч йөк баскандай, дәшми. Аның зиһене таралган, гәүдәсен ниндидер хәлсезлек биләгән иде. Ниһаять, ул авырлык белән генә трубкага үрелде.

— Сәлам, Вәли Гаязович! — район советы башкарма комитеты председателе Ризвановның һәрвакыттагыча көр, тәвәккәл тавышы аны бераз кузгатып җибәргәндәй булды. — Без синнән бүтән җавап көткән идек тә. Ярый инде, синеңчә булсын.

— Рәхмәт, Марс Ризванович.

— Ләкин табигать бушлыкны яратмый. Үзеңнең тәкъдимең бармы?

— Юк шул әле...

— Ул чакта миндә бар.

Вәли Гаязович сискәнеп киткәндәй булды.

— Кем ул? — диде ул бик акрын гына.

— Хәтерлисеңме, моннан бер атна элек минем кабинетта икәү сөйләшеп утырганда өченче кеше килеп керде! Шуңа тукталабыз.

Вәли Гаязович өнсез калды, аның тыны кысылды. Ул чакта Риз-

ванов кабинетына кергән кеше... Гайнетдинов иде! Әйе, әйе, башка беркем дә кермәде, ул моны ачык хәтерли...

Вәли Гаязович, үзе дә сизмәстән, ялт итеп Гайнетдиновка борылды. Аларның күзләре тагын очраштылар. Гайнетдинов керфеген дә селкетмәде, күз почмагы белән элеккечә карап тора бирде.

— Мин теш-тырнагым белән каршы, — диде ул, Гайнетдиновның күзләреннән күзен алмыйча. Гайнетдинов сүзнең үзе турында барганлыгын сизенде, «Я, кем кемне», — ди иде бу караш.

Вәли Гаязовичның йөзенә җәберсену билгеләре чыкты. Бүлмәдәгеләр директорның кара януына, аның ике яклап асылынып төшкән иреннәренә куркынып карадылар. Вәли Гаязовичның йөзендәге җыерчыклар тирәнәйде, һәрбер күзәнәге сулкылдап, бәргәләнеп типте. Көтелмәгәндә туган хәлдән бер мизгелгә югалып калу иде бу. Ризванов үзе нинди зирәк, тәҗрибәле җитәкче, ә Гайнетдиновның кем икәнлеген белми икән әле. Бу бөтенләй башка сыймый. Икенче мизгелдә ул капма-каршы уйларга керде. Гайнетдиновны Ризвановның туганы диләр, аңа Мәскәүдәге танышы аркылы сирәк очрый торган китаплар кайтартып бирә, диләр. Әллә хакмы? Ни генә булмасын, Гайнетдинов Ризванов каршында икенче төрле маска киеп эш итә.

— Ул сез уйлаган кеше түгел,—бу сүзләрне Вәли Гаязович шундый ачу, рәнҗү, нәфрәт белән һәм Гайнетдиновның бәбәкләренә кадалып әйтте ки, бүлмәдәгеләр, барысын да аңлагандай, урынбасарга төбәлделәр.

— Вәли Гаязович, кадрлар сайлаганда мин үз гомеремдә ике мәртәбә генә ялгыштым, — диде Ризванов. — Әгәр бусы өченчесе булса, мин синнән гафу үтенергә һәм хатамны төзәтү өчен барысын да эшләргә әзер. Ә бүген кич мин фикеремне бюро членнарына белдерергә тиеш.

«Миннән дә юләррәк кеше бармы икән? — дип, үз-үзен битәрләде Вәли Гаязович. Ризванов тәкъдим итсә итә белә инде ул. Хәер, Гайнетдинов үзен күптән инде тәкъдим итте. Төзелеш мәсьәләсе тикшерелгән район советы сессиясендә ничек чыгыш ясады! Бернинди язусыз-нисез. Ә нинди фикерләр! Министр диярсең. Җитмәсә, узган ел санаторийга киткәндә директорлыкны аңа тапшырган иде. Бераз муенына тузан кунсын, йокысы ачылсын дип, юри аны калдырган иде Вәли Гаязович. Тырышкан-тырмашкан — үзен күрсәткән Гайнетдинов. Кайтуына район җитәкчеләре мактап та торалар үзен, сынатмады, молодец, диләр. Вәли Гаязович та сөенде. Җитмәсә, Гайнетдиновны элек санга сукмавы, кискен бәрелүләре, җыелыш-киңәшмәләрдә тәнкыйтьләүләре өчен эченнән генә үкенде дә әле. Мин аңа инициатива бирмәгәнмендер, инициатива биргәч, әнә ничек җәелеп эшләгән, дип үзен сүкте. Шуннан аңа тулы ирек куйды, ләкин... Гайнетдинов элеккедән дә шомарак эш итә башлады. Эшләгән булып кылану өчен күпме энергия кирәк булса — ул шуны гына сарыф итте. Вәли Гаязовичның беркемгә дә аның хакында зарланып сөйләгәне булмады. Аның каршында көчсезлеген күрсәтәсе килмәүдән генә түгел, үзебез тәртәгә җигәргә, кирәк икән камчылап кеше итәргә тиеш дип уйлады. Хәзер инде әйтүе дә кыен, юри уйлап чыгара диярләр, барыбер ышанмаслар.

— Сез дә минем фикер белән хисаплашырга тиешсездер, — диде ул Ризвановка көчсез тавыш белән.

— Вәли Гаязович, аңламыйм, син ник каршы киләсең әле?

— Мин сезгә каршы килмим.

— Каршы килмә. Киресенчә, син хупларга, минем белән бер сүздә булырга тиешсең.

Шул чак Гайнетдинов Вәли Гаязовичка күз кысып куйды. Вәли

Гаязовичның карандаш-каләмнәр тутырылган пластмасса савытны аның алтын тешләренә, салынкы күз кабакларына тондырасы килде. Ул уң йодрыгының кысылып төйнәлгәнен сизеп, аны тиз генә өстәл астына яшерде.

— Ә сез беләсезме соң ул затның тулы мәгънәдә паразит икәнен?

— Ну, ну, мондый сүзләр белән син саграк! — Ризвановның нәрсә беләндер өстәленә чык-чык сукканы ишетелде. — Ә ник тотасың син аны паразит булгач? Арагызда килешмәүчәнлек бардыр, элекләрне онытмас, пенсионер кешегә кырын карар дип дә борчыласыңдыр. Анысы икегезнең эшегез, ә безгә районның уннан берен алып торучы эре совхозга хуҗа кирәк.

— Мин үз фикеремдә калам һәм теләсә кемгә шуны кабатлаячакмын.

— Әгәр инде син минем теләккә каршы икәнсең, башка кандидатура әйт.

Вәли Гаязович дәшмәде. Ачудан аның чигә тамырлары тартыша, колагы чыңлый иде. Гайнетдинов исә боты өстенә ботын салып, гәүдәсен артка табарак аударды, култыкларын урындык артына киереп салды. Хәзер ул Вәли Гаязовичка өстән аска таба карый иде.

— Нигә тынып калдың? Я, әйт, кем? — Ризвановның тавышында ниндидер көлү ишетелде кебек.

— Әйтәм, — диде ул.

Күпме күкрәк көче кергән шушы совхозның дилбегәсен Гайнетдиновка бирергәме? Юк, бу мөмкин түгел! Ләкин кемне калдырырга? Сугыштан соңгы еллардан алып бүгенге көнгәчә нинди генә авырлыклар, нинди генә ачы көннәр кичермәде ул бу хуҗалыкта. Ләкин барысын да җиңде. Гомеренең күкрәп торган чагын биреп корган нәрсәңне Гайнетдиновка какшаттырыргамы? Йөрәгеңне учыңа кысып, шуны карап торыргамы? Юк, бусы булмас! Ләкин кемне тәкъдим итәргә соң? Дөрес, бу хакта ул уйланмады түгел, бик күп уйланды, партком секретаре Мәҗитов белән дә бәхәскә кереп бәтеләр. Вәли Гаязовичның директор итеп кайнар йөрәкле, тәвәккәл яшь кешене калдырасы килә иде. Чөнки, аның уенча, хәзерге заманның кызу агымында бару өчен, олы эшләр кайнап торган зур хуҗалыкка дөрес, оператив җитәкчелек итү өчен әнә шул сыйфатлар бигрәк тә кирәк. Әгәр юк икән, җитәкченең маңгаеннан кара тир тама... Үзенә калса, тынгысызлыгы белән агроном Ленар Маликов директор урынына иң кулай кеше кебек. Ләкин аны аңлап бетереп булмый, ә сыналмаган кешене тәкъдим итү — беркатлылык булыр иде. Ичмасам, иң кирәк чакта Мәҗитов авырып китмәгән булса иде...

— Тыңлап карыйк, кем икән ул совхозны җитәкләргә сәләтле кеше?

— Ә сез алдан ук күсәк күтәреп тормагыз.

— Мин зур кызыксыну белән көтәм.

Ризвановка кемне тәкъдим итә ала иде соң Вәли Гаязович? Бер генә кешене. Ризвановның аңа каршы килә алмаячагы көн кебек ачык иде. Һәм Вәли Гаязович әйтте:

— Үземне күрсәтәм. Башка вариант юк.

Ризванов бераз дәшми торды. Әйтерсең телефон эшләүдән туктады. Гайнетдиновның ике күз кабагы да тәмам асылынып төшкән. Карыймы ул алар астыннан, юкмы — аермалы түгел. Сөяп куйган мәет тә мәет, Гайнетдинов та мәет бу минутта.

— Ишеттегезме? — диде Вәли Гаязович һаман да тынсыз калган Ризвановка.

— Уракны бетерергә карар кылдыңмыни?

— Юк, тулы бер хуҗалык елын.
Ризванов тотлыккандай булды, тамак кырды.
— Сезнең кайсыгызга ышанырга соң инде: Тәрҗемановкамы, сиңамы?
— Икебезгә дә. Ләкин әйтелү тәртибе буенча.
Ризванов сәер генә көлеп куйды.
— Ул чакта кабат директор булуың белән!
— Хушыгыз.
Вәли Гаязович үзен арып-талып озак күтәреп барган авыр йөкне бер җилкәсеннән икенчесенә күчергәндәге кебек хис итте. Ничә көннәр, ничә айлар татлы хыяллар белән яшәде ул. Пенсия, бакча үстерү, йөрәкне дәвалау. Сер итеп кенә әйткәндә, ул бер җитмешкә кадәр яшәп алырмын дип уйлый иде. Беркемгә дә, хәтта Айсылуга да әйтмәгән яшерен бер өмет иде бу. Ул әле академик А. А. Микулин язып чыккан актив рәвештә озак яшәү системасын кулланырга хыялланды.
Уйларын Маликов бүлде:
— Миңа китәргә мөмкиндер бит?
Вәли Гаязович башакларны алды да, агрономга янагандай, баягы сорауны кабатлады:
— Тагын бер мәртәбә чынлап уйладыңмы?
— Уйладым, — диде тегесе ышаныч белән. — Көтик, Вәли Гаязович.
Директор аңа авыр караш ташлады. Юк, икеләнми иде агроном.
— Синеңчә булсын, көтәбез.
Вәли Гаязович берничә генә секундка күзләрен йомды, шунда кабат телефон аваз салды. Трубкада Айсылуның сузынкы тавышы ишетелде:
— Вәли Вәли булмыйча кем булсын соң!
— Гафу ит... — аның нинди дер җылы сүзләр әйтәсе, акланасы, үзенең гаепсез икәнлеген аңлатасы килде, ләкин бер генә сүз дә таба алмады. Сәгатенә күз төшерде. — Гафу ит, мин кайтырга өлгерә алмадым... Хәзер инде Чаллыга кузгалам...
— Вәли, күпме дәвам итәргә мөмкин соң бу? Үзеңдә кан басымы, йөрәк, гастрит. Үзең һаман...
— Иртәгәдән — тәртип, — диде ул, үз-үзенә нык ышанып. Чаллыдан шушы кирпечләрне юлласа, чыннан да, эш кими бит. Хәер, ничә дистә еллар инде ул иртәгә тынычрак булачагын үз-үзенә һәм хатынына ихлас күңелдән ышандырып килә. Тик тормыш дигәнең барыбер үзенчә куалый, барысын бутый, үзгәртеп тора. Син уйласаң алтыга, дөнья кисә яртыга, дип белеп әйткәннәр.
— Ичмасам, кайчан күрермен шул пенсиягә чыгуыңны!
Вәли Гаязович ни әйтергә белмичә төртелеп калды, аннары ашыгыч кына:
— Кич сөйләшербез, — диде һәм трубканы куйды.
Шул чак көтелмәгән хәл булды. Баядан бирле үзенә урын тапмыйча утырган Кәлимуллин кинәт сикереп торды да Гайнетдиновның каршына барып басты һәм кычкырып җибәрде:
— Ялган! Барыбызны да алдый!
Үз гомеренә кешегә бер каты сүз әйтмәгән Кәлимуллинны мондый хәлдә күрү булмадагыларнең һәркайсына аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Хәтта Гайнетдиновның да күзләре шакмакланды. Шулай да ул яртылаш көлү, яртылаш мыскыллау кушылган тавыш чыгара алды:
— Син нәрсә? Әллә шизофренияң башландымы?
— Панельләрне шушы шома көпшә үзе озаткан булырга тиеш! — диде Кәлимуллин аңа күрсәтеп.

Гайнетдиновның күзләре караңгыда өркетелгән сарыкныкы төсле хәтәр ялтырап куйды.

— Сүзләреңне кабат җыеп алып, җавап бирергә туры киләчәген онытма!

— Бирермен! Ни өчен синең машинаң кичә төнге унберда «Урожай» прорабының капкасы төбендә тора иде?

— Шунда куйганга күрә.

— Тәнгә ябышкан хәшәрәт икәнсең син! Тфү! — Кәлимуллин ачу белән төкерде дә урынына барып утырды.

Вәли Гаязович барысын да аңлап, ниһаять, тыела алмады — өстәлгә сукты.

— Күпмегә сатылдың?!

— Ниндидер уйдырмага таянып, миңа җикеренмәвегезне үтенәм!

— Мин синнән татарча сорыйм: панельләрне озаткан өчен күпме алдың?!

— Миңа берни дә кирәкми. Ә менә сезгә килгәндә... комплексны срогыннан алда бетереп, дан һәм орден алырга исәп тотасыз. Нишлим соң — мин сезгә бу эштә башка ярдәм итә алмамдыр инде.

Гайнетдинов кесәсеннән кәгазь алып Вәли Гаязовичның алдына салды.

— Мин сезнең белән эшли алмыйм. Менә гаризам.

— Исәп ычкынырга мы? — Вәли Гаязович аның каршына ук барды һәм йөзенә иелде. Аның тавышы инде ярым пышылдап чыкты: — Синең кебекләр — үзенә аерым дәүләт. Кабахәт кеше бер кабахәтлек эшли дә җәзасын ала. Ә син явызлыкны һәр секунд саен, аз-азлап, яшертен генә эшлисең. Сезнең кебекләрне эләктерүе кыен. Ләкин без сезне буйсындырырбыз!

Аның тыны кысылды. Кесәсен капшады — валидолы да юк иде. Вәли Гаязович кыяфәтенә берни дә чыгармаска тырышты. Киресенчә, Гайнетдиновның калтыранган керфекләренә карап елмайгандай итте. Бүлмә тып-тын. Тәрәзәдә умарта корты безелдәгәне генә ишетелә. Ул, пыялага төртелә-төртелә безелдәп, бер өскә менә, бер аска төшә. Вәли Гаязович акрын гына тәрәзә янына килде һәм форточканы ачты. Умарта корты ерак зәңгәрлеккә чыгып очты. Тагын телефон шалтырады. Тагын Айсылудыр, юлда капкаларыңа әзерләдем, алып кына булса да чык, диярләдер...

— Әйе.

— Вәли Гаязович, нәрсә булды бу? — трубкада Тәрҗемановның үпкә катыш тавышы яңгырады.

— Беләсезме, Әкмал Әнвәрович...

— Мине кыенрак хәлгә куйдың, Вәли. Берне уйлап, икенче нәрсә сөйләү хәзер модада булса да, син бит инде мода куар яшьтән узгансың.

Аның авызы чәпелдәде.

— Булдыра алсаң, гафу ит... Шулай килеп чыкты.

— Берни дә аңламадым. Сәгать ярым элек миңа каршы килдең, ә хәзер... ышанырга мы соң?

— Әйе....

Ул трубканы куйды да гаризаны алды, вак кисәкләргә ертkалап, Гайнетдинов ягына бәрде. Тегесе калтыранып аягүрә басты.

— Ни хакыгыз бар?! Мин яңадан язам!

— Яз! Әмма китмәячәксең. Сине әллә моңарчы куып булмый идеме? Сине җибәрүе куркыныч. Чөнки яңа төштә тиз генә танымаячаклар. Ә бирәдә инде таныллдың. Ни өчен синең эшеләр тормышның каймагын гына җыеп йөрергә тиешләр? Юк! Сиңа өскә дә юл юк, аска да. Бер генә чараң бар: капитуляция. Тулы һәм берсүзсез капитуляция!

— Сез миңа яла ягасыз?!

Вәли Гаязовичның һәр сүзе теш арасыннан сыгылып чыкты:

— Сатлык җаннар гына синең кебек була ала. Чөнки алар өчен бернинди дә изге нәрсә юк. Һәм соңгысы: бәлкем син бездән егерме ел артыграк яшәрсең. Тик шуны бел: үз чордашларың белән бердәм яшәп, алар күргәннәрне күреп, алар белән бергә елап, бергә көлеп, алар белән бергә үлмәгән кешедән дә бәхетсез кеше юк!

— Мине эштән җибәрмәскә хакыгыз юк!

— Хакым бар! Син җитәкләгәндә төзелеп, хәзер инде иңгән стеналарны кемгә калдырмакчы буласың? Прокуроргамы? Дирекция исеменнән боерам; бер атна эчендә теләсә каян панель табасың. Әгәр үтәмәсәң...

Аның йөрәге үз гомерендә бер мәртәбә дә авыртмаганча көчле итеп чәнчеште, бөтен тәненә тир береп чыкты. Гайнетдиновтан кала барысы да кай арададыр аны уратып алганнар иде.

— Вәли Гаязович, төсегез китте, әллә скорый чакырыргамы? — диде Кәлимуллин.

— Кирәкми, борчылмагыз, һавага чыккач узар...

Вәли Гаязович чайкалып, күкрәген тоткан хәлдә, ишеккә атлады, арттан аяк тавышлары ишетелде. Ул борылып карамады, приемныйга чыккач та әз генә туктап торды. Барысы да тәртиптә, бөтенесен аңлыйм дигән уй йөгерде аның башыннан. Әнә радио да сөйли! Әйе, ул бик яхшы ишетә, зиһене эшли. Вәли Гаязович үзен көтеп торган «Волга»ны күрде, ләкин аңа таба китмәде, ундагы ярым ачык рәшәткә капкадан куе үләнле бакчага керде, ике куллап юкә кәүсәсенә тотынды. Күз алды әлҗе-мөлҗе килгәнгә, җир чайкалып өскә күтәрелә башлаган мизгелдә, ул чалкан авып китмәс өчен алга иелде. Иң мөһиме — аңны җуймаска кирәк иде. Ул кискен хәрәкәт белән башын күтәрде. Кемнәрдер йөгереште, кемнәрдер килеп култыклады... Күз алды бераз яктыргандай булды һәм Вәли Гаязович шактый еракта тыныч кына сигарет суыручы Гайнетдиновны күрде. Китү шушы булса, ләкин баскан килеш, дип уйлады ул. Гайнетдиновлар, Хантимерләр каршында егылыргамы? Беркайчан да! Аңны гына җуймаска кирәк. Кинәтрәк булды шул... Коймага бәрелә язып, «ашыгыч ярдәм» машинасы килеп туктады. Вәли Гаязович аны күрде, әмма үзен анда кертеп салганнарын сизмәде дә, белмәде дә. Бу вакытта ул әле үзендә икенче инфаркт булганын, өч ай больницада ятып, терелеп чыгасын да, совхоз директоры булып тагын өч ел — икенче зур комплексны төзеп бетергәнче эшләячәген дә белми иде. Әле ул культура йортында үзен пенсиягә озатырга җыелган халык каршында җитди утырачагын да, бер-бер артлы әйтелгән мактау сүзләрен тыныч кына тыңлаячагын да, совхоз яулаган байракларны яшь директор Ленар Маликовка тапшырганда, шушы кадәр халык алдында — ничә еллар үзенең бер генә мәртәбә дә йомшавын күрсәтмәгән халык алдында — күз яшьләрен тыя алмыйча елап җибәрәсен дә белми иде. Бу көннәр әле барысы да алда иде.



*Мин 1951 елда Балык Бистәсе районы Олы-Елга авылында тудым. Сигезьеллык белем алгач, бер ел колхозда эшләдем. Унынчы классны Лаеш районы Державино урта мәктәбендә тәмамлап, 1972 елда кооператив техникумында укып чыктым, сатучы булып эшләдем. Хәзер Казанда заводта эшлим.*

*Әдәбият белән бик яшьли кызыксынам. Шигырьләр язгаладым, хәзер хикәяләр язам. Туган телемә, халкым иҗатына мәхәббәтем көчле. Үзем дә саф татарча, халыкчан язарга тырышам.*

*Теләгем — олы әдәби диңгезгә бер чишмә булып килеп кушылу.*

## Мансур Шаһимәрданов

# ЮГАЛГАН КЫЗ

хикәя



Фәгыйлә авылда туса да, төрле сәбәпләр аркасында, шәһәрдә апасы квартирасында яшәп үсте. Баштарак ул әти-әнисе янына җәйге каникулларда гына кайткалый иде. Менә укулар тәмам. Апасы Фәгыйләне җитәкләп вокзалга алып төшә, билет алып автобуска кертеп утырткач, йөгереп кенә кибеткә дә барып килә. Үзенең киңәшләрен дә әйтергә өлгерә.

— Фәгыйлә кызым, авылга кайткач юньле генә йөри күр инде!

— Ярый, апа.

— Ата-анаң сүзеннән чыкма!

— Чыкмыйм, апа.

— Берүк минем йөземә кызыллык китермә, балам!

— Юк, апа.

Шул вакыт автобус кузгала башлый. Фәгыйлә тәрәзәгә сарыла.

— Сау бул, апа!

— Хуш, хуш...

Апа кеше инде түзми, кесәсеннән кулъяулыгын тартып чыгара. Фәгыйләнең күзләренә дә яшь тыгыла бу минутта. Ул, автобусны туктатып, янә апасының кочагына атылырга тели. «Апа, без бүтән беркайчан да аерылышмыйк, син мине яратасың, мин дә сине яра-

там, өйдә кире өйгә кайтыйк», — диясе килә. Ләкин тора-бара авылга якынлаша башлау белән бу уйлар үзгәрәләр. Фәгыйләнең күз алдына апасы кебек үк мөлаем, изге күңелле әнисе килеп баса. «Ничек каршы алыр?» — дип уйлый ул.

Әлбәттә, ана кеше зарыгып көткән кызына кочагын җәеп ташлана. Исәнләшеп күрешкәч, гадәттәге сокланулар, хәл-әхвәл сорашулар китә.

— Сине, кызым, танырлык та түгел...

— Ник, әни?

— Үскәнсең, чибәрләнгәнсең...

Ә Фәгыйлә елмая гына. Әнисеннән мондый назлы сүзләр ишетү аңа рәхәт. Шуннан соң, Фәгыйлә өчен тоташ бәйрәмгә әверелеп, көн арты көннәр үтә башлый. Иртән пәрәмәч, өйләдә йомырка тәбәсе, ә кич тагын әллә нәрсәләр... Хәтта шактый ук кырыс күренгән Вәли абзый да «кызым, кызым» дип үлеп тора: бер генә көн дә өйгә күчтәнәчсез кайтып кергәне юк. Ата-анасының күрсәткән сый-хөрмәтләре өстенә, авылның гаҗәеп табигате, урманы-болыны, елгасы-күле, саф һавасы — барысы бергә кызны үстереп кенә калмый, аны тазартып та җибәрә. Фәгыйлә һәр җәйне менә шулай үткәреп, үзгәреп китә иде авылдан. Ә киткәндә әнисе аны күзеннән яшьләрен мөлдерәтеп озатып кала иде. Фәгыйлә нигәдер әнисенең елап калуын теләми. Бер тапкыр ул аңа:

— Әнием, син мине озатканда елама! — диде. — Син елагач минем дә елыйсым килә, минем күңелем җәрәхәтләнә, син һаман шулай елап кына яшисеңдер төсле тоела миңа.

— Ярар, балам, еламам, — дигән иде аңа әнисе. Ләкин сүзендә тора алмады шул.

Кыз унны тәмамлаган ел иде ул. Җәйнең матур гына булып, яңгыры явасы килгәндә явып, кояшы кыздырасы килгәндә аяусыз кыздырып, тыныч кына, шау-шусыз гына үтеп барган чагы иде. Бер дә бер көнне Фәгыйлә атлыгып диярлек өйгә кайтып керде дә яшь кызларда гына була торган эчкерсез бер сөенү белән яңа хәбәр әйтеп ташлады:

— Апаем, матур апаем, мин Себергә эшкә китәм.

— Нәрсә? — диде апасы үз колагына үзе ышанмыйча. Аңлап алгач, артсыз урындыкка хәлсез кешедәй чүгеп, күрсенгәндәй итенде. — Булмаганны син дә...

— Ник, эшлиләр ич, мин дә эшләрмен...

— Сөйләмә юкны, атаңның холкы болай да начар, ишетсә — давыл куптарыр.

Фәгыйлә, апасына үпкәләп, иреннәрен турсайтты:

— Һаман бер балык башын чәйнисең син дә, апа. Унике яшемдә дә авылга озатканда шул сүзне әйткән идең, инде хәзер унсигез тулганда да шул.

— Юк, ата белән киңәшләшми булмый, кызым...

— Әллә тагын кырыкка якынлашканда да ата сүзеннән чыкмас идемме?

— Анысын белмим, кызым, хәзер киңәшләшергә кирәк, ул ни әйтер бит. Әгәр дөреслек синең якта икән, соңыннан күз күрер әле.

— Ярый, — дип, апасы белән килешкәнен белгертте Фәгыйлә. Ә кичен инде ул авылда табын янында утыра һәм астыртын гына куркынып атасына карап-карап куя иде. Бу куркыну юкка гына түгел: берәр артык сүз ычкындырсаң, Вәли абый коры дары кебек хәзер кабынырга гына тора. Күптән түгел әле Фәгыйләсе институтка имтихан тапшырып та, конкурстан уза алмагач, снаряд булып шартлый язган иде. «Әгәр шушында, кызының Себергә эшкә китәргә йөргәнен белсә, «атом бомбасы булып шартлавы бар», — дип уйлады

Фәгыйлә. Ләкин Вәли абзый атом бомбасын исенә дә алмый тыныч кына әйтеп салмасынмы шул чак:
— Сине Себергә китәргә йөри диләр, дөресме бу?
Фәгыйләнең койрыгына бастылармыни:
— Менә сиңа мә! Үзем кайтып әйткәнче ишеттергәннәр дә икән.
— Я әйт, дөресме?
— Дөрес.
— Әй, җитешмәгән! Әй, уңмаган! — дип тузына-тузына өстәл буеннан торып ук китте әтисе. Соңыннан, ачуы бераз сүрелә төшкәч кенә, кызы каршына килеп:
— Әйт, Фәгыйлә, мин сине ни өчен үстердем? Туган җиреннән аерылган кош кебек, читтә каңгырып йөрер өченме? — диде.
Бу сүз Фәгыйләнең күңелен, өермәдәй бөтерә-бөтерә, давыл котырган диңгез өстенә алып барып ташлагандай итте. Ул гүя шул диңгездәге җәһәннәм эченә кермәс өчен теше-тырнагы белән каршы тора, шунда бирешмәскә теләп сугыша иде. Фәгыйлә еламаска тырышып берникадәр вакыт өнсез торгач кына, башын читкә борып, күзләрен агач рам эчендәге зур карточкага юнәлтте һәм, үткән вакыйгаларның кайнар эзләре буйлап бара-бара, татлы хискә чумды. Ах, бәхетле чаклары бар иде шул аның.
Әнә теге карточкадагы иптәш кызы Зөһрә белән ничек ашкынып тәмамлаганнар иде алар унынчы классны. Инженер булабыз дип, эчтән янып та, тыштан ваемсыз, шат булырга тырышып, җиләкләргә дә бергә йөргәннәр иде. Барып чыкмады бит. Бер бәхетсез билет аркасында, барча планнар чәркә-мәркә килде дә бетте. Ах, Зөһрә чибәр, Зөһрә чибәр, сиңа гына институтның баскычларын санарга язган икән шул. Фәгыйлә хисләреннән арынып карточкадан күзләрен алганда, Вәли абзый инде тынычланып мич каршында папирос көйрәтеп утыра иде. Нәфисә апа самавардан чокырга чәй агызып куйды да, зәңгәр күзләрен Фәгыйләгә төбәп, әйтеп салды:
— Хәсрәтләнмә, кызым! Атаң әйтә инде ул, холкы шундый, ә мин әйтәм — заводка кереп эшләсәң әйбәтрәк булыр.
— Заводка? — диде Фәгыйлә гаҗәпләнеп.— Ә кайсы заводка?
— Курчаклар ясый торганына. Хәтереңдәме? Син бәләкәй чакта курчакларны бик ярата идең.
— Ярата идем,— диде Фәгыйлә күңеле тулып.— Ләкин минем курчак фабрикасына урнашасым килми.
— Ә кая урнашырга телисең соң, кызым?
— Белмим әле, бу турыда уйлап карармын, әни.
— Уйлап карармын дисеңме? Хә-хә-хә... Күп уйладың инде син, Себердә дә эшләп кайттың...
Бу баядан бирле сүзгә кысылмыйча утырган Вәли абзый тавышы иде. Фәгыйлә яңа бәла киләсен сизеп, тиз-тиз генә клубка чыгып китте.

Бу кич аны Әнәс исемле егет озата килде. Бакча янәшәсендәге бүрәнәләр өстенә утырып, байтак кына сөйләштеләр. Әнәс, авыл мәктәбен тәмамлаганлыктан, гел авыл турында, ә кыз исә гел шәһәр тормышы турында гына сөйләде. Сүз арасында егет: «Мин дә шәһәргә китәм,» — дип куйды.
— Кил шул,— диде кыз.— Кала, ни әйтсәң дә, кала инде.
Ул моны шундый кызык итеп әйтте, төнге һава салкыныннан аның тешләре тешкә тими иде кебек. Егет костюмын салып кызның иңенә япты.
— Юк, Фәгыйлә, шәһәргә бөтенләй үк күчмим әле мин, укып чыккач та авылга кайтырга исәп.
— Дөрес, Әнәс, бар кеше дә шәһәргә күчсә, авылда кем калыр!

— Шәһәргә ашкынучылар күчә бирсен.

Әнәснең авыл табигатенә күңеле берекканлеге кызга нык кына ошап куйды.

— Мин дә авыл хуҗалыгы институтына керәчәкмен әле,— диде ул.

— Бик әйбәт. Ә кайсы факультетка?

— Белмим әле...

— Минемчә, сиңа агрономия факультеты шәбрәк булыр.

— Ә син кайсына кердең? — дип пышылдады кыз. Егет әйтеп бирде. Икесе дә тынып тордылар. Әнәс күзләрен көнчыгыш яктан күк йөзенә җәелә барган шәфәкъ кызыллыгына төбәп уйга калды. Ул — үзенең менә җиде җәй колхоз малларын көтүен, эшен яратуын, малкайларның берәрсе яраланса-нитсә авыруга сабыша язуын,— барысын, барысын да кызга сөйләп бирмәкче булды. Ләкин бу турыда әйтергә авыз ачканда гына кәҗә Гайфиенең шпоры коелган карт әтәче бик ямьсез тавыш белән кычкырып җибәрде.

— Ой! — диде кыз сискәнеп һәм, тиз генә бүрәнә өстеннән төшеп, капкага ташланды.

— Фәгыйлә, бер генә минутка тукта инде,— диде егет, кызның шәһәрдәге адресын сорамый калуына эче пошып.

Фәгыйлә җавап бирмәде.

Иртәнге чәй янында Вәли абзый кызыннан ачулы гына сорап куйды:

— Көтүче Фәхри малае белән күптән йөрисеңме?

Фәгыйлә эчә башлаган чынаягын чак кына төшереп җибәрмәде, елардай булып, каш астыннан гына җавап бирде:

— Нинди Фәхри? Нинди көтүче? Һич аңламыйм, әти.

— Аңламыйсыңмы? Бәлки син таң атканчы егет белән бүрәнә өстендә утырмадым дип тә әйтерсең, ә? — Фәгыйлә, атасының бу соравыннан хурланып, кызарынган йөзен аска иде. — Менә бит, — дип дәвам итте Вәли абзый сүзен. — Институтка керүне булдыра алмады, ә егет белән йөрүне белә, башсыз.

Фәгыйлә инде керфек очларында мөлдерәгән яшьләрен тыеп тора алмады, сулкылдап-сулкылдап үксергә үк кереште:

— Си-и-ин, си-и-н... әти, мин кайткан саен тавыш күтәрәсең... Шул кадәрле күрә алмагач, нигә үстердең соң?..

— Эх, — дип авыр гына сулап куйды Вәли абзый. — Бердәнбер өметне дә аклый алмагач, нигә үстергәнмен, белмим. Үз башыма хәсрәт булсын диптер, мөгаен.

Фәгыйлә инде атасын тыңларлык хәлдә түгел иде. Ул күзләрен йомган килеш, битеннән бертуктамый аккан яшьләрен дә сөртергә онытып, өстәлгә капланды да: «Башка ка-айт-мыйм, ка-а-йт-мыйм»,— дип үкседе.

Баядан бирле тын гына табын янында утырган Нәфисә апа да күңеле борчылып:

— Җитәр, атасы, бердәнбер кызыбызны туган өеннән биздерәсең ич инде,— диде.

Вәли абзый аңа күтәрелеп тә карамады, борын эченнән генә мыгырданып:

— Юньле бала — озын гомер, юньсез бала — кара күмер,— дип куйды. Нәфисә апа кызының аркасыннан кагып юата-юата ак өйгә җитәкләп кертә киткәч кенә, Вәли абзый ишегалдына чыгып папирос кабызды, ике-өч минут йөрәгенә урын таба алмый әрле-бирле атлап йөренде. Аннан бер утын бүкәне өстенә килеп утырды да, арттырыбрак җибәрдем, ахры, кыз кешегә алай ук әйтү кирәк түгел иде дә, ярый инде, шәһәргә озатканда юлына утыз сум акча бирермен, дип күңелен тынычландырып куйды. Шул тынычлыгын саклаган көе,

төпчеген сулы чиләккә ыргытып, эшкә китте. Ә кичен эштән кайтканда инде өйдә Фәгыйлә күренми иде. Өстәлдә бары тик: «Сагынсагыз, рәсемемне алып карарсыз», дигән язуы гына калган иде.

Кызларын ата белән ана бик озак көттеләр. Берөзлексез вак яңгырлар сибәләп торган көзләрдә дә, күз ачкысыз әче буранлы кышларда да, беренче сыерчыклары белән йөрәкләрне яшәртеп җибәргән язларда да, хуш исле үләннәре, чәчәкләре белән дөньяны матурлыкка төргән назлы җәйләрдә дә көттеләр. Кыз кайтмагач, хат ташучы газета белән бергә, һич югы, хат калдырыр, дип тә өмет иттеләр. Ләкин барысы да бушка булды. Теге чакны, авылдан күз яшьләрен агызып киткәч, Фәгыйләне шәһәрдәге җизнәсе дә өнәми генә каршы алган иде. «Салып» кайткан вакытларында, Вәли абзый кебек, ник укымыйсың дип, теңкәсенә тиеп бетте. Кыз бик хурланчык булганлыктан, бу мәсхәрәләүләрне күтәрә алмый, көннәрдән бер көнне каядыр китеп югалды. Кая киткән, моны белмәделәр. Милициягә дә хәбәр итеп карадылар. Ләкин кыз суга төшкәндәй юкка чыккан иде. Вәли абзый әле һаман кызының табылуына өметен өзмәсә дә, Нәфисә апа инде кысыр сөенечләргә кулын селтәгән, Фәгыйләнең берәр нишләп һәлак булуына ышанган иде.

Шушы вакыйгалардан соң, җиде еллап вакыт үткәч, бер матур июль иртәсендә, Вәли абзый саусызланган йөрәген дәвалатыр өчен, санаторийгә китәргә җыенды. Алмашка киясе күлмәк-штаннарны инде Нәфисә апа кичтән үк пөхтәләп чемоданга тутырып куйган иде.

Нәфисә апа ирен пристаньнан озатып калырга тиеш иде. Автобус белән райүзәккә килеп төшкәч үк, туры шунда юнәлделәр. Дебаркадер баскычын менгәндә, Вәли абзый сул яктагы коңгырт утыргычка ишарәләде·

— Ял итә тор, Нәфисә! Мин хәзер, билет кына алам да...

— Бар, бар, Вәли!

Нәфисә апа иплә кенә урнашкач, күзләрен як-якка йөртеп карарга кереште.

Борынгы Каманың мәһабәт ярлары, ташлы кыялары, яшеллеккә күмелгән вак-вак утраулары тагын да матуррак, тагын да нәфисрәк булып күренде аңа бу иртәдә. Әнә еракта кояш нурлары белән җемелдәшкән дулкыннар арасыннан юл ярып, бирегә таба бер ак нәрсә йөзеп килә. Пароход бу. Озакламас, ул килеп җитәр дә, сөекле Вәлиен ерак җирләргә алып китәр. Ах! Нәфисә тагын ялгызы калыр...

Шул мизгелдә су өстенә акчарлаклар күтәрелде. Алар үзләренчә нидер кычкыра-кычкыра якыннан гына очып үтеп, каядыр юкка чыктылар. Тик төркемнән аерылып калган бер акчарлак кына, Фәгыйләнең теге чактагы елавын хәтерләткән яшь һәм нечкә тавыш белән үзәкләрне өзеп, дулкыннарга ташлана-ташлана оча калды.

— И, балакаем, — дип уйлады ул. — Син дә шушы кош сыман рәхимсез дулкыннарга ташланып очасың микән! Әллә инде канатларың талып егылдыңмы? Шуңа эндәшмисеңме?...

Вәли абзый әйләнеп килгәндә, Нәфисәнең кап-кайнар яшьләре юлюл булып ага иде.

— Нәфисә, әйдә! Пароход килә, —дип Вәли абзый тиз генә чемоданына үрелгәндә, хатынының елаудан шешенгән йөзен күреп туктап калды.

— Чү! Ни булды сиңа! Әллә... — Абзый сүзен әйтеп бетерә алмады, кинәт кенә тирә-юньне тутырган көчле су шавы һәм нәрсәнеңдер дөп-дөп килеп гүелдәп эшли башлавы аны шул якка борылып карарга мәҗбүр итте. Дебаркадерга галәмәт зур бер теплоход якынлашып килә икән. Менә инде ул яны белән дебаркадер бортына килеп орынды да. Дебаркадер палубасы, мондый зур көчкә каршы тора алмый-

ча, чайкалып куйды. Кешеләр дә йокыдан кисәк кенә уянгандай сискәнеп киттеләр һәм ашыга-кабалана дебаркадер капкасы янына килеп тезелделәр.

Өстенә елга хезмәткәре формасы кигән олы яшьтәге бер абзый капканы ачып җибәрүгә, теплоход палубасында торган кешеләр дә чыга башлады. Ике арада сөенечле кавышу, бәхетле очрашу авазлары китте. Вәли абзый боларга артык карап тормады, күңеле тулып бер почмакка барып басты да, кесәсеннән папирос алып кабыза-кабыза көрсенеп куйды..

— Эх! Язмыш-язмыш... Уналты яшемнән читкә китеп азмы нужа күрдем. Унсигез яшь̂емне Ленинград фронтында ут эчендә каршыладым. Илле биш яшемне дә менә читтә, санаторийдә каршыларга туры килә. Борынгылар: «Саулык — байлык», дигән. Дөрес икән шул...

Вәли абзый түбән иелгән башын күтәреп алга караса, бер мәлне үзенә якынлашып килгән ике хатын-кызның берсе Нәфисә, икенчесе Фәгыйләгә охшаш булуын күреп, урыныннан торып басты. Һәм шул мизгелдә кыз тирә-юньне яңгыратып кычкырып җибәрмәсенме:

— Әти! Исәнме, әти!

Бу сүз Вәли абзыйның баш түбәсенә күсәк белән орган кебек итте. Ул шаккаткан җиреннән йөрәген учлап хәрәкәтсез калды да, сүнеп барган күз карашын әле зәңгәр чиксезлеккә, әле кояш нурлары белән каймаланган матур үзәнлекләргә төбәгән көе акрынлап-акрынлап кына палуба идәненә чигә барды. Фәгыйлә:

— Әти, әти, нишләдең? — дип атасына барып ябышты. Ләкин Вәли абзый җавап бирмәде. Аның иреннәре кара көйгән, күзләре йомык, йөзендә нур әсәре дә калмаган, пульсы да бик зәгыйфь иде. Кызның башыннан яшен тизлегендә «приступ» дигән уй йөгереп узды. Мондый вакытта кеше гомерен секундлар хәл итә. Тизрәк, тизрәк!

Фәгыйлә, чемоданыннан тиз генә шприц алып, атасының беләгенә укол кадады. Укол үз эшен эшләдеме, әллә башка бер сәбәптәнме, Вәли абзыйның керфекләре кыймылдашып куйды һәм ул, күзләрен ачып бер мәл җыелган халыкка текәлеп торгач, кызының ярдәме белән урыныннан күтәрелде.

— Беткән идең ич инде, Фәгыйлә булмаса, — диде хатыны яшь аралаш.

Вәли абзый шунда гына кызын күреп күкрәгенә кысты һәм чыланган яңагын аның чәченә орындырып:

— Бөтенләйгә кайтуыңмы, кызым? — диде.

— Бөтенләйгә, әти.

— Ә без сине югалткан идек инде.

Фәгыйлә оялып күзләрен аска төбәде:

— Гаебемне таныйм мин, әти, гафу итегез.

— Ярый-ярый, ничава. Укыгансың, кеше булгансың, менә шунысы яхшы.

— Без дә укымагач, кем өчен сугыштыгыз соң сез, әти.

— Әлбәттә, сезнең өчен, кызым.

Әлегә хәтле сүзгә кысылмыйча түзеп торган Нәфисә апа, теплоход китәргә гудок биргәч, кузгалу турында иренең исенә төшерде.

— Ә, юк, — диде Вәли абзый. — Мин хәзер санаторийгә китмәм инде. Врач үзебез белән. Әйдәгез, өйгә кайтыйк!

Бу сүзгә Фәгыйләдән дә ныграк сөенүче булмагандыр. Менә, юл күрсәтүче маяк кебек, ул ярга алдан атлады. Бераз гына туктап, әтисе белән әнисен көтеп торды. Аннан өчәүләшеп, сөенешә-сөенешә үргә менеп киттеләр. Озак та үтмәде, аларның күзләренә үзләре яши торган Юлга авылының яшелле-кызыллы өй түбәләре дә күренде.

≈≈≈≈≈≈

# «ЭЛЕМТӘГӘ ЧЫГАМ...»



Ф. Фазлыйәхмәтов

*1977 елда Мәскәүнең политик әдәбият нәшриятында «Тын профессия батырлары» («Люди молчаливого подвига») дигән очерклар китабы басылып чыкты. Анда Бөек Ватан сугышы елларында чын батырлык үрнәге күрсәткән якташыбыз Фәрит Фазлыйәхмәтов турында да язма бар. Аның авторлары — «Красная звезда» газетасы журналистлары А. Сгибнев һәм М. Кореневский.*

*Моннан берничә ел элек миңа Фәрит аганың үзен күреп сөйләшергә туры килгән иде. Шунда аның Татарстан егете булуы ачыкланды. Туган җире — Кукмара районы. Хәзерге вакытта ул Мәскәүдә яши, башкала предприятиеләренең берсендә конструктор булып эшли.*

*Еллар үткән саен, совет кешеләренең, аеруча яшьләрнең, Бөек Ватан сугышы героикасы белән кызыксынулары арта бара, ул чордагы каһарманлыклар турында күбрәк беләселәре килә. Шуны искә алып, Фәрит Фазлыйәхмәтов һәм аның коралдаш дуслары турындагы әлеге язма белән журнал укучыларын таныштыру да урынлы булыр.*

**ДИФГАТ. СИРАЙ**

## Зур театр янында очрашу



Яз Тугызынчы майны кояшлы, якты, зәңгәр күкле матур көн белән куандырды. Элекке фронтовикларның инде күптәннән яраткан очрашу урынына әйләнгән Зур театр бакчасында мул булып бөреләр ачылган. Фонтан янындагы агачларда сугыш елларында фронт юлларындагы юл күрсәткечләргә охшашлы бик күп фанера уклар күренә. Шул уклар янына чал чәчле, орден-медальләре балкып, күбесенең яра эзләре беленеп торган, дулкынланган кешеләр килеп туктый. Алар, әлеге күрсәткечләргә карап, армияләрен яки дивизияләрен эзләргә тотыналар, ә инде тапкач, яшьләрчә һәм тантаналы итеп: «Саумысыз, полкташлар!» — дип кычкырып куялар... Пехотачылар — пехотачыларны, диңгезчеләр — диңгезчеләрне, очучылар — очучыларны коча. Бары тик җидесигез кешелек бер группа гына бу шатлыктан әле ничектер читтәрәк тора. Аларның үз-үзләрен тотышларыннан түземсезлек белән кемнедер көтүләре сизелеп тора иде...

Менә кинәт группа җанланып китте, йөзләргә елмаю чыкты. «Федор, Федор!» дигән тавышлар ишетелде. Һәм озын буйлы, киң җилкәле Федор шунда ук иптәшләренең кочагына чумды.

Озын буйлы, чак кына чал сара башлаган кара чәчле бу кешенең исеме чынлыкта Федор түгел, ә Фәрит. Ләкин Зур театр янына килгән иптәшләре аны нәкъ менә Федор буларак беләләр иде. Дошманның ерак тылында ике елдан артык булуы вакытында башкарган бик күп данлы эшләре белән билгеле ул.

Мина кыры кебек шартларга торган куркыныч ул вакыт күп еллар белән түгел, көннәр, сәгатьләр, минутлар белән исәпләнә иде. Кечкенә генә хата да — үлем дигән сүз. Монысы әле иң яхшы очракта. Ә начары — гестапо зинданнарында җәзалану. Гитлерчылар «озын Федор» башы өчен зур сумма акча, шулай ук «ике сыеры һәм төзек тракторы булган утар» вәгъдә итәләр. Хыянәткә өндәүче листовкада «большевик парашютчы»ның аерым билгеләре саналганнан соң, «уң кулының уч төбендәге, уң җилкәсендәге һәм күкрәгендәге пуля ярасы эзләре» дә күрсәтелә. Әйтергә кирәк, барысы да дөрес була. Күрәсең, «озын Федор»ны карт төлкеләр — тәҗрибәле контрразведчиклар аз эзләмәгән. Әйе, Фәрит дошман тылларында йөргәндә, чыннан да, өч тапкыр яралана. Өченчесе — иң авыры: пуля аның умыртка сөягенә тиеп үтә. Ләкин Фәрит ул вакытта да үз постында кала, Зур җиргә, Мәскәү госпиталенә кайтудан баш тарта, партизаннар землянкасында дәвалана. Әйе, ул — парашютчы: иң мөһим заданиеләр үтәр өчен җиде тапкыр дошман тылына төшә. Фашист көчекләре аның турында әнә шулай күп нәрсә белергә өлгерәләр, ләкин, нинди генә вәгъдә бирүләренә дә карамастан, утарга яки трактор белән сыерларга кызыгучы кара эчле кешене генә таба алмыйлар. Фәритне дошман күзеннән кешеләр дә, урманнар да, туган җире дә ышанычлы итеп яшерә!

...Без Фәрит Салиховичка кагылышлы документларны җентекләп карап чыктык. Хәрефләре сикереп торган штаб машинкаларында төрле кәгазьләргә бер нөсхәдә басылган, трофей итеп алынган топография карталарының икенче ягына кулдан язылган, хәрби телеграф тасмаларына сугылган һәм хәтта тукымаларга төшерелгән, бәя бирел бетергесез кадерле документлар алар. «Барлык часть командирларына! Иптәш Фазлыйәхмәтовның килүе турында кичекмәстән фронт штабының разведка бүлегенә хәбәр итәргә». Печать һәм имза.

Андый язуларны, шырпыдан нәзегрәк итеп бөтереп, пинжәк итәгенә яки якасына теккәннәр. Разведчик үзебезнекеләр янына кайткач, тиешле служба әлеге тукыма таныклыктан башка да барысына да төшенер, шунда ук кирәкле белешмәләр юллап алыр иде, әлбәттә.

— Ләкин, беләсезме, аның белән ничектер күңелгә җиңелрәк иде, — ди Фазлыйәхмәтов дулкынланып. — Янында — совет документы. Бердәнбер документ. Калын сукно аркылы хәтта капшап табарлык булмаса да, разведчикларга ул безнең «уракл ы-чүкечле паспортыбыз» кебек тоела иде. Син — Советлар Союзы гражданины! Ватан документы белән!

Фәрит Салихович таныклыгының ефәк тукымасын сыйпап куя. Аннары ниндидер өмет белән болай дип сорый:

— Ә сезгә архивта «Александр Матросов» дигән разведка группасының материаллары очрамадымы?

— Очрады, Фәрит Салихович, очрады. Теге яктан җибәрелгән беренче хәбәрдән, беренче сигналдан алып соңгысына кадәр — барысы да сакланган...

Һәм без Фәрит Фазлыйәхмәтов белән бергәләп ерак фронт елларына әйләнеп кайтабыз.

Ел ахыры якынлаша, кырык дүртнең декабре. Өченче һәм Икенче Белоруссия фронтлары һәм Беренче Балтик буе фронты флангысының Көнбатыш Пруссиядә стратегик һөҗүм операциясе башланырга егерме-егерме биш көн калган. Икенче Белоруссия фронты штабы начальнигы урынбасары , карта өстенә иелеп, һөҗүм булачак полосадагы торак пунктларның исемнәрен кат-кат укып чыкты да бераз тынрак тавыш белән әйтеп куйды:

— Аңлашыла... Монда да тулысынча аңлаешлы... Шулай ук монда да...

Кинәт генерал кашларын җыерды, каршында басып торучы майор Медведовскийга текәлде.

— Ә менә монда әлегә ачык нәрсә аз, — ул дүрт тимер һәм уннарча шоссе юллары кисешкән төштәге шәһәр исеме астына сызып куйды. — Тәртип түгел бу!

— Иптәш генерал, мин нәкъ менә шул Бютов районына төшерелергә тиешле группаның очышка әзер булуы турында әйтергә килгән идем. Группаны кече лейтенант Фазлыйәхмәтов җитәкләячәк...

— Нинди кеше ул?

— Тәҗрибәле разведчик буларак, Үзәк тарафыннан тәкъдим ителгән. Фронт сызыгы аръягына берничә тапкыр төшерелгән, аннары ике елдан артык дошманның ерак тылында эшләүче «Москва» исемле махсус десант отряды командиры урынбасары булган. Әйтүләренә караганда, кыю һәм тәвәккәл егет.

Медведовский, папкасын ачып, кече лейтенант Фазлыйәхмәтовның хәрби характеристикасын алды һәм аны генерал алдына китереп салды. Язу машинкасында басылган нибары ярты битлек текст иде ул.

— Һәм бер генә кимчелеге дә юкмы? — Фронт штабы начальнигы урынбасары, ышанмыйчарак күзләрен кысып, укылган кәгазьне өстәл кырыенарак этәреп куйды.

— Алар, иптәш генерал, Фазлыйәхмәтовның үткәндәге кимчелекләре. Шуңа күрә алар турында...

— Ә сез шулай да әйтегез әле. Чөнки Бютов — бик мөһим район.

Майор яңадан папкасын ачты һәм генералга бер-берсенә беркетелгән берничә кәгазь бите сузды.

— Менә сиңа мә! Яхшы яклары бер биткә дә җитмәгән, ә кимчелекләре биш биткә дә чак кына сыйган. Утырып торыгыз, Медведовский, үзем укыйм...

Бу биш бит Үзәк кушуы буенча «Москва» махсус отрядының хәрби эшчәнлеген анализлаган офицер язмасының бер өлеше иде. Анда башлыча Зур җиргә чакырылган командир урынына калган Фазлыйәхмәтовның отрядка җитәкчелек иткән чордагы эшләре тасвирланган иде. Язма авторына Фазлыйәхмәтов ачыктан-ачык ошамаган: янәсе, чамадан тыш кайнар, кирәкмәгән эшкә алына, яхшы конспирация турында кайгыру урынына, отряд алдына куелган бурычлар даирәсенә керми торган төрле идеяләр белән хыялланып йөри.

Аннары мисаллар тезелеп китә. Берничә минутка генералның күңелен күтәреп җибәргән мисаллар.

«...Фазлыйәхмәтов Марьин Горкалы иптәшләргә немецларның газогенераторлы тракторын урларга, ә Талька группасына броня табарга куша. Ул, берничә дә карамастан, танк ясарга һәм аны ки-

рәк булган очракта файдалану өчен урманда яшереп торырга карар итә.

Танк белән уңышсызлыкка очрагач, Фазлыйәхмәтов катапульта корырга тотына. Аның уенча, ул дүрт йөз граммлы тол шашкаларын мең метрга кадәр арага ыргытырга тиеш була. Һәм катапультага яраклы пружина табу өчен Марьин Горка һәм Талька подпольщиклары яңадан аякка бастырыла...

Фазлыйәхмәтов приказы буенча отрядта гитлерчыларны сурәтләгән плакатлар, карикатуралар ясала. Алар соңыннан дошман гарнизоннарына җибәрелә һәм күп кешегә күренә торган урыннарга эленеп куела. Рәсемнәр астына һәр вакыт: «Кызыл Армиянең десант отряды басмасы...» дип языла.

Ләкин язма авторы, объектив кеше буларак, Фазлыйәхмәтовның разведчикка хас булмаган кайнарлык күрсәтүенә дә, конспирацияне санга сукмавына да карамастан, аның көчле ихтыярлы, чын-чынлап куркусыз, байтак кына шәхси хәрби тәҗрибәгә ия булуын да билгеләп үтүне кирәк тапкан. Фазлыйәхмәтов дошманның сугыш кораллары, техникасы һәм җанлы көчләре төялгән унөч эшелонны шартлатуда катнаша. Мөһим булган тимер юл күперен җимерә. Махсус отрядның гитлерчыларның авиация бомбалары складларына һәм бензин саклау урыннарына һөҗүмнәре вакытында берничә тапкыр шартлату группаларына җитәкчелек итә. Марьин Горкада, Талька һәм Осиповичи станцияләрендә («гәрчә соңгы икесе аның зонасына кермәсә дә...») фашист оккупантларына каршы көрәшүче җирле халыктан ышанычлы һәм актив разведгруппалар оештыра.

— Ә нәрсә, җитди, таләпчән ревизор! — дип куйды генерал һәм карап чыккан кәгазь битләрен яңадан бер-беренә беркетеп, Медведовскийга бирде. — Ләкин бу кече лейтенантның кимчелекләре шулкадәр сокланырлык икән бит, ә? Хәзер кайда ул?

— Группа янында. Атна буе бик киеренке эшләделәр, бүген бераз тын алырга рөхсәт иттем. Сезнең янга чакырыргамы?

— Мин, ихтимал, үзем кереп чыгармын.

Разведчиклар землянкасына якынлашуга, генерал җыр авазы ишетте:

На позицию девушка
Провожала бойца...

Аны Фазлыйәхмәтов һәм аның сугышчан дуслары җырлый иде... Һәм менә кинәт кенә Зур театр янына җыелган сугыш ветераннарының кайсыдыр шатлыклы төркемендә фронтовиклар яраткан шул ук җыр яңгырап китте...

## Псевдонимны сайлау

Фазлыйәхмәтов группасына бирелгән иркен землянкада җылы һәм уңайлы иде. Разведчиклар, яңа гына ышкыланган такталардан ясалган өстәл янына җыелып, патефонга кушылып җырлыйлар иде. Ләкин генерал күренү белән барысы да җәһәт кенә урыннарыннан сикереп тордылар. Командирлары рапорт бирү өчен, аны нәкъ менә фронт штабы начальнигы урынбасары күз алдына китергәнчә, кискен итеп алга атлады. Кемдер патефон тәлинкәсенә үрелде.

— Алмагыз! Чын күңелдән бирелеп җырлый. Һәм тавышы да ягымлы, — диде генерал, рапортны туктатырга, ә җырны дәвам итәргә ишарә ясап. — Шинельне кая эләргә була? Чәй белән сыйлыйсызмы?

«Мин дә, ул вакытта землянкада булган башка кешеләр дә бу кунак хәзер безне тикшерә, имтихан ала башлар дип уйлаган идек, — дип искә ала Фәрит Салихович. — Ә ул өстәл янына килеп утырды да җыр тыңлый башлады. Аннары, әйдәгез, күтәреп алыгыз, дигәндәй ишарә ясап, үзе дә әкрен генә җырлап җибәрде:

Парня встретила дружная  
Фронтовая семья.  
Всюду были товарищи,  
Всюду были друзья...

Соңыннан чәй эчтек, генерал безнең туганнарыбыз һәм якыннарыбыз турында сорашты...»

Ул кичне фронт штабы начальнигы урынбасары разведчиклар алдында торган заданиене бары тик бер генә тапкыр искә алды. Ул да булса Фазлыйәхмәтовтан:

— Нинди псевдоним сайладыгыз? — дип сорады.

Фәрит, хәзер инде ул аны хәтерләми, «ский» кушымчасына тәмамланган нинди дер фамилияне әйтте.

— Юк, ошап җитми бу миңа. Разведчик псевдонимының мәгънәле булуын яратам. Юкса, күптән түгел миңа: разведка группасы җитәкчесе — Шукарь дип хәбәр итәләр. Мәгънәсезлек бит! Күз алдына Шолоховның кармакка эләккән карты килә дә баса. Уңышсызлыкка юрау кебек. Алыштырдым! Мин сезнең урында булсам, менә кем фамилиясен сайлаган булыр идем. — Һәм генерал землянкада эленеп торган плакаттагы Александр Матросов рәсеменә төртеп күрсәтте.

Фазлыйәхмәтов, герой фамилиясен алырга үземнең берничек тә тәвәккәллегем җитмәс иде, дип әйтте. Җаваплылыгы бигрәк зур бит.

— Ә син тәвәккәллә! Шулай дип килешик — Матросов.

Һәм, теманы кискен үзгәртеп, генерал разведчикларга болай дип мөрәҗәгать итте:

— Миңа нинди дә булса шәхси үтенечләрегез, сорауларыгыз юкмы?

— Иптәш генерал, — диде Фазлыйәхмәтов, кыюлана төшеп, — минем икенче ай инде дустымны очрата алганым юк. Александр Чеклуевны. Ул теге яктамы?

— Чеклуев?

— Әйе. Без аның белән өч тапкыр тылга төштек, бер үк приказ буенча бүләкләндек...

— Борчыласың, димәк? Иптәшләрең турында уйлавың бик яхшы. Ә Чеклуев исән-сау. Нәкъ шуңа инде менә Шукарь исемен такканнар иде. Яхшы исем белән алыштырдым һәм эшләре дә бик яхшы бара, — дип шаяртты генерал. — Булдыклы егет ул Чеклуев! Һәм сиңа да ышанам, Матросов!

Төн. Дошманның ерак тылына очу алды төне. Бу — һәр вакыт диярлек яңадан башлана торган гомер. Тик айлары аның минутлар булып кысыла, ә көннәре исә әйтерсең йөрәкнең берничә тибеше эчендә узып китәләр. Кайберләренә — өч, кайберләренә ун тибеш кирәк. Шуңа күрә аларны яңадан үз тәртибе белән хәтергә төшерүе дә мөмкин түгел.

...Яшерен очрашу квартирасы. Лейтенант Морозов йөгереп керә. Агарынган, калтыранган иреннәре чак-чак кына кыймылдыйлар — сүзләрен аңлап булмый. Әйдә, үз-үзеңне кулга ал да сөйлә инде! Прищепчик һәлак булган икән. Гестапочылар башта аны яралаганнар, аннары камый башлаганнар. Разведчик аларның якынрак ки-

лүләрен кәтә. Ниндидер сүзләр әйтеп кычкыра, ләкин нинди сүзләр икәнен аерып булмый. Аннары гранатасының әчкечен тартып ала да аны йөгерешеп килүче фашистлар өстенә тондыра: мәгез, кирәгегезне алыгыз, хәшәрәтләр!

Могҗизалар булмый булуын, һәм шулай да Фазлыйәхмәтов төнлә кешеләр җибәрә: бәлки исән калгандыр? Буш кул белән кайталар. Нәрсә әйткән, ни дип кычкырган икән соң Прищепчик һәлак булыр алдыннан? Геройның соңгы сүзләрен ишетәсе килгән иде... Айларны, озын айларны бергә үткәрделәр бит алар... Чын патриот иде — һәм бу турыда якташларына да белдерәсе килә.

...Лена Лиходиевская. Яки Елена Викентьевна. Фәриттән унбиш яшьләргә өлкәнрәк хатын. Милләте — белорус, партиясез, күп балалы ана. Аның яхшы кеше, чын патриот икәнен беләләр, ләкин шулай да отрядка чакырырга ашыкмыйлар иде. Балалары аркасында. Ул үзе килде: йомыш кушыгыз, сынап карагыз! дип ялынды. Сез бит туган Белоруссиямнең дөрләп янганын, совет кешеләренең һәлак булуларын күреп торасыз — мондый вакытта ничек читтә каласың да, ничек итеп сугышчы булмыйсың ди?

Башта аның эшкә карашы борчуга салды. Ул немец һәм бигрәк тә венгер, румын, итальян солдатларын һәм унтер-офицерларын аңлату, ялкынлы агитация белән Кызыл Армия ягына тартырга кирәк дип саный иде. Аларның күпчелеге эшчеләрдән һәм крестьяннардан тора бит, бөек хакыйкать аларга ничек барып җитмәскә тиеш соң? Еленаны: «Иптәш агитатор, саграк бул!» — дип кисәттеләр.

Бервакыт ул билгеләнгән урынга венгер унтер-офицерын алып килде. Һәм унтер-офицер махсус отряд вәкилләренә беренче мөмкинлек чыгу белән совет солдатларына әсир бирелачәген белдерде. Шундый адым ясарга кирәклегенә аны (ул Лиходиевскаяга таба күрсәтте) шушы акыллы хатын ышандырды. Ул икенче венгер армиясенә кергән 151 нче венгер дивизиясеннән. Ләкин бу армиянең чынлыкта инде яшәүдән туктавы турында хәбәрләр булган иде. Чөнки әлеге армиянең 106 нчы һәм 108 нче дивизияләренең күпчелек солдатлары, сугышка барудан баш тартканнары өчен, Брянск янында гитлерчылар тарафыннан пулеметлардан атып үтерелгән. Ә 151 нче Осиповичига килгән һәм Минскига китәргә җыена. Штаб ГФЛ га — яшерен кыр полициясе бинасына урнашкан...

Унтер-офицер, үзен ахыргача тыңлап бетермәсләреннән курыккандай, сөйли дә сөйли. Ә Елена Викентьевна елмая: менә күрәсезме, минем агитаторлык эшем дә үзенең нәтиҗәләрен бирә!

Гитлерчылар котырыналар, партизаннар хәрәкәтенә ярдәм итмәсен, аңа яңа көчләр өстәмәсен өчен, җирле халыкны аталар һәм асалар иде. «Бандитлар (фашистларның рәсми телендә партизаннар шулай атала иде) һәм аларның ирекле иярченнәре белән мөнәсәбәттә соңгы дәрәҗәдә катылык күрсәтергә», — дип приказ биргән Гитлер.

Ләкин иң кыргый чаралар да гитлерчылар көткән нәтиҗәне бирмәде: йөзләрчә патриотлар партизаннарга кушылды. Йөзләрчә кешеләр, үлем куркынычы белән исәпләшеп тормастан, дошман гарнизоннарына һөҗүм иттеләр, күперләрне һәм юлларны шартлаттылар. Ул геройлар, тереләр кебек, хәзер дә күз алдына килеп баса. Алардан башка махсус отряд берничек тә уңышка ирешмәгән, хәрби заданиеләрне тиешенчә үти алмаган булыр иде. Ә мөһим информация табу — бу кешеләрнең бөтен гомерләренең девизы, мәгънәсе булган иде бит!

Берәү болай дип хәбәр итә: Марьин Горка шәһәрчегенә 0/П-41 номерлы зенит-артиллерия мәктәбенең 1888 курсанты килеп урнашты. Шунда ук составында 1571 кеше булган 2635 номерлы гренадер полкы тора. Икенчесе моны раслый: әйе, дөрес, бу — кыр почтасы

номеры 11024 булган 2635 нче полк. Һәм өстәп куя: гитлерчылар Талька станциясендә 32 вагон авиабомба бушаттылар. 12 вагонның бомбасы Медведовка һәм Михайловкадагы складларга, калган егермесенеке Пуховичи аэродромына озатылды...

Бу мәгълүматларны, чак-чак кына шифрларга өлгереп, Үзәккә Николай Гришин тапшыра. Ул 1943 елның маеннан бирле «Москва» махсус отрядын ышанычлы рәвештә радиоэлемтә белән тәэмин итә.

Ә 1943 елның 20 ноябрендә Гришин Үзәккә болай дип хәбәр итте: «Гарнизонны һәм Осиповичи станциясен күзәтүче Е. В. Лиходиевская бүген гестапо тарафыннан кулга алынды. Җәзалау вакытында иптәшләренең исемнәрен фаш итмәү өчен төрмәдә үз-үзен үтерде...»

Авыр, дошманның ерак тылына — билгесез, көтелмәгән күп төрле сынаулар сагалап торган җиргә — очар алдыннан йокыга китүе бигрәк тә авыр. Разведгруппа командиры хәрби дусларының да йокламаганын, бары тик нәрсә турындадыр уйлап, үзләре өчен ниндидер мөһим мәсьәләне чишкәндәй тынып кына калганын яхшы белә. Ә менә С. Орджоникидзе исемендәге Мәскәү авиация институтының элекке өченче курс студенты, туган Ватаныбызга фашистлар һөҗүм иткәч, үзен разведчик итеп җибәрүләрен сораган Фәрит Фазлыйәхмәтов нинди мәсьәлә чишә икән соң? Ул хәзергә бернинди мәсьәлә дә чишми. Болай гына, рәте-чираты чуалып беткән төрле вакыйгаларны исенә төшерә...

Караңгыда Фәрит генералга мәгънәле псевдоним табарга булышкан плакатны карарга тырышты. Һәм аны, аның портретын, таныш портретын күрә, берничә кат укылган, мөгаен, инде ятланып беткән текстны яңадан укый төсле тоелды.

Локня — Великие Луки өлкәсе. Ә Бютов — бу инде Көнчыгыш Пруссия. Ләкин Александр Матросовның хәрби юлы Локня тирәсендәге Чернушка авылы янында өзелеп калмады, совет сугышчыларыннан беренче булып, ул дошман территориясенә аяк басар.

Землянкада тынлык.

— Барыгыз да йоклыйсызмы? — дип сорады ярым тавыш белән Фазлыйәхмәтов.

Аңа беркем дә җавап бирмәде.

## Дошман тылында

— Игътибар, әзерләнергә! Бу мизгелне ничаклы көтсәң дә, ул барыбер искәртмәстән генә килеп җитә. Күптән түгел генә әле фронт сызыгын үткәннәр иде, күптән түгел генә караңгы, бозланган иллюминаторлар артында зенит утларының чуалчык букетлары ялтырап калган иде.

Кискен итеп, салкын тигәндәгедәй тавыш белән, сирена гырылдый. Һәм гүя аңа өстәмә булып очучы кабинасы өстендә сары ут күз кыса. Бу — килеп җиттек дигән сүз. Бу — әзер бул! дигән сүз. Тавышсыз-тынсыз гына люк ачыла. Йөзгә кискен итеп салкын һава агымы бәрелә. Шаулап торган караңгылыкка капчыкларны этеп төшерделәр. Самолеттан бер-бер артлы разведчиклар сикерә башлады. Соңгы кеше булып командир сикерде. Беренче секундта ул үзен күе бозлы һавада асылынып, хәрәкәтсез калгандай хис итте. Як-ягына каранып алды: астагы утлар әйтерсең лә киңәеп, зураеп аңа каршы йөгереп килә иде. Утлар! Ләкин күңелгә ышаныч сала, син үзең генә түгел, сине көтәләр, дигән утлар түгел иде алар. Биредә, Көнчы-

гыш Пруссиядә, разведчикларны көтмиләр иде. Күңелне куандыручы коткару утларын да алар өчен кабызмаганнар иде. Парашютлар аларны ят, дошман җиренә таба алып киттеләр!

Бәхеткә каршы, утлар яныннан ату тавышлары ишетелмәде. Фазлыйәхмәтов җиргә тыныч кына, тирбәлеп кенә төшеп утырды. Шикләнерлек бер нәрсә дә булмавына ышангач, аягына торып басты. Тирә-якта сагайта, куркыта торган тынлык. Төнге тонык киңлек. Уңда, якында гына ниндидер таш корылма беленеп тора. Артында, борылып карауга, карта буенча таныш булган сирәк урманлыкны күрде. Шәрә, үтәли туңган агачлар, тонык кына тавыш чыгарып, теләр-теләмәс кенә шыгырдыйлар иде. Тиздән кар ява башлады. Монысы яхшы — эзләрне күмәчәк.

Көтмәгәндә карга кычкырды. Бер тапкыр, ике, өч тапкыр. Фазлыйәхмәтов шатланып куйды: димәк, Николай Гришин якынлашып килә — бу аның сигналы. Җавапны ишетеп дәртләнгән, күңеле күтәрелгән Николай бер минуттан аның янында иде инде. Калганнары да бер-бер артлы җыелып бетте. Дөрес, Михаил Козич кына аягын нык авырттырган һәм ул кыенлык белән генә атлый иде.

— Урман эченәрәк керәбез, — дип боерды командир.

Җилкәләренә капчыкларын салып, парашютларын алып, күләгәләр кебек, тын гына урманга таба юнәлделәр. Авыл өстендә кояш күтәрелгәндә разведчиклар инде куркынычсыз урында иде.

Фазлыйәхмәтов сугышның яртысын дошман тылында үткәрде. Ләкин анда, оккупацияләнгән туган җирдә, кешеләр үз итәләр иде. Биредә исә барысы да башкача: дошманлык һәм явызлык сагалап тора.

Парашютларны якын-тирәдәге печән кибәнчекләре эченә яшерделәр: хәзерге вакытта моннан да уңайлырак башка урын юк иде. Һәм моннан, урманга ышыкланып, фронт штабына түбәндәге хәбәрне җибәрделәр: «Җиргә исән-имин төштек. Эшкә керешәбез. Матросов.» Хуҗа исә үзенең җавабында тиз хәбәр иткәннәре өчен рәхмәт әйткән, җиргә уңышлы төшүләре белән котлаган һәм тагын бер кат болай дип кисәткән: «Кыен район, мөмкин кадәр саграк булыгыз!»

Бер көннән штабка яңа радиограмма китәр. Матросов гомуми характердагы мәгълүматлар тапшырачак. Шундый-шундый торак пунктлар һәм шундый эшләр бар: фашистлар окоп линиясе сузалар. Көнчыгыш Пруссия белән Польша арасындагы чикнең ике ягы да бер-береннән 100—150 метр ара калдырып, дзотлар белән ныгытылган. Окоплар өч рәтле. Юл буйлап тимер чыбык киртә сузыла. Бютов һәм Мышинец шәһәрләре берничә кат окоп һәм дзот линияләре белән уратылган.

Үзегезне разведкадан шундый донесение алган командующий урынына куеп карагыз. Аны кызыксындырган район ерак, бик ерак — аңа рекогносцировкага барып та, бинокль ярдәмендә дә карап булмый. Ә менә разведчикларның мәгълүматлары картаны ничектер җанландырып җибәрделәр. Алар эшне чынбарлыкка шулкадәр якынайттылар ки, барысын да күрергә, барысын да күз алдына китерергә мөмкинлек туды. Менә алар — бу авыл-крепостьлар. Сулда — кеше дә, машина да үтә алмаслык сазлык сузылган. Уңда — автомобиль юлына параллель рәвештә — дзотлар белән аралаштырылган күп километрлы окоп линиясе. Дзотлар чик буе буйлап та сузылган — менә алар! — Һәр 100—150 метр саен. Тимер һәм шоссе юлларның тыгыз төене булган Бютов янында шулай ук ныгытмалар. Ә сиңа, командующий, карта сокланып карап утыру өчен түгел, ә бәлки гаскәрләреңне шул юнәлештә һөҗүмгә алып бару өчен кирәк. Дошманның нәкъ оясына урнашкан һәм барысын да күрә торган күзләргә, барысын да ишетә торган колакларга әйләнгән чая егет-

ләргә синең рәхмәтең минә ни өчен чиксез зур. Алар анда беренче булып килделәр, кечкенә, ләкин сугышчан авангард булып килделәр.

Һәм менә шуңа күрә аның үз кулы белән язып, кичекмәстән аларга — «Александр Матросов» сугышчыларына түбәндәге хатны җибәрергә приказ бирүе очраклы түгел:

«Кадерле иптәшләр! Сезне Яңа, 1945 ел — дошманны тәмам тар-мар итү елы белән кайнар рәвештә котлыйбыз. Сезгә сәламәтлек, бөек Ватаныбыз файдасына, батыр армиябез даны өчен сезнең авыр хәрби эшегездә уңышлар телибез. Барыгызны да кочабыз!»

Базаның ерак сагы урнашкан агачлыктан өч тапкыр ябалак кычкырды. Аның тавышы командирга ваемсыз түгел, ә бәлки таләпчән, хәтта чак кына борчулы да төсле тоелды. Ябалак урман кырыена ук терәлеп торган торак пунктта җәзачылар күренсә генә телгә килергә тиеш иде.

— Икенче вариант! — дип боерды командир. Бу поселокка параллель булган һәм шунлыктан капланып торган урман ызаны буйлап эчкәрәк — «адашкан» снаряд җимергән ташландык каравыл алачыгына күчәргә дигән сүз иде. Анда ике якка да чыгу юлы булган подвал бар. Аннан Гришин көне буе җыелган информацияне тапшыра алачак. Анда кайбер кызыклы әйберләр дә бар: үзәк пункт аша фронтка китүче хәрби эшелоннар саны кимеде, һәм, киресенчә, һаман саен ешрак, аеруча төнлә поездлар кире якка чаба башлады: ачык платформаларда — чемоданнар өеме, шкафлар, сейфлар. Әллә бу фронт сызыгын чираттагы «тигезләүме»? Шулай, күрәсең. Моны командованиенең белүе мөһим. Эвакуацион чаралар күрүче дошман чигенергә әзерләнә. Сугыш законы шундый.

Таралышып, кызу, тир бәреп чыгарлык адымнар белән атладылар. Куркыныч иде. Командир үзләренең таштан да ныграк булулары белән мактанучыларга ышанмый иде. Аларны менә разведка тормышы гына үзләрен нык тотарга, кем әйтмешли, тимердәй чыдамлык күрсәтергә өйрәтте. Мондый чакта бернинди куркыныч та чыгырдан чыгара алмый. Уйлар да киеренке, ачык һәм конкрет булалар. Фазлыйәхмәтов үз тәҗрибәсендә тагын бер нәрсәгә — сынау сәгате сукканда дисциплинаның бик нык ярдәм итүенә ышанды. Разведкада гадәттән тыш кешеләр түгел, ә шундый ук гади, гадәти кешеләр эшли! Ләкин дисциплина сиңа штаб биргән теләсә нинди белемнәрдән дә өстенрәк.

Фазлыйәхмәтов бу яктан бәхетле: аның группасы тормышта да, эштә дә һәм үз-үзеңне тотуның барлык ваклыкларында да дисциплинаны изге итеп саклый белә. Менә хәзер дә шулай. Ул әле моңа охшашлы шартларда кайбер мәҗбүри үтәлергә тиешле кагыйдәләрне искә төшерергә дә өлгермәде, ә разведчиклар инде бункерны карадылар, дозорлар куйдылар, эшкә әзерләнделәр. Радист аппаратура белән кайнашкан арада башкалар антенналарны сузып өлгерде.

Николай Гришин, стационар шартлардагы кебек, алгычны ялгады, мөмкин булган кадәр кыштырдауларны бетерде, эшләп торучы, буталып беткән нокталар арасыннан чын осталарча үзенекен — иң якынын, бердәнберен эзләп тапты. Хәзер, дусларының күзәтүе астында, Гришин хуҗага дошман тылларының качуы-күченүе турында хәбәр итә. Ашыга ул, ашыга: гитлерчыларның да радиослужба разведкасы йоклап ятмый бит, үзенә билгеле булмаган рациянең һәр сигналын тотарга һәм урынын ачыкларга тырыша. Бютов һәм Мышинец урамнарында, аның тирә-якларында Фазлыйәхмәтов түбәләренә зур антенналар куелган машиналарны күп мәртәбәләр күргән иде.

Козич кайтты. Ул заданиега кичә кичтән, Тодт төзелеш подразделениеләренең чик буе авылларына ни өчен килгәнлеген тикшерергә киткән иде. Моңа кадәр анда, жандармнардан башка, хәрбиләрдән беркем дә юк иде. Бүген төнлә, диде Козич Фазлыйәхмәтовка, җир казу техникасы китерелде, солдатлар автоген белән ниндидер металл конструкцияләр ябыштыралар. Таң алдыннан эш башланды: төзүчеләр күп километрлы траншея казыйлар, ә флангларда шоссе буйлыгына каршы металл конструкцияләр куялар һәм аларны бетон белән катыралар — бронекалфаклар эшләнә. Әле тын да алырга өлгермәгән Гришин, командирдан текст язылган тар кәгазьне алды да, тиз генә шифрлап, оста радистларның гына көченнән килә торган тизлек белән аны фронт штабына тапшырды. Ул эфирда гадәттәгедән артыграк торуыннан курыкмады, чөнки бу базадан тапшыруларның алып барылганы юк иде әле. Аннары ябалак сигнал бирү белән разведчиклар да моннан китәчәк.

Ләкин ябалак кичкә кадәр диярлек тавыш бирмәде. Ул җәзачыларның, үз кешеләре өчен берничә йортны бушатып, кунарга калуларын күргәч, Фазлыйәхмәтов янына килде. Туңган, ачыккан. Ләкин ашарга утырмады, бары тик тәмәке төреп бирүләрен генә үтенде — чөнки үзенең өшегән бармакларын кыймылдату авыр иде.

— Моннан китәргә кирәк, иптәш командир! — диде разведчик. — Алар безнең эзгә төшкәннәрдер, дип уйлыйм. Ниндидер парашют алып килделәр, урманга таба күрсәтеп, авыл кешеләреннән нидер сораштылар...

Фазлыйәхмәтов үзе дә шул хакта уйлый иде. Бәхеткә каршы, Польша инде ерак түгел. Анда кешеләр башкарак: сыендырырлар да, ярдәм дә итәрләр. Ә монда, бу районга «эшкә генә килеп йөрергә» кирәк. Гришин яңадан элемтәгә чыкты, хуҗага, монда очар алдыннан сөйләшкәнчә, күршедәге базага күчү файдалырак булачагын хәбәр итте. Элемтә үзәгендә тәҗрибәле майор Медведовский иде — ул шунда ук ризалык бирде.

Һәм яңадан юлга кузгалдылар. Туңган җиргә сак кына, йомшак кына басалар. Күңелсез, кукраеп торган хуторны читләтеп уздылар: арттан атулары ихтимал. Аннары бер генә секундка да тоткарланмыйча, бердәм ыргылу белән ташланган чик буе контроль полосасын кисеп үттеләр: чик буе менә кая кадәр күчкән икән. Тагын хутор. Монысы инде полякларныкы: инде күптән ремонт күрмәгән тәбәнәк, агач өйчекләр. Аны да әйләнеп үтеп, Ольшин авылында тукталдылар. Күзәтү күрсәткәнчә, анда солдатлар, жандармнар юк кебек иде. Разведкага Михаил Козич китә. Поляк телен яхшы белүе дә ярдәм итәр аңа. Ул инде бер атна элек Ольшинда булган, алдан танышлык та урнаштырып кайткан иде.

Ялыктыргыч көтү минутлары. Авылда үлем тынлыгы. Урамда йөрүчеләр дә, тәрәзәләрдә утлар да күренми. Бары тик чаттагы, тыштан бай күренгән бер йортның морҗасыннан гына төтен чыгып тора. Фазлыйәхмәтов авылга башкаларга караганда якынрак килде, һәр кыштырдауны борчылып тыңлап торды.

Тынлыкны нык, куркусыз аяк тавышлары бозды. Димәк, Козичның юлы уңган.

— Танышыгыз, бу безнең дус, — диде Михаил, киң җилкәле, илле яшьләр тирәсендәге, өстенә таушалып беткән күн кием кигән ир кешегә ишарәләп. — Ул безгә барысын да сөйләр...

Җирдә күпме яшәргә туры килсә дә, Фазлыйәхмәтовның полякларны бервакытта да онытасы юк. Аларның яхшылыгын, дуслыгын, һәр вакыт ярдәмгә килергә әзер торуын онытып булмый. Менә ул — меңнәрнең берсе. Туганнарча җылы итеп күрешә. Өендә кабул итә

алмавы өчен гафу үтенә: солтыста, ягъни старостада, моржасыннан төтен чыгып торган өйдә жандармнар тукталган. Бүген бөтен авыл буйлап йөрделәр, иркенрәк биналарны карадылар: тәзүчеләр килә, диделәр. Күрәсең, чикне ныгытырга. Капчыгыннан бәрәңге, ипи сыныгы чыгарды, — гафу итегез, бүтән бернәрсә дә юк. Тирә-якта ни барганын, районның ничек «сулаганын» җентекләп сөйләп бирде. Аннары урман эченә — немецларның облава ясауларын күздә тотып казылган землянкаларга кунарга алып китте. «Монда бернидән дә курыкмагыз!» — дип тынычландырды ул саубуллашканда. Һәм, Козичны үзенә чакырып, китеп барды: Козич полякка тартым иде.

Иртән, чак кына яктыра башлауга, урманга җан керде: ул кешеләр авазы, машиналар гөрелтесе белән тулды. Арттан куып килүләре түгелме? Разведчикларга әзерләнергә приказ биргәннән соң, Фазлыйәхмәтов, бер агачтан икенчесенә күчә-күчә, шосседан тармакланып киткән юл кырыена килеп чыкты. Машиналар үтеп тора, ләкин алар җәзачылар түгел, саперлар икән. Конвой күзәтүе астында, җәяүләп, башларын түбән салындырган төрле яшьтәге ирләр атлый. Фәрит аларның көчләп эшкә куып китерелгән кешеләр икәнен аңлады. Землянкага кайткач, Фазлыйәхмәтов үзенең поляк дусты белән Козичны да очратты. Алар алдында дәфтәр бите кисәкләрендә иртәнге аш тора: җан башына икешәр бәрәңге, бер баш суган һәм бер телем ипи. Шешәләрдә кызгылт-көрән төстә чәй ялтырый: җиргә төшкәннән бирле беренче чәй.

Михаил, әле күптән түгел генә ашаганын әйтеп, Фазлыйәхмәтов белән бергә читкәрәк китеп утырды һәм үзенең барлык күргән-белгәннәрен сөйләп бирде. «Саперларны иске ныгытмаларны биегәйтү өчен китергәннәр. Жандармнар җирле халыкны оборона эшләренә куалар. Ә аерым исәптә торганнарны илле-алтмыш километр ераклыкка алып китәләр: сезне, дип аңлаталар моны, инде бирегә калдырып булмый, сез фюрер каһарманнарына хыянәт итәчәксез. Күпләрен «Советларга теләктәшлек өчен» концлагерьларга җибәрәләр: Бандыс авылыннан — илледән артык, Завада хуторыннан егерме җиде кешене озатканнар. Бер авылда кулга алынганнар: «Барыбер Советлар килер!» — дип кычкырган. Ерткычланган җандармнар аларны үтергәнче кыйнаганнар. Фәлән авыллар белән фәләннәр арасында, — дип дәвам итте Козич, — саперлар бронекалфакларга пулеметлар урнаштыра. Шоссе кисешкән җирдән ерак түгел, сазлыктан башлап, танкка каршы канау казылган».

Фазлыйәхмәтов игътибар белән тыңлады. Тегендә, йөзләрчә километр ераклыкта тулырак картина барлыкка килсен өчен, барлык бу мәгълүматларны күңеленнән бер бөтен итеп берләштерде. Фәрит сугышларда разведчик түгел, ә бәлки халык, армия отканлыгын, ләкин разведчикның да һөҗүмгә баручылар сафында чын-чыннан беренче сугышчы булып баруын аңлый. Һөҗүм итүчеләрдән шактый алгарак китеп, ул, разведчик, автомат белән түгел, ә бәлки тиз һәм тирән уйлавы, үткен күзе, бөтенләй көтелмәгән информациягә күз ачып йомганчы төшенү сәләте, дошманның уена үтеп керүе, аның адымнарын алдан сизеп алуы белән ярдәм итә. Хәзер Гришин ашап алыр да, тапшыргычын үзен фронт штабы белән күренмәслек итеп бәйләүче дулкынга көйләр.

«Хуҗага. Мышинец гарнизоны икеләтә диярлек артты. Ике танк батальоны, пехота полкы һәм ротага якын элемтәчеләр килде. Матросов».

«Хуҗага. Бютов аша бер көндә кешеләр һәм техника төялгән 26 эшелон узды. Җидесендә техника яхшылап брезент белән ябылган.

Солдатлар фюрер уйлап тапкан, Германияне коткарачак ниндидер яңалык турында шаулашалар. Матросов».

«Хуҗага. Көнчыгыш Пруссиядән Мышинец һәм Чарня аша Ольшинга һәм аннары Барановога таба мотопехота, танк һәм автомашиналар колоннасы хәрәкәт итте. Матросов».

Җил, кешеләр шау-шуы һәм моторлар гөрелтесе белән тулган чик буе урманы шаулый. Дошманның оборона сызыгы ныгытыла. Соңгы сәгатьне кичектерү өчен бөтен нәрсә шунда ташланган. Гитлерчыларның күп санлы частьларыннан һәм подразделениеләреннән ерак та түгел, урман караңгылыгына ышыкланып, совет радисты шакылдата: «Та-та-та... ти-ти-ти...»

Җәза көне якынлаша...

## «Мәгълүматлар кичекмәстән кирәк!»

«Матросовка. Сездән фронт яны полосасында дошманның төзелеш һәм оборона корылмалары системасы турында кыйммәтле мәгълүматлар алдык. Мотопехота һәм танк частьларының Көнчыгыш Пруссия районнарыннан алгы сызыкка таба хәрәкәте турындагы мәгълүматларыгыз да бик әһәмиятле. Молодцы! Хуҗа!»

— Кая, миңа укырга бирегез әле... Миңа да... Миңа да...

Фазлыйәхмәтов радиограмманың аның дусларын шулай дулкынландырачагын көтмәгән иде. Ул аны аларга тантаналы итеп кычкырып укып чыкты. Соңыннан радиограмманы кулдан ясалган пепельницада яндырды һәм көлен уып ташлады:

— Я, нәрсә, эшкә керешергә кирәк...

Командир заданиеләр бүлде, хәзер нәрсәгә күбрәк игътибар итәргә кирәклеген әйтте, сак һәм тупланган булу турында кисәтте. Ольшин һәм Завадада жандармнар яши башлаган. Өченче көн һәм кичә барлык каралтыларны карап чыктылар, печән өемнәрен шомполлар белән капшап карадылар. Дуслардан берәү хәбәр иткәнчә, монда яшәүчеләрдән кемнең урманга йөрүен, утын складыннан урман эченә илтә торган эзләрнең кемнеке булуын аеруча төпченеп сораштылар. Димәк, дип нәтиҗә ясады командир, без сагаерга тиеш, югыйсә, бәлага юлыгуыбыз ихтимал. Землянкаларда кыенмы? Әйе, кыен! Суык. Юеш. Ягарга ярамый. Көндез чыгарга ярамый. Ләкин ни хәл итәсең? Булганнары өчен дә әле поляк дусларга рәхмәт! Менә бу землянкалар өчен. Аларны шулкадәр оста итеп яшергәннәр ки, хәтта янында торып та таба алмыйсың. Икмәк һәм бәрәңге өчен дә рәхмәт. Алар аны үзләренең семья члennары арасындагы кебек итеп бүлештеләр.

Разведчиклар үзләренең командирларын аңлыйлар иде: ул базадан ике тәүлеккә генә китеп торды, һәм, табигый ки, борчылды. Үзе өчен түгел, беренче чиратта, алар өчен. Фронт яны полосасы чыннан да, гаскәрләр, димәк, абвер, гитлерчылар контрразведкасы подразделениеләре белән дә тулган.

Фазлыйәхмәтов беренче булып китте. Борис белән очрашу өчен аңа тагын алты-җиде километр үтәргә кирәк иде. Ә Борис дип разведчиклар бер яшь полякны атыйлар иде. Аның фашистларга нәфрәте гаять зур. Бернәрсәдән дә курыкмыйм, ди иде ул, аларны тар-мар итү өчен теләсә нинди куркыныч эшләргә барырга риза! Һөнәре буенча механик буларак, Борис, нинди дә булса йорт техникасын ремонтлау өчен, баерак семьяларга барып йөри. Ә юл уңаеннан, гадәттән тыш күзәтүчән Борис машина номерларын да, сакчылар алма-

шынудагы кечкенә генә үзгәрешләрне дә, документлар тикшергәндә гитлерчылар тарафыннан очраклы гына ычкындырылган сүзләрне дә бик тиз отып ала.

Бервакыт Борис Фазлыйәхмәтовка контроль-пропуск пункты янында булган бер вакыйганы сөйләде. Салам астында корал яки мина юкмы, дип крестьян чанасын тикшерүче немец солдаты кинәт кенә агарып китә һәм: «Майстертод», — дип кычкырып, иптәшенә ташлана. Ул курку һәм шул ук вакытта ялагайлык тулы күзләре белән якынлашып килүче җиңел машинага таба күрсәтә. Башка солдатлар да шоссейдан төрле якка сибеләләр һәм, юл кырыена чыгып, үрә каталар. «Ә» дигәнче шлагбаум күтәрелә. Ул да гүя фашист сәламләвенә охшап урынында катып кала. Машинада Мышинец үзәгендә аерым зур йортта яшәүче майор утыра иде. Ул яшәгән йорт янында даими рәвештә кешеләр йөренә, майорның үзеннән дә югарырак дәрәҗәдәге офицерлар утырган машиналар бертуктаусыз килеп-китеп тора. Димәк, хикмәтле кош! Борис сүзләре буенча Фазлыйәхмәтов группасы майорның эзенә төште һәм аны күзәтү астына алды. Ул «Майстертод» — үтерү остасы кушаматы алган абвер начальнигы булып чыкты. «Майстертод»ның Мышинецка аның үзен һәм группасын эзәрләү өчен җибәрелгәнен ул вакытта Фазлыйәхмәтов белми иде әле. Бу соңыннан, фронт штабына кайткач ачыкланды.

Бүгенге очрашуга Борис әле генә жандармнар заданиесен үтәп өенә кайтып килүче җир казучы кыяфәтендә килгән иде. Башында — кайчандыр куян тиресеннән тегелгән чамасыз таушалган бүрек, өстендә — тишекләреннән мамыгы тырпаеп торган, безнең Россиянең җылы сырмасын хәтерләткән куртка. Егерме ике яшьлек егет көч җитмәслек эштән арган иргә әйләнгән, бары тик күзләре генә яшь һәм дәртле ялтырыйлар.

— Хәерле көн...

— Исәнме...

— Әрдәнә. Бер сәгатьтән...

Куаклык каплап торган әрдәнәдә көрәге, сырмасы һәм бүреге калды; өстенә кыска пальто, башына колаклы кышкы бүрек киеп, кулына инструментлар тутырылган портфельга охшашлы сумкасын алгач, Борис яңадан үз яшендәге кешегә әйләнде. Ул яңадан механик иде. Шунда ук, салкында туң май белән берәр телем ипи ашадылар. Борис совет дустының ярлы паекта утыруын белә һәм очрашкан саен аны ашаткалап китәргә онытмый иде. Бары тик шуннан соң гына ул нәрсә күрүе, ишетүе, белүе турында хәрбиләрчә төгәл итеп сөйләп бирә. Чарня авылына алгы сызыкка киткән артиллеристлар урынына танк частьлары килде: егерме танк, ун данә, — Борис монда нәрсәнең нәрсәгә икәнен белә, — төрле техник летучкалар, бары тик йөртүчеләре генә булган утыз биш автомашина. Өстәвенә, машиналар барысы да яңа. Озакламый мәктәптән — күрәсең, штаб шунда урнашкан — интендант чыкты. Ул, үзен котеп торучы солдатлардан бер команда алып, полиция участогына чакырылган солтыс янына юнәлде. Интендант, хәтта исәнләшеп тә тормастан, бер сәгатьтән ашханә ишегалдына ике-өч дуңгыз баласы һәм бозау яки тана китерергә кушты: имеш, танкистлар арганнар, аларга тизрәк ит ашатырга кирәк. Кешеләргә әйтегез: вермахт барысы өчен дә түлиячәк. Һәм кыр почтасы 04765-Д булган частьны атады.

— Алар кайдан килгән соң? — дип сорады Фазлыйәхмәтов.

— Бютовтан. Бу дөрес!

— Машиналарында нинди билгеләр бар?

— Билгеләр була торган урыннар барысы да буялган.

Фазлыйәхмәтов гитлерчылар техникасында имән яфрагы, кабан дуңгызы, кара тәре һәм калкан ясалган түгәрәк, чабып баручы кабан, чәберчек кош сурәте кебек билгеләр булуын белә иде. Бервакыт «Москва» отряды разведчигының тыгыз итеп эләктерелгән брезент астындагы машиналарда римча язылган «Y» хәрефен, ә хәрефтән уңда тешен ыржайткан бүре танавын күреп кайтуы хәзер дә хәтерендә әле. Соңыннан ачыкланганча, алар химиклар булган.

— Борис, бу бик куркыныч эш, ләкин шулай булса да, буяу астында нинди билгеләр булганын ачыкларга кирәк.

Командир Борис белән саубуллашканнан соң, Чарняга китте. Анда тирә-юньнән өч йөзгә якын кешене җир эшләренә куып китергәннәр. Алар арасына кереп югалуы һич тә кыен түгел. Күптән түгел ул монда күргән артиллеристлар хәзер чыннан да юк. Шәһәрчеккә танклар килүе дәвам итә. Алар да, җиңел машиналар кебек, завод буявы төсен югалтырга өлгермәгәннәр әле. «Менә монда авиация чакыртсаң иде! Ә нигә чакыртмаска?» — кинәт аның башына шундый уй килде.

Командир базага кайтты. Аяклары уттай яна. Тәне үтәли туңган төсле. Үтереп ашыйсы килә: Чарняда бары тик бер миски генә бодай өйрәсе эләккән иде.

— Монда хәлләр ничек?

— Без табыш белән, — дип җавап бирде барысы өчен дә Гришин. Һәм алар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, резервка тартыла торган батальоннар һәм полклар, кыр телефоны өчен яңа линияләр, яралыларның агылып торуы, аларның хәтта аерым йортларга да урнаштырылуы туында сөйләргә тотындылар. «Ә моны, — диде разведчик канәгатьләнү белән, — Вера бирде».

Һәм ул командирга конверт сузды. Аны фашист сөргененнән качкан һәм полякларда вакытлыча сыену урыны тапкан рус кызы Вера тимер юл станциясе яныннан тапкан. Конверт тышына ашыгып һәм нервланып инде таныш булган кыр почтасы саны язылган иде: 04765-Д.

— Очучыларга эш ясыйкмы? — дип сорады Фазлыйәхмәтов.

Гришин үзенә эшкә әзерләнергә кирәклеген аңлады.

Икенче көн таңы еш шартлаган бомба авазлары белән истә калды. Шәфәкъ төсенә кергән күктә зенит залплары ялтырап китте. Ләкин соң иде, чөнки кызыл йолдызлы самолетлар тирә-яктагы җирне Ай ландшафтына охшашлы хәлгә китергәннәр иде инде. Танклар янды. Автомашиналар янды. Чыжылдап һәм каты тавыш чыгарып ягулык мичкәләре шартлады. Авыл буйлап ярым шәрә, акылдан шашкан дошман солдатлары һәм офицерлары кая карарга белмичә кыргыйларча чабышалар иде.

Урман ышыгындагы землянкада разведчиклар командирны, ә командир аларны кочты.

Соңыннан яңадан дары сөреме белән тулган тынлык урнашты. Бютов, Мышинец, Пшаснышедагы гитлерчы учреждениеләр, маскировка турында әллә ни кайгыртып тормастан, ашыгыч рәвештә җыена башладылар. Хәер, Мышинецта Фазлыйәхмәтов моны үз күзләре белән күрде. Абвер йортыннан чемоданнар чыгаралар иде. Аларда, һичшиксез, таланган байлык булырга тиеш. Яшерен документларны шулай чемоданнарга тутырып йөртмәсләр. Ялтырап торган күн итегенә камчы белән суккалый-суккалый, «Майстертод» төяү эшләренә үзе җитәкчелек итте. Соң, абвер чемоданнар белән шулай ашыга икән, димәк, озак калмаган...

Берлин аксөякләре үзләренең качуларын төрлечә яшерергә маташтылар. Ольшинда жандармнар алдында Геббельс министрлыгы-

ның җаваплы хезмәткәре чыгыш ясады. Ул бернинди дә дәлилләр китермәде, конкрет итеп бернәрсә турында да сөйләмәде, бары тик: «Без аларны кире борачакбыз!» — дип, трибунага гына суга алды: Жандармнар элеккечә, гайрәтләнмичә генә, карлыккан тавыш белән: «Зиг хайль!» — дип кычкырдылар.

Ә алдагы көрәш боҗрасы кысылганнан-кысыла барды. Хуҗа гаскәрләрнең хәрәкәте, резервларның туплануы, совет авиациясе өчен зуррак нокталар турында көн саен хәбәр итеп тору өчен Матросовка бөтен көчне җигәргә кушты. Заданиеләр торган саен ешрак: «Мәгълүматлар безгә кичекмәстән кирәк!» — дигән сүзләр белән тәмамлана башлады. Һәм донесениеләр бер-бер артлы агыла торды.

«Хуҗага. Хожеле-Миловидь участогында зур танк часте барлыгы ачыкланды: 40 танк, танкка каршы ата торган 50 туп, 70 кә якын мотоцикл, 250 кешелек мотопехота бар. Матросов».

«Хуҗага. Дылево районыннан Ольшин авылы аша Мышинецка чигенүче танк частен күзәтәм: 30 танк, күп санда автомашина бар. Матросов».

«Хуҗага. Хожеле районыннан зур танк часте чигенә. Аның алдагы маршрутын күзәтәбез. Матросов».

«Матросовка. Информация өчен рәхмәт. Гаскәрләрнең хәрәкәтен туктаусыз күзәтегез. Танк һәм артиллерия группаларына аеруча игътибар итәргә. Хуҗа».

«Хуҗага. Безнең узел аша «Бөек Германия» дивизиясе төялгән эшелоннар узды. Матросов».

Фронт штабыннан түбәндәге задание алынды: бернинди куркыныч белән исәпләшмичә, «Бөек Германия» танк дивизиясен аеруча игътибар белән күзәтергә. Ул, диелгән иде радиограммада, әлеге участокта иң куәтлесе һәм, шуның өстенә, Гитлерга фанатикларча бирелгәне. Бронеколонналарның һәр хәрәкәтен төгәл итеп белү мөһим.

Һәм менә яңа радиограмма: «Бөек Германия» түбәндәге районда тупланды... Күренгәнчә, ул контрһөҗүмгә әзерләнә».

...Ниһаять, архивның күп битле томыннан Матросов тарафыннан алынган соңгы радиограмма килеп чыга:

«Сезнең группа сугышчылары «Бөек Германия» танк дивизиясенең Көнчыгыш Пруссиядән фронтка күчерелүен үз вакытында күреп алдылар. Группаның бөтен личный составына рәхмәт белдерәм. Хуҗа».

Көнчыгышта каты, өзлексез гөрселдәү тавышы көчәйгәннән-көчәя бара. Җир селкенгәндәй тоела. Урман калтырана. Юллар тоташтан техника, солдатлар белән тулган. Алар инде: «Зиг хайль!» — дип кычкырмыйлар.

Фазлыйәхмәтов, паникага бирелеп качучы бу тараканнарга карап, Мәскәү янын, үзенең беренче мәртәбә дошман тылына чыгуын исенә төшерде: ул чагында гитлерчылар тәкәббер һәм оятсыз кыланалар иде. Димәк, бу тәкәбберлек сүрелгән...

Ә аннары Ольшин ягындагы төтен, гөрселдәү тавышлары эченнән сугышчыларның кадерле йөзләре күренде: аларның бүрекләрендә кызыл йолдызчыклар балкый иде. Кирза итекләргә йөзләрчә һәм йөзләрчә юлларның тузаны утырган. 139 нчы дивизия командиры Фәрит Фазлыйәхмәтовның рапортын тыңлады, разведка группасы җитәкчесе Александр Матросов дип язылган таныклыкны кулында озак һәм ничектер гадәттәгедән тантаналырак итеп тотып торды, һәм, җыелып торган офицерларга да игътибар итеп тормастан, разведчикларны берәм-берәм кочарга тотынды:

— Батырлар... Чын батырлар!

Ул көн турында Фазлыйәхмәтов башка берни дә хәтерләми. Ул бер тәүлек диярлек урыныннан кузгалмыйча йоклый...

Аның каравы, авыр, утлы бу көннәр барысы да хәзер ап-ачык булып хәтергә төшәләр. Фәрит Салихович разведчиклар, үзенең фронтташ дуслары белән очрашулары турында сөйли. Алар барысы да уңышлы эшлиләр.

Фәрит Салихович үзе турында дәшми, күбрәк башкалар, аеруча Чеклуев, үзенең иң яраткан кешесе турында сөйли. Фәрит Салихович үзе күренекле һәм талантлы инженер булып үскән. Партком секретаре безгә аның турында болай дип сөйләде: «Бик яхшы работник. Бик яхшы коммунист. Аңа контроль кирәк түгел — үз-үзенә иң таләпчән контроль. Тик бер генә үпкә бар аңа — моңарчы үзенең батырлык һәм каһарманлык белән тулы фронт тормышы турында бер генә сүз дә әйткәне булмады. Бәйрәмнәрдә орденнарын тага, ләкин иптәшләре: нәрсә өчен бирделәр, дип сораса, оялып кына җилкәләрен җыерып куя: сугыш өчен, әлбәттә. Һәм тагын тынып кала...»

Әйе, Фәрит Салиховичның күп сөйләшә торганнардан булмавы дөрес. Ул кабат-кабат басым ясап әйтә: барысы да сугышты, бөтен ил, бөтен халык сугышты.

Күптән түгел Фәрит Салихович Польшага барды, кайчандыр үзе яшеренеп йөргән җирләрдә булды.

— Безне кырык дүрттә үзенә сыендырган авылларны һәм шәһәрләрне танырлык түгел, — ди Фәрит Салихович, уйчанланып һәм дулкынланып. — Алтын куллы халкының хезмәте белән Польша төзекләнгән, яшәргән. Мин сугышның кырыс елларында безгә ярдәм иткән барлык кешеләргә хөрмәт белән баш идем. Алар да миңа, теге вакыттагы кебек, ихтирам хисе белән җавап бирделәр...

Бер нәрсә дә онытылмый. Барысы да йөрәктә изге истәлек булып саклана.

## Самат Шакир

# ЧЕМПИОН КЫЗ ГАЛИМӘ



Илебезнең гүзәл башкаласы Мәскәүдә Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXV съезды хөрмәтенә Спорт сараенда күренекле спорт мастерлары чыгышы булды. Монда дөнья чемпионы Галимә Шөгерова да катнашты. Алып баручы аның исемен әйтүгә, зал озак һәм бердәм кул чапты.

Галимә аренада кыршау белән фигуралы чыгышлар ясый иде. Төрле шәһәрләр, төрле илләр, җир шарының төрле материкларыннан килгән делегатлар һәм кунаклар бу яшь-яшь кызның шул кадәр оста чыгыш ясавына сокландылар, гаҗәеп оста чыгыш ясавына югары бәя бирделәр.

Бу мәһабәт Спорт сараенда Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының Генеральный Секретаре Л. И. Брежнев, шулай ук партия һәм Совет дәүләтенең башка җитәкчеләре дә бар иде.

Галимә үзенең номерларын башкарып бетерергә дә өлгермәде, зал озак итеп, көчле итеп кул чаба башлады... Кыз елмаеп башын иде. Аңа чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр.

Кызның мондый язмышы, зур таланты бик күп язучыларны, журналистларны кызыксындырды.

.... Галимә 1953 елның 8 ноябрендә Омск шәһәрендә туа. Семьяда шатлыкның иге-чиге булмый. Чөнки ул беренче бала була. Аңа исемне әнисе тәкъдим итә. Нәҗибә ханым, кыз бала булса, Галимә исеме кушарбыз дип, алдан ук уйланып йөргән була. Әтисе Әхмәтгәрәй, әнисе Нәҗибә Галимәне укытучы итәргә теләгәннәр. Шуның өчен аңа педагоглар турындагы китапларны күбрәк укырга киңәш биргәннәр. Әмма Галимәне башка нәрсә кызыксындырган. Ул кече

яшеннән үк нәфис гимнастика белән шөгыльләнә башлый. Әле икенче класста укыганда ук туп белән гимнастика ясауда ул укытучыны гаҗәпкә калдыра. Укытучының киңәше белән Галимә Омск шәһәрендәге балалар өчен оештырылган гимнастика мәктәбенә йөри. Ә көннәрнең берендә йөрмәс була. Тренер Галина Павловна Горенкова борчыла һәм Шөгерованың квартирасына килә. Галина аптырап кала, чөнки Галимә караватта авырып ята.

— Ни булды сиңа? — дип сорый тренер борчылып.

— Зарар юк, болай гына.

— Нинди сүз ул, «болай гына»?

Галимә өчен әнисе җавап бирә:

— Шук малайлар Галимәне куа башлаганнар. Ул ике катлы өйнең түбәсенә менгән. Малайлар да менә башлагач, шуннан сикергән һәм аякларын авырттырган.

Тренер бу нәрсәгә гаҗәпкә кала. Ул, кызның юрганын ачып, аякларын тотып карый.

— Авыртмыймы?

— Бераз гына...

Тренер аңа тизрәк аякка басуны теләп китеп бара. Галимә ул киту белән сикереп тора, ләкин, аяклары авыртуга чыдый алмыйча, караватка утырырга мәҗбүр була. Шул көнне үк аны «Ашыгыч ярдәм күрсәтү» машинасы больницага алып китә.

... Ярты елдан соң гына тынгысыз кыз яңадан гимнастлар мәктәбенә йөри башлады. Галимәнең бик яраткан ике әбисе — Мәфтуха һәм Зөләйха бар. Бу әбиләр оныкларының тазарып ике мәктәпкә дә йөри башлавына чын күңелдән куаналар. Куанмаслык та түгел шул, чөнки Галимәне алар тәрбияләп үстергән. Иң беренче сүзләрне дә шул әбиләрдән өйрәнеп үсә Галимә. Алар оныкларына татарча җырлар өйрәтәләр, әкиятләр сөйлиләр, тырыш булырга өндиләр. Галимә батыр кызлар, дөнья чемпионнары турындагы китапларны кызыксынып укый башлый. Спорт ярышларында да катнаша. Ул башта мәктәп күләмендәге беренчелекне ала. 7—8 классларда укыганда Галимә исә район һәм өлкә күләмендә нәфис гимнастика буенча ярышларда беренче урынны яулый. Аннары СССР күләмендәге ярышларда катнаша һәм тренерларны, судьяларны таңга калдыра. Тамашачылар аңа озак итеп кабат-кабат кул чабалар, чәчәкләр белән күмәләр. Советлар Союзының төрле шәһәрләреннән килгән кунаклар һәм туристлар Галимәне үзләренә чакыра.

Омск шәһәренең 134 нче мәктәбе укучысы Галимә кайларда гына булмады, кемнәр белән генә очрашмады! Ул Ленинградта һәм Мәскәүдә, Тбилисида һәм Бакуда, Алма-Атада һәм Дүшәмбедә үткәрелгән ярышларда да беренче урыннарны алып, дистәләрчә алтын медаль белән бүләкләнде. Таҗик кызлары аңа атап җырлар җырладылар, әзербәйҗан шагыйрьләре шигырьләр яздылар, Ленинград һәм Мәскәү журналистлары аның турында очерклар язып бастырдылар, казакъ музыкантлары, думбрада уйнап, Галимәне мактадылар. Галимә бу зур уңышларга карап масаймады, яңадан-яңа күнегүләр ясады, иртәнге 5—6 сәгатьтән алып, кичке 10 га хәтле яңа фигуралар, нәфис чыгышлар белән көн үткәне сизелмәде дә. Мәскәүдә булган уңышлы чыгышлардан соң атаклы спорт мастеры Елизавета Алексеевна Облыгина Галимәнең тренеры Галина Павловнага болай диде:

— Бу кызның киләчәге бик өметле. Ул бөтен дөньяны таң калдырырга мөмкин! Бу алтын кызны сез ничек кенә булса да саклагыз! Аның белән туктаусыз күнегүләр эшләгез.

Әйе, Елизавета Алексеевна алдан күреп әйткән бу сүзләрнең дөреслеген Галимә үзенең чыгышлары белән раслады. Ул 15 яшендә Болгариягә бара. Анда Варна шәһәрендә атаклы дөнья чемпионнары белән очраша, яңа төр спорт күнегүләре ясый... Ниһаять, Варна шәһәрендә үткәрелгән дөнья чемпионатында катнаша. Башта Галимә каушап кала. Каушамаслык та түгел, чөнки моңа кадәр аның дөнья чемпионатындагы атаклы гимнастлар белән очрашканы булмады. Шундый көн җитте: дөньяның бөтен радиолары, телевизорлары, газеталары 15 яшьлек кызның ярыш аренасына чыгуын хәбәр иттеләр. Менә Галимә аренада. Ул туп белән бик оста чыгыш ясады. Тасма белән чыгышын судьялар гаҗәпкә калып карадылар. Кыршау белән ясаган чыгышларында да Галимә югары балл алды. Менә ярышның нәтиҗәләре:

— СССРдан килгән 15 яшьлек кыз Галимә Шөгерова югары күрсәткечләргә иреште һәм дөнья чемпионы дигән мактаулы исемгә лаек булды!

Бөтен зал аны алкышлады. Бөтен дөнья газеталары Галимә Шөгерованың зур җиңүен язып чыктылар.

Бу турыда ишеткәннән соң әнисе Нәҗибә дә, әтисе Әхмәтгәрәй, әбиләре Зөләйха һәм Мәфтуха, энесе Рәшит тә чиксез шатландылар. Мәфтуха әби оныгының рәсеменә карап болай диде:

— Кечкенә чакта ук бау белән сикереп уйнарга бик ярата иде. Мин ачулана башлагач, ул авызын ерып көлә дә: «Мин спортчы булам», ди торган иде. Әйе, бәбкәм, бик дөрес әйткән икән.

Нәҗибә аны төзәтә:

— Дөнья чемпионы булды синең оныгың.

105 яшьлек Мәфтуха әби көлә генә. Ул үзенең йөрәк түреннән чыккан сүзләрен әйтә:

— Ул инде чәчәк таҗы киде, зур дәрәҗәгә менде. И минем кечкенәм, Галимәкәем!


Омск шәһәренең 9 класс укучысы Галимә Әхмәтгәрәй кызы Шөгерова турында «Правда», «Известия», «Советская Россия», «Советский спорт» һәм башка газета, чит илләрнең газеталары язып чыктылар. Ә журналлар аның рәсемен зур итеп тышлыкка урнаштырдылар. 15 көн буена телеграммалар һәм котлау хатлары килеп торды. Дөньяның төрле материкларында яшәүче халыклар унбиш яшьлек кызның спортта шул кадәр зур уңышка ирешүенә сокландылар һәм аларның күбесе Галимәгә үз телләрендә котлаулар җибәрделәр.

Галимә Варнадан өч алтын, берничә көмеш медаль һәм дөнья чемпионы дигән диплом алып кайтты. Аңа СССРның атказанган спорт мастеры дигән мактаулы исем бирелде.

Чемпион кыз яңадан-яңа күнегүләр эшләвен дәвам итте. Ул Советлар Союзының йөзләрчә шәһәрләрендә, Америка, Англия, Франция, Германия Демократик Республикасы, Чехословакия, Венгрия һәм башка илләрдә булып, нәфис гимнастика буенча ярышларда беренче урынны алды һәм алтын медальләр белән бүләкләнде. Аның җиңеп чыгуы уңае белән дөньяның зур-зур шәһәрләрендә Советлар Союзы Гимны уйналды. Советлар Союзының абруен күтәрүдә Галимә үзеннән зур өлеш кертте. Спорт мастерлары аның искиткеч зур уңышлары турында китаплар яздылар, радиоларда һәм телевидениеләрдә чыгышлар ясадылар.

... 1973 елда Галимә Роттердам шәһәренә бара. Монда бөтен дөньяның атаклы спорт мастерлары — спорт таҗының энҗеләре җыйналган була. Шөгеровага бу вакытта егерме яшь.

Шәһәрнең данлы «Ахой» спорт комплексының якты утлар белән яктыртылган зур залы. Залда кара күзле, кара кашлы, нәфис



гәүдәле Галимә басып тора. Ул дулкынлана, башында күп төрле уйлар... Исемнәре бөтен дөньяга яңгыраган гимнастлар. Алар нәфис гимнастика буенча дөнья чемпионатында көч сынашалар. Менә иң югары балл алган абсолют чемпион Мария Гигова. Кая инде аны узу дип уйлый Галимә. Шул чакта Галимә Шөгерованың нәфис гимнастиканың бер төре — туп белән чыгыш ясаячагын әйттеләр. Менә Галимә бөтерелеп килеп чыкты да туп белән күз иярмәстәй хәрәкәтләр ясый башлады. Тамашачылар һәм судьялар аңа карап гаҗәпләнделәр. Алар алдында гүя җир кызы түгел, ниндидер тылсымлы әкият кызы чыгыш ясый иде. Яңа бөтерчекләр ясаган саен кул чаптылар, ә ахырда ун меңле зал бердәм аякка басты һәм ун минут буена кызны алкышлады. Бу чын могҗиза иде! Галимәне аренага кабат-кабат чыгардылар, төрле телләрдә рәхмәтләр әйттеләр, «бис» кычкырдылар. Яшь кыз, Нидерландта иң югары балл җыйнап, дөньяның абсолют чемпионы дигән мактаулы исемне алды. Бу аның өченче мәртәбә чемпион булуы иде.

Вашингтонда булган ярышлардан соң журналистлар Галимәне күп кенә сораулар белән күмделәр. Аларның күбесе бу яшь совет спортсменкасының кем булып эшләвен һәм нинди семьядан чыгуын кабат-кабат сорадылар. Галимә аларга горурланып җавап бирде:

— Мин студентка. Әти заводта эшли.
— Димәк, сез эшче кызы?
— Әйе.
— Ә анагыз?
— Стадионда.
Журналистлар аңа гаҗәпләнеп карадылар.
— Тренермы?
— Юк, — диде Галимә, — техник эшче.

— Сезнең нәселегездә чемпионнар булганмы?

— Эш белән чемпион булганнар! Безнең эти-әниебез гади эшчеләр. Алар мине бик яшьтән үк спорт мәктәбенә биргәннәр.

Шакмаклы чалбар, маймыл сурәтләре ясалган яшел күлмәк кигән, таза, юан журналист, алтын бизәкләр төшкән авторучкасын авызына кабып уйланып торганнан соң, тәрҗемәчегә эндәште:

— Әйтегез әле аңа, ул укыган өчен күпме түли икән?

Тәрҗемәче әйтеп тә бетерә алмады, Галимә шунда ук аңлап алды һәм көлемсерәп җавап бирде:

— Безнең илдә укыган өчен студент бер тиен дә түләми. Киресенчә, әгәр студент яхшы укый икән, дәүләт аңа стипендия бирә. Бездә акча түләп укымыйлар.

Бу сүзләрне ишеткәч, журналистларның берсе сызгырып ук җибәрде.

Галимә үзенең СССРда яшәве, Советлар Союзы гражданкасы булуы белән горурлана, чын күңеленнән шатлана, чит ил журналистлары белән очрашу вакытларында бу турыда аерата басым ясап сөйли. Очрашуларның берсендә ул болай диде:

— Әгәр дә мин патша Россиясендә яшәсәм, мин дөнья чемпионы була алмас идем. Хәтта мин урта белем дә ала алмас идем. Чөнки патша Россиясендә эшче һәм крестьян балалары укый алмаган, аларны югары дәрәҗәгә күтәрмәгәннәр. Безнең илебездә эшче дә, колхозчы-крестьян да дәүләт белән идарә итүгә чаклы хокуклы!

Чемпион кыз Австралиядә дә, Һиндстанда да нәфис гимнастика буенча ярышларда булды һәм беренче урынны алды. Һиндстанның танылган кино артистлары аңа истәлекле бүләкләр бирделәр. Бу илне ул бары тик киноларда гына күреп белә иде. Ә хәзер үзе шул илдә, аның бакчаларында йөри, борынгы сарайларны, тарихи урыннарны карый. Әмма шулай да үз илеңә, үзең туып-үскән шәһәргә нәрсә җитә! Үз илеңнең таулары алтын шул!

... Галимә мәктәптә гел «5»легә генә укыды. Унынчы классны тәмамлап чыкканнан соң педагогия институтына укырга керде. Уку белән бергә, ул нәфис гимнастика белән дә шөгыльләнүен дәвам итте.

Галимә бик тырыш кыз иде. Ул һәр көнне иртәнге 6 да тора һәм нәфис гимнастика күнегүләре ясый, гүя ул бүлмәдә түгел, спорт залында. Лента белән чыгыш ясаганда аның гәүдәсе шундый кызу хәрәкәтләнә, әйтерсең лә ул канатлы кош. Туп белән чыгыш ясаганда аяклары, беләкләре буенча туп үзе шуыпмы, тәгәрәпме менә диярсең. Алай гына да түгел, яшь кызның гәүдәсе бу чыгышлар өчен тумыштан ук яраклашкан диярлек. Менә шул күнегүләр вакытында кулдан туп төшеп китсә яки алга сөрлегеп куйсаң — бу инде зур хата. Галимә андый хаталарны бер дә яратмый.

Ике сәгатькә якын күнегүләр ясаганнан соң ул ашап-эчә һәм мәктәпкә китә. Укудан кайткач, спорт залына ашыга. Анда аны тренер Галина Павловна көтеп тора. Яңадан күнегүләр — бөтерчекләр, лента белән сикерүләр... Карап торсаң, гаҗәпкә каласың! Ярты сәгатьтән кызның аркасына тир бәреп чыга.

Тренерга Галимә үз эшеннән канәгать булмавын әйтә. Спорт мастеры Галина Павловна аңа болай ди:

— Синең үз эшеңнән канәгать булмавың — әйбәт сыйфат. Димәк, тагын да күбрәк, тагын да тырышыбрак эшләргә кирәк!

Галимә тагын үзен-үзе онытып, бөтен күңелен биреп эшкә тотына, тренер тагын төзәтмәләр кертә. Бер сәгатьтән соң Галимә хәлдән тая, ләкин тренерга сиздермәскә тырыша, тренерның ял ит бераз дигәнен дә ишетми, яңа фигуралар ясый. Уңышлы күнегүләрдән

соң тренер аның күңелен күтәрергә тели. Ләкин Галимә канәгать түгел:

— Мондый фигураларны башка спортсменкалар да ясый ала. Ә мин алар эшли алмаганны ясарга тиеш!

Әнә шулай туктаусыз күнегүләр белән атналар, айлар уза. Кыз тырышып эшләвен дәвам итә, авырлыкларны җиңә бара.

Чемпион кыз Кубада булган вакытта да беренчелекне ала, аларны кубалылар тәбрикли. Трибунада утырган хөкүмәт һәм партия вәкилләре арасында Галимә Кубаның премьер-министры Фидель Кастроны да күрә. Фидель Кастро аларны тәбрикләп кулын изи.

Дөнья чемпионы һәм СССРның абсолют чемпионы, СССРның атказанган спорт мастеры Галимә Шөгерова комсомолның XVII һәм XVIII съездларында делегат булып катнашты. Ул залга спорт байракларын алып кергәндә беренчеләрдән булып килде.

Соңгы елларда чемпион кызның шәхси тормышында да зур үзгәреш булды. Ул үзе шикелле чемпион егет белән танышты. Алар яшьлекнең иң гүзәл көннәрен бергәләп ярышларда үткәрделәр, кино-театрларда булдылар, чит илләргә бергә бардылар. Казан ягыннан килгән Ринат Шәрәфуллин үзе дә танылган спортчы — велосипедта узышчы.

Соңгы ике елда Украина спортчысы Ирина Дерюгина Галимәдән өстен чыккан иде. Шул көннән соң Галимә күнегүләрне бик нык арттырды.

— Мин беренче урынны яңадан алырга тиешмен! — ди Галимә.

... Галимә 1978 елның 13 ноябрендә Испаниянең башкаласы Мадридта спорт ярышында катнашты. Анда ярышлар барган вакытта без Галимәнең квартирасында идек. Телевизор алдында Галимәнең әнисе Нәҗибә, әтисе Әхмәтгәрәй, әбисе Мәфтуха, энесе Рәшит утыралар. Менә диктор Галимәнең аренага чыгачагын әйтте. Нәҗибә ханым һәм Әхмәтгәрәй аренага чыккан кызларына төбәлделәр. Галимә тасма белән нәфис фигуралар ясый башлады. Нәҗибә ханым дулкынланып аңа карый, урынында тора алмый...

Шар белән нәфис гимнастика чыгышлары да уңышлы булды. Ниһаять, ярышның нәтиҗәсе турында судьялар үз фикерләрен әйтәләр. Диктор ярыш нәтиҗәсен белдерә:

— Галимә Шөгерова иң күп балл җыйнап, дөнья чемпионы Ирина Дерюгинаны узып китте һәм беренче урынны яулады. Ул Европа чемпионы дигән мактаулы исемгә лаек булды!

Бу сүзләрне ишеткәннән соң, Нәҗибә ханымның күзләренә шатлык яшьләре чыкты. Ул телевизор экраныннан карап, пьедестальдә басып торган кызына:

— И кызым, күз нурым, исемебезне кайларга кадәр алып киттең! Исән-сау йөреп, тизрәк кайт, — дип пышылдады.

Иртәгесен Галимә Шөгерованың Европа чемпионы булуы турында СССРда һәм чит илләрдә чыга торган газеталар зур хәрефләр белән язып чыктылар. Без газета хәбәрен укып утыра идек, телефон шалтырады. Трубканы алуга, Галимә тавышы ишетелде. Ул шат һәм көр тавыш белән исәнлек-саулык сорашты. Нәҗибә ханым аның кайдан сөйләшкәнен сорады.

— Испаниядән бүген иртә белән кайтып җиттек. Аэропортка төшү белән, сезгә шалтыратырга ашыктым. Әле Мәскәүдә булабыз, Комсомол Үзәк Комитетына барабыз, киностудиягә дә чакырдылар.

Нәҗибә ханым да аңа өстәп куйды:

— Монда безгә дә дистәләрчә телеграмма килде, кызым. Кайчан кайтасың?

— Озакламый кайтырбыз, сагындым сезне, әни! — диде Галимә.

... Без аның бүлмәсендәге сувенирларны карап утырдык. Кайсы илләрдән, кайсы шәһәрләрдән генә бирелмәгәннәр алар! Фоторәсемнәрнең дә исәбе-хисабы юк. Без ул рәсемнәр арасында бик таныш кешеләрне — дәүләт җитәкчеләрен, атаклы спорт осталарын, әдәбият һәм сәнгать вәкилләрен, Советлар Союзы һәм Социалистик Хезмәт Геройларын, Ленин һәм Дәүләт премиясе лауреатларын күрдек. Алар арасында — татар кызы, безнең дустыбыз Галимә Әхмәтгәрәй кызы Шөгерова.

1979 елны каршы алу уңае белән «Неделя» газетасында «Почет пьдестале» дигән рубрика астында биш сорау бирелгән иде. Бишенче сорау болай диелгән:

— Елның бик мөлаем, иң сөйкемле, күңелне үзенә тарта торган спортчысы кем?

Бу сорауга илебезнең төрле почмакларында яшәүче укучылардан 1756 хат килгән һәм аларның фикерләре газетада урнаштырылган. Барлык хатларда да Галимә Шөгерованың һәм Владимир Ященконың бик сөйкемле, күңелне үзенә тарта торган спортчы булуын язалар.

ТАСС хәбәрчесе Галимәгә мондый сораулар бирә:

— Сез бу уңышка ничек ирештегез?

— Барыннан да элек, зур тырышлык, нәфис гимнастика буенча үз өстемдә даими эшләү. Шуның өстенә башка спорт мастерларының тәҗрибәләрен өйрәнү һәм спорт турындагы китапларны күп уку да ярдәм итте, — диде Шөгерова.

— Киев кызы — дөньяның абсолют чемпионын узып китүегез турында сөйләсәгез иде.

— Мин күптәннән инде мондый җиңү турында хыяллана идем һәм хәзер икеләтә бәхетлемен. Беренчедән — континентның беренче чемпионы булдым. Икенчедән — бу югары исемне җитди көндәшләрем белән булган авыр көрәштә яуладым.

«Комсомольская правда» газетасы чемпион кыз турында берничә мәртәбә очерк һәм мәкалә язып чыкты. 1978 елның 14 ноябрь санында «Гүзәллекнең җиңүе» дигән мәкаләдә түбәндәге юллар бар: «Галимә Шөгерова нәфис гимнастика тарихында беренче буларак Европаның абсолют чемпионы булды. Ул Спорт сараеның аренасы читендә сулкылдап елап җибәрде. Беркем дә аны юатырга батырчылык итмәде, ни өчен елавы турында сорамады, чөнки аның күзләрендә шатлык яшьләре иде... Һәм менә, ниһаять, җиңү! Омск институтының дүртенче курс студенткасы зур уңышка иреште!»

Әйе, гүзәллекнең зур җиңүе иде бу!

ОМСК — КАЗАН

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

## БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

### Халыкчан, партияле һәм югары художестволы шигърият өчен

*Түгәрәк өстәл янында*

**Зәки Нури, шагыйрь, журналның баш редакторы.** Май аенда Татарстан Язучылар союзының чираттагы IX съезды була. Шул съездга хәзерлек тәртибендә журнал сәхифәләрендә бүгенге татар совет поэзиясе һәм аның актуаль мәсьәләләре турында сөйләшү башлап җибәрелгән иде. Һәм менә бер елдан артык вакыт үтеп китте, шул арада 24 авторның 12 табакка якын гомуми күләмдәге материаллары дөнья күрде. Фикер алышуда тәнкыйтьчеләр, язучылар гына түгел, төрле һөнәр кешеләре — укытучылар, инженерлар, геолог, философ һәм башка профессия вәкилләре катнашты. Карашлар төрле-төрле булса да, чыгыш ясаучы авторлар һәркайсы бүгенге поэзиябезнең торышы, аның гражданлылыгы өчен тирән борчылып, ихлас фикерләре белән уртаклашты. Бигрәк тә шагыйрьләребез иҗатының тормыш һәм халык белән тыгыз бәйләнеше мәсьәләләре алгы планга куелды. Шигъриятебез алдында торган үзәк бурычларның берсе буларак, югарыга аның гражданлык активлыгы һәм сугышчанлыгын арттыру проблемасы калкып чыкты. Һәм менә бүген — әлеге сөйләшүне йомгаклау максаты белән үткәрелгән түгәрәк өстәл янында фикер алышуда да әлеге мәсьәлә һәм проблемалар игътибар үзәгендә булыр дип ышанабыз.

**Нил Юзиев, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.** Бу сөйләшүне съезд алдыннан оештыру бик уңышлы дип саныйм. Поэзиябез турында сөйләшү журналда басылган мәкаләләр белән генә чикләнми, барысын җыеп караганда, сөйләшү нәтиҗәле һәм файдалы булып чыкты. Безнең сөйләшү конкрет шагыйрьләр, конкрет әсәрләр нигезендә барды һәм шуның белән дә отышлы. Бигрәк тә, үткән чордагы сөйләшүләр белән чагыштырганда, быел бер юнәлештә оештыру эше, редакциянең, стихиягә артык юл бирмичә, поэзиянең үзенчәлекле якларына игътибар юнәлтеп килүе зур әһәмияткә ия.

Бүген актив иҗат иткән шагыйрьләр иҗатында нинди әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә һәм яшь буын шагыйрьләрнең әсәрләре кайсы яклары белән аерылып тора? — Т. Галиуллин мәкаләсендә әнә шундый конкрет һәм әһәмиятле мәсьәләләр куелды. С. Сөләйманова мәкаләсе хатын-кыз шагыйрьләрнең иҗатын тулы яктыртуы белән уңышлы дип әйтер идем. Бу мәкалә әлеге өлкәне тулыландырып җибәрде. Сибгат ага мәкаләсендә традицияләр мәсьәләсе киң яктыртылды. Гомумән, башка мәкаләләр дә әйбәт тәэсир калдыра.



*Сөйләшү фәнни төстә бик җитди башланып китте.*

Сөйләшүдә поэзиядә гражданлык һәм шагыйрь шәхесе турында сүз барды. Поэзия һәм поэзия тәнкыйте турында... Сөйләшү шактый киң булды һәм кызыклы, әһәмиятле фикерләр әйтелде. Сөйләшүнең уңышлы ягы тагы шунда, анда шагыйрь һәм тәнкыйтьчеләр генә түгел, укучылар да актив катнашты. Безнең укучы шактый үскән икән, зәвыклы икән дигән фикер кала.

Сөйләшүдә яшь тәнкыйтьчеләр һәм шагыйрьләрнең актив катнашуы шатландыра, алар бүгенге поэзиябез турында фикер йөртеп, җитди мәкаләләр белән чыктылар. Мин аларны бик яратып укыдым һәм шунысы куанычлы, ул мәкаләләр бер-берсен кабатламый, һәркайсы үзенчәлекле. Сөйләшүнең отышлы якларыннан берсе — фикерне туры әйтергә мөмкинлек бирү һәм шул нигездә аерым шагыйрьләрнең, тәнкыйтьчеләрнең фикерләре ачыктан-ачык әйтелде. Аларның аерым концепцияләре белән таныштык. Тәнкыйтьчеләрнең бүгенге поэзиядәге кайбер мәсьәләләрне аңлатулары шигъриятнең асылы хакында бик кызыклы фикерләр уянуга җирлек бирә.

Бүгенге көнне төп тема булып хәзерге поэзиядә гражданлык юнәлеше, аның ничек яктыртылуы мәсьәләсе тора. Без поэзиядәге гражданлыкны ничек аңлыйбыз? Шул мәсьәлә буенча төрле-төрле фикерләр әйтелде. Гражданлыкны тарайтып, аны политик темага язылган шигырьләр белән генә чикләп карауга каршы чыктылар. Бу безнең поэзиянең үсеше дип карыйм мин. Гражданлык тойгысын социаль-политик мотивлар белән генә чикләү көчле иде. Күрәсең, чор үзе төп игътибарны социаль-политик юнәлешкә этәргән.

70 нче елларда поэзия дөньясы тагы да киңәйде, ата-ана, сөю, гаилә мәсьәләләренә игътибар бермә-бер көчәйде. Шагыйрьләр мәхәббәт турында күп язалар һәм бик матур шигырьләр язалар — бу поэзиябезнең казанышы. Нинди рәк рухта ачыла соң бу хисләр? Әлеге мәсьәлә безне җитди уйландырырга тиеш. Бу тема традицион рухтарак, Пушкиннардан килә торган традицион формада гына ачылуын дәвам итә түгелме?..

Хәзер безнең тормышта, семьяда гаять кискен үзгәрешләр бара. Моны көнкүреш революциясе дип атарга була. Семьяларның тотрыксызлыгы мәсьәләсе һәммәбезне җитди борчырга тиеш. Таралмаган семья эчендә дә кискен бәрелешләр баруы яшерен-батырын түгел. Шагыйрьләрне дә тирән уйлануларга этәрә бу мәсьәлә. Әмма әлегә ул җитәрлек дәрәҗәдә чагыламы соң? Юк, тиешле дәрәҗәдә чагылмый. Шагыйрьләр тарафыннан, гражданин буларак, кыю фикерләр азрак әйтелә. Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» повесте бу уңайдан күпләргә мисал булып тора ала. Гражданлыкны без шактый киң итеп аңлыйбыз. Шагыйрьләр шушы якка игътибар итсәләр, уйлансалар әйбәт булыр иде.

Фикер поэзиясе белән хис поэзиясен кара-каршы куеп сөйләшү белән килешеп булмый. Болар бер-берсен тулыландыралар, аларны бер-берсенә каршы куеп карау дөрес түгел, һәркайсының отышлы яклары бар. Төрле тип поэмаларны бер-берсенә каршы кую тенденциясеннән дә качарга, югарырак торырга кирәк.

Бу сөйләшү үзе үк бик күп фикерләр уята, һәм ул гомумән безнең әдәбият белеме өчен дә, поэзиябез өчен дә файдалы булачак. Киләчәктә дә шушындый сөйләшүләр уздырырга кирәк.

**Тәлгать Галиуллин, тәнкыйтьче, Алабуга дәүләт педагогия институты ректоры.** Соңгы биш-ун ел эчендә генә татар поэзиясе үсешенең гамәли һәм теоретик мәсьәләләрен менә шулай уртага салып, коллегиаль рәвештә тикшергән сөйләшүне хәтерләмим. Газета-журналларда, тәнкыйть мәкаләләрен туплаган җыентыкларда басылган мәкаләләр дә, тоташ, өзлексез процесс булган әдәбиятны тар вакыт рамкалары белән чикләргә мәҗбүр булган ел йомгаклары да шигъри байлыгыбызны бөтен тулылыгында күз алдына бастыра алмый иде. «Казан утлары» журналы битләрендә барган бу фикер-уй алышу әдәбиятыбыз тормышында мөһим бер вакыйга рәвешен алып бара. Тәнкыйтьчеләр, шагыйрьләр һәм поэзия сөючеләр арасында кабынып киткән сөйләшүнең Татарстан язучыларының булачак съездына хәзерлек көннәрендә баруы да дискуссиянең абруен күтәрә.


Чыгыш ясаган авторлар да, редакция үзе дә сөйләшү сферасын киң итеп куйдылар һәм фикерләшүнең үзәк проблемасын, максатын, нигез баганасын таптылар. «Казан утлары» тәнкыйтьче һәм шагыйрьләр игътибарын хәзерге поэзиядә гражданлык хисләренең яңгырашына һәм тиешле эстетик югарылыкта ачылуына юнәлтергә чакыруы белән хаклы иде.

Гражданлык хисе — поэзиянең җаны, яшәеш рәвеше. Ясалма гражданлык нинди генә ялтыравык һәм тантаналы сүзләргә төрелеп бирелмәсен, ул барыбер ясалма булып кала, хисне уятмый, зиһенне эшләтми. Олы иҗтимагый проблемалардан һәм аларны үз җилкәләрендә алып барырдай олы язмышлы кешеләрдән, олы хисләрдән башка поэзия яши алмый. Тукай, Такташ, Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов иҗатлары шул хакта сөйли. Чын поэзия үрнәкләрен яшьрәк буын шагыйрьләр иҗаты да күп бирә. Поэзия турында барган сөйләшү процессында басылган күпчелек мәкаләләрнең төбендә шул хакта уйлану ята.

Ш. Әхмәдуллинның «Әдәби тәнкыйть һәм эстетик тәрбия» исемле поэзия турында сөйләшүгә мөнәсәбәте шикле булган һәм авторның элегрәк әйткән фикерләрен, хәтта мисалларын кабатлаудан торган чыгышын һәм кайбер артык гомуми характердагы мәкаләләрне искә алмаганда, алда әйткәнебезчә, күпчелек чыгышларда актуаль һәм төпле мәсьәләләр күтәрелә, заманчалык, халыкчанлык, эстетик нәфислек кебек төшенчәләрнең бүгенге поэзиядә яңача үстерелеше турында җитди фикерләр әйтелә. Тәнкыйтьчеләр татар поэзиясенең уңышлары өчен сөенеп, ялгышлары, үсеш авырлыклары өчен көенеп язалар. Әмма поэзиянең киң аренага чыгуына тышау булып килгән кулагәле яклар, кыенлыклар турында сүз азрак булды. Күпчелек мәкаләләрдә поэзиянең йомшак якларын сылап-сыйпап үтү, конкрет анализ урынына пафоска бирелү, уңышлы шигъри үрнәкләрне позитив комментарияләү тенденциясе өстенлек итә. Әйтик, С. Сөләймaнованың «Шагыйрь — заман баласы» исемле поэзияне аңлап, яратып, ихлас күңелдән язылган мәкаләсен укыгач, безнең эшләр ал да гөл, талантларыбыз күп, борчылырлык мәсьәләләр юк икән дигәнрәк тойгы кала.

С. Сөләйманова М. Әгъләмов белән Зөлфәт иҗатларына биргән бәясендә нигездә хаклы. Соңгы елларда алар бик нык үсте, тирәнәйде. Күләме зур булмаган шигырьләрендә яшьләр галәмне борчыган проблемаларны калкытып куялар, кешенең әхлакый камиллеккә, гармониягә омтылышын, рухи матурлыгын үзләренчә җырлый беләләр. Ләкин әле моннан, әйтик, М. Әгъләмов шигъри өлгергәнлекнең югары үренә күтәрелгән, аны классиклар янына пьедесталга утыртып куярга вакыт җитте, дигән нәтиҗә ясалырга тиеш түгел. Мондый хөкем белән без үсеп барган шагыйрьне кыен хәлгә куяр идек. Иҗатында гражданлык хисләре тагын да калкурак чагылыш тапса, тормышны фәлсәфи анализлау тирәнәйсә, шартлы алымнарны киңрәк кулланса, моннан татар поэзиясе отар гына иде.

Талантлы һәм өметле, тырыш һәм эзләнүчән шагыйрьләргә тынгылы» бирмичә



*Зәки Нури (сулдан уңга), Нури Арсланов, Сибгат Хәким*

таләпне арттыра барганда, тәнкыйть сүзенә дөрес, объектив караш булганда гына, татар поэзиясе үзенең күп гасырлык данына яңа урләр өсти алыр. Хәзерге поэзиягә тәнкыйть күзлегеннән карау, канәгатьсезлек хисе, шигъриятнең хәле, гомуми торышы начар дигән сүз түгел. Тәнкыйть сүзе җәмәгатьчелек тарафыннан киләчәк үсеш турында кайгырту, идеалга омтылу буларак кабул ителергә тиеш.

Әдәбият тарихы җил-яңгыр тимичә, җылы урында гына үскән олы шагыйрьне белми диярлек. Һәр олы шигъри шәхес тирәсендә туктаусыз бәхәс, көрәш чыгып тора. Маяковский белән Такташка гомерләренең соңгы көннәренә чаклы, үз поэзияләре, стильләре, мәктәпләре өчен туктаусыз полемика алып барырга туры килә.

Үз чиратында шагыйрь эзләнмәсә, бәхәсләшмәсә, шул ук Маяковский әйткәнчә, билгесезлеккә юл тотмаса, ул укучының «күңел кыңгырауларын» хәрәкәткә китерә алырлык шигырь яза алмаячак.

Р. Фәйзуллиннардан соң килгән буынның шигъри эзләнүләрен җитдирәк анализларга вакыт җитте. Алар иҗатында ниндидер революцион борылыш, шигъри ренессанс эзләү, пафоска бирелеп, гомуми мактау урынына, бу шагыйрьләрнең индивидуальлекләрен һәм уртак якларын чагыштырмача планда өйрәнү нәтиҗәлерәк булыр шикелле.

Яшьләр эчке монолог формасын киңрәк кулланалар, объектив һәм җисемле тормышны сурәтләүгә рухи дөнья аша юл алалар. Алар иҗатында ярты тавышка үз-үзең белән сөйләшүгә, медитативлыкка, лирик аһәңгә омтылыш көчле.

Шул ук вакытта яшьләр гражданин буларак та тизрәк җитешсәләр, мәдәниятебезне үстерүгә зуррак өлеш кертә алырлар иде. Тукайның «мин коеп куйган шагыйрь генә түгел» дигән афоризмын онытырга ярамый.

Ниһаять, безгә яшьләрне ил аренасына алып чыгу, димәк ки, русча яңгырату турында да уйланырга вакыт. С. Сөләйманова, Р. Мингалим, К. Сибгатуллиннарның җыентыклары «Современник»та басылып чыгуы да куанычлы вакыйга булды. Р. Харис белән Г. Рәхимнең дә русча җыентыклары дөнья күрде, уңай бәя алды. Р. Фәйзуллин рус телендә шактый киң яңгыраш алды.

Татар поэзиясе беркайчан да тәрҗемәчеләрдән уңмады. Тукай, Такташ, Туфаннарны очраклы тәрҗемәчеләргә биреп, без аларның шигъри казанышларын ил һәм дөнья укучысына күрсәтә алмадык. Шуңа күрә яңа буын шагыйрьләрне союз укучысы хөкеменә чыгарганда, тәрҗемәләрнең сыйфаты турында да бергәләп уйлашырга кирәктер.

Ниһаять, минемчә, поэзия турында сөйләшү барышында басылып чыккан мәкаләләрне аерым җыентык итеп чыгару да файдалы булыр иде.

**Фарваз Миңнуллин, тәнкыйтьче, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары.** Дөресен әйтергә кирәк, сөйләшү башта бер эзгә төшә алмыйазапланды. Беренче мәкаләнең шундый артык гомуми һәм бераз таркаурак характерда булуы да тәэсир итте булса кирәк. «Без бәхәсләшмибез, фикер алышабыз гына» дип, журнал үзе дә хата җибәрде кебек. Миңа калса, Ш. Әхмәдуллин, М. Глухов һәм Ф. Сафин мәкаләләрен дә, гәрчә алар кызыклы гына булуга да карамастан, бу рубрикада бирмәскә мөмкин иде. Алар үзара бәйләнмәгән мәстәкыйль әйберләр, сөйләшүне җанландыруда аерым урын алып торырлык түгелләр. Дөрес, тора-бара сөйләшү бер эзгә төште һәм үз юнәлешен тапты (төп игътибар гаять әһәмиятле мәсьәлә — шигъриятебезнең гражданлыгына юнәлтелде), нәтиҗәдә без финишка матур килдек. Гомумән, без инде мондый зур сөйләшүләрне үткәрергә өйрәндек.

Шулай да, йомгаклау җыелышында тагын бер кат басым ясап үтәсе нәрсәләр бар. Иң элек, поэзиянең үткән чорларына һәм бүгенге хәленә бәя мәсьәләсен алып карыйк. Аерым мисалларда поэзиябезнең үткәнен кире яктан гына бәяләү нык сизелеп алды (Р. Фәйзуллин, З. Мансуров). Бу — тамырдан ялгыш тенденция, начар тенденция. Шигырь — заман рухы, заман сулышы дип, С. Хәким дөрес әйтә.

Мин 20—30 еллар турында сөйләп тә тормыйм. Бу чорларда бүгенге әдәбиятның асылын тәшкил иткән сыйфатларга нигез салынды. 50 елларда да поэзия бер урында тормады. Ә. Фәйзи, Х. Туфан, Ә. Давыдовлар иҗаты гына да бу хакта ачык сөйли. Үткәнне хурлау дөрес булмаган кебек, бүгенге фикер поэзиясен артык күпертеп бәяләү дә дөрес түгел. Чөнки бу — үсеш юлындагы соңгы баскыч түгел. Чираттагы баскыч кына. Алга таба ул нинди юнәлештә үсәр әле, моңа җавап бирү җиңел түгел, минемчә. Фикер поэзиясеме, әллә лирик башлангычмы — анысын тормыш үзе хәл итәр. Бүген макталган фикер поэзиясе киләчәктә ничек бәяләнер — бу шулай ук бәхәсле мәсьәлә. Тормыш күрсәтер.

Шигырь — ул заман рухы. Инде бүгенге күзлектән караганда искергән әйберләр бар икән, аны шул чор продукты дип карарга кирәк.

Укучы бүгенге поэзияне аңламый дип, укучыны наданлыкта гаепләргә омтылучылар да булды. Бу тамырдан дөрес булмаган фикер, әлбәттә. Журналда басылган укучылар хатлары үзләре үк шул хакта ачык сөйли.

Аерым шагыйрьләр тарафыннан тәнкыйть адресына бик авыр сүзләр ташланды. Н. Юзиев, Т. Галиуллин, Р. Мостафин, И. Ахунҗанов, М. Вәлиев кебек тәнкыйтьчеләре булган поэзия тәнкыйтенә бирелгән мондый бәя белән килешеп булмый.

**Нури Арсланов, шагыйрь.** Бу сөйләшүләрнең башланып китүе бик кызык булды. Авторларның берсе яшь, берсе өлкән, берсе галим, берсе шагыйрь. Һәр икесе үгезне мөгезеннән алыр дип көткән идем, алай ук килеп чыкмады. Ләкин анда да әһәмиятле фикерләр кузгатылды, бик кызык сүзләр әйтелде. Тора-бара сөйләшү нык кына үсте, җитдиләнде. Шунысы аеруча куанычлы, һәммә кешегә сүз бирелде, урын бирелде, теләгән һәм фикере булган һәркем катнаша алды.

Укучыларыбыз, журналда басылган кайбер фикерләрдән дә күренгәнчә, поэзияне аңлый һәм аның турында җитди фикер дә йөртә ала торган укучы. Ул инде кичәге укучы түгел, нык алга киткән, үскән. Дөрес, укучының һәммәсе дә поэзияне яратып бетермәскә мөмкин. Берәүнең академик булып та шигырьне бик үк аңлап бетермәве мөмкин булган кебек, сыер савучының шигырьне күпләрдән нечкәрәк һәм тирәнрәк тоемлавы, аңлавы мөмкин. Шуңа күрә әлеге уңай белән әйтелгән югары һәм эре тонлы сүзләрне яратмадым мин.

Без инде югары баскычка менеп җиттек дип, Такташ — инде ул үтелгән этап дип, Фатих Кәрим поэзиясе ролен киметеп күрсәтергә омтылулар белән һич килешеп булмый. Бу үз тамырыңа балта чабуга тиң. Безгә Такташтан күн-түн өйрәнәсе, Такташтай рухланып иҗат итәсе, Такташ сыман чын гражданлык поэзиясе үрнәкләрен тудырасы бар әле...

Шагыйрь мин беләмлек дәгъвасыннан котылырга тиеш. Безгә әдәплелек кирәк, бигрәк тә шагыйрьгә. Шагыйрь — ул гөнаһсыз кеше булырга тиеш. Аерым чыгышлардагы шундый нәрсәләр йөрәккә таяк белән төрткән шикелле булды.

Иҗат иттеңме, аны кеше әйтсен, аңа кеше бәя бирсен. Тыйнаклык дигән



*Зиннур Мансуров, Рашат Низамиев, Роберт Миңнуллин.*

әйбер — нәкъ үзе инде шагыйрьне үстерә торган нәрсә. Бик шәп яздым димә, халык әйтсен аны, укучы.

Бу сөйләшү журналның җитди сөйләшүләр оештырырга сәләтле булуын күрсәтте. Инде шундыйрак формада әдәби тел мәсьәләсен дә бер күтәрергә кирәктер.

**Хатип Госман, тәнкыйтьче, профессор.** Чын гражданлык рухы белән сугарылган поэзияне мин шулай аңлыйм: шигырьне уку барышында синең күз алдыңа җанлы, тулы канлы кеше килеп басарга тиеш. Ул кеше синең белән сөйләшә, синең дусың була, синең фикереңне уртаклаша. Һәм менә шушы герой аркылы ачылырга тиеш, минемчә, шигырьдә гражданлык. Хәзерге вакытта, иң элек, мәсьәләнең шушы ягы игътибарга лаеклы.

Шигъри уй һәм кичерешләр, нигездә, өч сферада чагылыш таба. Беренчесе, табигать турындагы хисләребез, икенчесе, тирә-яктагы кешеләр турында һәм, өченчесе, безнең үз шәхесебез турында уйлануларыбыз. Фәндә менә бу сфераларның һәммәсен аерып тикшерергә мөмкин. Ләкин шушы өч сфера кеше күңеленнән, шагыйрь йөрәгеннән әйләнеп чыкканда бер бөтен була. Монда табигать тә бар..., тирә-яктагы дус-ишләр дә, үзең дә...

Әйе, шигырь — бер бөтен, анда син үзең генә була алмыйсың, анда бөтен тирәюнь, дөнья һәм аларга шагыйрьнең мөнәсәбәте урын таба.

Гражданин дигәндә әнә шундый бөтен кеше күз алдына килеп баса. Һәр заманның үз гражданины бар. Кулга шигырь җыентыклары алгач, гадәттә алардан шундый бөтенлек көтәсең. Һәммәсен җыеп, җитлектереп күрсәткән бөтенлек көтәсең.

Гражданин — ул безнең заманның алдынгы кешесе. Ул һәммә яклап алдынгы: җәмгыятьтә дә, кешеләр белән мөгамәләдә дә, семьясында һәм бала-чагасы белән дә. Р. Харис һәм М. Вәлиев иҗәтендә бу мәсьәлә әйбәт кенә күтәрелә. Ләкин, минемчә, анда урыны-урыны белән берьяклылыклар да очрый әле.

Гражданлыкның төп эчтәлеге иҗтимагыять кенә түгел. Ул акыл поэзиясе, фикер поэзиясе һәм хис поэзиясенең органик бөтенлегендә. Минемчә, шигырьнең шушы өч сфераны әйләнеп чыгуы бөтенлек тудыра.

Поэзия тәнкыйте алдында нинди хәл ителәсе мәсьәләләр, темалар тора соң... Иң элек шагыйрьләрнең индивидуальлекләрен табарга кирәк түгел микән? Равил поэзиясендә сискәндерү зур, Зөлфәттә — кеше күңеленә моң белән керү. Мөдәрристтә — халык рухын тирәнтен тоемлау һәм... анда хәвеф төсмере дә бар. Менә

шушылай аерып алып анализ ясалса, минемчә, шагыйрьләр һәм шигърият турында сөйләшү тагы да файдалы һәм тагы да нәтиҗәлерәк булыр иде...

**Мөдәррис Әгъләмов, шагыйрь.** Безнең шигъриятгәге гражданлык мәсьәләсендә моңа кадәр йөзгә кызыллык китерердәй янсә ачу кузгатырдай сәбәпләр булмады, киләчәктә дә булмас дип уйлыйм мин. Сүзнең, әдәби сүзнең көче гаять зур. Менә шуны аңлаган кеше генә бу хакта сүз кузгата ала.

Безнең шигърият дип әйтәбез икән, анда гражданлык мәсьәләсе, дибез икән, бераз гына үткәнгә кайтып карыйк.

**Французларны җиңдек без,**
**Парижга да кердек без.**
**Ап-ак ташлы урамында**
**Җир җимертеп йөрдек без.**

Халкыбызның бу бәете генә түгел, шигъри иҗаты һәммәсе дә шулайдыр сыман. Кайсыдыр бер җыелышта Сибгат ага Хәким Дәрдмәнд хакында үзенең бик якты фикерләрен әйтеп чыккан иде. Бу исә минем күңелдә бик тә уелып калды. Ә Дәрдмәнд болай ди:

**Каләм! Кальбеңдә ни сер бар, гаян ит,**
**Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.**
**Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,**
**Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!**
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
**Кара туфрак тулы мазлум нидасы,**
**Алар кемдер!.. Алар кемнәр фидасы!..**

Әнә шундый, ил-халык сагышын сагышлап язылган юлларны Дәрдмәндтә табарга мөмкин.

Шул мазлумнарның нидасы хакында язган, шулар кайгысын кайгыртып яшәгән Тукай бүгенге көндә иң зур шагыйрь түгелме? Гражданлык поэзиясе. Бездә моны еш кына аерым бер тема белән чикләү бар.

Күптән түгел Чыңгыз Айтматовның бәйрәмендә Мостай Кәрим үзенең котлау сүзен: За твой талант, за твое мужество! дип тәмамлаган иде. Шигъриятнең гражданлык йөзен, гомумән әдәбиятның гражданлык йөзен шушы ике төшенчә — зирәк акыл һәм ир була белү билгели түгелме соң? 27 яшьлек Тукай, 37 яшьлек Җәлил, 35 яшьлек Фатих Кәрим, 80 яшьлек Туфан, 58 яшьлек Гамил Афзал, 68 яшьлек Сибгат Хәким, 35 яшьлек Равил Фәйзуллин... Төрле буын шагыйрьләре. Аларның шигъриятен, гражданлык йөзен шушы ике төшенчә ачык күрсәтә.

Бу ике төшенчә һәр буын алдында үзенчә. Тукайда ул үзенчә булса, Җәлил белән Туфанда үзенчә. Ә үзенчәлек үзеңнең шагыйрь икәнлегеңне исбат итү дигән сүз ул.

Инде бу барган сөйләшүләрдә тагын бер мәсьәлә күтәрелә язып калган иде. «Аңлашыла һәм аңлашылмый торган шигырьләр» дип аталган иде ул. Ибраһим ага Нуруллин моңа мисал да китереп, Равил Фәйзуллинга сорау биргән иде. Мисал мондый: Вазада җикән камыш. Хатын күлмәк салгандагы җил җилмени ул?

Бик тә гыйбрәтле «аңлашылмаган» шигырь. Җил иркендә шаулы камышлар арасында гомер кичергән җикәнне, инде килеп вазада җил көтеп утырган җикәнне күз алдына китерү өчен, кысаларга, вазаларга күнеккән булу гына җитми торгандыр. Монысы сүз иярә генә. Минемчә, шигырь аңлашыла яки аңлашылмый дип түгел, аңлаучы яки аңламаучы янсә хәзерлекле һәм хәзерлексез укучы хакында гына сүз барырга мөмкин. Ә инде укучыны әзерләү, тагын кайтып, шул тәнкыйтьчеләребез эше түгелмени?

Минемчә, төп мәсьәлә биредә аңлашылу яки аңлашылмауда түгел. Аңа китсәк, аңлашылмый торган юлларны минем, мәсәлән, татар шигъриятендә гомумән күргәнем юк шикелле. Биредә мәсьәлә шигырьнең эшләнеп бету-бетмәвендә түгел микән? Ә бәлки татар шигыренең яңа мөмкинлекләре, аның камиллеге, аның соңгы еллардагы үзгәреше хакында махсус сөйләшергә кирәктер? Әмма бу хакта сөйләшер өчен әзерлекле, югары шигъри культуралы кешеләр кирәк. Югары шигъри культура мәңгелек. Хәсән Туфанның шигырь төзелеше, аның мөмкинлекләре ха-

кында сугышка кадәр үк басылып чыккан мәкаләләрен укып карыйм да, шул кадәр яшьләй шигъри культурага ия булган икән бу карт, дип куям.

Мин биредә сөйләнгән сүзләрдән Фарваз Миңнуллинның фикерләре белән тулысынча килешәм. Чыннан да, мондый сөйләшүләрне фикерне бер ноктага җыеп була торган конкрет темаларга алып барырга кирәктер. Бу очракта «Вопросы литературы», «Литературное обозрение» журналларының эш тәҗрибәләре кызыклы. Алар, мәсәлән, аерым шагыйрьнең иҗатын уртага алып, төрле-төрле карашларда торган тәнкыйтьчеләрнең үзенә күрә бер фикри ярышын оештыралар. Бу очракта һәркем ота. Тәнкыйтьче аерым бер әсәр яисә шагыйрь иҗаты аша нинди дә булса агымга яки күренешкә ачык мөнәсәбәтен белдерә ала. Укучы, үз карашларының бергә оешып, ачыклануына ирешә. Автор, үз чиратында, яңа укучыларын таба.

Инде йомгаклап, булып узган сөйләшүләрнең уңай якларына да тукталасым килә. Безнең шигърият бай дибез. Анда тарихи исемнәр дә күп. Бүгенгебез дә зур итеп сөйләшерлек дибез. Әмма, ни өчендер, соңгы елларда шигъри сүзнең популярлыгы бераз кими төшкән кебек иде. Шул җәһәттән караганда, бу сөйләшүне оештырган һәм башлаган иптәшләр бик зур эш эшләделәр. Минем аңлавымча, аларның төп максатларыннан берсе дә әнә шул иде. Һәм бу максатка ирешелде. Күп кенә укучыларның, әдәбият белгечләренең сөйләшүгә тартылуы бу хакта ачык сөйли.

**Шамил Маннапов, шагыйрь, «Социалистик Татарстан» газетасының бүлек мөдире.** Шигъриятта гражданлык. Җисемле һәм җисемсез һәрнәрсә шикелле бу төшенчә үзе дә заманалар узган саен үзгәрә, мәгънәсе киңәя. Яисә без элегрәк аңлаган таррак рамкалардан чыгып, үз асылына кайта. Үз шәхси интересларың белән халык, ил, дөнья мәнфәгатьләре, уй-теләкләре, кайгы-шатлыклары аерылмаслык булып кушылып китә икән — чын гражданлык поэзиясе, минемчә, әнә шунда.

Кайсы гына заманда булмасын, әдипләрнең, сәнгать әһелләренең кыйбласы бер: яктылыкны, яхшылыкны, хакыйкатьне, ирекне яклау һәм, киресенчә, караңгылыкка, начарлыкка, хаксызлыкка, ирексезлеккә каршы аяусыз көрәш. Заманалар үтү белән әлеге төшенчәләр үзгәргән шикелле, әдәбият-сәнгать тә үзгәрешләр кичерә.

Дөньяда иң гадел җәмгыять — коммунизмда яшәячәк гражданнарны, яңа кешеләрне тәрбияләү — бүгенге әдәбият-сәнгать алдында әнә шундый гаять катлаулы һәм мактаулы бурычлар тора. Бу зур эш планетабызда капма-каршы ике система яшәп һәм кеше җанын яулап алу өчен рәхимсез көрәшеп килгән шартларда тагын да катлаулана.

«Казан утлары»нда барган сөйләшүдә катнашкан Равил Фәйзуллин белән Ибраһим Нуруллин, Ренат Харис белән Мансур Вәлиев, Хатип Госман, Ринат Мөхәммәдиев, Саҗидә Сөләйманова һәм башка иптәшләрнең мәкаләләрендә дә әдәби әсәрләрдәге гражданлык мәсьәләсе үзәк урынны алды. Р. Мөхәммәдиевнең: югары гражданлык әсәрләрен авторның изге ният белән, үзенең җәмәгатьчелек алдындагы гражданлык бурычларын үтәүгә омтылышы нәтиҗәсендә ашык-пошык кына язып ташланган әсәрләр белән һич кенә дә бутарга ярамый, дигән фикере белән килешми мөмкин түгел. («Казан утлары», 1978 ел, 10 сан, 149 бит).

Бу нисбәттән, тагы яшьтәш шагыйрь Гәрәй Рәхимнең бик әйбәт чакыруы хәтердә: «Халтурачылардан көн кадагына суккан темаларны тартып алырга кирәк!» Сүзен иҗаты белән дә раслап Г. Рәхим илгә, партиябезгә, Ленин комсомолына һ. б. багышлап, менә дигән шигырьләр язды.

Иҗтимагый-политик темаларга, көн кадагына суга һәм кешеләр рухын алга әйди торган югары художестволы әсәрләрне оператив язучылар турында сөйләгәндә замандаш шагыйрьләрдән беренче чиратта Сибгат Хәкимнең юлбашчыбыз образын, Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы тыныч хезмәт еллары сулышын бер йөрәккә сыйдырган поэмаларын, күпләгән шигырьләрен, җырларын, публицистик мәкаләләрен мисал итәр идем. Өлкән шагыйрьнең күпләгән шәкертләре аның әнә шушы гаять кыйммәтле сыйфатын да үзләренә өлге итсеннәр иде.

Мәгълүм булганча, «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә дә, язучыларның IX съездын каршылап, зур сөйләшү башланды. Анда катнашучыларның фикерләре дә нәкъ әнә шушы яссылыкта тәңгәл килә: социалистик реализм методы белән



*Шагыйрь Нури Арсланов.*

иҗат ителгән, партияле, халыкчан һәм югары художестволы әсәрләрне генә без гражданлык әсәрләре дибез, заманча яңгырашлы дибез, киләчәктә дә халыкка хезмәт итәчәк әсәрләр дибез.

Әдип, сәнгать кешесе — көрәшче булырга тиеш. Шул вакытта гына аның әсәрләре иҗтимагый-политик яңгыраш алачак.

**Рашат Низамиев, шагыйрь, «Татарстан яшьләре» газетасының җаваплы секретаре.** Заманыбыз — интеллектуаль һәм югары культуралы заман. Кешенең шәхесе, хис һәм акыл дөньясы үсте, катлауланды. Теләсә, хәзер һәркем диярлек урта кул шигырьләр яза ала. Моның белән мин шигырь язу бик ансат эш дип әйтергә җыенмыйм, әлбәттә. Әмма шунысы хак: шигырьләр күп языла. Бер яктан, бу бик тә куанычлы хәл, әдәбиятка өзлексез рәвештә алмаш килә, дигән сүз. Икенче яктан исә, бу хәл җитди генә сораулар да куя: шигъриятнең чын энҗеләрен халтурадан ничек аерырга? Менә шуңа күрә бүгенге көндә поэзия тәнкыйтенең аеруча актив, сугышчан, гадел булуы сорала! Кемгәдер «удар» ясау түгел, ә бәлки поэзиягә дөрес юнәлеш бирү, укучыларның әдәби зәвыгын һәм эчке культурасын баету максатын күздә тотып язылган тәнкыйть мәкаләләренең кирәклеге үзен көннән-көн ныграк сиздерә.

Бу сөйләшүдә гражданлык мәсьәләсенең үзәккә куелуы бик табигый. Чөнки гражданлык хисе белән сугарылган һәм ил, Ватан кебек олы сүзләр килеп кергән шигырьләрдә шагыйрьнең талантлы яки талантсыз булуы биграк тә ачык чагыла. Шагыйрь никадәр талантлырак булса, аның югары хисләр турында җырлавы шул кадәр табигый һәм ышандыручан була. Талантлы шагыйрь «Ватан» дигән сүзне кулланмыйча да Ватаның яратуы турында искиткеч әсәр язарга мөмкин. Төче һәм купшы сүзләрне еш куллану — көчсезлек билгесе ул.

Тагын бер нәрсә турында әйтергә кирәк: соңгы елларда яшьләр иҗатын бәяләгәндә «шагыйрь үзе, биографиясе күренми» дигән штамп модага кереп бара шикелле. Гәрчә бу сүзләрдә дөреслек орлыгы булса да, минемчә, мондый «штамп сугуның» тискәре ягы да бар: яшь шагыйрьләр «мин» дигән сүзне артыгы белән куллана башладылар, туйдырып бетерделәр. И. Нуруллин әйткәнчә, ярый да бит укучыга тәкъдим итәрлек күңел энҗеләре булса! Роберт Әхмәтҗанов та үзенең мәкаләсендә әнә шул хакта бик хаклы борчылып яза.

Кабатлап булса да мәгълүм хакыйкатьне әйтик: теләсә кайсы шигырь — шагыйрьнең үзе ул! «Мин» һәммәбездә дә бар ул, ләкин «мин» — **характер дәрәҗәсенә** күтәрелергә тиеш.

**Роберт Миңнуллин, шагыйрь, журналның хатлар бүлеге редакторы.** Сөйләшүнең күбрәк Р. Фәйзуллиннар, Р. Гатауллиннар буыны тирәсендә баруы, күрәсең, табигый хәлдер. 60 нчы елларда күтәрелгән шигъри шау-шуның әле булса тынганы юк бит. Бу — юкка гына түгел, әлбәттә. Ни дисәң дә, көчле буын, нык буынлы шагыйрьләр. Шуңа күрә дә тәнкыйтьчеләребез аларның иҗаты белән чын мәгънәсендә сихерләнделәр. Өлкән буын белән урта буынга булган игътибар шактый сүрелде. Ә инде яшь буын турында әйтеп тә тормыйбыз. Менә ничә еллар инде алар (Р. Вәлиев, Ф. Сафин, М. Галиев, З. Насыйбуллин, З. Мансуров, Э. Мостафин, Г. Садә һ. б.) яшь шагыйрьләр исемлегенә теркәлүдән ары уза алганнары юк. Тәнкыйть әлеге шагыйрьләрне ни өчендер күрмәмешкә салына. Миңа калса, Р. Фәйзуллиннар турында сөйләшү дә бер тирәдәрәк барды кебек. Әйтик, алар буыны татар шигъриятенә стильләр яңалыгы алып килде, шигырьнең тукымасын яңартты, алар үзләренең яңа образлар системасын булдырдылар. СҮЗнең яңа төсмерләрен ачтылар.



*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов.*

Аннары кайбер мәкаләләрдә традицион шигырьгә карата тенденциозрак карашлар сизелеп китте. Ирекле шигырьне югары күтәреп, традицион шигырьне кимсетү шикеллерәк фикерләр булды. Әйтерсең лә фәлсәфи фикерле шигырьләрне верлибр белән генә язып була.

Традицион шигырь яклауга мохтаҗ түгел. Ул — шигъриятебезнең нигезе. Интеллектуаль поэзия хакында да Хатип ага Госман бик дөрес әйтте. Әгәр дә без кайбер яшьләргә интеллектуаль поэзия вәкилләре дигән исем тагабыз икән, С. Хәким белән Н. Арсланны, И. Юзеев белән Ә. Баянны, Рәшит Әхмәтҗановны һәм башка бик күп шагыйрьләрне нинди поэзия вәкилләре рәтенә кертергә соң?

**Рәдиф Гатауллин, шагыйрь, журналның поэзия бүлеге редакторы.** Мондый сөйләшү, һичшиксез, вакытлы, кирәкле иде. Мәсьәләнең куелышында ук бәхәсле моментлар булу, парадоксальгә якын нәтиҗәләр ясау очраклары әңгәмә барышын кызыклырак, җанлырак итте.

Гражданлык поэзиясенә мөнәсәбәттә, аның безнең шигырьдә магистраль юл — Тукай, Җәлил, Такташ традицияләренең бүгенге дәвам ителеше, үстерелешен күрсәтү белән бергә бу мәсьәләгә яңача караш, шагыйрьнең шәхесе, дөньяга карата актив позициясе, эстетик принципларының халыкка якын, кешечел булуына игътибар ителде, бүгенге тәҗрибә белән расланган үсеш принциплары билгеләнде дияргә була. Үткәннәргә сак караш, бай шигъри мирасны актив өйрәнү, Сибгат ага Хәкимнең «Тукай аша карыйм дөньяга» дигән юлларындагы кебек, бүгенге үзгәрешләр һәм дәвам ителергә тиешле төп сыйфатлар белән бәйле каралды. Шунысы куанычлы, бүгенге поэзия дигәндә өлкәннәребез һәм урта, яшь буын шагыйрьләр белән берлектә, Нурия Измайлова кебек иң яшь каләмдәшләребез иҗатына да игътибар һәм җитди караш булды. Бу җәһәттән Тәлгать Галиуллин мәкаләсе аерылып тора.

Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов кебек, укучылар игътибарын күптән җәлеп итеп, танылып өлгергән талантлар турында да җитди, тәфсилле сүз әйтелде диясе килә.

Шул ук вакытта, буыннарга бүлеп, исемнәр санап чыгуның шагыйрьләребезнең индивидуаль йөзен, иҗат стильләрен калкурак, ачыграк күрсәтү мөмкинлеген чикләгәнен дә искәртәсе килә. Сөйләшүдә аерым шагыйрьләрнең үзенчәлекле яклары, новаторлык алымнары киңрәк тукталуга лаек иде шикелле.

Шунысы әһәмиятле, сөйләшүдә бай традицияләргә нигезләнгән һәм заманча яңа алымнар, шул исәптән яңа шигъри форма белән үстерелгән лирика, фикри һәм халыкчан поэзия үзәккә алынды.

**Ринат Мөхәммәдиев, журналның әдәби тәнкыйть бүлеге редакторы.** Миңа калса, әлеге сөйләшү барышында ясалган нәтиҗәләрнең иң әһәмиятлесе шул булды: гражданлылык — ул шигъриятнең җаны, партиялелек, халыкчанлык һәм тормышчанлык принципларына нигезләнгән чын шигъриятнең үзе. Шагыйрьнең гражданлык йөзе олы масштаблы төшенчә һәм темаларны кузгатуда гына түгел, ә аның һәр әсәрендә, һәр юлында һәм һәр сүзендә аермачык чагылыш табарга тиеш. Укучы күңелендә урын тапкан, аның күңеленә шифалы йогынтысын салган һәм аны рухландырырга сәләтле булган шигырь гражданлы булмый мөмкин түгел. Табигать һәм мәхәббәт лирикасында шагыйрьнең олы гражданлык хисләре тирән чагылырга мөмкин, дөресрәге, алар да гражданлык рухы белән өртелергә тиеш. Әлбәттә, үз эченә бикләнеп яшь кою, ах-вах итүләр булмаган тәкъдирдә...

Бүгенге шартларда — нык үскән социализм чорында — үз Ватаның гражданнарын тәрбияләүгә билгеле бер өлеш кертергә сәләтле һәр шигъри әсәр поэзиябезнең гражданлыгына үзеннән өлеш кертә, аның аерым үрнәген тәшкил итә.

Шагыйрь үз тавышын тапсын, үз җырын җырласын, үзендә саф тенор булуын белә торып, бас партиясен җырлап газапланган җырчыны хәтерләтмәсен иде...

Гражданлык — янам, көям дип әйтүдә, сүзләрдә януда гына түгел. «Кайнар» сүзләр һәм хисләр кайнарлыгы бер үк нәрсә түгел. Безгә, бигрәк тә әдәби тәнкыйтькә, боларның аермасын күрергә, танырга вакыттыр, шәт.

Тәнкыйть «галочка» өчен язылган язмаларга, әһәмиятле теманы түбән пробалы шигырь кысаларына кертергә азапланучыларга кискен рәвештә каршы чыгарга тиеш. Моның гражданлык булмыйча, шигъриятнең изге исеменә, укучыга һәм бер үк вакытта әлеге әһәмиятле темага хыянәт икәнлеген күрсәтә белергә кирәк.

**Я б запретил декретом Совнаркома**
**Писать о Родине бездарные стихи!**

— дип язган М. Кульчицкий белән килешми мөмкин түгел. Өстәп шуны гына әйтергә кала: туган ил турында гына түгел, хезмәт темасына, изге хис — мәхәббәт турында да талантсыз шигырьләр язылмаска тиеш.

Димәк, чын шигырь, әгәр ул шагыйрьнең олы масштаблы кичереш-борчулары һәм гаме нәтиҗәсендә туа икән, ул һәрвакыт гражданлы. Ә шагыйрь — ул Ватанына һәм халкына ахырынача бирелгән, кешелеккә гашыйк, табигате белән гүзәл кешегә гашыйк шәхес. Аның бер генә шигыре дә, бер генә шигъри сүзе дә үзенә һәм үзенең иманына каршы килмәс. Ә иманы аның — гомумиләштереп әйткәндә, **гражданлык**. Гражданлык пафосы шагыйрь күңеленнән каен суы кебек бер ширбәттәй бәреп чыгарга, язгы урман һавасыдай бөркелеп торырга тиеш.

**Роберт Әхмәтҗанов, шагыйрь.** Бүген безнең сөйләшүләр ике төрле юнәлештә бара. Аның берсе рәсми, икенчесе — җыелышлардан соң да күңелдә йөргәне. Мәгълүм «айсберг теориясе» асылда безнең күңел төбендә яткан сүзләргә туры килә һәм безнең бөтен сөйләшүләргә дә бер тон бирә дип уйлыйм. Әлбәттә, нинди дә булса теорияләр белән генә поэзиягә юнәлеш бирү мөмкин түгел. Ул юнәлешне заман үзе бирә.

Сер түгел, соңгы вакытта исем урынына башына өч йолдыз тәрткән лирик монологлар бик озынаеп китте. Метражы озын. Әмма авторның иҗади йөзен ачыклау мөмкин түгел. Моннан шигърият цехының ОТКсы кирәклеге туа. Иҗатта сыйфат контролеры буларак шигырь тәнкыйте чыга. Әмма бу юнәлештә шигъри иҗатның кухнясына кереп эш итү җитми әле. Язылган тәнкыйть мәкаләләре, әсәрнең художество кыйммәтен ачасы урынга, гомуми күзәтү ясаудан узмыйлар. Шагыйрьләрнең индивидуаль сыйфатларын яктырту эше әле тиешенчә түгел. Күп очракта поэзия тәнкыйте өстән-өстән генә тамгалап киткән «һ. б.»ларга бүгенге көн поэзиясенә тон бирүче шагыйрьләр дә кереп китәләр.

Әдәби осталыкка өстән карау — әдәби таләпчәнлекнең кимүе. Әсәрнең бәхәс кузгатуы бераүләр өчен кабул ителмәслек хәл булып тоела, күрәсең. Бездә дә төрле иҗади мәктәпләрнең мөстәкыйль яшәү хокукын якларга кирәк, минемчә. Хис поэзиясен фикер поэзиясеннән аерып карарга кирәк түгел. Бүгенге шигърият өчен бу сыйфатларның икесе дә зарур дип уйлыйм.

**Сибгат Хәким, шагыйрь, РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.** Мин моңа кадәр дә поэзиябез турындагы уйлануларымда гражданлык мәсьәләсенең әһәмиятен искә ала, ассызыклый килдем. Поэзиягә һәркем үз юлы белән килә. Иҗатында шәхеснең тәҗрибәсе, фикре, рухи һәм эстетик тәрбиясе чагыла. Гражданлылык күзлегеннән карaганда, мин татар поэзиясен һичкемнән калышмый дип саныйм.

Поэзиябезнең үткәндәге һәм бүгенге кайбер кимчелекләренә сөйләшү барышында игътибар ителде, шулай да алар аның казанышларын киметеп күрсәтми, аз гына да тоныклаңдырмый. Кайсы гына чорны алып карама, аның талантлылары, олы гражданлык хисләре белән янып иҗат иткән талантлы шәхесләре шагыйрь, чын шагыйрь булып кала биргән.

**Агыла да болыт агыла**
**Туган-үскән җирләр ягына;**
**Тәрәзәгә чиртер дә яңгыр**
**Нәрсә әйтер туганнарыма!!**
**Агыла да болыт агыла...**

— дип яза Хәсән Туфан. Болай караганда шәхси фикер генә кебек, җентекләбрәк тикшерсәң, кеше шәхесе, чор сулышы шул кадәр укмашкан... Шагыйрь һәм язучы, әгәр ул үз заманын бөтен күзәнәкләре белән тоя икән, сизә икән, халык язмышын үз язмышы белән органик бәйләп алып бара икән, бу аның өчен зарури икән, бу инде үзе гражданлык. Гражданлык — ул ниндидер зур темаларда гына түгел, ул язучының һәр әсәреннән аерылгысыз. Мәхәббәт шигырьләрендә дә гражданлыкның менә дигән үрнәкләрен күрсәтеп була. Шундый мисаллар, уйландыра торган әйберләр күп. Мин Илдарның (Юзеев), Робертның (Әхмәтҗанов) поэмаларын беләм. Соңгы вакытта гына Фәннур Сафинның «Алма бакчасында» дип исемләнгән яңа шигырьләр циклы белән таныштым. Ул мине сокландырды. Шагыйрь үзүзен табу юлында тагын бер кыю адым алга атлаган. Зур осталык белән һәм үзенчәлекле язылганнар, һәр шәхеснең үз уйланулары, үз борчулары. Әле менә Ә. Еники повестьларын укып ятам һәм рәхәтләнеп укыйм. Аның әсәрләре дә, шигърият кебек, үзләренә ихласлыклары белән тартып тора.

Бу сөйләшүнең язучыларыбыз съезды алдыннан булуы бик әйбәт. «Литературная газета»да да ун еллар буена бертуктаусыз поэзия турында сөйләшү бара. Димәк, ихтыяҗ бар!..

**И. Нуруллин, тәнкыйтьче, профессор.** Бу фикер алышудан мин икеләнеп калам. Р. Харис белән М. Вәлиев әңгәмәсендә аңлаешлы һәм аңлаешсыз шигырьләр турында сүз кузгатуның кирәге һич юк иде диелде. Юкса, сөйләшүне башлап җибәргән әңгәмәдә бу нәрсә ачык әйтелгән иде. Әйтик, ике шагыйрь бар, ди, икесе дә тумыштан ук илаһи очкынга ия. Аның берсе ил язмышы, халык язмышы белән яши, икенчесе исә үзе турында гына уйлап гомер итә. Беренчесенең шәхси хисе, тойгысы халык фикере белән бәйләнгән. Ә икенчесенең шәхси фикерләре халык тойгысына юл таба алмый. Беренче төр язучы традицион формада язса да, ак янсә ирекле шигырьгә мөрәҗәгать итсә дә, чын поэзия үрнәкләре — оригиналь әсәрләр тудыра. Шуңа күрә дә аның язган шигъри әсәрләре һәркемгә аңлаешлы. Икенчесе могез чыгарырга азапланса да, традицион «шапка» астында язарга омтылса да, әсәрләре аңлашылмый, чөнки аларда халыкчанлык юк, алар гражданлык пафосыннан мәхрүм.

Бүгенге чыгышлар, бәхәсләр, нигездә, поэзиядә гражданлылык турында барды. Күп кенә чыгышларда кызыклы гына фикерләр әйтелде. Ә Р. Фәйзуллин белән безнең арада хәл ителмәслек принципиаль каршылыклар юк. Равилне зур шагыйрь дип саныйм, ләкин бераз мавыгу бар дип уйлыйм. Аның «мин шулай дип уйлыйм» дию ендә тыйнаксызлык күрмим.

**Равил Фәйзуллин, шагыйрь, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт һәм М. Җәлил премияләре лауреаты.** Бу сөйләшүгә беркадәр иртәрәк йомгак ясала шикелле. Материаллары, яртышар ел алдан әзерләнә торган журнал шартларында бер ел чамасы вакыт әллә ни күп түгел. Мәкалә авторларының байтагы, бигрәк тә сөйләшүнең беренче яртысында күренгән иптәшләрнең, бүгенге поэзиягә карата үзбаш мөстәкыйль фикер йөртү яки берәр актуаль проблема күтәрүдән бигрәк, күбрәк сөйләшү башындагы кереш мәкаләгә уңай яки тискәре мөнәсәбәт белдерү белән чикләнүләрен дә искә алсак, бу бәхәс вакытының кыскалыгы тагын да сизелә төшә... Шулай да, булганына канәгать була белергә дә кирәктер. Безгә калса, беркадәр максатка ирешелде кебек. Поэзиябезнең мирасы һәм бүгенгесе зур һәм бай икәнлеге, аның халык тормышындагы әһәмиятле роле, иҗтимагый тормышның гыйбрәтле бер күренеше буларак, фәнни нигезле, төпле анализлы зур тәнкыйтькә лаек икәнлеге тагын бер мәртәбә ачыкланды. Гомумән, бу сөйләшүдән соң, шигырьгә игътибар көчәер, шагыйрьләр иҗатына, поэтик хәрәкәткә җитди, тотрыклы караш туар дип ышанасы килә. Чөнки поэзия мисалында — бүгенге әдәбиятыбызның үсешенә хас байтак характерлы күренешләрне күзәтергә, бәяләргә, кирәк чакта тиешле бәя дә бирергә җай һәм мөмкинлек бар. Бу сөйләшү тагын бер ягы белән гыйбрәтле: ул безнең — шагыйрьләрнең һәм тәнкыйтьчеләрнең — теоретик әзерлегебезнең һәм фикерләү культурабызның ни дәрәҗәдә икәнлеген дә шактый ачык күрсәтте. Баксаң, бик биек менеп һәм матур итеп оча белмибез икән әле! Бәхәсләшү тәҗрибәбез азрак икән! Бу җәһәттән хөрмәтле галимебез профессор Ибраһим ага Нуруллин белән без фәкыйрегезнең бәхәсне ачып җибәргән

мәкалә дә кайбер җитешсезлекләрдән азат түгел иде. Башлап җибәрү һәрчак кыен, анысы да бар. Бер эз салынгач, бару җиңелрәк. Башта үз сүзен әйтмичә, бүтәннәрнең теге яки бу ялгышларын күреп, шул ялгышлар тирәсендә сүз куертып, «акыллы» чыгыш ясаучыларга, нәтиҗә-йомгак ясау осталарына, әлбәттә, күпкә җиңел. Ләкин андый «җиңеллек»тән кемгә файда соң?

Сөйләшү процессында, шулай ук, вакыты-вакыты белән сәер рәвештә үзара аңлашып ук җитә алмаган моментлар да булды. һәр ике як яки берничә бәхәсче бер үк поэтик күренеш турында бер үк фикердә, һәрберсе бер үк нәрсәне телиләр, омтылалар һәм парадокс... бер-берсен гаеплиләр! 30 нчы еллардагы поэзиягә һәм аның әйдәүче көчләренә карата булган сүзләрдә бу бик ачык чагылды. Үткәнне зурлау, мираска ихтирамлы булу бик кирәк. Кемдер теләи икән, әйдә табынсын да! Ләкин үткәннәргә табынып кына киләчәк үсешне тәэмин итеп булса икән! Укучылар хатларының байтагында поэзиябез турында шактый гына кызыклы фикерләр булды. Шул ук вакытта, кайбер хат авторлары язучы хезмәтен берьяклырак аңлап, тактсызрак сүзләр дә әйтеп ташладылар. Тыйнаклык төшенчәсе — һәр кешегә дә, шулай ук язучыга да караган кебек, ул хокук укучының үзеннән дә тартып алынмаган бит!

Сөйләшү вакытында 60 нчы еллар башында поэзиягә килгән бер төркем шагыйрьләр иҗаты турында байтак сүз булды. Күрәсең, бүгенге көн татар поэзиясен алар иҗатыннан башка бөтен тулылыгы белән күзаллау кыен. Бу буын шагыйрьләр турында соңгы ун-унбиш елда бик күп сөйләнде һәм күп очракта бертөрлерәк сөйләнде һәм хәзер дә шул рухта сөйләшүләр дәвам ителә. Алар турында һаман гел күмәкләп сөйләү, бер яктан, күңелле хәл булса, икенче яктан, әллә ни дәрәҗә дә түгел. Чөнки һәр шәхеснең иҗаты — ул үзгә иҗат, индивидуаль иҗат. Чөнки аларның бу чордагы актив иҗаты һәрберсен аерым-аерым җентекләп өйрәнүгә, һәрберсе шәхес һәм художник буларак, индивидуаль тәкъдир ителергә лаек. Вакыт ягыннан әдәбиятка бергә аяк басу, ул әле иҗади һәм эстетик приципларның берлегенә билге түгел. Бу буын шагыйрьләр соңгы ун ел эчендә һәрберсе шул кадәр үзгәреп бетте, шактый кызык метаморфоза кичерде ки, бу хәл — аерым бер сөйләшүне сорый. Шагыйрьләрнең бердәмлекләрен аларның әдәбиятка хронологик килү тәртипләре буенча түгел, ә аларның дөньяга карашы, фәлсәфи-эстетик платформалары, поэтик фикерләү уртаклыклары буенча билгеләргә кирәк. Кайчак, ул шагыйрьләрнең бер-берсе белән охшашлыкларына караганда, кайберләренең бөтенләй бүтән чор, бүтән дәвер шагыйрьләре белән уртаклыклары күбрәк булырга мөмкин.

Шулай да, соңгы 15—20 ел эчендә актив иҗат итүче шагыйрьләрнең иң яхшы әсәрләре инде уку-укыту программаларына, мәктәп дәреслекләренә кереп өйрәнелергә тиеш. Яшь буынны тәрбияләү эшендә алар хезмәте дә үзенең уңай ролен үти алачак.

Тагын бер теләк: бүгенге поэзиябез турында «Казан утлары» битләрендә басылган бу сөйләшү материалларын бергә туплап, билгеле бер тәртипкә китереп, аерым бер китап итеп чыгарырга иде. Ул күпләр өчен файдалы хезмәт була алыр!

**Зәки Нури.** Йомгаклап әйткәндә, бу сөйләшү бик вакытлы, файдалы да һәм кирәкле дә. Шигырьдә фикер булырга тиеш. Әгәр ул тирән фәлсәфи фикер икән, бигрәк тә яхшы диган нәтиҗәгә киләдек. Фикер, хис һәм сурәт гармониясе булганда гына чын поэзия үрнәкләре туа. Некрасов сүзләре белән әйткәндә: поэтом можешь не быть, а гражданином быть обязан. һәр шагыйрь алдында шундый таләп кую дөрес булыр.

Шагыйрь булу өчен үзең яшәгән чорның, үзең белән заманның алдынгы фикерләрен аңлый белергә, шулар эчендә янып яшәргә һәм иҗат итәргә кирәк. Ана телеңне белү дә, талант та кирәк. Заман таләпләренә җавап бирерлек, заман пафосын тирәнтен чагылдырган әсәрләр иҗат итү өчен шагыйрьдән, шул рәвешчә, бик күп нәрсәләр таләп ителә.

Инде кыскача гына булса да шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: гражданлылык һәм сугышчанлык шигъриятьтән аерылгысыз төшенчәләр. Партиялелек, халыкчанлык принципларына нигезләнгән бүгенге татар поэзиясе гражданлык активлыгын үстерә,

көндәлек һәм рухи тормышыбызда көннән-көн зуррак урын һәм авторитет яулый бара. Аның алдында торган төп бурычлар, үсеш перспективасы да, иң элек шул күзлектән чыгып аңлатыла.

Гомумән алганда, әлеге сөйләшү шигъриятебез үсешендә, аның турындагы тәнкыйди фикер үсешендә әһәмиятле бер этап булыр дип ышанабыз. Һәм мин фикер алышуда катнашкан барлык иптәшләргә — тәнкыйтьчеләргә, шагыйрьләргә һәм бигрәк тә укучыларыбызга редколлегия исеменнән зур рәхмәт белдерүне үзебезнең бурыч дип беләм.

**Редакциядән.** «Бүгенге поэзия турында сөйләшү»не йомгаклау максаты белән оештырылган түгәрәк өстәл янында фикер алышу шушы елның 22 мартында журнал редакциясендә узды. Анда, югарыда чыгышларыннан өзекләр китерелгән иптәшләрдән тыш, филология фәннәре докторы, профессор Йолдыз Нигъмәтуллина, журналның җаваплы секретаре Кояш Тимбикова, тәнкыйтьче Мансур Вәлиев, шагыйрьләрдән Зөлфәт, Зиннур Мансуров, журналның сәнгать бүлеге редакторы Рим Ширияздановлар катнашты. Фотолар — Исмәгыйль Ишмөхәммәтовныкы.

**Фатих Хөсни**

# ОРЛЫКЛАР КАЯ ТӨШӘ...

*Этюдлар*

## Керешү алдыннан

Г. Тукайның революциягә хәтле чыгарылган юкарак кына бер җыентыгы «Күңел җимешләре» дип аталган иде. Чын иҗат әсәре булып туган шигырьләргә моннан да төгәл һәм дөрес исемнең табылуы мөмкинме икән! Чыннан да, җимешләр. Чыннан да, шагыйрь күңелендә пешәләр... пешәргә тиешләр. Ләкин бер алшарты бар моның. Җимешләр чын җимеш булып пешкәнче шагыйрьнең күңеленә, барыннан да элек, аның орлыклары төшкән булырга тиеш. Кайдан? Әлбәттә, куктән түгел, тормыштан, тормышның үзеннән. Хәер, бер караганда, бу чаклы кистереп әйтү дә берьяклылык булып чыкмагае. Ник әле без күкне бер читкә чөеп аттык? Шагыйрь күңеленә, җир кебек үк, күк тә якын. Шагыйрь күңеленә, гомумән, барлык җисемнәр дә якын. Шуның өчен дә шагыйрь күңеле, бөтен нәрсәне, дөньяны, аның барлык каршылыкларын сыйдыра алганлыгы өчен дә шагыйрь күңеле.

Орлыклар, аларның нинди туфракка төшүе, шытуы, үсеп китүләре һәм, ниһаять, чәчәк атулары, җимеш бирүләре... Очраклы хәл түгелдер, шушы бәйләнештә минем борынгы карурманга әйләнеп кайтасым, алар белән үз итеп бер сөйләшәсем килде.

Карурман! Бүреләр, төлкеләр, куяннар, бөҗәкләр белән тулган моңлы карурман!

Хәер, мин ялгышам түгел микән, фән һәм техника революциясе көннән-көн ныграк гөрелте салып дөньяга җәелә барган бер чорда, тракторлар, комбайннар, агитбригадалар шау-шуы кырларны, җәйләүләрне биләп алганда, урманнарда электр 'пычкылары чыжлап, анда да, монда да агачлар авып торганда, кайда ул бүре бичарага, куянкыек күзгә иркенәер урын? Күрсәк, без аларны зоопаркларда, дәүләт тарафыннан саклана торган заповедникларда, аннары тагы «Хайваннар дөньясы» дигән телетапшыруларда гына атнага бер күрә торганбыздыр. И ансат та соң бусы, куркасы, артларыннан чабып этләнәсе юк, телевизор алдында йомшак креслода гына утырасы, хәтта шул утырган җирдә черем итеп алырга да мөмкин. Джаз-оркестрлар, юк тавышларын

---

Журналда кыскартып басыла.

бар итеп һәм төрлечә кыланып-ясанып чыгыш ясаучы җырчылар әкренләп моңны да кысрыклый бара кебек... Әйтеп кара аптырап берәр сүз, каршы сүз димим, «ничек соң әле без кинәт болай бер якка сөрлегә башладык, кеше күңелендә моңга ихтыяҗлыкны кая куябыз?» дип сорау гына бир, синең шундук консерваторлар, иске тормышны сагынучылар төркеменә элгүең ихтимал.

Искеме, яңамы, шулай да күңелемдәге яшермичә әйтәм: мин төрле-төрле җәнлекләр, сайрар кошлар белән тулы моңлы карурманнарны сагынам.

— Газиз карурман җаным! Кеше ишетмәгән-белмәгән нинди дә булса яңа төр берәр җиләк-җимеш тапмаммы дигән хыял белән үз гомеремдә ничәмә-ничә тапкыр ялан аяклап мин синең куе чытырманлыкларың арасына барып кердем. Һәм ничәмә-ничә тапкыр ботак-чатакларыңнан, кырмавык-кычыткannарыңнан тәпиләремне тырнатып, ару-талчыгудан кәефем кырылып чыктым. Синең уйнаклап торучы яшел-зәңгәр нурларыңа үтә нык сокланып карый-карый, инде менә күзләремнең җителеген югалттым. Тавыш-өннең кайсы яктан килгәнен һәм яхшыгамы-ямангамы икәнлеген җәһәт аера торган сизгер зиһенем бар иде кайчандыр... Кайчандыр мин яшь идем, «матур идем!» дип үк әйтергә кыюлыгым җитмәсә дә, һәрхәлдә, ямьсез дә түгел идем. Мин кызлар сөям, кызлар мине сөяләр иде. Их, нинди күңелле факт ул кызлардан мәхәббәт хатлары алу, кызлар хаты уку — кайбер романнарың бер якта торсын. Ә хәзер ник кенә бер кыздан хат килсенче!

Шулай да... никадәр генә артта калса да, ыштан балакларын сызганып, сиңа чаба әле ул карт улың. Дөрес, мин җырлаудан гына син инде әллә ни яңгырамассың, мин хәзер теге чактагы Мин түгел. Ләкин син дә теге чактагы Син түгел, син дә байтак кына туналгансың.

Ләззәтле дә, газаплы да булган әдәби иҗат эшен, кыргый тартылу белән булса кирәк, нишләптер борынгы карурманнар белән чагыштырасы килде һәм бармы тавышым, юкмы тавышым, ай-һай ла, борынгы карурман көенә:

Караңгылай-й-й урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...

— дип бер җырлап җибәрергә иде.

Кайдан һәм ник башка килде әле бу аваздашлык? Карурманда да, әдәби иҗатта да без белмәгән, әлегә беркем дә аермачык кына әйтә алмаган серле яшертен почмаклар, уртаклыклар бар. Чагыштыру бәлки әнә шуннан килгәндер. Нинди дә булса гыйльми бөтенләй дауламастан, шулай ук «Яңа Америка ачтым!» дип шапырынырга да һич теләмичә, картаймыш көнемдә әдәби иҗатның әнә шул серле яклары турында бер уйланасым килде.

## Иҗат төшенчәсе, аның асылы

Нәрсә соң ул иҗат? Кайдан башлана? Кайда туктый? Туктыймы, юкмы? Иң соңгы сорауга иң элек җавап биреп үтик: дөньяда тереклек һәм яшәү тукталмыйча торып, иҗат процессы да туктамый — моны ышанып һәм ышандырып әйтергә мөмкин. Чөнки иҗат — яшәешнең иң актив һәм иң нурлы бер гәүдәләнеше ул. Дөнья тарихына, сәнгать-әдәбият практикасына борылып карасак, эшләп утырган җирләреннән башлаган фикерләрен очларга, җөмләнең соңгы ноктасын куярга өлгермичә сыгылып төшкән күпме гали җаннар турында ишетергә һәм укырга мөмкин. Ләкин алар кузгаткан, кызганычка каршы, азагына җиткезә алмаган фикер, әгәр ул, чынлап та, яшәешкә хезмәт итә торган фикер икән, сүнеп калмый, аны башкалар дәвам иттерәләр.

Хөрлеккә һәм яшәүгә хас тик шул кеше,
Тормыш өчен көрәш — көн дә кылган эше,

— дип, Фауст соңгы сәгатьләрендә тиктән генә дөньяга аваз салмагандыр

Дөресен әйткәндә, без «иҗат» сүзен урынлы да, урынсыз да кулланып, беркадәр аның бәһасен төшерә дә барабыз бугай. Чынлыкта исә, иҗат төшенчәсе, вакламыйча аңлаганда, нәкъ Фауст әйткәнчә, яшәү өчен, яшәүнең нурлылыгын, аның байлыгын һәм камиллеген арттыра бару өчен көн саен көрәшкә ташлану, көрәшү дигән сүз ул. Шул гына, бары тик шулай аңлап хәрәкәт итү генә кешегә чын шатлык, җан тынычлыгы китерә дә.

Ташчымы син, күмер чыгаручымы, җир куеныннан нефть күтәрүчеме, терлек караучымы, игенчеме яки әдәбият, сәнгать өлкәсендә эшләүчеме — кем генә булма, әгәр эшеңне яратып, шул үзең башкара торган эшкә мәхәббәт көче салып эшләсәң, син, әлбәттә, иҗат кешесе.

Шулай да бу очракта мин иҗат төшенчәсен беркадәр тарайтыбрак, конкретлаштыра төшебрәк алуны кирәк табам. Үзем дә шул өлкәдә эшләп, кырык-илле ел гомеремне әдәби иҗат эшенә биргән һәм шул эштә азмы-күпме тәҗрибә туплаган бер кеше буларак, бу этюдлар агышында сүзне күбесенчә, әлбәттә, әдәби иҗат турында алып барырмын һәм, өлешчә, сәнгать бакчаларына да сугылырбыз.

Һәр төр иҗатның нигезендә, барыннан да әүвәл, башкара торган эшеңә олуг мәхәббәт һәм аның «технологик» нечкәлекләрен, форма үзенчәлекләрен виртуозларча белү, белергә тиешлек ята. Әле моннан олугraклары, шартларның да алшарты булып ятканы бар. Бу — иҗат итүченең күңелендә һәр даим бәреп чыгарга атлыгып торучы кайнар гражданлык хисе, Туган илеңне, туган халкыңны, гомумән, барлык халыкларны, аларга ризык бирүче җирне, аларны һәм шулай ук җирнең үзен дә җылытып, тереклек көче биреп торучы мәрхәмәтле кояшны, кыскасы, табигатьне, җәмгыятьне, аларның эчке һәм тышкы каршылыкларын, асыл диалектикасын аңлый һәм ярата белү. Шушы алшарттан башка бернинди нечкәртелгән профессиональлек тә язучыны чын язучы итә алмый.

Әдәби иҗат дидек. Хәлбуки, аның да үзенә хас билгеләре, закончалыклары, теге яки бу художникның дөньяны аңлавыннан, сәләт үзенчәлегеннән килеп чыгучы бормалы юллары бар. Алда без «Мәхәббәт» дидек һәм ул очракта без әлеге төшенчәне гражданлык төшенчәсе белән бәйләп, туган илгә, туган халкыңа, аның теленә, җырына-моңына, башкара торган эшенә мөнәсәбәт белән берлектә, киң мәгънәсендә алдык.

Хәлбуки, мәхәббәт хисенең тар, кешеләр арасында бер-беренә табигый тартылуы, егет белән кызның сөешүләре, шуннан бөек ләззәт һәм рухи яңарыш табулары, кавышу шатлыклары, шуңа ирешү юлында төрле каршылыкларга очрап, мәхәббәт дигәннең чәлпәрәмә килү очраклары да була. Бу төр коллизияләргә әдәби иҗатта гомумән зур урын бирелә. Алай гына да түгел, әдәбият тарихында бөтен иҗатларын диярлек шул бөек хисне җырлауга багышлаган шагыйрьләр дә бар.

Ике мең еллар элек дөньяда бары тик утыз ел яшәп киткән, безгә тик сиксән җиде шигъри парчаны эченә алган «Лирика китабы» гына килеп җиткән борынгы римле Катулл, әйтик, шул кыска иҗадиятенең яртысыннан күбрәген сөйгәне Лесбиягә багышлап җырлаган икән һәм аның шул җыры озак еллар аша безнең көннәргә җитеп, бездә дә үзенең укучысын тапкан икән, димәк, дөньяның вак-төяк мәшәкатьләреннән өстен торып, илаһи пафос белән җырланган мәхәббәт лирикасының көчен гасырлар гына сүндерә алмый дигән сүз... Шулай ук римле, ләкин бусы инде урта гасырлар җырчысы булып культура тарихына кергән Петрарка исә Лаура дигән бер кызга мәхәббәт сонетлары белән безгә килеп җиткән. Ә без аны югалтырга ярамый торган дөнья ганимәте итеп киләчәккә алып китәчәкбез... Бөек немец классигы шагыйрь Генрих Гейненең иҗатында һәм шәхси тормышында Матильда дигән гүзәл азмы роль уйнаган дип беләсез!.. Ватаныбызның карты-яше йотлыгып укый һәм ләззәт ала торган зәңгәр күзле, бөдрә чәчле мәшһүр русны — Сергей Есенинны, аның әрмән кызы Шаһәнәгә багышлап язган лирик циклын алып карыйк. Еллар яки гасырлар гына юып бетерә алырмы бу шигырьләрдәге мәхәббәт һәм кешелеклелек хисен?.. Мисалларны үз җиребездән, татар әдәбиятының үзеннән дә бик күп табарга мөмкин. Габделҗаббар Кандалый бабабызның иҗаты, мәсәлән, нигездә үзенең сөйгәннәренә мәдхия җырлаудан гыйбарәт дияргә була. Мәхәббәттәге эзлеклелеге, бөтенлеге һәм тулылыгы аны кеше һәм шагыйрь буларак та бөтен итеп гәүдәләндерә... Ә «Йосыф-Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Буз егет» һәм башка дастаннар. Аларны соң зур һәм вакланмас мәхәббәт хисе үзенең

канатында йөз еллар аша күтәреп килмәгәнмени!.. Бүгенге шагыйрьләребез адресына юллап әйтергә калса, беркадәр кисәтү белән искә төшерәсе сүзебез шул: юкка гына алар мәхәббәт темасына ничектер өркетебрәк карыйлар. Бөтенләй читләтәләр дип раславрга һич җыенмыйбыз, язалар, ара-тирә бик дәртле итеп әйтелгән мәхәббәт чаткылары да очрап китә. Ләкин болар барысы да өзек-төтек, башка мәшәкатьләр арасында гына. Хәлбуки, мәхәббәт темасының бөтен зурлыгы, күңелләргә ут үрләтә торган чаткылары белән күтәрелер заманы нәкъ менә бүген. Гасырлар буена чын мәхәббәт хисен ахыр чиктә теткәләп, бер-берсе белән ихластан сөешүче ике яшь арасына кара күләгә булып төшүче сыйнфый киртәләр хәзер инде алынган, «Син бай малае, мин ярлы кызы, без тиң түгел!» хорафаты инде беткән. Революция китергән тарихи мәйдан үзе үк мәхәббәт хисенең чын-чынлап чәчәк атуына замин булып төшергә тиеш иде кебек.

Шул ук вакытта җиңел бер мавыгу еш кына безнең башны әйләндермиме? Нәкъ әнә шул тигезлек төшенчәсен үтә ялангачландырып аңлау нәтиҗәсендә безнең бүгенге яшьләребез арасында мәхәббәт хисенә ансат карау, аны вакландыру үзен нык кына сиздерә башлады түгелме? Ай башында загска язылышырга барып, айның азагында кенәгәгә беркетелгән шул никахны боздырырга дип чапкан яшьләрне дә, кызганычка каршы, еш кына күргәли торабыз. Кыскасы, безгә мәхәббәтне канатлырак, бөтенрәк итеп, курыкмыйчарак җырларга бик-бик вакыттыр.

## Югалту, сагыну-сагыш.
## Әллә болар юкмы?

Без мәхәббәт хисенең якты, кояшлы ягына күбрәк тукталдык. Хәлбуки, кеше җаны — карурман. Аның күләгәле, моңлы, хәтта хәсрәтле яклары да була. Кеше рухының бу каршылыклы диалектикасы шулай ук иҗаттан да читтә кала алмый. Кеше башыннан тетрәткеч вакыйгалар уза. Әйтик, берәүне җан атып сөйгән яры ташлый. Икенче берәүнең газиз бер кешесе фаҗигале һәлакәткә дучар була. Нинди дер котылгысыз сәбәпләр аркасында кемдер үзенең туган-үскән, бала чак шатлыкларын кичергән җиреннән аерылып яшәргә мәҗбүр — ул туган якларын гел сагынып яши. Әллә болар, бу югалту хисләре җырга бәреп кермиләрме? Әле ничек кенә керәләр. Карл Маркс ничектер бер җае чыкканда әйтеп уза: уртаклашылмаган мәхәббәтнең коммунизм чорында яшәгән кешеләр өчен бөек фаҗигаләрнең берсе булып калкып чыгуы да мөмкин, ди. (Цитата рәвешендә түгел, тәп фикерен китерүем — Ф. Х.) Әйтик, мин бер чибәрне үләрдәй булып яратам, ә ул бу изге хисне сизмәмешкә салыша, белергә теләми, ул миңа битараф. Бу хәл минем өчен җиңел булыр дип уйлыйсызмы? Әлбәттә, аңлатып бетергесез зур фаҗига.

Алыгыз сез йөзләгән-меңләгән халык җырларын. Чәчрәп торган шатлык, җорлык, күңел көрлеге белән тулы җырлар, такмаклар рәтеннән, әлбәттә, моң-сагыш җырлары да тулып ята.

**Исле гөлләр күчерәм, исләренә исерәм,**
**Исләремнән чыгасың юк, сагынып гомер кичерәм.**

Шөбһәсез, халык җыры бу. Хәтта конкретрак әйтергә дә була: кыз җыры. Сөйгәнен югалткан кыз җыры. Нинди аллитерация! Нинди ритм көче! Ә барыннан да көчлерәге нинди юксыну, моңлану, сагыш. Әйтәсем килгәне шул: иҗат гел алсу-зәңгәр бизәкләрдән генә, гел шатлыктан гына тормый, иҗат югалтуны да, фаҗигане дә эченә ала. Бу — аның закончалыгы. Чөнки бу — тормышның үз закончалыгы. Рус шагыйре Павел Антокольский сугышта каһарманнарча һәлак булган улы турында «Улым» дигән поэма язды. Әйтеп карагыз аның моңа хакы юк дип! Аның моңа ата буларак та, югалту хәсрәтенә баткан шагыйрь буларак та хакы бар иде. Ә ул моның белән генә калмады, әсәренә социаль пафос та сала белде.

Әнә бит теге җырда әйтелгән кыз да үзенең югалтуын поэзия дәрәҗәсенә күтәрә алган. Исле гөлләр кучерә. Исләренә исерә. Кыскасы, шул: кирәк һәм урынлы дип тапсаң, югалтуны да, кайгы-моңны да поэзия дәрәҗәсенә күтәрергә мөмкин икән. Хәтта мин, тәвәккәлли төшеп, болай дип тә әйтә алыр идем: поэзия, билгеле дәрәҗәдә, үзенең башлангычын югалтудан ала.

Кайгы-моң турында башладыңмы, шатлык һәм очыну турындамы—шул чактагы халәте рухияңне бөтен килеш саклый белү шарт. Бу — төп камертон. Әгәр инде як-ягыңа каранып, тегеләй булмагае, болай булмагае дип икеләнеп, яки, тагын да хәтәррәге, «базар бәяләренең» ничек торганлыгын күздә тотып, башта керешкән рухи халәтеңә хилафлык эшләсәң, камертонны боздың дигән сүз. Ике строфалы шигырендә, әйтик, шагыйрь:

**Чын күңелдән сөйде мине берәү.**
**Чын күңелдән аны сөймәдем,**

— дип бер-беренә капма-каршы торган хисләр белән кызыклы башлап та, икенче строфада ук, үзенә-үзе каршы килеп:

**Искә алып ул шук минутларны,**
**Үз-үземне тотып тиргәдем,**

— дип очлый икән, монда инде ике строфа арасында рухи халәтнең бердәмлеге бозылганлыгы әллә кайдан сизелеп тора. Шул бөтенлекне саклый белмәү—уен эш түгел. «Бер колак каккач мөселман уйнамас!» — ди Тукай. Син бер рухи халәт белән керештеңме, шуңа тугрылыклы булып кал инде, җан-кисәгем — берьюлы үз-үзеңә патша да, кол да була бел.

## Үзең шатландыңмы?

Әдәби иҗатның адаштыргыч «чытырманлыкларына», игътибардан читтә калдырырга мөмкин булмаган башка «вак-төякләр»енә кереп батканчы, тагы бер җитди уртаклыкны, мотлакан сакланырга тиешле таләпне искә төшереп үтү кирәк.

Бу — әдәби әсәрнең кешеләргә шатлык, яңа, моңа хәтле татып күрелмәгән өр-яңа шатлык орлыгы алып килергә тиешлеге. Еш кына моны тәнкыйть тә, без үзебез дә «хәтердән чыгарабыз». Әсәрнең нинди идея-эстетик «нагрузка» алып килгәнлеген, бу «нагрузканың» ниндирәк форма чараларына төрелгәнлеген, әсәргә нигез итеп алынган тормыш материалының ни дәрәҗәдә чынлыгын, ышандыру көченә ия булганлыгын, масштаблылыгын искәртәбез. Болары да, әлбәттә, һичшиксез кирәк. Ләкин, кызганычка каршы, еш кына без бик әһәмиятле бер якны искәртеп җитмибез.

Әсәр укучыны шатландырамы? Ә бит бу сәнгать әсәренә куела торган төп критерийларның берсе.

Әсәр укучыны шатландырсын өчен, барыннан да элек, ул язучының үзен шатландырган булырга тиеш. Иҗат процессы — аның нинди генә авыр һәм йончыткыч яклары булуга карамастан — язучы өчен бәйрәм булсын. Бу «бәйрәмнең» якты нуры, язучы үзе сизәме аны, юкмы, әлбәттә, кәгазьгә төшәчәк һәм кәгазьдән укучының күңеленә күчәчәк.

Яшь язучылар белән (алайга китсә, танылган олы язучылар белән дә) теге яки бу әсәр уңаеннан әңгәмә кузгалганда, мин һәр вакыт сорыйм:

— Кара әле, күгәрченем, кулны күкрәккә куеп, турысын гына әйт әле: бу әсәреңне язганда син үзең шатлык хисе кичердеңме? Бәйрәм булдымы моны язганда?

Әңгәмәдәшем ык-мык килә, иңбашларын сикерткәләп куя. Янәсе:

— Нигә кирәк монда минем нинди хис кичерүем? Бар булганы әнә шунда, кәгазьгә төшкән. Шуңа карап хөкем ит.

Әгәр егет юмор хисеннән бөтенләй үк мәхрүм кеше булмаса, хәтта тартынып тормыйча әйтеп үк җибәрә:

— Юк, абый, бәйрәмдә мин бөкремне чыгарып язу өстәле янында чиләнмим, бәйрәмдә күңеллерәк шөгыльләрем дә бетәсе түгел — кунакка барам, үзем кунак чакырам.

Беренчесенә, иңбашларын җыергалап, теләр-теләмәс кенә әйткәненә минем җавап:

— Юк, дускаем, әсәрең белән бергә ук миңа син үзең дә кирәк. Мин монда бары син күргәнне генә күрәм — артык та түгел, ким дә түгел. Ә син, язмаңнан чыгып көкем йөрткәндә: әлегә тик маңгай күзең белән күргәнне генә кәгазьгә төшергәнсең. Күңел күзең, эчке хисләрең кузгалмый калган. Ә алардан башка чын әдәби әсәр мөмкин түгел.

Ә икенчесенә, бәйрәмдә башка шөгыле булганына, минем җавап рәхимлерәк чыга. Чөнки, ни генә димә, бусы юмор хисенә ия кеше, бәлки аңардан, бик тырышса, киләчәктә чыгып та куяр:

— Бәйрәм итә белүең әйбәт, туганкай, кунакка баруың яки кунак чакыра белүең дә мактауга лаек. Кем белсен, исеңнән чыгармасаң, бәлки бер күңелең төшкәндә мине дә чакырып куярсың. Ә шулай да әйтәсемне әйтми кала алмыйм: син язу өстәлең янына килгәндә дә үзеңне кунакка баргандагы кебек хис итә бел. Иҗат, тәмен татып эшләгәндә, шулай ук бәйрәм ул!

Юмор турында сүз чыкты бит әле монда. Алайса, аңа бераз тукталып үтик. Әдәби әсәрдә укучыларга яңа шатлык китерү өчен төп шартларның берсе — юмор хисе белән идарә итә белү. Нинди генә җитди ситуацияләр турында тасвир кылмыйсың, шунда бер ара табып, укучыңны чак кына «кытыклап» алу, ай-һай ла, бер дә артык түгел. Ул аңа син тасвирлый торган җитди хәл-әхвәлләрне җиңелрәк үзләштерергә, тизрәк сеңдерергә бер этәргеч булыр. Югыйсә, яшерен-батырын түгел, без укучы белән үтә җитди, ничектер чырай сытыбрак, аны малайсытыбрак сөйләшәбез. Ә бу укучыны рәнҗетә, ул үзен малайсытканны кабул итә алмый.

Яшь язучылар белән әңгәмәгә кердек бит әле. Шул уңайдан тагын бер мәсьәлә калкып килеп чыга. Мин аларның берәрсе белән кара-каршы утырып, әсәрен тыңлагач, суынмас борын шул минутта ук аңарга тәкъдим ясыйм.

— Ягез әле, агай-эне, әле генә укып чыккан шушы әсәрегезне телдән, гади итеп, адәм аңларлык итеп сөйләп карагыз.

Әлбәттә, аптырап калу. Озын пауза. Аннан соң иптәш уңайсызланып кына сөйләп китә. Әлбәттә, бутала. Әлбәттә, кызара. Шулай да ничек кирәк алай ерып чыга. Бу әле уңай очрак. Ничек кенә буталмасын, әсәрдә гади телгә күчереп сөйләп бирерлек вакыйга бар дигән сүз. Ә еш кына гади тел белән сөйләп бирүгә күчкәч, эш ык-мыкка килеп терәлә. Ник дисәң, әсәрдә тема бар. Авторның яхшы теләге бар. Ара-тирә исемнәр ишетелеп китә... Ә менә эзлекле логика белән очын-очка ялгап сөйләп бирердәй вакыйга юк. «Гыйффәт» саклап утырырга урын калмый, иптәшкә ачык итеп әйтергә кирәк: аның әле бәлеше пешмәгән, мондый бәлешне табынга чыгарырга, әлбәттә, ярамый. Нәкъ әнә шундый «пешмәгән бәлеш» белән кеше сыйларга йөрүче җиңел карашлы яшьләр, гадәттә, телчән булалар, алар үзләреннән аз биреп, дөньядан күбрәкне каермакчылар.

Партия карарларын, аталарча кайгыртуны дөрес кабул итик. Яшь иҗат көчләре белән эшләргә, аларга ярдәм итәргә һичшиксез кирәк. Бу юнәлештә иҗат оешмаларында төрле оештыру эшләре бара да. Ләкин оештыру эшләре — үзеннән берни дә чыкмаган һәм чыкмастай талантсыз кешеләрне артларыннан этеп әдәбиятка кертергә маташу дигән сүз түгел ул.

Бу уңайдан бер хакыйкатьне ачыклап китәргә кирәк. Әдәби алмаш, аны тәрбияләү, аларны өлкән осталарның тәҗрибәсе нигезендә өйрәтү, әлбәттә, фарыз. Ләкин яшьләр дә, картлар да шуны белеп торсыннар, әдәбият үзе бер кайчан да яшь әдәбият яки өлкән әдәбиятларга бүленмәде. Чын әдәбиятта яшьлек өлгергәнлек белән органик кушылган булыр. Егерме җиде яшендә үлеп киткән Габдулла Тукай озак дәвам итмәгән иҗат гомерендә никадәр зур өлгергәнлек, әдәби осталык, рухи зирәклек үрнәкләре калдырып китте. Ә Лермонтов! Пушкин! Байрон! Болары исә, бөек иҗатлары белән, дөньяны таңга калдырырга өлгерделәр. Бөек талант ияләре мәңге яшь булып кала беләләр һәм яп-яшь кенә бер иҗат кешесенең гомер иткән өлкән кешеләр әйтә алмаган олы фикерне, тирән зиһенләү көче салып, әйтеп бирүе мөмкин.

Кыскасы, яшьме син яки сакалың биленә җиткән могтәбәр картмы, әгәр әдәбиятта, сәнгатьтә эшлисең икән, иҗатыңда һәр вакыт яшьлек хисе белән өлкәнлек, өлгергәнлек зирәклеген бергә кушып алып килә бел. Синең иҗатың һәр вакыт кешеләргә яңа шатлык алып килсен, күңелләрне яңа хисләр белән баетсын. Төп критерий әнә шул!

# Тел яшермичә генә сөйләшкәндә...

«Абый! Фәлән китаптагы фәлән-фәлән героегызның адресын безгә җибәрә алмассызмы? Тарихлары ни белән бетте? Алар бергә кушылдылармы? Кушылсалар, бүгенгесе көндә ничә балалары бар?»

Әлбәттә, без моны үтә шәрәләндереп, көлеп әйтәбез. Ләкин мондый һәм боларга охшаш беркатлы сораулар язучыларга әледән-әле килә тора. Бер караганда, бу игътибарга да лаек. Димәк, укучы язучының теге яки бу әсәрендә тасвир кылынган геройларының язмышы белән нык кызыксынган, ул аларның китапта язылмаган хәл-әхвәлләрен дә белергә тели. Икенче яктан, әлеге сораулар кайбер укучыларның әдәби әсәргә, сәнгать әсәренә карашы, аны аңлау дәрәҗәсе бик тә примитив булганлыкны күрсәтә. Әйтерсең язучы теге яки бу әсәрендә сурәтләнгән вакыйгаларны, геройперсонажларны, фотограф кебек, тормыштан «чырт» итеп төшереп алган да китап битләренә китергән дә салган.

Хәтта тарихи шәхесләрнең эшчәнлеген, яшәешен сурәтләүгә багышланган әсәрләрдә дә тормыш фактлары шәрә хәлләрендә, ничек булган — нәкъ шулай күчереп кенә утыртыла алмый. Язучы, шул чорның табигый атмосферасыннан чыгып, теге яки бу дәрәҗәдә үз фантазиясен дә өсти, вакыйганы камилләштерә ала. Тик бу әлеге тарихи шәхес яшәгән чорга, яки ул шәхеснең өстенә кигән киеменә, бигрәк тә аның кылган гамәленә ак җеп белән «чәпәлгән» ялган ямау гына булмасын. Борис Полевойның очучы Мересьев турында язылган «Чын кеше» повестен, яки Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романын, Габдрахман Әпсәләмовның «Газинур»ын алып карыйк. Бу әсәрләрне язганда аларның авторлары, иҗат процессын бер якка куеп, тормыш фактларын механик рәвештә күчереп кенә утырганнардыр дип уйласак, бик нык хаталанабыз.

Яшәп, теге яки бу өлкәдә эз калдырып киткән тарихи шәхесләр белән бәйләнмәгән тормыш фактлары, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, «ирекле кешеләр» белән эш иткәндә, язучы-художникның «хөррияте», әлбәттә, бераз иркенрәк. Бу очракта ул үзенең иҗат фантазиясен ирекләрәк очындыра ала. Ләкин бу очракта да фантазия тормыш чынлыгыннан узып сикерә алмый. Бу яктан алганда, язучыны күккә очып китүдән саклый торган, аны һәр даим «киртәдә» тота торган бер мәсьәлә бар. Аның алдында берөзлексез сорау тора: «Тукта! Минем язганнарым тормыш чынлыгына хилаф түгелме? Укучы моны «нәкъ тормыш үзе!» дип кабул итәрме?» Ә чын язучы-художник бу сорауны җиңел генә сикереп уза алмый инде. Тормыш чынлыгы, аның каршылыклары белән чәбәләнеп беткән катлаулылыгы, укучыны язганыңа ышандыру — менә болар, ахыр чиктә, чын язучыны һавасыз бушлыкка очып китүдән саклый торган иң төп шартлар инде.

Тагы бер серле як шунда: чын язучы-художник белән тормыш, башка гади кешеләргә караганда, ничектер юмартрак кылана: ул аңарга ачылмаган «ишекләрен» ача, моңа чаклы берәүгә дә күрсәтмәгән «карурманнарын» күрсәтә. Монда художникның аларны күрә белә торган үзенә бертөрле күзләре, күңел тирәнлеген тоя белү сәләте булуы хәлиткеч роль уйный торгандыр. Шуның өчен дә бит ул художник, шуның өчен дә бит ул талант.

Һәр очракта да язучының тормыш чынлыгына карата хыянәтсез булырга тиешлеге төп критерий булып калуында дәвам итә. Ул чынлыкны тау токымын чүкеч белән чүкып, яки динамит белән шартлатып, умырып алган кебек алмый. Тау токымын чүкеч яки кәйлә белән чүкеп үзеңә кирәкле асылташларны табу да, әлбәттә, җиңел эш түгелдер. Ләкин язучының тормыш чынлыгына ирешүе — ул, болар белән чагыштырганда, бик күпкә читенрәк. Ул ватмый, җимерми, ул тормышта башкалар йөргән юлдан ук йөри. Ләкин ул бер нәрсәгә карата да битараф түгел, ул мәңгелек эзләнүдә, мәңгелек төпченүдә — тикшеренүдә, чагыштыруда, дусларны дошманнардан аера өйрәнүдә. Тынгысыз, тыныч йокысыз, куанычлы һәм ару-талуны белмәс эш ул. Бер үк вакытта үзе эзләгәнне тапса һәм аны башкалар өчен кызыклы итеп оештырып чыгара алса һәм оештырып чыкканлыгына үзе ышанса, бүтән берәү дә татый алмаган куаныч китерә торган эш.

Язганын сәнгать дәрәҗәсенә күтәрү өчен ул, газаплы баш, тормыш чынлыгының вак-вак энҗе бөртекләрен бераемтекләп җыя, берәмтекләп күңеленә сеңдерә бара, со-

нынан иҗат процессы башлангач, аларны күңел тирәнлегеннән шулай ук берәмтекләп актарып чыгара, берсен икенчесе белән чагыштыра, кирәклеләрен, үз алдына куйган идеясенә хезмәт итә алырдайларын сайлап, эшкә куша... Гәрчә «реаль прототиплары менә шулар!» дип бармак белән төртеп күрсәтерлек конкрет тормыш материалы салынган булмаса да, гасырлар буена төс җуймас һәм барлык буыннарга да гыйбрәт булырлык, бер үк вакытта тәм-ләззәт бирерлек чын сәнгать әсәрләре бары тик шулай гына иҗат ителә. Моңа хәтле дә шулай булды, моннан соң да шулай булачак. Яшь буынга әдәбият төшенчәсен өйрәткәндә бу хакыйкатьне тел яшермичә әйтергә кирәк. Әгәр без берәмтекләп, бөртекләп җыелган тормыш энҗеләреннән коелган чын сәнгать әсәрләренә битараф калып, персонажының кайда яшәгәнлеген, адресын, ничә балалары барлыгын чәйнәп бирергә мөмкин булган конкрет кешеләр турында язылган әсәрләрне генә үрнәккә куеп, яшь буынны тик шундый әсәрләрне генә кабул итәргә өйрәтсәк, дөресен әйтергә кирәк, әдәбиятны бик тә примитив аңлауга һәм аңлатуга китеп бару куркынычы килеп басачак.

Әгәр әдәбият эшен нинди дә булса тарихи бер шәхесне почмакка сын итеп бастырып та, иҗатны шул сынга, чуар конфет кәгазьләре ябыштырган кебек, матур сүзләр, ялтыравыклы эпитетлар ябыштыру итеп кенә карасак, әйтәсе дә юк, моннан да ансат кәсепнең булуы мөмкин дә түгел... Мин дөньяда нинди дә булса мәгънәле эз калдырып киткән тарихи шәхесләр турында язмаска кирәк дигән карашны һич алга сөрмим. Язарга кирәк. Ләкин катып калган сын итеп түгел, яшәгән, көрәшкән, шатланган һәм вакыты белән хәтта елый да белгән чын кешеләр итеп сурәтләргә кирәк. Югыйсә, әгәр бер яклы примитивлыкны яклый башласак, безнең соңга таба Гамлетны һәм аның үлгән әтисе өрәге белән сөйләшүе кебек тетрәткеч эпизодларны, Дон Кихотның «изге тилелеген», ул бичара идальгоның гади крестьян кызы Дульсинияны принцесса дип кабул итүен һәм аны яклап, җил тегермәннәре белән сугышып йөрүе кебек кызганыч мәзәкләрне тоймый башлавыбыз да мөмкин. Ә үз заманыбыздан, үз революциябездән каршылыклар арасында бәрелгәләп йөдәгән һәм соңыннан «кара кояш» астында аптырап калган Григорий Мелехов язмышын алып ташласак?

Кыскасы, әдәбият һәм әдәби иҗат турында сүз чыкканда, без, бернинди фани компромиссларга да бармыйча, мәсьәләне бөтен тирәнлегендә, каршылыгында һәм шул каршылыклар арасыннан балкып чыга торган чынлыгында алып барырга тиешбез.

## Орлыклар... нинди туфракка төшәләр?

Без моңарчы әдәбиятның, аерым алганда иҗат процессының, кайбер гомумирәк якларына тукталдык. Әлбәттә, болардан тыш әдәби хәрәкәтнең тулаем барышын билгеләүче, язучыларны, гомумән сәнгать өлкәсендә эшләүче кадрларны әйдәп барган факторлар да бар. Бар гына түгел, алар магистраль сызыклар: әдәбиятның халыкчанлыгы, партиялелеге, әдәби иҗатның, барыннан да элек, якты, ачык максатка юнәлтелгән булырга тиешлеге, художникның самимилек белән юнәлгән кыйбласы... Болары булмаса, язучы-художник әдәби осталыкның нинди генә «әфсенле» серләрен белмәсен, заман һәм халык күңелендә уелып калырлык зур әсәр иҗат итә алмый.

Ә инде әдәби иҗат эшенең яшертен серләренә төшенү — бусы инде безнең «үз цехыбыздагы» эш. Һәр язучы үзенчә баш вата, үзенчә эзли, үзенчә таба һәм, әгәр тапканы күңелгә ятышлы чыкса, үзенчә шатлана. Хәтта конкрет алынган аерым бер язучының да алдан чарланып куелган, «чөйдән алып» эшкә генә кушасы әзер кораллары юк һәм булуы да мөмкин түгел. Һәр очрак, һәр конкрет тормыш материалы, һәр конкрет тема әдиптән шул очрак өчен конкрет уйлануны, тик үзенә генә хас, тик үзе генә керелп утырырдай «оя коруны» сорый. Иҗатның катлаулылыгы, иҗатның газабы һәм, ниһаять, тантанасы шунда.

Биредә без язучының тормышны аның бүтән кешеләр күрмичә дә узуы мөмкин булган кызыклы «вак» детальләрен күрә белү осталыгына ия булырга, тормышка художник күзе белән карый белергә тиешлеге турында сүз ачабыз.

Хосусан алганда, әйтик, яз картинасы. Әдәбиятта күпләр тарафыннан күп вариантларда, төрле бизәкләрдә тасвирланган мотив. Тагын да конкретлаштыра төшеп әйткәндә, шәһәр язы. Түбә кыекларыннан чалт-чолт тамчылар тама. Урам читләреннән челтерәп гөрләвекләр ага башлый һәм башкалар, һәм башкалар. Шулай дип тә башлап китәргә мөмкин, әлбәттә. Ләкин моның укучы күңеленнән, әллә ни йогынты ясамыйча, тиз генә шуып үтүе мөмкин. Чөнки бу тасвир күп мәртәбәләр кабатланган, болар кулдан-кулга йөреп шомарып беткән вак бакыр тиеннәргә әверелгәннәр. Ә менә «Шәһәрдә яз балалар кулыннан төшеп калган бияләйләрдән башлана» дип язып китсәк, ә? Кызыграк булмас идеме? Әһәмиятле ягы шунда: тормышның нәкъ үзеннән. Монда — әни булган кешенең «йөрәк парәсе» турында үтә нык кайгыртуы да (көннең җылы икәнлеген күрә торып, шулай да кадерле төпчегенә бияләй кидереп чыгарырга онытмаган!). Монда — баланың уен белән мавыгып, онытылып китүе дә. Ниһаять, монда кулны тирләтә башлаган кояшлы апрель дә. Кыскасы, монда барысы да бар, монда тик колак күнеккән стандарт чагыштыру гына юк...

Үзем кичергән тагын бер хәлне искә төшерәм. Туган авылым Мәтәскәдә сабан туенда кунакта булган җирдән безне Казанга китү өчен, җиде-сигез километр әйләнечтән, Теләчегә чыгардылар. Янәсе, аннан автобуска утыру уңайрак булыр. Казан—Теләче маршрутының башы. Кая ул! Шыгрым халык. Билетлар хәтта кичке рейсларга да сатылып беткән — сабан туе безнең өчен генә түгел икән шул. Арлы-бирле сугыла торгач, шулай да бер таксины тоттык. Ләкин бездән бәхетлерәк дүрт кеше аңа кунаклап өлгергән иде инде.

Бик тилмереп сөйләшкәч, таксистның күңеле йомшады.

— Ике сәгать көтәрдәй чамагыз булса,— диде ул шоферларча өзеп,— мин әйләнеп килəм. Только бәясеннән вакланырдай булмасагыз гына...

Кайда ул вакланып торырга! Тик таксистның сүзенә ни дәрәҗәдә ышанырга? Теләче белән Казан арасы җитмеш километр.

— Таксист ике сөйләми, килеп җитәм булгач, җитәм, — диде бу, безнең икеләнебрәк торганны күреп, — мин боларны трамвай остановкасында ук бушатачакмын да, әллүр бу якка — сезне алырга.

Егет икән, хәтта ике сәгать тә үтмәстән килеп җитте! Утыртты безне. Безгә өстәп парлы ике кунакны да утыртты һәм безгә кызык кына итеп карап куйды — гозерләгән дә кебек, чак кына уңайсызлана да бугай.

— Только сезнең рөхсәтегез белән,— диде бу мыек астыннан гына көлемсерәп.— Казан ягына юл тоткачны, менә монда, ике генә километрдагы рус авылына кереп чыгабыз. Сездән элек алып киткән пассажирларым кичкенә бер төеннәрен онытып калдырганнар. Шул авылныкы иделәр, үзара тапшыру юлын табышырлар, әйберләрен илтеп кенә бирик.

Шундый изге теләккә ничек каршы килмәк кирәк. Илтеп бирдек. Карчык, озата чыгып, рәхмәтләр әйтеп калды... Пассажирлары төшкән дә юлларына киткәннәр, ә бу үз юлында. Ә юк, егет илтеп бирүне кирәк тапты. Сөйләшеп кайта-кайта ул безгә башка кайбер якларын да ачты: ул дөнья күргән, шактый ук ватылган, гыйбрәткә лаек әйбәт егет булып чыкты. Киләчәктә минем ничек тә булса аны әдәбиятка «сөйрәп кертергә» ниятләнүемне аңлап, ныграк сораштыра башлагач, кул гына селтәде бу:

— Куегызсана, минем әдәбият герое булырлык нинди эшем бар. Простой таксист. Эшләргә тиешле эшемне эшлим, и все.

Хәлбуки, герой ук итмәсәң дә, шулай да андый егетләрнең дә әдәбиятта гәүдәләнергә хаклары бик бар — эшлисе эшен яратып эшли, намуслы. Ә нигә аңарга әдәби герой булырга ярамый?

Аннары җәйге ял көннәренең берсендә Бутлеров урамыннан узып барышлый мин бер тамашаның шаһите булдым. Шул чаттагы бала тудыру йортының каршына килгән дә, бер сәрхушы тилереп-тилереп гармун уйный. Икенче катның ачык тәрәзәләренә хатыннар ябырылган. Гармунчы сәрхуштан көлүләреме, гармун тыңлауларымы? — белмәссең. Тик арадан берсе, карап торырга бик тә сөйкемле, ләкин гаять җитди чырайлы яшь хатын гына бу тамашаны күтәрә алмады булса кирәк:

— Кит, тиле. Кеше келдермә, — дип, чапаланып кулын изи. Ә гармунчының үз сүзе сүз:

— Апкил малайны тәрәзәгә, колагына этисенең гармун тавышы керә башласын,— дип тәкрарлый үз кирелеген.

Мин монда тормыштан чәчрәп төшкән «орлыклар» турында ашыгып-ашыгып кайбер штрихлар ташладым. Ә теләгәндә һәм төшкән туфрагы ул «орлыклар»ны үз итеп кабул итә калса, алардан менә дигән хикәяләр коеп чыгарырга мөмкин булыр иде. Күктән төшми, әнә шундый «орлыклардан» шытып тамыр җибәрә, өскә калкып, күңелләргә үсеп керә хикәя дигәнебез.

## Башлануы әллә шушымы?

Юк, түгел! Башлана башлаганчы әле күп кирәк. Әле аларны — ул тормыш фактларын — «иләргә», чарларга, күңелеңдә йөртеп җылытырга кирәк, үзеңнеке итеп сайлап аласы бар. Тәэсиргә тиз бирелүчән язучы-художник (ә художникка йомшаклык хас сыйфат!) кай очракта бу вак факт кисәкләрен тышкы ялтырауларына кызыгып та күңел «сандыгына» салып куйган була. Чынлабрак карасаң, алар бернинди дә энҗе бөртекләре түгел, гади бер таш кисәкләре генә икән. Шулай да күңелгә бер эләккән бу «таш кисәге» төшеп калмый, үзеннән аерым бер сәнгать парчасы үсеп чыкмаса, бу таш кисәге икенче бер сәнгать сарае салганда, төзү материалы буларак, үз урынына ярап куя. Шуңа күрә художник тормышка, табигатькә, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә һәр даим игътибарлы булырга, художник күзе белән карый белергә тиеш.

Бу яктан А. П. Чехов безгә үрнәк була ала. Үткен тәгъбирләр, кызыклы тормыш «валчыклары», характерлы детальләр, лирик халәтне чагылдыра торган мәгънәле ымлыклар, читләтеп әйтелгән кинаяләр, җан җылысын эченә алган җыр кисәкләре, әйтемнәр... Чехов аларны һәр вакыт күңеленә яки күңел дәфтәренә теркәп бара.

— Йөздән артык сюжет. Кирәк икән, берәрсен сатып та җибәрә алам,— дип, дуслары, яшь каләмдәшләре арасында шаяртып та куйгалый торган була Чехов.

Тормыш материалына, табылган детальләргә, әгәр алар чынлап та тормышның үзеннән чәчрәп төшкән булсалар, бик тә игътибарлы булырга, аларны күңелеңдә «тирбәтеп» йөртә белергә кирәк. Бусын үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: шулай иркәләп, күңелеңдә тирбәтеп йөрткәндә генә алар үсәләр, шытым бирәләр һәм, ниһаять, аларның бөтен бер әдәби әсәргә үсеп җитүләре дә мөмкин. Аларның «иркәләнү» һәм шыту процессы күбесенчә бер ялгызың озаклап-озаклап ялланда, шәһәр читләрендә җәяү йөргәндә үзен сиздерә. Кырда яки урманда, кыскасы, табигать кочагында бу процесс күңелдә аеруча актив кузгала...

Бу — бер язучылар өчен генә дә түгел, барлык төр сәнгать кешеләре өчен дә уртак бер психологик момент булса кирәк. Җырчы Гөлсем Сөләймәнованың тууына 70 елны билгеләгәндә аны якынтын белүче иптәшләреннән берсе мондый фактны китерде: Яңа бистә ягында яшәүче Гөлсем радиокомитетта эшләгәндә, студиягә — микрофон алдында җырларга киләсе булганда, ерак араны һич авырыксынмыйча җәяү килүчән булган. Бер карашка, җырлыйсы җырлары да әзер инде, югыйсә. Текстны әллә кайчан ятлаган, көйне яхшы белә, студиягә керәсе дә сузасы гына кебек. Юк икән шул, аңарга хәтта килешли дә җырланачак җырның көендә әкрен генә «тирбәлеп» килү кирәк икән.

...Тагы да киртәгә кермәгән бер гадәтем бар: машинкада язуны яратмыйм. Язу машинкам бер почмакта тузан җыеп ята, ә мин әкрен генә кулдан язып утыруымны дәвам иттерәм. Бу бит консерваторлык дип әйтүләре мөмкин. Ихтимал, алай әйтүчеләр дә хаклыдыр. Ә бәлки кай очракта консерватор була белү дә кирәктер. Язучының эше бик тә катлаулы, консерваторлыкны белмәгән кешенең новаторлыкны чын-чыннан аера белүенә дә ышанмыйм мин. Машинкада язу, әлбәттә, тизрәк, эшне бик купкә җиңеләйтә. Ә язучылык эше — ат чабыштыруга караганда, чагыштыргысыз катлаулырак. Авыр язу, ашыкмыйча язу — ихлас иман белән әйтәм бу сүзләрне — кеше күңеле көткән нәтиҗәне күбрәк бирә.

Әйтик, күңелгә тормыштан бик тә ятышлы орлык төште, ди. Син аны рәхәтләнеп кабул иттең, ул сине җылытты. Шул җылы туфракта ул шытырга да тотынды, үзенә

якын булган икенче бизәкләрне дә үзенә тарта башлады. Хәтта сюжет сыман бер формасын да таба язды. Берәү булса, аны тизрәк кәгазьгә төшерергә ашыгыр иде. Әлбәттә, соңыннан карау, төзәтү, камилләштерү шарты белән. Иҗат эше «соңыннан карау»га һәр вакыт мохтаҗ. Кыскартасың, тулып җитмәгән дип тапкан урыннарыңны тутырасың, камилләштерәсең. Ләкин тәүге кат кәгазьгә төшерүнең бик зур әһәмияте бар. Ничек кенә булып төшмәсен, ул инде сине үзенә бәйләде, ул «бәйдән» ычкыну һич тә ансат түгел, ә кайчакта аңардан ычкынып та булмый. Шунлыктан, кабатлап әйтәм, күңеленә ятышлы беренче «орлык» төшү белән үк яки ул инде «шыта» башлагач та, кайбер форма компонентларын тапкач та, хәтта сюжетны алып барырга тиешле кешеләрнең — персонажларның сурәтләрен, кылырга тиешле гамәлләрен күрә башладым дигәндә дә кәгазьгә төшерергә ашыкма. Син ул кешеләр белән элек үзара серләшеп йөр, алар белән туганлаш, кирәк икән — бәхәскә кер, сөйләш, аларның сөйләшү, бәхәсләшү, фикер йөртү манераларын өйрән, кыскасы, ярат син аларны, кызганырга кирәк икән — кызгана бел. Күңелеңдә шул хиснең барлыгына, ул хиснең чынлыгына ышан. Нәфрәткә генә лаек булганнарына да битараф калма. Чөнки аларны син тудырасың, яхшымы, яманмы, алар синең балаларың, синең хыялың тудырган җан ияләре. Ләкин бу әле дошманны яратырга чакыру дигән сүз түгел. Дошманга карата укучыга «йоктырырга» уйлаган нәфрәтеңне үзең тиешенчә белмичә, хис итмичә язасың икән, ул укучыда син тудырырга тырышкан нәфрәтне тудырмаячак.

Ярый, боларның барысын да үзең кичердең, күңелең аша уздырдың, ниһаять, әсәр кәгазьгә төште, ди... Тик анда да кош тоткандай куанып редакциягә яки нәшриятка чабарга ашыкма. Салып куй язганыңны. Вакытлыча онытып тор. Нинди дә булса башка берәр шөгыль тап. Суын, һәм, өзеп әйтергә мөмкин, әнә шундый «озак пауза»дан соң әйләнеп кайтып укый башлаганда, син кәгазьгә төшергән, хәтта бик яратып төшергән «рәсемнәрең»нән дә кимчелекле якларын, тиешенчә әйтелеп җитмәгән урыннарны, үзен акламый торган озынлыкларны, «ак җепләр»не табачаксың.

Мин үзем И. Бабельны бик яратып укыйм. Кирәк тапкан урында аңардан цитата китереп чак кына кыланып алудан да качмыйм. Тыгыз фикерле, «рәхимсез» реалист булуы өчен һәм бигрәк тә, кыска яза белүе өчен яратам мин аны. Шул Бабель дигән әдип әйтә миңа: «Кайбер кешеләр бар: әйберне язалар да, икенче кабат әйләнеп карыйсылары да килми. Минем гадәт икенче төрлерәк: язганда мин авыр язам, ә яңадан кайтып эшләү миңа рәхәтлек бирә» ди. Аннары шул ук Бабельдан мин: «Дөньяда үз урынына һәм үз вакытында куелган ноктадан да көчлерәк тәэсир иткән нәрсә юк!» дигән җөмләне дә еш кына цитата итеп китерергә яратам. Ихтимал, монда минем субъектив зәвыгым да билгеле бер роль уйный торгандыр. Барлык кешеләр дә Бабельча язсыннар һәм Бабель сыйган кысаларда кысылып калсыннар дип уйлаудан мин, әлбәттә, ерак торам. Ләкин юк кына материалны һәм энә очы хәтле генә фикерне су буе сузуга мин башым-аягым белән каршы. Шулай ук бер язган әйберенә икенче, өченче кабат әйләнеп кайтырга иренүче ялкауларга да тешем-тырнагым белән каршы.

*Дәвамы бар.*

# МӘГЪРИФӘТЧЕ ЯЗУЧЫ ГАРИФ ЧЫКАЛЫЙ

Мәгълүм булуынча, Беренче рус революциясе дулкыннарында татар вакытлы матбугаты туды. Бер-бер артлы газета-журналлар чыга башлады. Алар тирәсенә алдынгы идеяләр белән рухланган, актив иҗат эшенә омтылучы яшьләр тупланды. Ул чордагы газета-журнал битләрен актарсаң, һәр санда диярлек яңа исем, яңа авторны очратасың. Аларның кайберләре каләмен сыный, кайберләре инде җитлеккән әдәби әсәрләр яза. Шушы дистәләрчә авторлар арасында без мәгърифәтче шагыйрь Гариф Гайнуллин-Чыкалыйны да күрәбез.

Гариф Чыкалыйның иҗаты бүгенге яшьләргә генә түгел, урта буынга да билгесез диярлек. Әле шушы язманы әзерләп йөргән көннәрдә Казанда яшәүче сиксән җиде яшьлек укытучы-пенсионер Фазылҗан ага Хәмидуллин белән Гариф Чыкалый турында сүз кузгаткач, ул: «Аның кайбер үлемсез шигырьләре минем күңелемдә һаман саклана. Без, ул вакытның яшьләре, Гариф Чыкалыйның шигырьләрен бик яратып укый идек»,— диде. Ул шигырьләрнең кайберләре вакытында мәктәп дәреслекләрендә дә урын алганлыгы мәгълүм. Иске Чыкал авылының төбәкне өйрәнү почмагында саклана торган материаллар, мәсәлән, шул хакта сөйли. Аларны 1972 елда Буа районы, Толымбай авылында яшәүче укытучы пенсионер Йосыф Рыбаков җибәргән булган. 1927 елда Иске Чыкалга килеп, ул Гариф ага белән очрашып сөйләшкән. Йосыф ага, хатына теркәп, Г. Чыкалыйның «Татарча уку» дәреслегенә урнаштырылган «Куркынычлы кичә», «Җәйге кичә вә тулган ай», «Атлар белән кунарга барганда» исемле шигырьләрен күчереп салган.

Гариф Чыкалыйның матбугатта чыккан сигез шигырь һәм проза җыентыгы билгеле. Моның өстенә газета-журнал битләрендә иллеләп шигыре табылды.[1]

Гариф Гайнуллин (Чыкалый) 1878 елда Сембер губернасы, Буа өязе, Иске Чыкал авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Элек авыл мәктәбендә белем ала, аннары Сембер мәдрәсәсендә укый. Шул ук елларда үзлегеннән русча укырга да өйрәнә.

Чыкал кешеләре еллар буена шахталарда, Баку нефть промыселларында, Юзовкада эшлиләр. Гариф Чыкалый да (әсәрләренә караганда) хезмәт кешеләре тормышын яхшы белә. Аның җыентыклары белән танышкач (бишесе шигырь, икесе проза һәм берсе шигырь белән проза катыш), Гариф Чыкалыйның хезмәт халкына аң-белем бирү өчен армый-талмый көрәшүен күрәсең. Әсәрләрендә ул дин сөреме белән агуланган хезмәт халкын рәхимсез изүгә каршы тирән нәфрәтен белдерә.

Г. Чыкалыйның беренче җыентыгы «Биш мужик» дип атала (Казан, 1910 ел, Кәримовлар матбагасы). Бу җыентыкта автор биш мужиктан төрле уйдырмалар сөйләтеп, халык арасында төрле ырымнарга ышануларны тәнкыйть итә. Сүз башында ук ул: «Вакыт безгә сөйләп юкны, сарыф итмәскә гомерне»,— ди. Аннары: «Безнең гайрәтемез күп тә, урынсызга әрәм китә»,— дип кисәтә. Мужикларның берсе, ку-

[1] Ул шигырьләрне әдәбиятчы Рашат Гайнанов барлаган. Әле күптән түгел «Шура» журналы битләрендә әдипнең «Зәңгелә» исемле көлемле мәкаләсе һәм тагын бер шигыре табылды. Кара: «Шура», 1914 ел, 14 сан. — **Автор искәрмәсе.**

енына әтәчен кыстырып, җиде төн уртасында, җиде юл чатына казна эзләп чыккан бабай турында сөйли. Бабай «Сәйфи» догасын укып җибәрүе була, җеннәрнең койрыкларына ут каба:

**Җеннәр сүзенә карамый, һаман укыган бабай,**
**Башлаганнар алтын, көмеш ташырга җеннәр, давай!**

Соңыннан исә автор, юк-барга ышанучылардан ачы көлеп, болай дип яза:

**«Сәйфи догасы» лә әтәч алып бирсә икән алтын,**
**Татарлар, без барыбыз да, җигәр идек фаэтон.**

«Надан ата» исемле икенче китабында да шагыйрь шул ук теманы дәвам иттерә, гыйбрәтле шигъри хикәя мисалында укучыны дөньяви белемнәргә ия булырга өнди. Әсәрдә надан ата белән укытучы булырга хыялланучы малай арасындагы конфликт сурәтләнә. Автор фәннең көчен, бөеклеген раслый, иске хорафатларны фаш итә. Шул ук вакытта бу әсәр ислам дине йолаларына сатира булып та яңгырый. Ул хаҗга баручыларның «Мәрьям ана чәче» дип «хөрмә мунчаласын», изге су дип Мәккәдәге кое суын алып кайтуларыннан ачы көлә.

«Тәрәкъкый мәхәббәте» исемле җыентыкта (Казан, Кәримовлар матбагасы, 1911 ел, 40 бит) Г. Чыкалыйның карашлары аеруча калку гәүдәләнеш таба. Ул үзе яшәгән җәмгыятьтә хезмәт ияләренә карата шәфкатьсезлек хөкем сөрүен күрә. «Рәхәтлек алтында түгел» исемле шигырендә автор позициясе бик ачык төсмерләнә:

**Гомердә һичкайчан байлык та кәтми,**
**Вә һәм «байлык» дигән сүзне дә ишетми.**
**Тынычлык, тик азатлык кәтә җанга!**
**Шуны ходай бирер диеп кайчанга!**

Шагыйрь тормыштагы гаделсезлекләргә каршы көрәшкә чакырудан да өркми:

**Ятма тыныч, тик көрәш син шул залим дөнья белән.**
**Гәрчә рәхәт күрмәсәң дә, җәфалансаң да, кинән!**

Г. Чыкалыйның тагын бер җыентыгы «Кызыклы шигырьләр» дип атала. Анда утыздан артык әсәр тупланган. Шулардан сигезе — рус шагыйрьләреннән тәрҗемәләр.

«Ялган доносчыга» исемле шигырендә автор милләткә кара ягучыларга кискен нәфрәтен белдерә.

**Саф көмеш тик пакь милләт ул, һич каралмый ак йөзе,**
**Былчыранмый һәм буялмый син кара якмак белән;**
**Алга атлый, дәхи атлар — туктаталмыйсың аны,**
**Кара елан төсле булып аягын чакмак белән;**
**Ул каһарман, ул арыслан, ул куәтле барчадан.**

«Бер фәкыйрьнең фәрьяды» шигырендә ярлы-ябагайларның газап белән тулы икүрешләрен түбәндәгечә сурәтли:

**Бик ирегеп җылы язны шатланып тордым көтеп,**
**Карлар эреп, җир ачылып, килгәч инде нурлы яз,**
**Бу фәкыйрь дә рәхәт табып, шатланыр, дидем, бераз.**
**Яз да килде, тик алай да теләгәнем һич тә юк,**
**Якты язда да рәхәтем иртә дә юк, кич тә юк.**
**Көн буенча каты хезмәт итеп, китә дә хәлем,**
**Төнлә бераз хәл алыйм соң, дисәм дә, тынмый җаным.**
**. . . . . . . . . . .**
**Бер сәгать һәм бер минут та рәхәт гомер сөрмимен,**
**Төрле фасыл килсә дә, мин җан тынычы күрмимен!**

Фәкыйрь халыкның патша Россиясе шартларындагы авыр тормышы «Дөньядан шикаять» исемле тәрҗемә әсәрендә хәтергә сеңеп калырлык образлар аша гәүдәләндерелә.

Карыйсың зур нәһерләргә[1], хосусән һәм Иделгә дә, —
Гаҗәп фөрьяд тавышлары дәвам итә Иделдә дә.
. . . . . . . . . . . .
Синең суың кеби инде, адәмнәрнең тулып ташты
Ачы фөрьяд тавышлары, агып күп җирләрне басты.

Г. Чыкалый «Яхъя» суфи» исемле проза әсәрендә иске мәдрәсәләрдә еллар буе гомер черетеп тә, бернигә дә ярарлык һөнәр, белем ала алмаган сакаллы шәкертләрне тәнкыйть итә. Алар хәер-садака каргасы булып көн күрергә мәҗбүрләр.

Г. Чыкалыйның тагын бер чәчмә әсәре «Гаффар агайның тормышы» дип атала. (Казан, 1912 ел). Әсәрнең герое Гаффар агай — ярлы халыкның дошманы. Ул яз башында ярлыларга иген өләшеп, көз җиткәч, аны икеләтә түләтә, үз игенен бик арзан хакка урдыра, ялчыларын җәберли. Ахырда бу саран бай үзенең ак келәтендә, акча сандыгын кочаклап, утта янып үлә. Бу әсәрендә дә язучы хәрәм юл белән табылган байлыкның кешегә бәла китерүен күрсәтә.

Г. Чыкалыйның «Чын вәгъдә» исемле әсәрендә (Казан, 1910) хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе күтәрелә. Әсәрнең герое Хәлимә әтиләре теләгән кешегә кияүгә чыгудан баш тарта һәм, үзе теләгән кешесенә ябышып чыгып, матур тормыш кора.

Күргәнебезчә, Гариф Чыкалый 1910—1914 нче еллар арасында актив иҗат итә. Шул дүрт-биш еллык эшчәнлеге дәверендә үз әсәрләре белән халык күңеленә өмет яктысы чәчә. 1914 нче елдан, ягъни беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң, Г. Чыкалыйның китап булып басылган әсәрләре күренми. Аның озак кына еллар тегүчелек һөнәре белән шөгыльләнүе билгеле. 1919—1921 нче елларда Буа өязе халык мәгариф бүлегендә инструктор вазифасын башкаруы турында мәгълүмат бар. Искә алынган әсәрләренең кайберләре 1916—1919 нчы елларда берничә кабат басылып чыга. Г. Чыкалый 1935 елда дөнья куя.

1905 ел революциясеннән соң әдәбият мәйданына күтәрелеп чыккан күп кенә әдипләребез мирасы белән беррәттән Г. Чыкалый иҗаты да өйрәнелүгә лаек. Аның әлегә табылмаган әсәрләре дә табылыр, өйрәнелер, һәм алар әдәбият тарихыбызны тагын да тулырак күз алдына китерергә ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

**ӘХМӘТ БУЛАТОВ.**

[1] Нәһер — елга.

# ЯМАШЕВНЫҢ ТУГАНЫ, ТУКАЙНЫҢ ДУСТЫ

*М. Дулат-Алиның тууына 90 ел тулу уңаеннан*

Беренче Майны хезмәт ияләренең халыкара бердәмлек көне буларак билгеләп үтәргә нәкъ бер ел калганда, 1889 елда, Казан мәчетенең мәзине Алиевның беренче баласы — бөтен аңлы гомерен эшче халык, социализм өчен көрәшкә бирәчәк Мәхмүт дөньяга килә.

Мәхмүт бәхетле кеше була — татар халкының Хөсәен Ямашев, Мулланур Вахитов, Габдулла Тукай, Гафур Коләхметов, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Хәсән Урманов кебек күренекле кешеләре белән очраша, хезмәттәшлек итә.

Мәхмүт Алиевның (1917 елдан ул — Дулат-Али) иҗтимагый-политик карашлары формалашуга әнисе ягыннан туган тиешле кеше Хөсәен Минһаҗетдин улы Ямашев белән аралашу зур йогынты ясый. 1903 елда Ленин партиясенә кергән, Казан комитетының актив члены Хөсәен Ямашев һ. б. социал-демократлар ярдәмендә Мәхмүт «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда ук марксистик әдәбият белән таныша башлый, укучы яшьләрнең алдынгы өлеше белән бергә революцион чыгышларда катнаша.

1905 елны М. Дулат-Али татар язучысы Ф. Әмирхан җитәкчелегендә төзелгән революцион фикерле шәкертләр комитетының члены була. «Ислах» («Яңару») дип аталган бу комитет милли мәктәпләрдә укыту тәртипләрен яңартуга, дини-схоластик укыту алымнарын кысрыклап чыгаруга, дөньяви фәннәрне, бигрәк тә рус телен күбрәк укытуга ирешү бурычларын куя.

1907 ел Мәхмүт Дулат-Али өчен истәлекле ел була: ул РСДРП сафларына керә һәм мөһим партия йомышларын үти башлый. Мәсәлән, РСДРПның Казан комитеты листовкаларының татарчасы Алиевлар ишегалдындагы утын сараеның базында (хәзерге Ямашев урамы, 35 йорт) гектографта басылуы билгеле. 1907 елның көзендә Уральскидан кайткан шагыйрь Габдулла Тукай белән большевик Хөсәен Ямашев беренче мәртәбә Мәхмүт квартирасында очраша.

М. Дулат-Али 1907 елның октябреннан 1909 елның җәенә кадәр Казанда легаль рәвештә чыгып килгән демократик газета «Әльислах» («Реформа»)ны оештыруда һәм аның эшендә турыдан-туры катнаша. Бу газетаның рәсми редакторы булып Вафа Бәхтияров саналса да, барлык эш Фатих Әмирхан кулында була. Газетада татар



демократик интеллигенциясенең иң алдынгы көчләре — Г. Тукай, Г. Коләхметов һ. б. язуы. «Әльислах» газетасында беренче әсәрләренең берсе «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»н бастырган, язучы һәм журналист буларак шунда беренче адымнарын ясаган, аның даими корреспонденты, татар совет әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов бу газета турында соңыннан зур җылылык белән искә ала [1].

М. Дулат-Али «Сәйяр» труппасы белән дә тыгыз элемтәдә яши, татар театрының оешуына комачауларга маташкан буржуаз-милләтчеләрнең һәм фанатик-клерикаль элементларның һөҗүменә кискен рәвештә каршы чыга. Ул танылган артист Габдулла Кариев һәм аның күп кенә атаклы сәхнәдәшләре белән якыннан таныш була. М. Дулат-Алиның «Сәйяр» артистлары белән төшкән фоторәсеме бу дуслыкның шаһите булып калган.

1911 елдан алып Мәхмүт Дулат-Али Хөсәен Ямашев тарафыннан төзелгән һәм алдынгы карашлы яшьләрне революция идеяләре белән коралландыру бурычы куйган әдәби түгәрәккә йөри. 1912 елны какшамас революционер Хөсәен Ямашев кинәт вафат булганнан соң төзелгән матәм комиссиясенең берсен җитәкләү Дулат-Алига тапшырыла.

Мәгълүм булган материаллар М. Дулат-Алиның Габдулла Тукай белән дә якын дуслыгы турында сөйлиләр. Габдулла Тукай 1910 елда Алиевлар йортының флигелендә берничә ай яши, шул вакыт көн дә Мәхмүт белән очраша [2]. Г. Тукайның «Иптәшем Мәхмүткә ядкәр. Г. Тукай, 3 октябрь 1912 сәнә [3]» дигән язу белән Дулат-Алига бүләк иткән фотосы безнең көннәргә кадәр саклана.

1912 елны, патша хөкүмәте тарафыннан Казан большевикларының бер төркем җитәкчеләре кулга алынгач, Дулат-Алига да төрмә яный. Шунлыктан ул, гаиләсен калдырып, Бохарага китә, анда Геликин байның тире эшкәртү предприятиеләрендә чималны сортларга аеручы булып эшли.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач Мәхмүт Дулат-Али армияга алына һәм Төньяк фронтка җибәрелә. Ул анда солдат массалары арасындагы революцион хәрәкәткә катнаша. Патша бәреп төшерелгәч, Төньяк фронт армиясе мөселман социалистлар комитеты председателе була. 1917 елның октябрендә Дулат-Алины 5 нче армиянең мөселман хәрби комитеты члены, ә аннары фронт комитеты члены итеп сайлыйлар. Хәсән Урманов, Минһаҗ Конов, Йосыф Ибраһимов, Һади Килдебеков, Әхмәтҗан Алмаев һ. б. да фронт комитетында була. Яшь көрәшчеләрнең энергиясе кайнап тора. Тумыштан сәләтле Дулат-Али, ялкынланып, «Сугыш сафы» дигән революцион газетаны редакцияләүгә керешә. Бу газета нигезендә 1918 елда «Кызыл Армия» чыга башлый һәм ул татар телендә басылган беренче совет хәрби газетасы булып санала.

Наркомнац (Центромуском) каршында эчке Россия мөселманнары эше буенча Комиссариат төзү турында Ленин имзасы белән декрет чыкканнан соң, Мулланур Вахитов кушуы буенча, Галимҗан Ибраһимов Псков шәһәренә, Төньяк фронтның мөселман комитеты урнашкан җиргә килә. Озакламый мөселманнар комитеты тулысы белән Петроградка күчә һәм Үзәк мөселман комитеты (Центромуском) белән кушыла. Бу комитетта Дулат-Али җаваплы участокларның берсен — буржуаз милләтче оешмаларны бетерү комиссиясен җитәкли. Совет милли комиссариатлары эшчәнлегенең бу өлкәсе буржуаз милләтчеләр һәм алар матбугатының бик нык ачуын

---

[1] «Казан утлары», 1968, 8 сан, 95 бит.
[2] Бу хакта кара: Н. Исәнбәт, Г. Тукайның мәгълүм булмаган бер шигыре һәм Мәхмүт Дулат-Али хакында, «Казан утлары», 1976 ел, 4 сан.
[3] «Советская Татария», 275 сан, 21 ноябрь, 1965 ел.

чыгара. М. Дулат-Али Үзәк мөселман комитетының матбугат органы булган «Чулпан» газетасында актив язышып, милләтчеләргә каршы кискен көрәш алып бара.

Көнчыгыш фронттагы хәлләр 1918 елның җәендә аны Казанга кайтырга һәм шәһәрне акгвардиячеләрдән саклауда катнашырга мәҗбүр итә. Шул көннәр турында ул «Эш» газетасында болай дип яза: «... коммунистлар бөтен көчләрен Казанны дошманнан саклап калуга бирделәр... революция хакына үз-үзләрен корбан итәргә әзер иделәр... Эшчеләр, коммунистлар һәм солдатлар соңгы мөмкинлекләренә кадәр сугыштылар»[1].

Казанны акчехлар басып алганнан соң М. Дулат-Али М. Конов, Г. Таҗетдинова һәм башка иптәшләр белән бергә, гражданнар сугышының данлы герое В. М. Азин гаскәрләре торган Арчага килә һәм совет хәрби комендатурасында эшли башлый. Командованиенең кушуы буенча, яшерен рәвештә бернечә тапкыр Казанга килеп разведка мәгълүматлары җыйный, большевистик листовкалар тарата.

Казан акгвардиячеләрдән азат ителгәннән соң үзәк органнарның карары белән М. Дулат-Али Мәскәүдән килгән Махсус Гадәттән тыш комиссиягә кертелә. Революцион-пролетар оешмаларны аякка бастыру һәм Идел буе, Урал тирәсе, Себер мөселманнары арасында контрреволюция белән көрәш вазыйфалары йөкләнгән бу комиссиядә ул махсус уполномоченный була[2]. Урындагы партия һәм совет оешмалары, культура-агарту учреждениеләренең эшчәнлеген җайга салуда актив катнаша. 1918 елның 1 октябрендә, мәсәлән, Мәхмүд Дулат-Али Казанның Яңа татар бистәсендә район партия оешмасының беренче оештыру җыелышында председательлек итә һәм «Россиядә революция хакында» дигән доклад белән чыга[3].

1918 елның ноябрендә М. Дулат-Али Мәскәүгә Бөтенроссия мөселман коммунистларының беренче съездына килә, анда аны мандат комиссиясе члены итеп сайлыйлар[4]. Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының РКП(б) ҮК каршындагы Үзәк бюросы членлыгына кандидат итеп сайлап, делегатлар аңа лаеклы ышаныч белдерәләр[5].

Съездан соң Мәхмүт Дулат-Али РКП(б)ның Казан губерна комитеты каршындагы мөселман секцияләренең бюро җитәкчесе һәм Совдепның губерна президиумы члены була. Бу көннәрдә ул халык белән нык аралаша, митингларда, эшче клубларында еш кына чыгышлар ясый, совет хөкүмәте урнашкач Казанда беренче мәртәбә сабан туй оештырып, бәйрәмнән килгән керемне яралы кызылармеецларга җибәрә. «Эш», «Эшче», «Кызыл Армия» газеталарында актив языша, Центропечатьның губерна бүлеге эшендә катнаша.

М. Дулат-Али алдынгы татар интеллигенциясенең политик белемен күтәрүгә, аны яңа социалистик культура төзү эшенә тартуга күп көч куя. Мәсәлән, 1919 елның 6 мартында атаклы татар язучысы Ф. Әмирханга ул, үзлегеннән өйрәнү өчен, 20 исемнән артык политик әдәбият тапшыра. Алар арасында В. И. Ленинның «Пролетар революция һәм ренегат Каутский», «Совет хөкүмәтенең чираттагы бурычлары», «Социализм һәм сугыш» дигән әсәрләре, шулай ук А. Бабель, В. Либкнехт, И. Степанов-Скворцов һ. б. хезмәтләре була. РКП(б)ның Казан губкомы һәм аның мөселман бюросының Ф. Әмирханга партиянең мөһим документлары — VIII съездда кабул ителгән РКП(б) программасын, М. И. Калинин хезмәтләрен һ. б. тәрҗемәгә бирүе дә юкка булмагандыр.

Мәхмүт Дулат-Али коммунистларның партия дисциплинасын һәм партия тормышы нормаларын нык саклаулары өчен көрәшә. Бу җәһәттән шундый факт характерлы. 1919 елның апрелендә Сызраньда бер группа коммунистлар, РКП(б) ҮК рөхсәтеннән башка, «Көнчыгыш фронттагы татар-башкорт оешмаларының Үзәк бюросы»н оештырырга карар кыла. 1919 елның май ахырында Казанда, М. Дулат-Али председательлегендә, Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының РКП(б) ҮК каршындагы Үзәк бюросы членнары, РКП(б)ның Казан губкомы каршындагы мөселман секцияләре бюросы һәм шәһәр коммунистлары активының берләштерелгән утыры-

---

[1] «Эш», 57 сан, 16 сентябрь, 1918 ел.
[2] «Знамя революции», 171 сан, 21 сентябрь, 1918 ел.
[3] «Эш», 68 сан, 4 октябрь, 1918 ел.
[4] «Эш», 94 сан, 11 ноябрь, 1918 ел.
[5] «Эш», 105 сан, 24 ноябрь, 1918 ел.

шы була. Анда, Дулат-Али докладын тыңлаганнан соң, югарыда әйтелгән оешманы законсыз дип табу турында карар кабул ителә. Бу карар РКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан да хуплана[1].

1919 елның җәендә колчак бандаларын куганнан соң, Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының РКП(б) ҮК. каршындагы Үзәк бюросы, партия мобилизациясе тәртибендә, Мәхмүт Дулат-Алины Кече Башкортстанның Стәрлетамак шәһәренә Башкортстан совнархозының бүлек мөдире итеп җибәрә. Шушы әһәмиятле хуҗалык эше постында да ул бөтен көчен биреп хезмәт итә. Кызыл Армия өчен тиреяры әзерләү буенча командировкага барган җирендә М. Дулат-Али фаҗигале төстә һәлак була: бандитларга каршы көрәш өчен җаваплы кеше, элеккеге эсер Поленов дигән бәндә тарафыннан законсыз кулга алына һәм 1920 елның июль ахырында атыла. Аның белән бергә кантон комиссары Булатов, ревкомның элекке председателе Абдрахманов, кантон мәгариф бүлеге мөдире Гумеров, халык судьясы Тартышев һәм ревизор Кузнецовлар да һәлак була.

Поленовның законсыз эш итүе җәзасыз калмый. Бер төркем коммунистларның урынсызга атылу мәсьәләсе РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты президиумында махсус тикшерелә. БашЦИКның 1920 ел 9 декабрь карарында: «Җинаять эшләре өчен каты җәзага тартырга, Ревтрибунал судына бирү өчен тикшерү комиссиясе төзергә, В. Поленовны кулга алырга һәм... Ревтрибунал карарына кадәр төрмәгә ябарга», — дип әйтелә[2].

Башкортстан АССРның Баймак шәһәрендә, яшел бакча эчендә, Совет хөкүмәте өчен һәлак булган сугышчыларга һәйкәл тора. Мәрмәр ташка Ленин партиясенең тугрылыклы улы Мәхмүт Дулат-Алиның да исеме уелган.

**Т. НАСЫЙРОВ,**
тарих фәннәре кандидаты

---

[1] Татарстан АССРның төзелүе. Документлар һәм материаллар җыентыгы. Татарстан китап нәшрияты. 1963. 120—121 битләр.
[2] Р. У. Кузыев. Шәһит Ходайбирдин. Башкортстан китап нәшрияты. Уфа, 1964 ел, 43 бит.

# ТЫНГЫСЫЗЛЫК УТЫ

**Ни ул әрни безнең җанда,**
**Ни ул туа безнең аңда!**

**М. Әгъләмов**

Табигатьтәге һәм җәмгыятьтәге һәр нәрсәнең, һәр күренешнең үзенә бер үсү, үзгәрү юлы була. Кешенең дә әнә шундый рухи үсеш, үзгәреш юлы бар. Тик ул алдан бирелгән яки сызып куелган әзер юл түгел. Аны тышкы тирәлекнең, тормышның һәм үзенең эчке халәтенең һәр даим үзгәреп торучы ситуацияләре буйлап, шулар эченнән, шулар аша, шулар арасыннан кеше үзе сала, үзенең рухы, җаны, акылы белән берлектә сала.

Заман яшьләрен рухи формалаштыруда, шәхес буларак ныгытуда, чыныктыруда партиябез куйган төп лозунг: «Һәркемгә — ныклы идея ышанганлыгы һәм актив тормыш позициясе!» Әнә шул юлның кеше күңеленнән табигый рәвештә килеп чыккан булуын, алар арасында каршылык калмавын таләп итә. Ягъни яшь кешенең иң башта үз күңеленең ышанычлы, дөрес һәм ныклы иманы булсын, шуны ул эчке дөньясының аерылгысыз бер өлеше итеп яшәтә алсын. Ә аннары инде реаль, практик яшәештә, аның һәр мизгелендә үзенең шул иманына тугры булып уйлый, эшли һәм керәшә белсен.

Әлеге тугрылык тормышның иң зур вакыйгаларын, тирән, олы масштаблы күренешләрен, үткән чорларның күренекле шәхесләрен аңлауны да җиңелләштерсен, аларның яшәүләрен бер-берсенә шактый аваздаш итсен. Әнә шундый аваздашлык бүгенге художникка тарих, үткән чорлар турында сөйләгәндә, уйланганда безнең хәзерге яшәешебез өчен бик кирәкле нәтиҗәләр ясау, үткәннәр тәҗрибәсен бүгенге, җанлы тормышка китереп ялгый алу, бергә яшәтеп җибәрә алу мөмкинлеге бирә.

...Менә шагыйрь М. Әгъләмов та бер шигырендә үткән чорларның бөек кешеләре тормышы белән очрашкан. Ул аларны — бөекләрне — бүгенгә, үзе янәшәсендәге яшәешкә дәшә:

Мин чакырам. Әмма алар кайтмый,
Алар кайтмый, легендада кала...
Ә үзебез менә сизмибез дә,
Алар бездә — бездә кабатлана!

Бүгенге катлаулы тормышта яшәүче кешенең, үзен һәр мизгелдә үткәннәр белән нык бәйләнгән итеп тоючы, үзен үткәннәрнең диалектик үсешенең бер җимеше, бер җаны итеп тоючы кешенең күңел дөньясын ачып салу бу. Ул үзенең урынын хәрәкәттәге тарих эчендә күрә.

Китаптан тагын бер мисал: яшь егет үз халкының ерак тарихына кагылышлы кадерле ташлар арасында йөри. Шул чагында аңа бер юлаучы очрап, нишләп йөргәнен сорый. Егет: «Бабамнар кичергән йөрәк өзгеч кайгыларны кичерәм»,— дип җавап бирә. Ә юлаучы, бүген еш кына ишетергә мөмкин булганча, аңа: «Кайгырма юк өчен!» — ди җиңел генә. Шуннан соң егет әлеге юлаучыга менә нәрсә белдерә:

— Кайгылар зур итәләр.

Шәхесне үстерүнең, аны чордашлары каршында җитди сүз әйтерлек олайтуның шифалы чишмәсе — халык тойгыларын, аның иң эчкәредәге уй-хисләрен кичереп олы булу, шулай үсү җирлеге табылган бу сүзләрдә.

Атасыннар, әйдә, «хыялый» дип,
Булсак булыйк, әйдә, «фанатик»...
Әмма яшик — дөрес дошман күреп,
Әмма языйк — дөрес яратып.

Язма кыскартылып басыла.

Көрәсезме, биредә дә шагыйрь өчен иң мөһиме — дөрес дошман күреп яшәү! Иң мөһиме — дөрес яратып язу! Димәк, тугры булу. Һәм ул — тормышның башка бик җитди күренешләре белән бәйләнгән, аларның килеп чыгуына сәбәп булган реаль көч чыганагы. Без аны «Николай Ершов турында уйлану» шигырендә ачык тоябыз.

Чыпчыкларга кыек — оя,
Бөркетләргә — биек кыя.

— кебек кискен һәм кыю фикер белән башланып китә ул шигырь. Аңлашылса кирәк, бөркетләр — халыкның батыр уллары, биектә һәм туры юл ярып баручылар, чыпчыклар исә (без бу кошларның үзләрен күргә караганда күбрәк тавышларын ишетәбез) — нәрсәгәдер ышыкланып, кырыйгарак посып, җайлабрак, үзләрен кискен хәлләргә куймыйчарак яшәүчеләр. Николай Ершов, әлбәттә, беренчеләр арасында.

Халык өчен яшә. Ирекне
Һәр адымда сакла, һәркайда —
Милләте юк аның — Ирекнең,
Казан да бер аңа, Байкал да...

Ниһаять, шагыйрьнең бу зур шәхес турындагы һәм башка кешеләр, аларның ничек яшәве хакындагы уйларының иң көчле, иң калку җире:

Ут гомерләр калмый юк булып,
Ялкын булып дөрли уйлары.

М. Әгъләмов бу шигырьдә Николай Ершовны һәм Галимҗан Ибраһимов, Муллануp Вахитовны тормышлары мәңгелек утка — яктылык көлтәсенә әверелгән кешеләр итеп күрә.

«Исәнме, йөрәк»нең[1] шактый шигырьләрендә ялкынланып раслау яки нәфрәтләнеп кире кагу, шул каршылыкларның тере яшәеше чагыла. Шагыйрьнең күңел күзе аларда, нигездә, кешенең социаль яшәешен, аның башка кешеләр белән актив чолганышта булган тормышын күзәтә. Фикер һәм хис дулкыннары әнә шул сферада көчлерәк булып һәм тирәннәнрәк хәрәкәтләнә. Әлеге үзенчәлек — әлбәттә, иҗат уңышы. Ләкин китапта шулар арасында да аерылып, үзләренә бүтән бер игътибар сорап торган берничә шигырь бар. «Җилле көндәй җилләләр», «Соңгы сүз», «Төнге сулар» һәм «Язгы уяну» — әнә шундыйлардан.

Озаккарак китте бугай, озаккарак,
Күзен текәп киткән иде һәммә тараф...

...Чыкты буран — ком бураны,
Өермәсен тыялмады.
Чыкты болыт актарылып,
Офыкларга сыялмады.
Килгән иде кояр булып,
Бар дөньяны юар булып,
Ул яумады...

Җан биргәндәй талпынды да
Ауды басу уртасына
Теткаләнгән ялгыз нарат.
... Озаккарак китте шул, әй, озаккарак...

Алып китте басудагы
Өеп куйган күбәләрне,
Салам эшләпә чөйгәндәй,
Алып чөйде түбәләрне.

Керде әллә ничә төргә,
Ә игелек күрсәтергә
Теләмәде.
Тик сөенде давыл белән
Суга төшкән мамык канат,
Еракларга китеп барды
Башын чөеп, горур карап.

...Озаккарак китте шул, әй, озаккарак...

Табигатьнең кешене зарыктырган бер күренеше — коры җил котыруы тасвирлана шигырьдә. Ә кешеләр аннан яңгыр көтәләр. Табигать алышынуының, үзгәрүенең шигырьдәге нечкә реальлеге, кеше тойгыларының дөреслеге нәтиҗәсе булып безнең күз алдында, күңелдә бөтен җанлылыгы, тәэсир көче белән образлы күренеш пәйда була, яшин башлый. Ә шулай да шигырь табигатьнең шушы бер күренеше хакында гынамы?

Юк, «Җилле көндәй җилләләр» табигать турында гына түгел, моңа аның исеме үк ишарәли: «...җилләләр». Димәк, шигырь кешеләр турында. Бу юлы шагыйрьнең иҗат дөньясы тудырган яктылыкта буш, коры җил тудырып, файдасыз шау-шулар белән мавыгып, эш кыяфәте чыгарып йөргән затлар ап-ачык булып күренә. Үзәккә куелган проблема шул: буш тузыну белән генә алдырып булмый, һәр шәхестән халык бары тик эш, чын эш көтә.

Картлар тора көлемсерәп:
«Файдасызга очынуны
яшьләргә бер күрү кирәк.
Яшьләргә бер күрү кирәк».

Ә «Соңгы сүз» шигыре исә бер карауга инде байтак кабатланган темага багышланган кебек. Яшь егет үз гомерендә беренче мәртәбә зур сугыш белән очраша. Анда яшәү дәрте чиксез көчле. Чөнки ул «яшәү» дигән матурлык белән яңа очрашкан гына әле, аның белән ныграк танышасы, аннан үзенә күбрәк бәхет, шатлык һәм кешелек ләззәте аласы килгән иде. Шуңа аның күңеле куркыныч, шом сизә. Һәм егет әйтерсең ярдәм сорап, күңелендәге яшәү көченә, омтылышына мөрәҗәгать итә, аның шушы куркыныч мизгелдә үзен яклавын, үлем кулына бирмәвен тели.

Иң беренче зур сугышка керәм бүген,
Иң беренче зур сугышны күрәм бүген.
Идел буйларында якты киңлекләрдә — зәңгәр күгем,

Зур сугышка керәм бүген.

Көтә мине яр астында инеш,
Суы — көмеш.

[1] Мөдәррис Әгъләмов. Исәнме, йөрәк. Шигырьләр. Казан, 1978 ел.

Мин кайтырга тиеш исән килеш,
Мин кайтырга тиеш.

Мин кайтырга тиеш туган илгә,
Мин кайтырга тиеш туган өйгә.
Сабантуйга алган затлы киемнәрем калды
чөйдә,—

Мин кайтырга тиеш өйгә...

Әйе, яшәүнең зурлыгы шигырьдә гап-гади итеп, әмма үзәккә үтәрлек моң белән ачыла... Күңелгә яшәү белән аерылу моңы ташкыны агыла... Яшәүнең кадерлелеге, зурлыгы төшенелә. Һәм шигырь:

Илгә кайтыр өчен исән килеш,
Без җиңәргә тиеш.

— дип бетә. Яшәү өчен кирәкле, аны зурайта торган моң.

Шагыйрь күңеленең әнә шундый моңы кушылу нәтиҗәсендә әсәрдә сурәтләнгән гади генә зурлык, масштаблылык, көчле гомумиләштерү сәләте алуын күрәсең. Әйтик, мәсәлән: «Халык урын бирә: төркем булып Кереп килә арган савымчылар. Бәрәм-бәрәм түргә уза алар. Халык урын бирә, дәшеп ала... Шигырьләрем җитдиләнеп кала»... Шагыйрь үзенең җитди, олы эш кешеләре, үтә акыллы кешеләр алдында басып торганын белеп алган шикелле, без, укучылар да, тормыш турында тирән гамь белән яшәүче күңелне, аны дулкынландырган көчле заман җилләрен, агымнарын тоеп алабыз.

Каләмдәше Зөлфәткә багышланган «Язгы уяну» шигырендә шагыйрьнең күңел төбе тагын да тирәнрәк ачыла.

Бер туңабыз шулай,
Бер янабыз.
Без таударак,
Алдан уянабыз...

Безнең иңнән сөеп дәшә-дәшә,
Иң беренче бездә уйный рәшә.

Бусы инде, безнеңчә, шагыйрьләр яшәве турында гына түгел, ә һәр кешенең дә башкалар өчен бер ут булырдай балкып, күңеле белән югарырак, рухы белән таударак, җаны белән алдан уяныбрак яшәргә тиешлеге турында. Салкын исәп-хисапка, тормыш ваклыкларының баш әйләндергеч ыгы-зыгысына баш имичә, саф һәм матур, олы һәм тирән күңел белән ахыргача яшәү идеалы әнә шулай раслана. Ә икенче бер урында исә шагыйрь төнге учакка карап уйлана: «Инде сүнәр... Уяу кеше җитми Ыргытырга коры талчыбык».

Кыскасы, шагыйрь М. Әгъләмовның ышанычлы позициясе — аның поэзиясенең тамыры нык булу, тирәнгә киткән булу дияргә мөмкин. Бу тирәнлек халык күңелен үзеңнеке итеп тоя алып яшәүдәндер, күрәсең. Һәм шуннан ук килеп чыга торган икенче ныклык — ул шагыйрьнең һәрчак үз күңеле белән бердәм, аның белән бер сүздә, бер омтылышта булуы. Шушы ук сыйфат дәвам итеп иҗатның тагын өченче ныклы җирлеген хасил итәдер дисәк, анысы тирән хиселелек, моңлылык, шигырьдәге хәрәкәтләр һәм авазларның кешеләрдәге тирән кичерешләргә барып тоташканлылыгы диярге тиеш булабыз.

Инде шагыйрь тоткан фронтның йомшак урыннарын эзләп карасак, мөгаен, шундыйрак бер фикергә килербез: һәр үсемлекнең — бирегә исә поэзия үсемлегенең — үсүе өчен тирән тамырдан килгән көч кенә түгел, ә өстән, без сулый торган һавадан, атмосферадан алынган матдәләр дә бик кирәк. Шуны аңлап, шагыйрь киләчәктә үзенең поэтик энергиясен шул якка күбрәк юнәлтсен — бүгенге һаваны ныграк сулап, аны тамырдан килгән сут белән күбрәк кушсын, яхшырак синтез булдырсын иде.

Аннан соң М. Әгъләмовның кайбер шигырьләрендә бераз кабатлану, элек шагыйрьнең үзендә яки башкаларда инде очраган уй-хисләрне яңартып язу да күренеп ала. Димәк, шагыйрьгә тагын да күбрәк фәлсәфи яңалык кирәк! Һәрбер шигырьнең яңа бер ачыш булуын көтә бит укучы.

Ә укучының мондый өметләре акланырга тиеш. Шагыйрьнең бер дустына атап язган сүзләрен аның үзенә карата да куллануп була.

Ышан, дустым, килер язга ышан!
Бушан, дустым, шигырь язма! Бушан!
Һәрбер күзәнәгең тора моңнан —
Ул вакытлы туңган,
Тик вакытлы туңган.

...Менә без яңа бер китап укып, шагыйрь кичергән олы хисләр, тирән кичерешләр эчендә яшәп алдык. Шул кайнар һавалы дөньяда йөрдек, шигырьләр тудырган уйлар белән уртаклаштык. Шушы яшәп алу, шушы йөрү безнең күңелгә нәрсә бирде? Ни белән баетты ул безне? Йомгак ясап әйткәндә, бу яшәп алу безнең күңелгә тынгысызлык уты салды. Безнең рухи дөньябызда үз-үзенә һәм тормышка карата сизгерлек тудыра торган бер ритм, сүнми торган эчке пульс булдырды.

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

# ЛЕССИНГ

*Готхольд Эфраим Лессинг (1729—1781) — немец классик әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган мәгърифәтче язучы. Ул рухани семьясында туа. Лейпциг һәм Виттенберг университетларында белем ала. 1760—65 еллардагы Җидееллык сугыш вакыйгаларын күргән һәм тирән кичергән драматург комедияләр(« Яшь галим», «Минна фон Барнхельм»), трагедияләр («Мисс Сара Сампсон», «Эмилия Галотти»), «Натан Мудрый» исемле драматик поэма яза. Шулай ук дини аскетизмга каршы җырлар, эстетик һәм фәлсәфи темаларга күп санлы фәнни хезмәтләр авторы Лесинг үз заманының зыялылары әхлакыннан усал көлеп язган мәсәлләре һәм эпиграммалары һәм мәсәл жанрының теоретигы буларак та («Мәсәл турында уйланулар») дөнья әдәбиятында киң билгеле әдип.*

## МАЙМЫЛ БЕЛӘН ТӨЛКЕ

— Җәнлек-җанварлар арасында ул булып мин кылана белмәгән берәр җан иясен әйтеп кара әле миңа? — дип мактана Маймыл Төлкегә.

Төлке аңа каршы килми.

— Ә менә син үзең шуны әйтә алырсыңмы икән: синең үзең булып кыланырга теләү нинди ахмак җәнлек-җанварның башына килер икән соң?

...Илем әдипләре!.. Шуннан да ачыграк итеп тагын нәрсә әйтеп булыр икән?

## БҮРЕ ҺӘМ КӨТҮЧЕ

Бөтенесе рәттән сырхаулап, көтүченең сарыклары үлеп бетә. Шул хәбәрне ишеткәч, Бүре аның кайгысын уртаклашырга килә.

— Көтүчекәем, — дип сүз башлый, — синең шундый коточкыч авыр бәла кичерүләрең чынлап та дөресме? Бөтен сарыкларың да юкка чыккан бит. Нинди юаш-сабыр, матур һәм симез сарыклар! Мин шул хәтле кызганам ки, менә хәзер күземнән кайнар яшь коярга әзермен.

— Рәхмәт, Изегрим әфәнде, — дип җавап бирә көтүче. — Син бик олы җанлы икәнсең...

— Аның җаны, — дип сүзгә кушыла шунда көтүченең Гилакс исемле эте, — якыннарына бәхетсезлек килгәндә һәр вакыт шундый була диләр.

## ТӘВӘ КОШЫ

— Менә хәзер очып китәм мин! — дип сөрән сала шыксыз зур гәүдәле Тәвә кошы һәм бөтен кош халкы, ошбу гайре табигый тамашаны күрергә теләп, аның тирәсенә җыела. — Хәзер очам! — дип кабат кычкыра ул, киң һәм озын канатларын җәя һәм, җилкәннәре инде күтәрелгән кораб сыман, әмма җирдән бер генә секундка да аерылмыйча алга ыргыла башлый...

Менә сезгә шагыйрь булмаган акылларның шигъри сурәте. Алар да бит озыннан да озынрак булган одаларының беренче юлларында үзләренең горур канатлары белән мактана башлыйлар, болытлардан, йолдызлардан да өскәрәк очып менәчәкләрен белдерәләр, ләкин барыбер җиргә... «тугры» булып кала бирәләр.

## ТӨЛКЕ ҺӘМ БИТЛЕК

Моннан бик күп еллар элек бер Төлке сәхнәдә көлдерүче булып уйнаучы берәүнең эче буш, ә авызы бик зур итеп ачылган битлеген таба.

— Менә сиңа баш! — дип уйлана ул, битлекне әйләндереп-әйләндереп караган чакта. — Мие юк үзенең, ә авызы ишегалды хәтле зур! Берәр лыгырдык затның башы булмадымы икән бу?!.

...Тел тыя белмәүче ораторлар! Бернинди гаепсезгә теләсә кемне хөкем итәргә һәр вакыт әзер булган рәхимсез судьялар! Бу Төлке сезнең турыда әйтә түгелме?

## КАРГА БЕЛӘН ТӨЛКЕ

Бер Карга, тырнаклары белән бик шәпләп кыстырып, шактый зур ит кисәге алып кайта. Аны, күршем мәчесе шуны ашап үлсен әле дип, ачулы бер бакчачы юри ташлаган икән.

Табышын тәмләп ашар өчен, Карга карт имән башына менеп кунаклый. Нәкъ шул чакны, кача-поса элдертеп, имән янына Төлке килеп чыга һәм, Каргага мөрәҗәгать итеп әйтә:

— Даннар яусын сиңа, Юпитер кошы!

— Син мине кемгә саныйсың? — дип сорый Карга.

— Ничек кемгә саныйм? — ди Төлке аңа җавабында сорау белән. — Әллә син Зевс кулыннан очып миңа ризык китерер өчен менә шушы имәнгә төшеп куна торган мәрхәмәтле Бөркет түгелме!..

Үзен бөркет итеп таныганга, карганың, әлбәттә, исләре китә һәм ул чамасыз куана. «Юк, Төлкене бу уеннан һич тә кайтарырга кирәкми!» дип уйлый ул.

Һәм, күңеле кинәт йомшарып киткәнгә, үз авызындагы ит кисәген Төлкегә ташлый да горур кыяфәт белән каядыр очып та китә.

Елмайган йөзле Төлке итне шунда ук эләктереп ала һәм ниндидәр үзенә бертөрле шатлыклы явызлык белән ашый да башлый. Әмма бу шатлык каты авыртуга әйләнә — агу үзенекен итә һәм төлке уфылдый да алмыйча җан бирә.

...Икейөзле һәм эчкерле ялагайлар, сезнең дә барыгызга, бүтәннәрне урынсызга һәм бушка мактауларыгыз өчен, шундый агудан башка бернәрсә дә эләкмәсен иде.

## КҮГӘН КУАГЫ

— Әйтче шуны, зинһар, ни өчен син яныңнан узган һәр кешенең киеменә чәнечкеләрең белән ябышасың? — дип сорый тал агачы Күгән куагыннан. — Нәрсә телисең син? Нигә кирәк ул кием сиңа?

— Берниемә дә кирәкми! — дип җавап бирә Күгән. — Нәрсәгә ул миңа кеше киеме. Мин аны бары тик ертырга гына телим.

## САНДУГАЧ БЕЛӘН ТУРГАЙ

Күпләгән укучыларны түземсезләп җиде кат күкләргә менеп очуны яраткан шагыйрьләргә нәрсә әйтергә? Бервакыт Сандугачның Тургайга әйткән сүзләрен кабатлау бик җитәр кебек: «Дустым минем, тавышыңны ишетмәсеннәр өчен шулай биекләргә менеп очасыңмы әллә син?»

## ӘРЛӘН БЕЛӘН КЫРМЫСКА

— Эх, сез, хәсрәт җан Кырмыскалар! — ди икән Әрлән. — Нигә дип шулай җәй буе арып-талып эшләп тә кышлыкка чамасыз аз ризык җыясыз? Сез менә минем запасымны күрсәгез иде!

— Синең запасың үзеңә кирәк ризыктан күбрәк икәнен без беләбез, — дип җавап бирә Кырмыска, — шуңа күрә дә кешеләр синең ояңны актарып, шунда җыйган бар ашамлыгыңны юкка чыгарып бик дөрес эшлиләр. Ерткычларга хас комсызлыгың өчен гомереңне бирергә мәҗбүрсең син!

# ШАГЫЙРЬНЕҢ АБЫЙСЫ

Күренекле әдәбият белгече һәм публицист Гази Кашшаф үлемсез шагыйрь Муса Җәлилнең шәхес булып формалашуында, Октябрь идеаллары хакына соңгы тамчы канынача көрәшкән патриот булып җитүендә абыйсы Ибраһим Җәлиловның йогынтысы, аның тәрбиясе гаять зур булган дип бәяли.

Ибраһим Җәлилов Совет властен яклаучы көрәшчеләр сафына бик яшьли кушыла. Ул егерменче елда Коммунистлар партиясенә кергән. Башта туган якларында — хәзерге Оренбург өлкәсенең Шарлык районы җирләрендә — революциядән соңгы елларда башланып киткән кискен сыйнфый бәрелешләрдә чыныгу ала, аннары Каракум чүленең кайнар комнары һәм Памир тавындагы тарлавыклар арасында Октябрь казанышларын яклап сугыша. Тугандаш халыкларга революция максатларын, партиянең милли политикасын аңлата, Ленин сүзләрен җиткерә.

Абыйсы эшчәнлегендә Муса тормыш мәгънәсен күрә, бәхетнең көрәштә, халыкка хезмәт итүдә икәнлеген аңлый. Шул елларда абыйсының альбомына язган бер шигырендә үсмер Муса «бөтен илләр өчен без юл ачарбыз» ди, Октябрь көрәшчеләренең ялкынлы рухын, ул чор яшьләренең зур омтылышлар белән җилкенүен чагылдыра. Әле каләмен тибрәтә генә башлаган шагыйрь революция казанышларын саклау өчен абыйсы белән бер сафка басарга әзер тора.

Үсмер Мусага эше, көрәше, сүзе, рухы — бөтен тормышы белән зур тәрбияви йогынты ясаган, хәзер союз күләмендәге пенсия алып ялга чыккан Ибраһим аганың тормыш юлы беренче адымнарда ук яшьләргә үрнәк булырлык, аларны рухландырырлык.

Без бу олы гомер юлының кайбер сәхифәләренә генә күз салабыз.

## «Үләргә рөхсәт юк»

Памирның ак кар белән капланган кыялы түбәләрен — болытлар, ә тау арасыкларын куе томан сарган. Кичләрен ул бөтен тирә-юньне томалый, алагаем йомгаклар сыман, урала-бөтерелә. Ике адымнан җайдакны күрерлек түгел. Тау сукмакларын капшанып кына табарлык. Мондый чакларда кыя-таулар арасында йөрү хәтәр — кавалерия эскадронының политругы Ибраһим Җәлилов моны бик яхшы белә. Хәер, томанын гына ничек тә ерып чыгарлар иде. Монда аларны һәр адымда зуррак хәвеф сагалый: сукмак буендагы ташлар арасында башкисәр басмачылар утыра.

Җәлилов җитәкчелегендәге отряд шуларның эзенә төшәргә йөри. Аңа җитди һәм хәтәр бурыч куелган. Ибраһимга эскадрон командиры аны төгәл аңлатты:

— Дошманның каршысына чыгасың, политрук, — диде ул. Отряд басмачылар өенә һөҗүм итә. Ләкин синең бурыч — аларның игътибарын җәлеп итеп тору. Атышыгыз, һөҗүм итегез, әмма төп максатны истән чыгармагыз: синең отряд

басмачылар өере белән атышкан арада, эскадрон аларның тылына чыгарга тиеш. Нинди хәлдә калсагыз да — чигенү юк.

— Үлсәк тә чигенмәбез!

— Үләргә рөхсәт итмим, политрук. Бары җиңәргә кирәк!..

Моннан күп еллар әүвәл, 1926 елда, Памир таулары арасында бирелгән сугышчан боерыкны Ибраһим Җәлилов отряды уңышлы үтәп чыга. Ул чактагы бәрелешләр аның хәтерендә яхшы саклана. Кечкенә генә отряд ярсыган басмачыларның берничә һөҗүм ташкынын кире кайтара. Ә эскадронның төп көчләре дошман тылына чыга да хәлиткеч һөҗүм башлый...

Политрук бу сугышта командир буларак та осталык күрсәтә. Шуннан соңгы бәрелешләрдә ул һәр вакыт иң хәтәр урында — алгы сызыкта була. Кызыл Армиянең басмачыларга каршы көрәшүче махсус частьлары сафында политрук Ибраһим Җәлилов Памирда һәм Караком чүлендә котырган бүреләр чирүедәй йөргән Җаваһи хан һәм Разгельда хан бандаларын тар-мар итүдә турыдан-туры катнаша. Аның хәрби сәләте һәм сугышчан хезмәте ул чакта ук югары бәяләнә. Ибраһим аганың шәхси документлары арасында Төркестан республикасы Үзәк Башкарма комитеты тарафыннан 1932 елның 20 февралендә бирелгән таныклык саклана. Саргайган кәгазьдә мондый юллар: «Төркмәнстан ССРның Эшче, Деһкан һәм Кызылармеец депутатлары Советының Үзәк Башкарма комитеты 1932 елның 11 февралендәге утырышында карар итте: басмачылык хәрәкәтен тар-мар итүдә, Караком төбәкләрендә социалистик төзелешне өзәргә омтылган бай феодаллар катлавына каршы көрәштә актив катнашуы һәм пролетар революциягә җаны-тәне белән бирелгәнлеге һәм ныклыгы өчен 82 нче полкның эскадрон политругы Җәлилов Ибраһим Мостафа улын костюмлык тукыма һәм Коровин системасындагы револьвер белән бүләкләргә».

Пролетариат эшенә бирелгәнлек... Бу сыйфат Ибраһим Җәлиловта бик яшьтән күренә, аны тормыш үзе революцион рухта тәрбияли. Унҗиде яшьлек Ибраһим туган авылында укытучы була, ярлы балаларына белем бирә. Ул үз заманы өчен укымышлы егет булган, авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң Оренбург шәһәрендәге Хөсәеновлар мәдрәсәсе — «Хөсәения»дә дә ике ел укыган. Балаларга өйрәтерлек гыйлеме, аларны тәрбияләрлек сәләте бар. Укучылар аны ярата, авыл халкы үз итә, якын күрә. Ул үткәргән дәресләргә еш кына яшьтәшләре кереп утыра, картлар да килә. Ибраһим Октябрь турында, революция юлбашчысы Владимир Ильич Ленин хакында сөйли, аның һәр сүзе авылдашларының күңеленә сеңә. Мөгаллимнең уйлары киләчәккә дә төбәлгән, ул аны матур, якты итеп күрә. Хыяллары тыңлаучыларны да яңа тормышка ашкындыра, шуның хакына бүген барган көрәшкә кушыларга өнди...

Бу дәресләрдә укытучы абыйсыннан дүрт яшькә кече Муса да утыра. Ибраһимның революция турындагы сүзләре, киләчәк якты тормышны күз алдына китерүе — барысы да мавыктыргыч, кызыклы, күңел җилкеткеч. Яшьләрне шулай уйландырып, дәртләндереп, мөгаллим аларны революция казанышларын яклаучылар сафына басарга өнди. Мусага да, тәгаен, шулар юл ачкандыр, шулар аны Оренбургтагы хәрби-партия мәктәбенә алып килгәндер. Нәкъ шул вакытларда, энесе белән сөйләшкән чакта, Ибраһим аңардан:

— Киләчәктә ничек яшәргә уйлыйсың, Муса, тормыш идеалың нинди? — дип сорый.

Әтиләре 1919 елда тиф авыруыннан үлгәч, гаиләдә өлкән ир-ат булып калган Ибраһим энесенең нинди юлдан китәргә җыенуын белергә тели. Аның соравына Муса капылт кына җавап бирми, беравык уйланып тора, әчке бер ышаныч белән, тирән мәгънәле итеп:

— Үлгәннән соң да яшәрлек булып яшәргә телим мин, абый, — ди.

Ибраһим аның күңелендә нинди уй-хисләр дөрләвен яхшы аңлый. Мостафа авылындагы бик күп яшьләр шикелле үк, Муса да Совет властеның арка таянычы булачак, ул инде моңа әзер диярлек.

Революция казанышларын саклау өчен ул, кирәк булса, тормышын да кызганмаячак, үлем дә куркыта алмаячак аны. Энесенең шундый булуына Ибраһим әйтеп бетергесез сөенә.

1921 елда Ибраһим үз язмышын Зөбәйдә исемле бик чая һәм сөйкемле кыз белән бәйли, алар өйләнешә. Ике яшьнең туен котлап, Муса шигырь яза.

> **Түзә алмабыз, кара кан да коярбыз —**
> **Басарбыз, киртәләргә бирмәбез юл;**
> **Теләсәләр, асарлар — без үләрбез,**
> **Ләкин һичбер вакытта булмабыз кол!**

Болар инде яшь шагыйрьнең идея-политик кыйбласы нинди булуын ачык белдереп торган юллар.

Әйе, бертуган Җәлиловлар революциянең тулысынча җиңүе, Совет властен ныгыту өчен барган аяусыз көрәшнең авырлыкларына беркайчан бирешмәделәр. Аларның һәркайсы гомерләрен шул көрәшкә багышлады һәм, бөтен кыенлыкларны җиңеп, ил алдындагы гражданлык бурычын намус белән үтәде.

## Бүре ядрәсе

Ибраһим аганың күңелендә, хәтерендә күп нәрсәләр саклана. Аның гомер юлы — олы бер тарих, һәм ул башыннан ахырынача ил тормышына тоташкан.

Гражданнар сугышы тынып килә. Уфа, Оренбург, Уральск акгвардиячеләрдән азат ителә. Бу якларның халкы, ниһаять, иркен сулыш ала һәм, җиң сызганып, тыныч хезмәткә керешә, җир сөрә, иген игә, хуҗалыкны торгыза, Совет властен ныгыта.

Әмма гражданнар сугышы кырларында тар-мар ителеп бетмәгән кара көчләр дә тик ятмый. Аларга кулаклар булыша. Алтыннан кыйммәтрәк ашлык салынган келәтләр яна, тимер юллар зарарлана, күперләр шартлый, коелар агулана... Олы юлларда промышленность үзәкләрендәге эшчеләргә ашлык илтүче обозларны талыйлар...

Контрреволюция калдыкларының бу явыз эшләрен бик тиз арада чикләргә кирәк. һәр авыл Совет властен саклап калу өчен барган сыйнфый көрәшнең алгы сызыгына әверелә. Шундый хәтәр чакта Ибраһим үз авылларында комсомол ячейкасы оештыра, аның беренче секретаре була. Оешма члennарыннан бер төркем яшьләр ул чорда хәрәкәт иткән махсус частьлар — ЧОН составына кушыла. Мостафа авылында да алар зур эш башкара.

— Советларны тыгындырырга дип урган урагым юк. Кем дә кем минем йортыма ашлык эзләргә керә икән — белсен: маңгаен бүре ядрәсе җимерәчәк! — авыл кулакларыннан берсе авылда икмәк җыючы ЧОН отряды членнарын шулай кисәтеп куя.

Ибраһим да, аның иптәшләре дә яхшы белә: кулакның яшерелгән ашлыгы бар. Комсомол штабы шуны табарга һәм шәһәргә озатырга карар итә.

Кулак өенә башлап Ибраһим берүзе керергә була — шулай килешәләр. «Бөтен авыл ихтирам иткән мөгаллим белән капйот та шикләнмичә сөйләшер, бәлки», дип өметләнә егетләр.

— Аю өенә кергәндә сак булырга кирәк,— дип киңәш итәләр аңа.

— Борчылмагыз! — Комсомол секретаре аларны тынычландырырга тырыша.

Кулак ерткычларча ташланса да, Ибраһим югалып калмаячагына ышана. Сабан туйларында көрәштә бил бирмәгән егет лабаса! Хуҗаның бер карашыннан ук хәлне чамалар, кирәген эшләр.

Капка шыгырдап ачылуга, эт өрергә тотына. Чылбырын өзәргә җитешеп ыргылган эткә игътибар итмичә, Ибраһим эчкә үтә. ЧОН отряды комсомоллары — типсә тимер өзәрдәй егетләр — урамда сигнал көтеп кала. Кинәт кулак йортының тәрәзәләрен зыңлатып, өй эчендә мылтык шартлый. Урамдагы егетләрнең йөрәге жу итеп китә. «Ибраһимга аттылар!..» Барысы да дәррәү кубып, ишегалдына йөгереп керә.

Исән икән!.. Комсомолларны ул бусага төбендә каршылый. Кулында — ике көпшәле мылтык. Кулак идәндә бөгәрләнеп ята. Мылтыгын төбәргә өлгергәнче, Ибраһим

аны кулыннан борып алган да идәнгә аударган. Бүре ядрәсе өй түшәменең киң нарат тактасын чәрдәкләгән.

Яшерелгән ашлыкны егетләр бик тиз эзләп таба. Бәрәңге бакчасында үткән елдан калган сабаклар өемен актаргач, базга юлыгалар. Аны ачсалар — гәрәбәдәй бодай! Ике ат белән көн буе ташырга җитә...

Кулакларның ашлыкны болай яшерүе комсомоллар өчен сер түгел. Дошманнарның уй-ниятләре билгеле бит: «Чересә чересен, әмма Советка булмасын!» Яңа тормышны шулай җимерергә тырыша алар. Өмете суга сәнәк белән язылган булса да, сыйнфый дошман иске тәртипләрне кайтарырга тели.



## Идеалларга турылыклы

Памирда һәм Караком чүлендә хәрәкәт иткән басмачылар да шундый ук ният белән совет властена каршы корал күтәрә.

Бу якларга Ибраһим 1924 елның апрелендә килә. РКП(б) Үзәк Комитетының коммунистларны Кызыл Армия сафларын тулыландырырга чакыруына җавап итеп, ул, үзе теләп, өстенә солдат шинеле кия. Политик яктан җитлеккән сугышчы, дүрт еллык партия стажы булган Ибраһимны командирлар бик тиз күреп ала. ЧОН отрядларында чыныккан, авылда партия ячейкасына җитәкчелек иткән, аннары волость башкарма комитеты секретаре һәм Шарлык райкомы инструкторы булып эшләгән Җәлилов сугышчылар арасында зур политик эш алып бара.

Ул көннәр — киеренке һәм хәтәр. Басмачыларга каршы көрәштә уяулык, кételмәгән хәлләргә һәр вакыт әзер тору, куркусыз һәм акыл белән эш итә белү кирәк. Ибраһим Җәлилов — мондый сыйфатларга ия кеше. Аның революция, Ленин партиясе турындагы сүзләре кызылармеецлар рухын күтәренкелек белән өретеп тора. Катлаулы мәсьәләләрне дә гади итеп аңлата белер ул, сугышчыларны дошманга каршы көрәштә нинди хәлдә дә аптырап калмаска өйрәтер.

Озакламый Ибраһим Җәлиловны эскадрон политругы итеп билгелиләр. Шул хезмәтендә инде ул үзен оста тәрбияче, коммунистлар партиясенең зирәк политикасын оста аңлатучы агитатор һәм канлы бәрелешләрдә куркусыз солдат булуын күрсәтә. Командование аңа берничә мәртәбә рәхмәт белдерә, кыйммәтле бүләкләр бирә.

1927 елның җәендә ул хезмәт иткән частьтан политруклар хәзерләү мәктәбенә җибәрү өчен кешеләр билгеләгәндә, беренче итеп аның исеме телгә алына.

Хәрби курста уку Ибраһим Җәлиловның киләчәк тормыш юлын билгели. Аның шуннан соңгы хезмәте, пропагандист һәм политик җитәкче буларак, кызыл сугышчыларны тәрбияләүгә багышлана.

Ибраһим Җәлилов — үзенең бөтен рухы, җаны-тәне белән интернационалист. Ул коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасын яхшы аңлый, аны тормышка ашыруда Төркмәнстан, Кыргызстан территориясендәге җирле совет һәм партия оешмаларына булыша. Монда яшәүче халыкларның гореф-гадәтләрен яхшы белүе дә аңа зур булышлык итә. Үзбәкләр, кыргызлар, төркмәннәр белән Ибраһим бик тиз аралаша, уртак тел таба һәм аларның һәркайсына совет властеның максатларын ачык итеп аңлата белә. Аның бу эшчәнлеге дә командование тарафыннан күп тапкырлар билгеләп үтелә.

Эскадрон политругы сүздә дә, эштә дә — һәр нәрсәдә үзенең Октябрь идеалларына турылыклы булуын раслый. Аның политик белемнәре нигезле, кешеләр белән аралашу культурасы югары. Ул рус әдәбиятын яхшы белә, татар әдипләренең әсәрләрен яттан укый, Көнчыгыш язучыларының бик күп язмалары белән таныш була. Тарихны да төпле өйрәнгән. Болар барысы да аның абруен күтәрә. Ибраһим Җәлиловны полк мәктәбенә политрук итеп күчерәләр. Монда инде ул — командир да, укытучы да. Тиздән аны 8 нче дивизиянең кыргыз кавалерия полкына пропаганда инструкторы итеп күтәрәләр. Кая гына җибәрмәсеннәр, Ибраһим Җәлилов командованиенең ышанычын аклый, сугышчылар арасында политик эш алып баруда зур осталык күрсәтә.

# Халык бәхете өчен

Туган илебезгә фашист өерләре ябырылгач, Ибраһим Җәлилов та яуга китә. Икенче Белоруссия фронтында хәрәкәт иткән частьларның берсендә рота командиры була.

Сугышкача елларда ул — укытучы. 1936 елда хәрби хезмәттән кайтып, Кыргызстандагы Югары коммунистик авыл хуҗалыгы мәктәбендә җәмгыять белеме укыта, үзе дә экстерн тәртибендә педагогия институтын тәмамлый. Тагын да зуррак белем, олырак тәҗрибә һәм тыелгысыз дәрт белән эшли башлаганда гына — сугыш! Ибраһим Җәлилов фронтка, ут эченә ашкына. Аларның дивизиясе, дошманны кыйный-кыйный, көнбатышка омтыла. Өлкән лейтенант Җәлилов ротасы канлы бәрелешләрдә күп тапкырлар катнаша һәм һәр вакыт җиңүче булып чыга. Коммунист командир сугышчыларны хәрби осталыкка да өйрәтә, иң кирәкле сүз белән аларның күңеленә дә үтеп керә һәм атакаларга беренче булып үзе күтәрелә. Ялкынлы сүзе белән Ватанга турылыклы булырга чакырса, куркусызлык үрнәге белән җиңүгә рухландыра. Татар халкының «Ир егет үзе өчен туа, иле өчен үлә» дигән сүзләрен сугышта бик еш искә төшергән Ибраһим Җәлилов. Анда бит бер җиңү дә югалтусыз килми, туганың кебек газиз булган сугышчан дусларыңны җуясың. Сугыш үткән юлларда күпме туганнар кабере кала!..

Әйе, «Илем өчен!» дип яшәгән кеше, кирәк чагында, ил хакына үлемгә дә керә. Коммунист һәм командир Ибраһим Җәлилов сугышчыларына шул кырыс хакыйкатьне телдән генә түгел, кан койгыч һөҗүмнәрдә үзенең шәхси батырлыгы белән дә аңлаткан.

Ибраһим ага Җәлиловның күкрәгендә Ватан бүләкләре — орденнар һәм медальләр балкый. Алар илгә турылыклы ирнең сугышчан батырлыгын зурлап бирелгән.

Бер тапкыр яралана Ибраһим — госпитальдән дәваланып чыгуга, яңадан фронтка кайта, икенче яралана — җәрәхәтләре төзәлүгә, кабат сугышка ыргыла. Тик өченче ярадан соң гына хәрби врачлар аны өйгә кайтарып җибәрә. Офицер шинелен чөйгә элеп куярга туры килә. Яралар әрнесә дә, Ибраһим Җәлиловның рухы нык, җаны тынгысыз. Ул яраткан хезмәтенә кайта.

Сугыш еллары — Кыргызстандагы югары уку йортларында тәҗрибәле укытучылар җитмәгән чак. Фронттан кайткан офицер педагогия институтында партия тарихы укыта, марксизм-ленинизм нигезләре кафедрасына җитәкчелек итә. Соңыннан Фрунзе политехник институтында КПСС тарихы кафедрасында эшли, шуннан аны, зур хөрмәтләр күрсәтеп, ялга озаталар.

Ибраһим аганың Кыргызстан югары уку йортларындагы хезмәтләре дә югары бәяләнде. Республиканың Верховный Советы Президиумы аны берничә Мактау грамотасы белән бүләкләде. Күренекле педагогның күкрәген бизәгән сугышчан орденнар янына тагын «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале дә өстәлде. Алар Ибраһим Җәлиловның тыныч хезмәттә ил хакына куйган тырышлыгын зурлый, халык бәхете өчен көрәшкә багышланган гомернең матурлыгын раслый.

Хөрмәтле ялга чыкса да, Ибраһим аганың кул кушырып утырган көне юк. Октябрь солдаты, Бөек Ватан сугышы ветераны һәм педагог һаман яшьләр арасында, һаман тәрбия эшен дәвам иттерә. Техник училищеларда, мәктәпләрдә укучылар, югары уку йортларында студентлар белән очрашулар үткәрә, аларга бүгенге тормышыбызның матурлыгы, илебезгә Октябрь биргән җимешләр турында сөйли. ЧОН отрядларында көрәшкән дусларын искә ала, Урта Азиядә совет властен яклап кан койган сугышчыларны яд итә, Ватан сугышында арысландай сугышкан солдатлар һәм командирларны хәтергә төшерә. Үзе турында тел тибрәтми, илебез узган юллар, халкыбыз яулаган җиңүләр турында сөйли.

— Безнең буын узган юллар — илебез тарихында,— ди ул. Болай әйтергә хакы, нигезе бар аның.

— Ибраһим Мостафовичның укучы яшьләр белән очрашуларында сөйләгән сүзләре — тәрбия китабына алтын хәрефләр белән язарлык,— диде безгә республика

министрлыкларының берсендә эшләүче Таң Абдуллаевна Хәерова.— Аның гомер юлы ил тарихыннан аерылгысыз. Ул тарихның һәр сәхифәсе безнең яшьләребез өчен аеруча кадерле...

Чыннан да, давыллы елларда яшьнәп яшәде, хәтәр чакларда илгә терәк булды безнең Ибраһим агабыз.

Муса Җәлил үзенең бер шигырендә, яшәү мәгънәсе турында уйланып:

**Эзе калсын керсез намусыңның,**
**Ни узса да синең кулыңнан,**

— дип язды.

Ибраһим Мостафович Җәлиловның намус эзе тормыш юлында балкып тора.

**А. ГАЛИЕВ,**
**Фрунзе политехник институтының политэкономия кафедрасы доценты.**
**В. МАКСИМЕНКО,**
**КПСС тарихы кафедрасының өлкән укытучысы.**



# ҖӘЛИЛНЕҢ САБАКТАШЫ

**1920** ел. Оренбург яклары акгвардиячеләрдән тулысынча азат ителүгә, җирле совет органнары халык хуҗалыгын торгызырга, мәгариф эшен юлга салырга керешә. Партия милли кадрлар тәрбияләүгә зур игътибар итә. Шуның бер чагылышы буларак, элеккеге «Хөсәения» мәдрәсәсе татар халык мәгарифе институты итеп үзгәртелә.

Имәнгул авыл мәктәбен тәмамлаган Гайшә Мөхәммәдиева 1921 елда шушы институтка укырга керә. Нәкъ шул елларда ук монда яшь шагыйрь Муса Җәлил дә укый. Ул — институттагы җәмәгать эшләрендә башлап йөрүче, комсомол оешмасының «күз өстендәге кашы».

Муса Җәлил бик күп яшьләрне тынгысыз комсомол эшчәнлегенә тарта. Яшь шагыйрь оештырган үзешчән сәнгать түгәрәгенә Гайшә Мөхәммәдиева да йөри, кичәләрдә шигырьләр укый.

Гайшәнең әтисе Камал ага Мөхәммәдиев укытучылык иткән, башта — авылда, соңыннан Оренбург шәһәрендәге мәктәпләрнең берсендә рус теле һәм әдәбияты укыткан. Өендә шактый зур китапханәсе булган, анда рус һәм татар язучыларының китаплары, Көнбатыш һәм Көнчыгыш классикларының әсәрләре тупланган. Гайшә шул китапханәдәге әсәрләрне укып, алардагы рухи хәзинәне үзләштереп үсә.

Татар халык мәгарифе институтында укучы яшьләр еш кына Мөхәммәдиевлар квартирына җыелып, китап укыйлар, фикер алышалар. Үзешчән сәнгать түгәрәгенең репетицияләре дә шунда үткәрелә. Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнәләр, җырлар җырлыйлар. Шулай итеп, Мөхәммәдиевлар өендәге очрашулар үзеннән-үзе әдәбият-сәнгать кичәсенә әверелеп китә. Студентлар арасында шигырь язып каләм тибрәтүче яшьләр дә, матур итеп җырлаучылар да, нәфис сүз яратучы һәвәскәрләр дә ачыла.

Муса Җәлил мондый мәҗлесләрнең түрендә булган, билгеле. Ул үзе язган шигырьләрне укый, иптәшләрен яңа җырлары белән таныштыра. Аларны яшьләр шундук ятлап ала, күмәкләшеп җырлый.

Ул елларда татар егетләре һәм кызлары арасында мандолина бик популяр булган. Гайшә ханым Мусаның бу инструментта оста уйнавын хәтерли. Ул үзе дә мандолинада яхшы уйнаган. Татар халык мәгарифе институтының актлар залында үткәрелгән кичәләрдә студентлар аларның чыгышларын яратып тыңлаган.

Институтның комсомол ячейкасы ул елларда төрле кичәләр, диспутлар, үзешчән сәнгать концертларын еш үткәрә. Бу чыгышларда, гадәттә, кыллы оркестр уйный. Ут йөрәкле Муса аларны оештыруда ялкынланып йөри. Концертны да алып барыр ул, сәхнәдән шигырь дә укыр, кыллы оркестрда мандолинаны да соклангыч итеп чиертер. Студент яшьләр шуңа аны ярата, корыч бөртекләре магнитка тартылгандай, барысы да аңа елыша.

«Муса без башкара торган бөтен эшләрнең башы да, җаны да иде,— дип искә төшерә Гайшә ханым Мөхәммәдиева.— Культура-масса эшләрен, концерт-кичәләрне аңардан башка үткәрүне без күз алдына да китермәдек».

1923 елда Муса Казанга китә, рабфакка укырга керә. Оренбургтагы халык мәгарифе институтында калган яшьләр аның белән элемтәне өзми, хат язышып тора. Ә җәйге каникул вакытларында Муса туган авылына кайта. Шул чаклар инде яшьләр өчен бәйрәмгә әверелә. Алар бик еш очраша. Институтта бергә укып йөргән көннәрне искә төшереп, гадәттә, әдәби кичәләр үткәрәләр, шигырьләр укыйлар, җырлыйлар һәм, әлбәттә, мандолина чиертәләр...

Муса Җәлил киңәше белән Гайшә Мөхәммәдиева 1925 елда Казанга укырга китә. Күңеле күбрәк тарткан уку йортына — медицина техникумына керә. Җәлил, исә, рабфакны тәмамлап, Оренбургка кайта һәм комсомолның тынгысыз эшенә чума. Башта Орскида, аннары Оренбургта эшли. Тагын ике елдан инде ул — Мәскәү дәүләт университетының әдәбият бүлеге студенты.

Гайшә Мөхәммәдиева, медицина техникумын тәмамлап, туган якларына кайта. Шагыйрь белән бүтән очрашмаса да, аның күңелендә комсомолец Җәлил кабызган рухи яктылык һәм балкыш гомер буе сүнми-сүрелми. Гайшә ханым, яшьлегендә бергә укыган Муса шикелле үк, җәмәгать эшләрендә ялкынланып, зур дәрт белән эшли, гражданлык бурычын фидакарь үти. Сугыш вакытында ул — медицина өлкән лейтенанты — Оренбургтагы госпитальләрнең берсендә хезмәт итә. Шунда оештырылган санитар-инструкторлар курсында йөзләрчә хатын-кызларны үз һөнәренә өйрәтә, алар шәфкать туташлары булып фронтка китәләр. Яралыларга булышканда Гайшә Мөхәммәдиева үз-үзен аямыйча эшли. Ул елларда аның исеме госпитальнең Мактау тактасыннан төшми.

1944 ел. Кышкы зәмһәрирләр. Төннәрнең берсендә эшелоннан яралы сугышчыларны ташыганда, берничә тәүлек буе ял-йокысыз эшләүдән хәлсезләнеп һәм бик каты туңып, Гайшә Мөхәммәдиева аяктан егыла, һушыннан яза. Соңгы чиккәчә яралыларны кайгырта медицина өлкән лейтенанты. Шундый фидакарьлеге өчен ул берничә медаль белән дә бүләкләнгән.

Гайшә ханым Мөхәммәдиева 1961 елдан бирле хөрмәтле ялда. Врачлар кушуын тыңлап күченеп килгән шәһәрдә — Наманганда яши. Монда ул мәктәп укучылары, студентлар, эшче яшьләр белән очрашуларга йөри. Бу очрашулар аңа моннан күп еллар элек Оренбургтагы татар халык мәгарифе институтында үткәрелгән шау-шулы, истәлекле кичәләрне искә төшерәләр. Гомергә онытылмаслык Муса Җәлил белән очрашуларын сөйли. Шагыйрьнең аңа Казаннан язган күп кенә хатлары да бар. Муса Җәлилнең китапларында басылып чыксалар да, Гайшә ханым аларның төп нөсхәләрен изге истәлек итеп саклый.

Гайшә Мөхәммәдиевага илебезнең төрле өлкәләреннән хатлар бик күп килә. Яшь җәлилчеләр патриот шагыйрьнең тормыш юлын яхшырак белергә телиләр һәм бетмәс-төкәнмәс сорауларын яудырып кына торалар. Гайшә апа аларның барысына да җавап яза. Аның һәр хаты — Муса Җәлилнең яшьлеге турында язылган җанлы хикәят, күңелнең иң түрендә саклаемган онытылмас хатирә.

**ИСХАК ЗӘБИРОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**
**Ташкент шәһәре.**

# ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫН ИТЕП...

## ЮЛЬЯЗМА

**Китә казлар, китә казлар,**
**Китә казлар Себергә;**
**Кер, газиз башым, кабергә,**
**Рәхәт күрмәдең бер дә.**

*Борынгы татар халык җыры.*

**Омски да безнеке,**
**Тарски да безнеке;**
**Себер белән куркытмагыз,**
**Себер үзебезнеке.**

*Себер татарлары җыры.*

Ижевск шәһәренә без җиденче сентябрьдә иртән сәгать алтылар тирәсендә килеп төштек. Г. Камал исемендәге академия театры артистларының Урал һәм Себер калаларында үтәчәк гастрольләре шунда башлана. Гастрольләр кырык көнгә сузылачак һәм безнең соңгы спектакльләр чорыбызның гигант төзелеше — БАМның үзәге Тында шәһәрендә куелырга тиеш. Юлыбыз шактый озын буласы. Ләкин без — күнеккән халык. Юл дигәнебез озын булсын, истәлекле булсын. Шулай яхшы. Андый юлга чыгарга ашкынып тора артистлар. Югыйсә, без бит әле дүрт кенә көн элек КамАЗда бер айлык гастрольдә булып кайттык. Бөтенебез әле анда алган тәэсирләрне кичереп яшибез. Ә хәзер Урал һәм Себер аша БАМга юл тотабыз. Димәк, дөньяны шаулаткан удар төзелешләренең бер төбәгеннән — икенчесенә.

Анысы шулаен шулай: безгә юлда күп йөрергә туры килә. Ләкин мондый ерак һәм җаваплы сәфәргә безнең әле беренче тапкыр чыгуыбыз. Бөтен илнең күз карашы төбәлгән БАМга бару, әлбәттә, һәрберебезнең күңелендә җаваплылык хисе белән бергә чак кына каушау, дулкынлану хисе дә тудырды дисәм, мөгаен, ялгыш булмас.

Ижевск шәһәрендә ике көн уйнадык. Безнең репертуарда ике спектакль: К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы һәм Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» музыкаль комедиясе. Театрыбыз бу шәһәрдә еш була. Монда безнең үз тамашачыбыз бар, гастрольләр дә биредә һәрчак уңышлы үтә. Соңгы тапкыр без монда ике ел элек кенә булып киткән идек, шул вакыт эчендә шәһәрдә яңа культура йорты җиткергәннәр. «Металлург» дип атала. Зур, матур, якты. Зәвык белән, тамашачыларның бөтен таләпләрен канәгатьләндерерлек итеп төзелгән.

Свердловск шәһәренә самолетта очасы. һәм, гомумән, алдагы юлыбыз гел самолетта үтеләчәк. Ижевскидан самолет иртәнге сәгать дүрттә китә. Ләкин безгә вәгъдә ителгән автобус вакытында килеп җитмәде (дөресрәге, нигәдер бөтенләй килмәде). Кыскасы, без мең төрле мәшәкать белән аэропортка килеп җиткәндә билетларга регистрация беткән, самолет инде моторын кабызган, пропеллерлар бөтен көчләренә әйләнәләр иде. Ләкин самолет әле җирдән күтәрелмәгән бит. Шулай булгач... без тиз генә диспетчерскийга: «Зинһар, самолетны тоткарлагыз. Без БАМга. Без махсус бригада» һ. б. һ. б. Ничек итсәк иттек, самолет моторын сүндерде. «Хәерле булсын, — диде диспетчер, — аэропорт тарихында беренче тапкыр булган хәл: кабызган самолетны туктаттык. Ну, бу артистлар...»

Свердловскида безнең театр — көтеп алына торган кунак. Һәр килүдә бу шәһәрнең үсүен, матураюын тоясың. Бу юлы без данлыклы «Уралмаш» заводына оч-

рашуга бардык. Заводның кешеләре белән, аның тарихы белән таныштык. Легендар разведчик Николай Кузнецов сугышка кадәр шушы заводта эшләгән. Батыр разведчикны якташлары бүген дә зур горурлык белән искә алалар. Шәһәрдә бернечә спектакль уйнаганнан соң труппабыз Омск шәһәренә юл алды.

Без бу шәһәрдә беренче тапкыр. Дөрес, моннан утыз ел элек академия театры бу якларда булган. Ләкин аңа күпме вакыт үткән бит инде... Ничек каршылар-лар? Тамашачы спектакльләрне кабул итәрме? Бередә без дүрт көн уйнарга тиеш. Беренче спектакль ук инде күп сорауларга җавап бирер, беренче көннең уңышлы үтүенә күп нәрсә бәйләнгән. Бередә Татарстанның концерт бригадалары булганын белә идек, ләкин бит спектакль концерт түгел. Бәлки Омск тамашачысы татар телендә спектакльне беренче тапкыр карыйдыр?..

Ләкин безнең борчылулар урынсызга булган икән. Филармониянең концерт залы, бинаһая зур булуына карамастан, тамашачы белән шыгрым тулы иде.

Залда ут сүнеп, «Сүнгән йолдызлар» башланып китте. Дулкынланабыз. Сәхнә зур ансамбльләр, хорлар өчен исәпләп төзелгән һәм гадәти сәхнәләргә караганда ике тапкырга зуррак. Аның уртасына хәтта барып җитүе сине гаҗиз итә. Югыйсә мин — башкарган ролем буенча авыл егете — каз өмәсе күренешенә йөгереп диярлек килеп керәм бит.

С. Сәйдәшевнең «Каз канаты» көенә язган увертюрасы тамашачылар күңелен спектакль башында ук сихерләп куйды. Тамашачылар Сәрвәр, Исмәгыйль, Мәхдүм фаҗигасен үз йөрәге аша уздырып, алар язмышы өчен дулкынланып утырды.

Икенче көнне шәһәр белән танышабыз. Чиста, матур. Барыннан да бигрәк — яшеллеге мул. Шуның буенча ул союзда икенче урында икән.

Гражданнар сугышында һәлак булган каһарманнарның каберлегендә булдык. Колчакчылар тарафыннан җәзалап үтерелгән кызыл гвардиячеләр истәлегенә һәйкәл куелган анда. Ә һәйкәл төбендә — һәр вакыт тере чәчәкләр өеме. Гастрольләр тәмамланган көнне без спектакльгә, чемпион, гимнастка Галимә Шөгерованы чакырдык. Уку белән шөгыльләнгән чагы булса да (ул Омск физкультура институтын тәмамлый) — килде. Каршы алдык. Хөрмәтле урынга утырттык.

Чынлап та, экранда күргәнчә, искиткеч чибәр, тыйнак икән безнең Галимәбез. Башка тамашачылар белән бергә, спектакльнең башыннан ахырынача көлеп карап утырды «Диләфрүзгә дүрт кияү» спектаклен ул көнне.

Соңыннан ул безгә үзе турында, алдагы планнары турында сөйләде. Казанны күрәсе килүен әйтте. Казанда бер дә булганы юк икән. Без аны кунакка чакырдык. Ул Европа чемпионатына әзерләнә иде. Без аңа ихлас күңелдән уңышлар теләдек. Теләгебез, күрәсең, хәерле сәгатькә туры килгәндер, күп тә үтми, Галимә Испаниянең Мадрид шәһәрендә Европа чемпионы исемен яулады. Без театрдан аны котлап телеграмма җибәрдек.

...Прокопьевск — шахтерлар шәһәре. Анда безнең бик күп якташларыбыз эшли. Данлыклы шахтерлар алар — безнең якташлар. Күбесен гел мактап телгә алалар. Араларында Социалистик Хезмәт Геройлары да, Ленин ордены кавалерлары да байтак.

Беренче спектаклебезне Артем исемендәге культура сараенда уйнадык. Шахтер халкы — кыю, нык халык. Ләкин күңелләре нечкә икән үзләренең. Без моны спектакль барышында бик ачык сиздек. Фәрхи карчык Исмәгыйльнең колагына агу салырга җыенгач: «Тыңлама син аны, Сәрвәр. Аның үзен бәреп үтерергә кирәк!» — дип кычкырып куйды берсе залда. Кычкыручыны берәү дә шелтәләмәде. Күрәсең, аның кичерешләре башкалар күңелендәге хисләр белән тәңгәл килде.

Икенче көнне Ворошилов исемендәге шахтада шахтерлар белән очрашу вакытында без шахтага төшеп карарга теләгебез барлыгын белдердек. Читлеккә утырып, «җиде кат җир астына» төшүнең нәрсә икәнен үзебез тоеп, сынап карыйсыбыз килде. Ләкин без уйлаганча ансат кына эш түгел икән ул. Башта бик яхшылап инструктаж ясадылар. Шахтага төшкәч нәрсә эшләргә яраганын, нәрсә ярамавын аңлаттылар. Ниһаять, бөтен шартын китереп, чын шахтерлар кебек киендек. Тик Равил Шәрәфиевка ярарлык спецовка табылмады. Смена начальнигы — Равил кебек озын, гәүдәле шахтер — үз өстеннән салып бирде. Артисткаларыбыздан Н. Гәрәева белән Ф. Хәйруллина да шахтага төшә. Тәвәккәлләр икән. Һәм менә без шах-



*Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Прокопьевск шахтерлары янында.*

тада. Забойларга керәбез. Чынлап та, ни генә димә, якты җир өсте түгел инде бу. Күнекмәгәнгә дип әйтимме, күңелгә шик тула. Баш өстендә генә йөзләрчә метр калынлыктагы авыр тау-таш катламнары шомлы тынлык саклыйлар. Зеленодольск егете, проходчиклар бригадасы бригадиры Рәшит Хәялиев безне шахта белән таныштырып йөри. Мактаулы шахтер ул, Ленин ордены кавалеры, күкрәген өч дәрәҗә «Шахтер даны» орденнары бизи. «Якташыгыз белән горурланыгыз, ул — безнең шахтаның йолдызы», — диделәр шахтерлар аның хакында. Буйга-сынга бер дә пәһлеван түгел үзе, урта буйлы мөлаем генә егет. Ләкин хәрәкәтләре җитез, тере. Таныш шахтерлары алдында: «Карагыз, минем якташлар, Татарстан артистлары килде, кичкә безнең артистларны карарга килегез», — дип, балаларча куанып канатланып йөрде Рәшит.

Бу шәһәр белән аерылу хәтергә аеруча тирән уелып калды. Спектакль бетүгә, Фуат Әбүбәкеров җитәкчелегендәге кече форма оркестр һәм баянчы Рәис Сафиуллин С. Сәйдәшевнең «Совет Армиясе маршы»н уйнап җибәрделәр. Залга электр тогы үткәндәй булды. Бер мәл тынып калдылар, аннары көчле кул чабулар башланды. Алкыш көй беткәнче дәвам итте. Тамашачылар сәхнә алдына ук килеп бас-

тылар. Шахтерлар арасыннан: «Рәхмәт сезгә, тагын килегез!», «Татарстанга бездән сәлам җиткерегез!» дигән сүзләр яңгырады. Без аларның сәламнәрен Татарстан хезмәт ияләренә түкми-чәчми җиткерергә вәгъдә бирдек.

...Красноярск шәһәрен урталай бүлеп Енисей ага. Куәтле ага ул елга, ургып ага. Тикмәгә генә анда данлыклы Красноярск ГЭСы төземәгәннәр. Тарихи урыннарга да бай бу шәһәр. Безгә В. И. Ленинның сөргендә чакта яшәгән бүлмәсен күрсәттеләр. Тар, кысан, ләкин җыйнак бүлмә. Шул бүлмәдә ул үзенең иптәшләре, көрәштәшләре белән очрашкан. В. И. Ленинның Шушенскоедан Красноярскига күчкәндә утырып килгән кечкенә пароходы хәзер дә саклана.

Бу шәһәрдә дә без берничә спектакль уйнадык. Якташларыбыз белән очраштык, данлыклы «Красноярск баганалары»на күтәрелеп ерак офыкларны күзәттек.

...Октябрьның алтысында без инде Иркутск шәһәрендә идек. Менә бу шәһәрдә инде безнең театр беркайчан да булмаган. Без — беренчеләр. Себер үзен сиздерә башлады: безгә пальтоларны һәм җылы ботинкаларны алып кияр чак җитте. Иркутск шәһәре мәшһүр Байкал күленнән ерак түгел. Белеп җырлыйлар икән җырларда, Байкал — гаҗәеп матур күл. «Зәңгәр Байкал — Себернең йөрәге», дип куйды Флера Хәмитова, тәэсирләнеп.

Без, гадәт буенча, күлгә көмеш акчалар ташлыйбыз. Бу якларга әле тагын юл төшүен телибез, димәк.

Иркутскида без дүрт көн уйнадык. Зал көн саен тулы иде диярлек. Монда да күп икән безнең тамашачыларыбыз. Спектакль беткәч тә китеп торалар, автобуска утырып, гостиницага кайтып китмичә таралмыйлар. Без монда да танышларыбызны, якташларыбызны очратабыз. Равил Шәрәфиев белән минем хәтта авылдашыбыз табылды.

«Сүнгән йолдызлар» спектаклендә вакыйга элекке татар авылларының берсендә бара. Ул заманда Себер караңгы һәм салкын, күбесенчә каторжаннар, зимагурлар гына яши торган җир булып исәпләнгән. Спектакль барышында Фәрхи карчык Сәрвәрне: «Әгәр агу салганыңны кеше белсә, сине дә, мине дә, Исмәгыйльне дә Себер китә», — дип «куркыта» башлагач, залда көлешеп алдылар. Әллә бервребез ялгыш сүз ычкындырдымы дип, бер-беребезгә караштык. Баксаң, сәбәбе бик гади лабаса. Без бит бу спектакльне Себер тамашачылары алдында уйныйбыз! Тик Себер үзе генә ул чактагы Себер түгел икән. Промышленносте, культурасы нык үскән як ул, БАМ ягы. «Себергә сөрү» белән куркыту үзе үк көлке уята икән. Монда кешеләр шат, мул яшиләр, көр күңеллеләр.

«Гөлчирә» дигән романы Казанда басылган язучы Хәерниса ханым Сафина Иркутскида яши. Аның белән якыннан таныштык. Спектакльдән соң чәйгә алып китте. «По-ангарски» пилмәне белән сыйланып, шактый озак гәпләшеп утырдык.

Безнең гастрольнең максаты спектакльләр күрсәтү генә түгел, ә бу шәһәрләрдә яшәүче тамашачыларыбызны республикадагы яңалыклар, театрның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәккә планнары белән таныштырып үтү дә иде. Театрның директоры Ә. М. Хәсәенов моны һәркайда бик оста һәм җыйнак итеп, җиренә җиткереп башкарды.

Кайсы гына шәһәргә килеп төшмик, аларның җитәкче оешмалары, җәмәгатьчелек, җирле матбугат безгә бик игътибарлы булдылар, һәр нәрсәдә ярдәм күрсәтелде.

Казаннан безнең декорацияләр, костюмнар һәм башка кирәк-яраклар КамАЗ машинасына төялеп озатылган иде. Без шәһәрдән-шәһәргә самолет белән очканда, безнең КамАЗ үз йөреше белән бер урыннан икенчесенә чаба-чаба, Иркутскига кадәр килеп җитте. Һәм, әйтергә кирәк, юлда техник сәбәп белән берниндн дә туктальш һәм тоткарлану булмады. Ә бит анда юлларның төрлесе бардыр. Бу факт үзе үк КамАЗның нинди машина икәнен исбатлап, һәркемне бик куандырды.

... Менә, ниһаять, безнең иң төп максатыбыз. БАМ. Фидакарь хезмәтләре белән бөтен илне шаулатып, бөтен дөньяга танылып, гигант тимер юлын төзегән батырларга культура хезмәте күрсәтү теләге белән килдек без биретә.

БАМ турында күп укырга да, күпне ишетергә дә туры килгән иде. Ә үз күзләребез белән әле күргән юк: нинди икән соң ул? Кемнәр төзи аны? Биретә аяк басканда барыбызның да күңелен шушындый кызыксыну хисе тынгысызлый иде.

...Самолеттан төшәбез. Бөтен тирә-якта ап-ак кар, һава зәп-зәңгәр, көн кояшлы. Аэропорттан шәһәргә килешли юл буенда биек чыршылар, картаеп ауган зурзур агачлар күренә. Әйе, тайганың нәкъ эчендә утыра Тында. Шәһәргә керәбез. Ул әлегә әллә ни зур шәһәр түгел кебек. Элегрәк салынган бер катлы агач йортлар да күзгә чалына. Ләкин шәһәрнең нинди темплар белән үсүе күренеп тора. Иске өйләр янәшәсендә генә күп катлы биек йортлар, культура сарае, кунак йорты, биш катлы мәктәп калыккан. Кая карама — корылма, корылма...

Без кешеләр белән танышырга ашыгабыз. Кунакханәгә урнашу белән урамга чыктык. Иң элек шәһәрнең кызу хезмәт ритмы күзгә ташлана. Һәркайда хәрәкәт: кешеләр, бихисап санда техника, бульдозерлар. Кинәт кенә тормоз чыелдаган тавышка артыма борылдым. Янәшәмә кирпеч төягән үзаударгыч машина килеп туктады. Яшь кенә бер егет кабина тәрәзәсеннән башын чыгарды.

— Исәнмесез, Хәлим абый, әллә бүген театр куясызмы?

— Исәнме, энекәш. Шулайрак иде исәп. Татарстаннанмы үзең?

— Әйе, Казанның үзеннән. Әле гостиница янында үткәндә Әюпов абый белән Таҗетдинов абыйны да күреп киттем. Тик туктап исәнләшергә уңайсызландым. Артистлар килгән диген, вәт син, ә!

Егетнең артистларны күрүенә шатлануы да, гаҗәпләнүе дә йөзенә чыккан иде. Ул машинасыннан ук төште. Таныштык. Ренат исемле икән.

— Инде әллә кайчаннан бирле көтәбез, абый, афишаларыгыз күптән эленеп тора.

— Тормышлар ничек соң, Ренат? Казанны сагынмыйсызмы?

— Төрле чак була инде. Әле хәзергә гомум торакта яшим. Полный порядок!.. Ярый, абый, мин кузгалыйм әле — олау тик тормасын... Кичен культура сараенда очрашырбыз!

БАМда инде кыш. Ләкин без хәтәр Себер суыкларын татымадык. «Быел кыш кичекте, үткән ел бу вакытта салкынлык 40 градус иде», — диләр БАМчылар.

Кичен без культура сараенда БАМ төзүчеләре белән очраштык. Үзенең бүлмәдәш егетләре белән Ренат та килгән иде. Безнең якташларыбыз белән бергә залда башка милләт вәкилләре дә бар. Һәммәсе дә яшьләр. Артистларның чыгышыннан соң ВЛКСМның Тында шәһәр комитеты секретаре В. Муконин безгә рәхмәт сүзләре әйтеп грамоталар, истәлекле бүләкләр тапшыра. Гомергә онытылмаслык минутлар.

Икенче көнне безне БАМ музеена алып бардылар. Әле моннан берничә ел элек кенә оештырылса да, музей экспонатларга бик бай. БАМ тарихы белән танышабыз. Шунда сакланган бер хатка текәлеп озак кына сүзсез басып тордык. Аны утызынчы еллардагы фәнни-эзләнү экспедициясе җитәкчесе Александр Михайлович Кошурников язган: «3. XI. Мөгаен, соңгы тапкыр язуымдыр, өшим. Кичә 2/XI катастрофа кичердек. Костя белән Алеша һәлак булдылар. Сал батты, сал белән бергә Костя да боз астына китте. Алеша боз өстенә сикереп менде һәм бозлы су буйлап 25 метрга якын шуышып барды. Мин аңа ярга кадәр килеп җитәргә булыштым, ләкин яр өстенә алып менәргә хәлем җитмәде. Ул шулай суда килеш катып үлде. Мин җәяү барам. Бик авыр. Ач, бөтен өс-баш юеш, ут та юк, бер кавым ризык та юк. Мөгаен, бүген туңып үләрмендер».

Бу хат тетрәтте безне. Әнә нинди адымнар һәм сукмаклардан башлана Урал һәм Тын океанга хәзерге сикереш.

...Кич белән Могота поселогына килдек. Зал шыгрым тулы. Очрашу монда да күңелле бара. Артистларның һәр чыгышын көчле алкышлар күмә, аларны кабаткабат сәхнәгә чакырып чыгаралар. Сораулар, җаваплар... Очрашу өч сәгатьтән артыкка сузылды. Тагын рәхмәт сүзләре, хәерле юл теләүләр.

...БАМда соңгы көнебез — уникенче октябрь. Онытылмас истәлекләр, гаҗәеп тирән тәэсирләр белән баеп, Казанга юлга җыенабыз. Көн чалт аяз. Күзләрне чагылдырып ап-ак кар җемелди. Як-40 самолеты кызу тизлек белән югарыга күтәрелә. Аста иксез-чиксез тайга. Курс — көнбатышка, Казан ягына.

**ХӘЛИМ ҖӘЛӘЛЕВ,**

**Татарстанның атказанган артисты.**

≈≈≈≈≈≈

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Сәет Кальметов

## ДУСТЫМНЫҢ ФӘРЕШТӘСЕ

хикәя



Мин Билал исемле егет белән бергә армия сафында хезмәт иттем. Холкыбыз да бер төслерәк булганга күрә, бик тиз дуслашып киттек.

Солдаттан кайту белән Билал шәһәрдә, ә мин туган авылымда төпләндем. Дус итеп аны туйга чакырдым.

— Озакламый мин дә өйләнәм, сезне дә туйга чакырам, — дип вәгъдәсен бирде ул да.

Без аның туена барырга бик дәртләнеп тордык. Менә бер заман Билал дустан хат килеп төште. «Кәүсәрия исемле тол хатынга йортка кердем. Шулай булгач, туй ясауны килештермәдек. Кәләшем юаш, басынкы, фәрештә диярсең».

Тату яшәсеннәр! Котлау телеграммасы суктык. Бераздан сабан туйга чакырып хат салдык. Ләкин җавап килмәде. Шулай итеп, ара бераз суынды, элемтәбез үзелде кебек. Инде Билалны күрмәгәнгә өч ел тулып китте.

Күптән түгел, юк йомышны бар итеп, шәһәргә барырга булдым. Тукта әле, мин әйтәм, Билал дусның да хәлен белеп чыгармын. Күчтәнәчкә дип каз түшкәләре арасыннан иң зурысын сайлап сумкага салдым. Шәһәрдә йомышларымны башкардым да, ашкынып, Билал дуска юнәлдем. Ишекләрен шакыйм. Ачмыйлар. Әллә өйдә юклармы? Шулай аптырап торганда, өстенә затлы тун, башына мех бүрек кигән хатын күренде. Ул баскычтан мену белән, алтын тешләрен күрсәтәсе килгәндәй, елмаеп:

— Мин сезне күрү белән төсмерләдем. Солдатта Билал белән төшкән фотоларыгыз бездә бик күп, — дип, миңа кулын сузды.

Кәүсәрия сумкасыннан төрле зурлыктагы ачкычлар чыгарып, өч йозакка бикләнгән ишеген фокусчы сыман тиз генә ачып та җибәрде.

— Рәхим итегез! — диде ханым. — Тик менә Билал өйдә юк. Командировкага киткән иде.

Кәүсәрия ут кабызып чишенә башлады. Мин сумкамнан казны чыгардым да:

— Менә сезгә нәни генә күчтәнәч, — дидем.

Кәүсәрия ягымлы елмаеп кулына казны алды.

— Нәни генә, имеш... Торна хәтле ич бу. Рәхмәт яусын... Билалның туганнары күчтәнәчкә тавык тәпие дә китергәннәре юк. Авылдан кәтүләре белән килеп, сосып китәргә генә беләләр...

Ул суыткычны ачты да, казны урнаштырмакчы булды. Сыйдыра алмагач, балконга куярга итте. Шуннан соң гына, минем чишенми торганны абайлап, үзе килеп төймәләрне ычкындыра башлады. Бу инде китмә дигән сүз. Чишенгәч, нафталин исе аңкып торган залга уздым. Үзебезнең кибет складына килеп кердем дип торам. Ниләр генә юк иде монда! Шулай да китап-фәлән күренми. Бүлмәдә газета-журнал заты да юк. Монысы инде бигүк ошап бетмәде. Бераз пошынып диванга утырдым.

Менә Кәүсәрия гәүдәсенә сыланып торган чәчәкле халат киеп чыкты. Көзге алдына басып ясана-төзәтенә башлады. Билалдан биш-алты яшькә өлкәнрәк булса кирәк. Шулай да чибәр каһәр! Моны чыннан да фәрештә дисәң була. Үзе камыш кебек, кырмыска билле, көянтә кашлы. Тик менә күпереп торган калын чәчен сарыга манып харап иткән.

— Хәниф, гаеп итмәгез инде, зинһар, — диде бу бераздан. — Сезне бу юлы кунак итә алмам. Чөнки муеннан бурычка баттык. Бераүдән менә бу зур келәмне алган идек. Сигез йөз сум тора. Үзем кассир булып эшлим. Эш хакы да ташка үлчим инде.

— Зинһар, борчылмагыз.

— Бәлки сезгә мебель гарнитуры кирәктер, әмәлләрбез.

— Әллә Билал дус базада-мазарда эшлиме?

— Мин аны тәэминатчы итеп урнаштырдым. Урта белеме белән багана башына менеп йөрмәс бит. Монтер да булдымы эш...

— Менә монысы гаҗәп... Үлеп ярата иде бит ул эшен...

— Ир кеше иң элек хатынын яратырга тиеш, — диде ханым, янә алтын тешләрен ялтыратып. — Минем Билал — каз муены сыман, кая телим, шунда борам.

Аңлашылды! Кереп капкан икән егет... Фәрештәнең шәбен тапкан икән шул. Йөрәгем әрнеде, шулай да бу тәтәй ханыма күңелемдәген әйтә алмадым. Тизрәк урамга чыгып киттем.

... Икенче көнне кайтып китәр алдыннан базарга сугылдым. Әни мүк җиләге алырга кушкан иде. Шуны эзләп йөрим. Кинәт күзем бер сатучыга төште. Карале, Кәүсәрия ханым ич бу! Билалның фәрештәсе өстенә иске тун киеп, шакмаклы шәл бөркәнгән дә, мин күчтәнәчкә китергән казны (күтәргәндә җайлы булсын дип үзем бәйләгән тасмасын да алыштырып өлгермәгән!), әйе, шул казны сатып ята.

## Рамазан Шаһгалиев

# ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

●

Сүз башласаң, көтмәс сөйләп бетүеңне,
Көй башласаң, көтмәс көйләп бетүеңне.
«Тозсыз», дияр дә үз сүзен сөйли башлар,
«Моңсыз», дияр дә үз көен көйли башлар.

●

«Дошманнарым кабыгымнан таныйлар», — дип,
Елан ел саен тырышып кабык сала.
Төсе үзгәрсә дә танымаслык булып,
Явызлыгы үзгәрүсез торып кала.

●

Тырнак астыннан кер эзләп
Гомер итте.
Шул керләре хәзер үзен
Күмеп китте.

●

Алтын табак тәмләндерми
Тәмсез ашны.
Түрә булу ямьләндерми
Ахмак башны.

●

Бер танышым чебешләрне
Көзен түгел,
Язын санап гомер итә.
Көзен санар иде дә соң,
Аңа тиклем
Чебешләре үлеп бетә.

●

Эзләп-эзләп табалмагач
Сөзешкән үгезнең үзен,
Көтүдәге һәр үгезнең
Кисеп аттылар мөгезен.

*1978.*
*Чиләбе.*

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА

РСФСР Язучылар союзы правлениесе секретариатының утырышында Татарстан һәм Дагстан Язучылар союзларының яшь әдәби көчләр белән эшләү тәҗрибәсе турында җитди сөйләшү булды.

Башлап язучыларга һәм яшь талантларга игътибарлы караш — совет әдәбиятының бик яхшы традициясе. КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карарыннан соң әдәби алмаш үстерү мәсьәләсенә игътибар аеруча көчәйде. Бу яктан Татарстан Язучылар союзының эшчәнлеге РСФСР Язучылар союзы тарафыннан уңышлы дип табылды һәм аның тәҗрибәсе махсус тикшерелде.

Секретариат утырышында Татарстанда яшь талантлар белән эшләү турында ТАССР Язучылар союзы правлениесе председателенең урынбасары Илдар Юзеев сөйләде. Иҗат яшьләре белән ел саен республика семинарлары һәм зона конференцияләре үткәрелә, аларда уңышлы дип табылган әсәрләр коллектив җыентыкларда, «Идел» альманахында, газета-журналларда басылып чыга. Утырышта Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе Г. Ахунов, шагыйрь Ш. Галиев, Р. Бохараев һәм башкалар чыгыш ясады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТОЕШМАСЫНДА

19 февральдә үткәрелгән чираттагы җыелыш КПССның Бауман район, Казан шәһәр һәм Татарстан өлкә партия конференцияләре йомгакларын өйрәнүгә багышланды. Докладчы Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов коммунистларны партия конференцияләренең карарлары белән таныштырды һәм язучылар алдында торган мөһим бурычлар турында сөйләде. Эшчеләр сыйныфының бөек эшчәнлеген, баһадир образларын сәнгатьчә чагылдырырга, колхоз авылында барган зур үзгәрешләрне тулы канлы образларда гәүдәләндерергә, советча яшәү рәвешен калку итеп күрсәткән яңадан-яңа әсәрләрне язарга кирәк, диде. Безнең китапларыбыз бөтен союз күләмендә яңгырарлык булсын.

Балалар язучысы Л. Ихсанова, фикер алышуларда катнашып, яшь буынга атап языла торган китапларда әхлак тәрбиясенә игътибар итәргә өндәде. Башка язучылар да бу мәсьәләнең әһәмиятенә аеруча басым ясап әйттеләр. Язучыларның партия җыелышында катнашкан ТАССР Верховный суды председателенең урынбасары М. М. Мәүләтшин да әдәбиятның әхлак тәрбияләүдә зур роль уйнавын сөйләде, язучыларның төрле сорауларына җавап бирде.

## ТЕОРЕТИК СЕМИНАР

Безнең көннәрдә барган фәнни-техник революциянең әдәбият-сәнгать үсешенә йогынтысы гаять зур. Техника прогрессы кешеләрне дә үзгәртә, аларның рухи байлыкларын арттыра. Замандашлар образын иҗат иткәндә язучы бу күренешнең геройлар күңелендә нинди формаларда, ничек чагылуын сиземләми кала алмый.

Язучылар союзында даими эшләп килүче теоретик семинарның чираттагы дәресендә сүз нәкъ менә шул хакта барды. Анда «Фәнни-техник революция чорында культура үсеше һәм аның бурычлары» дигән темага докладларны «Казан утлары» журналының бүлек редакторлары Абдулла Сәләх һәм Әхәт Гаффар сөйләделәр. Фикер алышуларда Р. Мөхәммәдиев, Г. Латыйп, М. Галиев, М. Хәбибуллин, Д. Зөбәерова, Р. Ишморатова, Л. Ихсанова һәм башкалар катнашты.

## ЯЗУЧЫ — СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЫ

4 март илебездә СССР Верховный Советына сайлаулар көне иде. Ул көнне 645 нче Чистай сайлау округы хезмәт ияләре үз тавышларын язучыга бирделәр. Бу сайлау округыннан СССРның унынчы чакырылыш Верховный Советына депутат итеп РСФСР Язучылар союзы правлениесе секретаре, Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе **Гарифҗан Ахунҗанович Ахунов сайланды.**

## ФАТИХ КӘРИМНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

9 февраль көнне Казандагы Төзүчеләр культура сараена язучылар, журналистлар, әдәбият сөючеләр җыелды. Монда фронтовик-шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичә үткәрелде.

Гражданин, солдат, шагыйрь Ф. Кәримнең тормышы һәм иҗат юлы турында шагыйрь Илдар Юзеев сөйләде. Тантаналы кичәнең икенче өлешендә Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе һәм Казан театрлары артистлары зур концерт бирделәр. Юбиляр шагыйрьнең сүзләренә язылган җырлар, аның үлемсез шигырьләре яңгырады.

Тантаналы кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин иптәшләр катнашты.

## «КЫСКАЧА ӘДӘБИЯТ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ»НДӘ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

Мәскәүдә «Краткая литературная энциклопедия»нең соңгы — 9 нчы томы басылып чыкты. Аның беренче томы 1962 елда дөнья күргән иде. Бу әдәби белешмә-басманы «Большая советская энциклопедия» нәшрияты әзерләгән. Аның төрле томнарында татар әдәбиятына, татар язучыларына һәм аларның иҗатларына бәйләнешле 115 мәкалә-белешмә урнаштырылган.

Революциягә кадәр яшәгән һәм иҗат иткән әдипләрдән энциклопедиягә Мөхәммәдьяр, Г. Кандалый, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Гали Чокрый, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Я. Емельянов, Г. Ильяси, Ф. Халиди һ. б. язучылар — барлыгы 28 автор кертелгән, алар турында белешмәләр бар. Әдәбият тарихында зуруча зур роль уйнаган әдипләр турында белешмәләр шактый киң бирелә. К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, К. Нәҗми һ. б. хакындагы мәкаләләр авторларның рәсемнәре белән дә иллюстрацияләнә. Әдәбиятыбызның борынгы чорлардан алып хәзерге көннәргә хәтле тарихының төп моментларын шактый тулы чагылдырган зур күләмле мәкалә дә урнаштырылган. Аның авторлары — М. Х. Гайнуллин һәм М. Х. Хәсәнов.

Татар әдәбиятына караган материалларны энциклопедия өчен әзерләүдә күп кенә әдәбиятчыларыбыз, тәнкыйтьчеләребез катнашкан. Алар арасында А. Әхмәдуллин, Х. Хисмәтуллин, Х. Хөсәенова, Х. Хәйри, Б. Гыйззәт, А. Гумеров, М. Маһдиев, Р. Башкуров, Р. Мостафин, Л. Лебедева, Н. Юзиев, И. Нуруллин, В. Воздвиженский, А. Гыйниятуллина исемнәрен күрәбез. Бу өлешне әзерләүдә редактор-консультант вазифаларын исә профессор М. Гайнуллин башкарган.

## ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ТЕЛЕНДӘ

«Советский писатель» нәшриятында күренекле татар совет шагыйре, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең күләмле яңа җыентыгы әзерләнә. «Шагыйрь китапханәсе»нең зур сериясендә чыгачак бу басмага Муса Җәлилнең поэмалары һәм шигырьләре туплана. Җыентык патриот-шагыйрьнең киң колачлы иҗатын рус укучысына мөмкин кадәр тулырак җиткерүне күздә тота. Анда Муса Җәлилнең яшь чакта язган беренче шигырьләре дә, дөньякүләм дан казанган «Моабит дәфтәре» циклындагы әсәрләр дә урнаштырыла.

* * *

Мәскәүнең «Известия» нәшриятында (1978) «Избранные страницы. Поэзия 1939—1979» дигән китапның икенче томы басылып чыкты. «Дружба народов» журналының 40 еллыгына багышланган бу китапта, төрле милләт әдипләре белән беррәттән, татар шагыйрьләренә дә зур урын бирелә. Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Әхмәт Ерикәй, Сибгат Хәким, Зәки Нури шигырьләре басманың күп кенә сәхифәләрен били. Шагыйрьләребез әсәрләрен русчага А. Николаев, Р. Моран, В. Звягинцева, О. Дмитриев, Л. Хаустов, Н. Беляев тәрҗемә иткән.

* * *

«Современник» нәшрияты прозаик Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Чоңгыллар» («Водовороты») китабын бастырып чыгарды. Романны рус теленә Николай Нефедов тәрҗемә иткән.

* * *

Шул ук нәшриятта Әхсән Баяновның «Тау ягы повесте», «Яшьлегемне эзлим» һәм «Дүрт монолог» повестьларын берләштергән бер томлыгы русча «Повесть горной стороны» дигән исем белән чыгарылды. Әсәрләрне В. Федоровский һәм Н. Нефедов тәрҗемә иткән.

* * *

Мәскәүдәге «Советская Россия» нәшриятында ТАССРның Тукай исемендәге Дәүләт һәм комсомолның Муса Җәлил исемендәге премияләре лауреаты шагыйрь Р. Фәйзуллинның «Мой звездный час» дигән китабы басылып чыкты. Аңа кереш сүзне Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәрим язган. «Правда» газетасының быелгы 44 нче санында шул китапка шагыйрь Олег Шестинскийның рецензиясе басылды.

* * *

«Мысль» нәшриятында (Мәскәү) Ч. Г. Гусейновның «Формы общности советской многонациональной литературы» дигән хезмәте дөнья күрде. Китапта күп милләтле совет әдәбиятының эстетик проблемалары тикшерелә. Шул җәһәттән татар совет әдәбиятын анализлауга да зур урын һәм аңа югары бәя бирелә.

* * *

«Наука» нәшриятында «Советский роман. Новаторство. Поэтика. Типология» дигән зур фәнни хезмәт басылып чыкты. Китапка кертелгән С. Хитарованың «Роман системасында кеше һәм аның эше» исемле мәкаләсе күренекле татар язучысы Шәриф Камалның «Матур туганда» романына багышланган.

## «ЛӘЙСӘН» КОЛАЧЫН ҖӘЯ

Чаллыдагы «Ләйсән» әдәбият-сәнгать берләшмәсе члennары тарафыннан иҗат ителгән әсәрләр үзәк матбугатта һаман ешрак басыла башлады. Узган ел яшь шагыйрьләрдән Мәхмүт Газизов һәм Хәниф Хөснуллин шигырьләре В. Шленский тәрҗемәсендә «Новый мир» журналының 10 нчы санында дөнья күргән иде. Быел шул ук

авторларның шигырьләре «Волга» журналы сәхифәләрендә дә урын алды. Әсәрләре белән бергә, яшь язучыларның фоторәсемнәре һәм кыскача биографик белешмәләр дә бирелгән. Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинның былтыр «Современник» нәшриятында «Полет радуги» исемле китабы чыгу да (тәрҗемәчесе А. Зорин) «Ләйсән» берләшмәсе өчен шатлыклы булды. Үзәк нәшриятлар быел да «Ләйсән» берләшмәсе членнарының әсәрләрен бастырып чыгарырга әзерләнә.

## ӘТНӘ ХАЛЫК ТЕАТРЫНА 60 ЕЛ

1918 ел. Декабрь аенда укытучылар, партия һәм совет органнары хезмәткәрләре «Бәхет кошы» исемле ике пәрдәле спектакль куялар. Театр тарихы шулай башлана. 1968 елда театрның 50 еллыгы үткәрелә. Шул уңай белән ул Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнә. Өлкән артистка Галимә Сибгатуллинага һәм театрның режиссерына «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелә. Соңгы елларда халык театрының репертуары бик баеды. Т. Гыйззәтнең «Шомлы көннәр», «Чаткылар», М. Әмирнең «Хөррият», «Тормыш җыры», С. Шәкүровның «Туган туфрак», Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш», Г. Ибраһимов әсәре буенча әзерләнгән «Татар хатыны ниләр күрми», А. Гыйләҗевның «Көзге ачы җилләрдә» кебек әсәрләр аның сәхнәсендә зур уңыш белән бара. 1973 елда Әтнә татар халык театры коллективы Мәскәүнең А. С. Пушкин исемендәге драма театрында Ч. Айтматовның «Кызыл яулыклы чибәркәй генәм» повесте буенча куелган спектакльне күрсәтеп, икенче мәртәбә «Бөтенроссия смотры лауреаты» дипломына лаек булган иде.

## ОЧРАШУЛАР, КИЧӘЛӘР

Хөсәен Ямашов исемендәге Татарстан мех берләшмәсенең тулай торагында Совет Армиясе һәм Диңгез Флоты көненә багышлап шигърият кичәсе үткәрелде. Шагыйрьләрдән Разил Вәлиев һәм Фәннур Сафин поэзия сөюче яшьләргә бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

*

*   *

Язучы Самат Шакир Казан дәүләт педагогия институты студентлары һәм укытучылары белән очрашты, үзенең «Легенда егетләре» һәм «Һәйкәлдә чәчәкләр» повестьларының язылу тарихын сөйләде. «Легенда егетләре» повесте Бөек Ватан сугышының өч батыры — Х. Фәттахетдинов, В. Каменщиков һәм Рубен Ибаррурига багышланган. Сталинград сугышларында һәлак булган бу баһадирлар шәһәр үзәгендәге мәйданда туганнар каберлегенә күмелгән. Испания коммунистлар партиясе председателе Долорес Ибаррури «Легенда егетләре» авторы белән шунда очраша һәм соңыннан язучыга аның китабы турында хат яза.

*

*   *

«Казан утлары» журналының бүлек хезмәткәре Абдулла Сәләх һәм «Яшь ленинчы» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире Госман Садә Пермь өлкәсенең Октябрь районындагы татар авылларында булып, колхозчылар һәм мәктәп укучылары белән очраштылар. Тыңлаучылар һәр урында татар әдәбияты, сәнгате хакында, аерым язучыларның иҗат эшчәнлегенә караган бик күп сораулар бирделәр. Кичәләрдә А. Сәләх — яңа мәсәлләрен, Г. Садә шигырьләрен укыды.

*

*   *

Казан Яшьләр үзәгендәге китапханәдә язучы Юрий Белостоцкий 71 нче мәктәп укучылары белән очрашты. Элекке хәрби очучы, әсәрләрен дә авиаторларга багышлаган Ю. Белостоцкий китап сөюче яшьләргә Бөек Ватан сугышы елларында очучыларның тиңдәшсез батырлык күрсәтүен сөйләде.

*

*   *

Хәрби өйрәнүләр вакытында һәлакатькә очрап, хезмәттәшләрен коткарып калу өчен үз гәүдәсе белән гранатаны каплаган каһарман якташыбыз Рифкать Миргазизов турында газеталарда язылган иде. Шагыйрь Разил Вәлиев ул укыган һәм яшәгән Түбән Кама шәһәрендә берничә тапкыр булды, батыр солдат хезмәт иткән частька барып, аның хезмәттәшләре, командирлары белән очрашты, материаллар туплады. Күптән түгел аның Рифкать Миргазизовка багышланган документаль повесте тәмамланды. «Яшисе килә» дип исемләнгән бу әсәр Түбән Камадагы әдәби берләшмәдә тикшерелде. Батырның туган ягында повесть турында фикер алышу булды.

*

*   *

Февраль аенда тугандаш казакъ халкының күренекле шагыйре, прозаик һәм драматург, галим Әбдильда Тажибаевка 70 яшь тулды. Алма-Атада шул уңай белән үткәрелгән юбилей тантанасында катнашу өчен Казаннан шагыйрь Рәдиф Гатауллин барды. Ул юбилярны татар әдипләре исеменнән котлап, аңа истәлекле бүләкләр тапшырды.

## РӘССАМНАРЫБЫЗ КҮРГӘЗМӘЛӘРЕ

Бакуда «Совет Татарстаны рәссамнары» дигән зур күргәзмә булды. Әзербәйҗан дәүләт картина галереясында оештырылган бу күргәзмәдә республикабызда иҗат итүче 64 рәссамның йөздән артык әсәре күрсәтелде.

РСФСР һәм Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССРның һәм Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Лотфулла Фәттахов Баку тамашачыларына үзенең яшь Ульяновка багышланган «Уйлар» дигән

яна картинасын тәкъдим иткән. Рәссам Г. Д. Мелентьевның «Ана» дигән картинасында В. И. Ленинның әнисе Мария Александровна Ульянова образы гәүдәләндерелгән.

Республикабызның бүгенге казанышларын, замандашларыбызның күркәм образларын чагылдырган картиналарга зур урын бирелгән иде. М.Госмановның «Яңа кала», В. Кудельскинның «КамАЗ хатын-кызлары», В. Скобеевның «Беренче биеклек» әсәрләрен меңләгән тамашачылар яратып карады. Татарстанның атказанган художнигы В. Маликов, РСФСРның атказанган, Татарстан АССРның халык художнигы Бакый Урманченең скульптура әсәрләре тамашачыларның игътибар үзәгендә булды.

*

* *

Татарстан сынлы сәнгать музеенда рәссам С. Кузьминых әсәрләре күргәзмәгә куелган иде. Күренекле художник, татар халык сәнгатенең күп төрле мөмкинлекләрен өйрәнеп, соңгы елларда бик үзенчәлекле хезмәтләр башкарган — тукымага төшерелгән бизәкләр, күнгә язылган мозаика, палас-тукымалар, кул-чигү эшләре үрнәкләре һәм башкалар. Рәссам үз иҗатын татар милли орнаментларыннан файдалануга нигезләгән. Чигешле түрләмәләр, пәрдәләр, Казан сөлгеләре авторның иҗатын яңа бизәкләргә баеткан.

*

* *

Татарстан Художниклар союзында республикабызның атказанган сәнгать эшлеклесе В. Карамышевның күргәзмәсе үткәрелде. Анда художникның балалар өчен Татарстан китап нәшриятында чыгарылган китапларга ясаган графика әсәрләре куелган иде. Балалар китабын бизәү — бик үзенчәлекле сәнгать. Карамышев бу сәнгатьнең нечкәлекләрен һәм балалар психологиясен белеп эш итүче художник. Аның әсәрләрен өлкәннәр дә, яшь тамашачылар да зур кызыксыну белән карады. Художник тарафыннан Г. Тукайның «Су анасы» әкиятенә ясаган акварельләре бай фантазия белән язылган һәм алар игътибарны аеруча җәлеп итә.

## СЕНЕГАЛДА ТАТАР ҖЫРЛАРЫ

Күптән түгел генә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Сенегалда булып кайтты. Татарстан артистлары анда ике ил арасында культура казанышлары алмашу турындагы килешү нигезендә бардылар.

Ансамбль артистларының осталыкларына сокланып, үзәк газеталарның берсе — «Солей» «...ансамбльнең бу уңышы ике ил арасында үзара аңлашуга ярдәм итәр», дигән зур ышаныч белдерә.

*

* *

Мәскәүдәге «Фитиль» кинотеатрында Татарстанның сатирик рәссамнары Юрий Денисов белән Лотфи Насыйровның «Ниебары кырык рәсем» дигән күргәзмәсе 27 февральдә ачылды. Аны РСФСР Художниклар союзы, СССР Журналистлар союзы, «Фитиль» киножурналы редакциясе һәм «Крокодил» белән «Чаян» журналлары редакцияләре оештырды.

Ю. Денисов белән Л. Насыйров — республикабызда гына түгел, ил күләмендә танылган рәссамнар. Алар «Сатира тынычлык өчен көрәштә» дигән халыкара күргәзмәдә дә катнашканнар иде. Ике авторның да күп кенә хезмәтләре халыкара Дипломнар һәм Бөтенсоюз призлары белән бүләкләнгән.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм җитмеш яше тулу уңае белән язучы **Әмирхан Еники** (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникиев) СССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 1 март Указы нигезендә **Хезмәт Кызыл Байрагы** ордены белән бүләкләнде.

*

* *

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм җитмеш яшь тулу уңае белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты — СССРның халык артисты **Фуад Ибраһимович Халитов** СССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 16 февраль Указы нигезендә **Халыклар дуслыгы** ордены белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисткасы **Рауза Котдусовна Ганиева-Хәйретдиновага** РСФСР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 1 март Указы нигезендә **РСФСРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ДОСААФ БҮЛӘГЕ

Татарстан ДОСААФ өлкә комитеты хәрби-патриотик темага язган әсәрләре һәм авторның бу өлкәдә актив эшләве өчен язучы **Самат Шакирны** икенче мәртәбә СССР ДОСААФының «Почет билгесе» белән бүләкләде. Знак-медаль таныклыгына авиация маршалы, СССР ДОСААФ Үзәк Комитеты председателе, өч тапкыр Советлар Союзы Герое П. Покрышкин кул куйган.

## «ШҮРӘЛЕ» БАЛЕТЫ — ЛЕНИНГРАД СӘХНӘСЕНДӘ

Ленинградның С. М. Киров исемендәге Ленин орденлы дәүләт академия опера театры үзенең быелгы сезонында да репертуарга татар композиторы Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетын керткән. Күптән түгел балет 160 нчы тапкыр күрсәтелде. Ленинградлылар аны, һәр вакыттагыча, бик яратып, зур кызыксыну белән карадылар.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Июнь ае җиттеме, безнең хәтердә Бөек Ватан сугышы башланып киткән дәһшәтле көннәр исәлеге яңара. Халкыбызның илгә турылыгын, батырлыгын, бердәмлеген һәм гаҗәеп чыдамлылыгын тагын бер кат раслап күрсәткән бу сугыш елларына күп әсәрләр багышланды. Язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Таңы ерак төндә» исемле хикәясе дә шул теманы яктырта. Хикәя журналның 6 нчы санын ачып җибәрә. Әсәрдә бүгенге көн хуҗалары булып өлгергән ир-егетләрнең авыр сугыш елларына туры килгән бала чагы сурәтләнә.

Шагыйрьләр Ренат Харисов, Фәнис Яруллин, Мөдәррис Әгъләмов журналның бу санына яңа шигырьләрен тәкъдим иткәннәр. Алар арасында гражданлык рухы белән сугарылганнары да, лирик шигырьләр дә байтак.

Драматург Туфан Миңнуллин «Яшьлегем-юләрлегем» пьесасы белән катнаша. Пьесаны журнал укучылары яратыр дип ышанабыз.

Болардан тыш журналда Азат Вергазовның «Нәзер» повесте басылачак.

Яшь язучы Солтан Шәмсинең «Сагыну» хикәясе яңа гына гаилә корган яшьләрнең кайнар хисләрен тасвирлый.

Очерклар бүлегендә Изаил Зариповның «Хыяллар остасы» исемле язмасы урнаштырыла.

Журналның 6 нчы саны әдәбият белеменә караган материалларга аеруча бай. Күптән түгел Казанда әдәбият галимнәренең Бөтенсоюз киңәшмәсе уздырылган иде. Й. Нигъмәтуллина, З. Кедрина, Л. Залесская, Ф. Мусин мәкаләләре әнә шул киңәшмәдә ясаган чыгышлары нигезендә язылганнар.

М. Фәйзуллаеваның сәнгать бүлегенә урнаштырылган язмасы халык музыкасы белән композиторлар иҗаты арасындагы бәйләнешне анализлавы ягыннан кызыклы.

«Китап күзәтү», «Әдәбият тарихына материаллар», «Безнең календарь», «Төрлесеннән», «Елмаеп та, көлеп тә...» рубрикалары да укучыны кызыксындырырлык материалларны эченә алган.

6 нчы санның соңгы битләрендә, гадәттәгечә, республикадагы әдәбият һәм сәнгать яңалыклары хәбәр ителә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210